
ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

5. 1993



# СИҢА ЭНДӘШӘБЕЗ, МИЛЛӘТТӘШ!

(БӨТЕНТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ҮЗӘГЕНЕҢ III КОРЫЛТАЕНДА КАТНАШУЧЫЛАРНЫҢ ТАТАР ХАЛКЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ)

Хөрмәтле милләттәш, мөхтәрәм кардәш! Без, Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең өченче корылтаенда катнашучылар, Җир шарының кайсы төбәгендә яшәвеңә карамастан, сиңа — татар кешесенә эндәшәбез.

Билгеле ки, 1552 елдан һәм аннан соң чит ил баскыннары тарафыннан илебез яулап алынып, безгә — дәүләтсез халык, үз җирләребездә милли хокуклары чикләнгән, кысылган халык буларак яшәргә, үз хокукларыбыз өчен һәрчак көрәшеп гомер итәргә язган. Дүрт гасырдан артык татарларга карата алып барылган рухи геноцид, җәбер-золым эзсез узмаган. Татар халкы ассимиляциягә дучар булган, үз җиреннән Җир шарының барлык континентлары, илләре буйлап таралган. Хәзер татар зыялылары шушы таркалган халкыбызны туплау һәм аны табигый милли яшәеш юлына кую өчен олы дау алып баралар. Хөрмәтле милләттәш, бу мөрәҗәгатьне шушы милли зыялыларыбызның йөрәк тавышы итеп кабул ит, колак сал, гамәл кыл. Бел: халыкны башка милләтләр белән тигез иткән, горур иткән, аңа рух бөеклеге биргән нәрсә — милли дәүләт. Хәзер синең рухи терәгең, ышанычың булып Татарстан дәүләте күтәрелә. Ачык аңла: бу синең дәүләтең, ул синең — татар кешесенең, таянычы, ышанычы, өмете. Кайда яшәвеңә карамастан, аның мөстәкыйль дәүләт булып яңадан торгызылуы өчен көч-куәтеңне кызганма. Татарстанга, Татарстан халкына, татар милләтенә карата нахак сүз ишетсәң, дөреслекне төшендер.

Ачык аңла, кардәш, син — татар халкы вәкиле, димәк ки, олы төрки дөньяның аерылгысыз бер кисәге булган милләтнең газиз кызы яки улысың. Шушы бөек туганлыкның кадерен бел, олыла. Син яшәгән ил, син яшәгән дәүләт сәясәте безнең бу бөек туганлыкка зыян китерә икән, син бу бердәмлек мәсләгендә калырга көч тап. Тугандаш халыкларга һәм гаделлеккә омтылучы бүтән милләтләргә кул күтәрмә.

Шуны да бел, милләттәш, безнең күп гасырлар буе кыерсытылган, таркатылган милләтнең рухын ныгыту, милләтне аякка бастыруның нигезе — милли мәгърифәт. Яшәгән урыннарында милли балалар бакчалары, мәктәпләр ачуга бөтен тырышлыгыңны куй. Каршы килүләр булса, дөрес итеп, аңлат: бу — кеше хокукын бозу. Татар халкы да, башка милләтләр кебек үк, кайда гомер итүенә карамастан, үз мәктәбен, үз мәдәни үзәкләрен, үз гыйбадәтханәләрен булдырырга хокуклы. Әгәр дә бу омтылышыңа киртә куелса, халыкара нормаларга, конституциягә нигезләнеп хокукыңны якла.

Милләттәш, татар дигән кәүемнең яшәве һәм үсеше синең гаиләңә бәйле. Әгәр балаларыңны милләт вәкиле итеп үстерә аласың икән, татар халкы яши дигән сүз. Юк икән — бернинди дәүләт статусы да милләтеңне саклап кала алмаячак. Башка милләт вәкилләре белән гаилә корырга уйласаң яки гаилә коручыларга фатиха бирергә җыенсаң, шул турыда уйла: син үз милләтеңнең дәвамчыларын тәрбияләүгә булыша алырсыңмы? Юк икән, син милләтеңнең юкка чыгуына ярдәм итәсең, милләт каршында җинаять кыласың дигән сүз.

Мөхтәрәм милләттәш, син — татар дигән олы халыкның бер вәкиле. Шул милли бердәмлекнең кадерен бел, олыла, тәкъдир ит, кайда очратсаң да татар кешесен туганың, кардәшең дип сана. Яхшы киләчәгебез хакына берләшик, туганнар!

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**5**

**(847)**

**1993**

КАЗАН


## *Бу санда*


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

З. ХӘКИМ. Агымсуда ни булмас... *Сатирик роман* . . . 3
Х. ӘЮП. Бишексезләр өчен бишек жыры. *Шигырьләр* . . . 71
З. ЗӘЙНУЛЛИН. Хикәяләр . . . 76
Л. ШАГЫЙРЬҖАН. Иҗат бакчам. *Шигырьләр* . . . 91
Ш. ҖИҺАНГИРОВА. Ачы бал. *Хикәя* . . . 97
З. МӘҮЛИДОВ. Галәй. *Кыйсса* . . . 107
Г. МОРАТ. Мин әкият кебек дөрес идем. *Шигырьләр* . . . 115

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. НИЗАМИЕВ. Саумысез, татар генераллары! . . . 121
М. ӘХМӘТҖАНОВ. Үз асылыбызга кайтыйк . . . 127
М. МАЛИКОВА. Үлеп терелгән «җәмгыяте хәйрия» . . . 137

ДИСКУССИЯ ДӘВАМ ИТӘ

Ф. ХАТИПОВ. Мөлкәтебезне барлаганда . . . 144
Ф. ЯРУЛЛИН. Ачы язмыш сәхифәләре . . . 154

ТЕЛЕБЕЗ ТАРИХЫННАН

Р. СИБӘГАТОВ. Көнбатыш Башкортстанның борынгы теле . . . 157

КАЙТКАН ИСЕМНӘР

Ш. РАХМАНКОЛОВ. Онытылган шәхес . . . 166

МӨХӘММӘТ САДРИГА 80 ЯШЬ

М. САДРИ. Син сугышны оныт, диләр. *Поэмадан өзек* . . . 172

НӘҖИП ДУМАВИНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Н. ДУМАВИ. Корьән. *Шигырьләр* . . . 176

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕНДӘ — ТАТАР ШӘХЕСЛӘРЕ

Б. СОЛТАНБӘК. Ризаэтдин бин Фәхретдин галәсе . . . 181

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Марс Шабаев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәуфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Б е з н е ң  а д р е с: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 53-07-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Г. МИХАЛЕВА. Оренбурдагы Сәгыйть бистәсе . 183

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

Ә. САФИУЛЛИН. Йөрәккә — ачкыч. Шаян хикәя 186
А. КОЗИОЛ. Компьютер. *Хикәя* . . . . . . . 187

ЛАТИН ГРАФИКАСЫ НИГЕЗЕНДӘ
ТАТАРЧА УКУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

Г. ТУКАЙ. Китмибез. ***Шигырь*** . . . . . . . . 189

Безнең календарь . . . . . . . . . . . 171
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . . . 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: сатирический роман З. ХАКИМА «Встреча с водяной», рассказы З. ЗАЙНУЛЛИНА, З. МАВЛЮДОВА, Ш. ЗИГАНГИРОВОЙ; стихи Х. АЮПОВА, Л. ШАКИРЗЯНОВОЙ, Г. МУРАТОВА.
«Публицистика»: статьи Р. НИЗАМИЕВА «Здравствуйте, татарские генералы», М. АХМЕТЗЯНОВА о проблемах воспитания молодого поколения на основе народных традиций, М. МАЛИКОВОЙ о деятельности Благотворительного общества.
«Дискуссия: Наша жизнь. Наша литература»: статьи Ф. ХАТИПОВА «Взгляд на современную литературу», Ф. Яруллина «Страницы горькой судьбы».
«К истории языка»: статья Р. СИБАГАТОВА «Древний язык запада Башкортостана».
«Возвращенные имена»: статья Ш. РАХМАНКУЛОВА о драматурге А. Тазетдинове.
«Выдающиеся личности — на страницах истории»: статья Б. СУЛТАНБЕКА «Семья Р. Фахретдинова».
«К истории культуры»: статья Г. МИХАЛЕВОЙ «Слобода Сагита в Оренбурге».
«Веселые рассказы»: рассказы А. САФИУЛЛИНА и польского писателя А. КОЗИОЛ.
В номере отмечаются 80-летие М. Садри, 110-летие Н. Думави.
Навыки чтения на основе латинской графики.
На наших обложках: «Голубь» — картина Санкт-Петербургского художника М. Тажибаева, известный писатель К. Латыйп.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 2.04.93 ел. Басарга кул куелды 4.05.93 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кагазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 26 413. Заказ Я-168. Бәясе 20 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1993 ел.

## Чәчмә әсәрләр



Зөлфәт Хәким

# АГЫМСУДА НИ БУЛМАС...

САТИРИК РОМАН

## Беренче кисәк

Тау артыннан, җиз таз сыман ялтырап, кояш килеп чыкты. Шул ук тауның артыннан, колак чистартырга дип иске матрастан йолкынган мамыкны хәтерләтеп, болыт кисәге пәйда булды. Һаман да шул тауның артыннан, аның итәге буйлап сузылган юлда тузан өере куптарып, бер мотоцикл күренде. Мотоциклда тирә-яктагы кешеләрнең, хайваннарның һәм кош-кортның котын алып торучы участок инспекторы — милиция капитаны Миңлебаев утыра иде.

Җырыклы авылы кешеләре белә: тау артыннан кояш килеп чыкса — көн туа, әгәр дә инде тау артыннан капитан Миңлебаев килеп чыга икән — йә җинаять эше, йә башка төрле беркетмәле-актлы матавык туа.

Теге болыт кисәге дә, участковыйның юлы якты булсын дип, кояшны капламыйча, тиз-тиз генә читләтеп урман ягына ашыкты. Ә кояш исә, чиксез куанып, инспекторның погоннарында, фуражка кокардасында, китель төймәләрендә чагылды. Зәй буе әрәмәсеннән чыккан кигәвеннәр дә аңа бәрелмәскә тырыштылар.

Кешеләр яши торган һәр планетаның үз кояшы булган кебек, һәр авылның үз участковые бар. Җырыклы авылын да ходай милициядән мәхрүм итмәгән. Әнә ул. Килә!

Инспектор Миңлебаев күрше авылда яши. Аның карамагында — җиде авыл. Алты керәшен авылы уртасында әле һаман да чукындырылмаган татар авылы Җырыклы яшәп ята.

Керәшен авылларында тәртип. Эчүен эчәләр, ләкин сугышмыйлар. Урлыйлар, ләкин тотылалар. Көчлиләр, ләкин өйләнәләр. Көмешкәне гаҗәп шәп куалар. Кичләрен көмешкәнең куе һәм яшелле-мөшелле исе Зәй әрәмәлекләренә, Җырыклыдан көньяктарак шаулап торган урманнарга иңә.

---

Зөлфәт ХӘКИМ (1960) — *язучы, драматург, җырчы. Эстрада җырлары, рок-композицияләр иҗат итә. Татарстан китап нәшриятында «Ышанырга кирәк» исемле сатира һәм юмор китабы басылып чыкты. Казанда яши.*

Гади кеше ул исне химкомбинаттан килә дип уйлый. Ә Миңлебаевның борыны аны-моны аера — бу ис аңа таныш һәм якын. Күп иснәде ул керәшен авылларындагы көмешкәне, күп эчте.

Юк, керәшен халкы әйбәт халык. Сүз тыңлаучан халык.

Ә менә Жырыклы авылы... Бу татар авылы белән участковыйның сугышы мәңге дәвам итәр, ахрысы. Явыз Иван да чукындыра алмаган авылны бер участковый җинә аламы инде, йә?!

Бу авылда гел сугышалар. Матавыклар юктан гына килеп чыга. Керәшеннәрдән көмешкә куарга өйрәнделәр дә, хәзер инде «остазларыннан» да шәбрәк ясыйлар хәмерне. Бу авылдан ел саен берничә яшүсмер төрмәгә утыртыла. Әйтерсең лә ел саен ул мәктәптә бер-ике кеше укып белем алып кайтырга тиеш.

Жырыклының жор күңелле, пычак телле, мәзәккә бай һәм сугышчан халкы арасында капитан Миңлебаев нигез салып урнаша алмады. Керәшеннәр белән тынычрак дип, күрше авылда яши.

Участок инспекторы капитан Миңлебаевның тәрҗемәи хәлен дә, шәҗәрәсен дә, кайсы яклардан икәнлеген дә, туган елын да, хәтта исемен дә беркем белми. Һәм үзе дә сөйләми. Халык телендә ул — «Миңлебай», ә үзенә «иптәш Миңлебаев» дип дәшкән булалар. Аның хатыны һәм мотоциклы бар. Әнә шул ике әйбердән төшми инде ул. Дөрес, аның мотоциклы хатынына караганда тазарак, матуррак. Хатыны исә, гомере буе участковый белән яшәп, шыр сөяккә калган һәм иске велосипед рамын хәтерләтә. Аларның балалары юк һәм булмавы яхшырактыр да, чөнки милициянең эше куркыныч — бүген исән, иртәгә юк дигәндәй... Илдә ятимнәр болай да күп.

Әйткәнемчә, участковый Миңлебаевны участковый дип беләләр һәм дә моны махсус рәвештә исбатлауның кирәге юктыр. Мәсәлән, чыбыркының чыбыркы икәнен, этнең эт икәнлеген исбатлап торуның кирәге юк лабаса...

Нишләп бүген кояш белән бергә торган соң әле ул?.. Нәрсә булган икән Жырыклыда?..

Миңлебаевның кыяфәте шулкадәре яман, әйтерсең лә ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан участковый итеп яратылган һәм тәртип урнаштыру вазифасы белән күктән шушы мескен Җиргә төшерелгән. Аның итләч чырае мотоцикл дырылдавыннан мыймылдап селкенә, борын, бит алмалары, өч катлы ияк һәм күз төбендәге саргылт капчыклар дер-дер килә.

Нишләп аның чыраеннан нәфрәт чәчри? Ник яратмый Миңлебаев кешеләрне? Нигә аның үзен дә кешеләр дошман итә?.. Бу сорауга җавапны калын-калын китаплардан да табып булмастыр. Җавапны күп еллар үткәч кенә табачаклар. Әле хәзергә аннан куркалар, шуңа күрә хөрмәт итәләр. Ни гаҗәп: дошман да күрәләр, хөрмәт тә итәләр!

Мотоцикл нигә Жырыклыга бара — әйтер вакыт җитте. Миңлебаевның бу сәер авылга ни сәбәп һәм ни йомыш белән баруын мин сезгә хәзер үк әйтеп бирәм. Кеше дә үтермәгәннәр анда, янгын да чыгармаганнар, беркемне көчләмәгәннәр дә... Кичә кич белән клубта сугышканнар. Яшьләр... Сугышканда клубның тәрәзәләре кырылып төшкән, тышкы як ишеге кубып очкан, клуб алдындагы багана ауган һәм урамда өйгә кайтмый исәңгерәеп йөргән дүрт сарык тапталып үлгән. Ә сугышучыларның үзләренә берни булмаган.

«Чукындырам, барыгызны да утыртам! — дип уйлап бара инспектор.— Унбишәр тәүлек белән генә котылмассыз бу юлы!»

Чукыну дигәннән... Алты керәшен авылы уртасында бердәнбер чукынмый калган авыл — Жырыклы дип әйткән идем инде мин. Аның чукынмавының сәбәбе хакында халык телендә төрле риваятьләр, имеш-мимешләр йөри. Имеш, чукындыручылар килүен ишеткәч, авыл халкы урманга качкан булган. Кемдер әйтә: авыл, коралланып, чукындыруга каршы торган, ди... Кемнеңдер әйтүе буенча, имештер, ул заманда бу

тирәдә шушы Җырыклы авылы гына булган. Тирә-якта сазлык та әрәмәлек кенә... Шул сәбәпле бу төбәккә поплар, солдатлар керергә курыкканнар, батырчылык итмәгәннәр. Ә менә бу алты керәшен авылы, имеш, ул вакытта әле булмаган. Алар — чукындырылып монда китерелгән угрофин кешеләре, имеш...

Бу имеш-мимешләрнең кайсысы дөрестер, әйтүе кыен. Моны хәтта мотоциклы белән татар авылын таранларга килүче капитан Миңлебаев та белми. Ничек кенә булмасын, авыл чукынмаган. Көчле халык! Көчле холык! Шунысы кызык — ниндидер бер капитан шул авылны җиңәргә маташа!.. Майор да түгел ичмаса... Ничәмә ел инде тырыша, ләкин юк, булмый. Авылның холкы ничек булган — шулай калган. Күрәсең, шул дуамал холыклы, сугышчан булганга чукынмаган бу авыл. Менә шулай һәрвакыт каршы торырга, сугышырга аны язмыш, яшәеш үзе өйрәткән. Кызу канлы, сугышчан булмаса, ул авылның дине дә, дене дә, жырымоңы, хәтта исеме дә исән калмаган булыр иде.

Миңлебаев моны аңламый. Чөнки ул башка милләт кешесе. «Участковый» дигән милләттән ул. Участковыйлар — күпсанлы һәм интернациональ милләт. Һәр милләтнең үз сыйфатлары була. Мәсәлән, грузиннар — кәкре борынлы, тәскә-биткә кара халык, якутлар — кысык күзле, табак битле... Участковыйларның чырае итләч, усал һәм кызыл була. Аларның милли киеме — милиция формасы һәм күн папка. Алар төрле телдә сөйләшәләр һәм күп телдә сүгенәләр.

Бихисап күп булсалар да, илебездә участковыйлар житми, шуңа күрәдер инде тәртип юк. Колхоз саен берәр инспектор гына бик аз, урам саен кирәк.

Әнә бит авыл хәтле авылга мотоцикл Миңлебаевның берүзен генә алып бара. Иманым камил, Миңлебаев кичәге сугыш чукмарларын авызлыклар һәм тиешле җәзаны бирер. Ул авылга килсә, тикмәгә килми.

Аның мотоциклы авылга килеп житә инде. Ләкин мин аны авылга житкәндәрәк калдырып торам, чөнки хәзергә әле ул миңа да, укучыларым, сезгә дә кирәк түгел. Барсын ул авылга, язсын беркетмәләрен, төзесен актларын — болар барысы да аның эше.

Мин бит җанны өшетерлек бер вакыйганы сөйләмәк булам. Ә капитан Миңлебаев турында бераз мәгълүмат бирү кирәк иде, чөнки бу мажараларда ул да катнаша. Ничек кенә катнаша әле! Тузанга баткан мотоцикл өстеннән очып баруыбыз фәкать Миңлебаев белән танышыр өчен генә булды.

* * *

Миңлебаевның мотоциклы жәйге иртәнге ертып Югары оч урамына килеп кергәндә, Түбән оч урамы буйлап ике ир кеше авылдан чыгып баралар иде. Аның берсе озын гәүдәле, кара чәчле, ябык, озынча битле һәм кылыч борынлы иде. Бу — Гаделша. Икенчесе тәбәнәк буйлы, пеләш башлы, кысык күзле һәм җәенке борынлы иде. Монысы Мәрданша булыр.

Мәрданша белән Гаделша балык тотуга бик хирыслекләре белән тирә-якта танылган кешеләр. Авылдан ике чакрым чамасы еракльпкта бормаланып аккан Зәй елгасы булмаса, аларның бу мескен дөньяда гомер кичереп ятулары бөтенләй мәгънәсез булыр иде. Көннәр буе кармак салып утырырга мөмкинлек булсын өчен алар икесе дә каравылчы булып эшлиләр. Мәрданша ферма каравылчысы, Гаделша мәктәпне саклый. Каравылчылар дип... Соңгы тапкыр каравылда кайчан булганнарын алар хәтерләмиләр дә инде. Карак кеше урлыйсы әйберне барыбер урлый инде аны, чөнки заманы шундый — урлашмыйча яшәп булмый.

Инде кырыкны тутырсалар да, Мәрданша белән Гаделшаны сабыйлык бөтенләй ташларга уйламый. Әнә бит, уттай кызу эш өстендә,

көн-төн хезмәт таләп итүче җәй уртасында дуслар, җил-җил атлап, авылны чыктылар һәм инде әрәмәлеккә дә якынлаштылар. Әнә инде Зәй дә күренә. Аларга соңгы вакытта хәтта бармак буе шыртлака да эләкми башлады. Зәй елгасында биш-алты балык кына калганын алар белми иде шул.

Бу юлы да, көн буена бернәрсә дә тота алмагач, ике дус, елгаларны пычратучы заводларны, ГЭСларны каргый-каргый, кайтырга җыена башладылар.

— Ул заводларны, ГЭСларны имынны елга буена салырга кирәк микәнни инде?— диде Мәрданша ачынып.

— Әй, белгән юк инде... бетерделәр елганы,— дип өстәп куйды Гаделша.

Әйберләрне җыеп капчыкларга тутыргач, кайтып китәр алдыннан тәмәке көйрәтеп алырга булдылар.

— Әти мәрхүм әйтә торган ие...— дип тагын сүз башлады Мәрданша,— Зәйдә элегрәк балык мыжлап тора иде дип... Бер утыруда берәр чиләк тота идек ди торган ие...

Гаделша авызыннан бер бүрек ачы төтен чыгарды да:

— Әй, алай ук булмагандыр инде,— диде.

Мәрданша аның сүзләренә игътибар итми дәвам итте:

— Әти мәрхүм әйтә торган ие... Зәйдә эре-эре балыклар гына түгел, зәһәр еланнар, хәтта Су анасы да бар ди торгание.

— Әй, әллә ниләр сөйләп утырмасана,— диде Гаделша урыныннан кузгалып.— Әйдә кайтабыз.

Яр өстенә менгәч, дуслар күңелсезләнеп калган Зәй буйларына күз ташлап, тагын кат-кат офтанып, зарланып куйдылар. Елгага күз салгач, Гаделша кинәт кулындагы кармак таягын төшереп җибәрде.

— Мәрданша, кара әле! — диде ул, куак артына чүгәләп.

Егерме адымнар чамасы читтәрәк, ярдагы тал төбендә, баеп килүче кояшның соңгы нурларында назланып, бер шәрә хатын утыра иде. Ул, балыкчыларны әллә күрмичә, әллә күреп игътибар итмичә, суга карап, алтын тарак белән тузган чәчләрен тарый башлады. Аның табигатьтә сирәк очрый торган искиткеч матур тавышы нииндидер җыр җырлый иде. Ишетелер-ишетелмәс ул җыр су аккан көйгә әллә тирбәлә, әллә ага иде.

Ахирәтләр өнсез калдылар.

— Шәп бу! — дип пышылдады Мәрданша, куак төбендәге «күзәтү пункты»на урнашкач.— Әйдә, якынрак барыйк әле.— Һәм дустының күлмәк җиңеннән тартты.

Гаделшаның шул Су анасы шикелле бер хатыны бар иде инде. Ул дулкынланудан сулкылдаган башын чайкады:

— Юк, Мәрди, ычкыныйк яхшы чакта... Су анасы бит бу!..

* * *

Кырык яшенә кадәр ялгыз яшәгән Мәрданша Су анасына гашыйк булды. Әрәмәлек арасыннан барганда чыбыкларның битне камчылавы да, чебен-черки талавы да сизелмәде аңа. Әрәмәне чыккач авылга йөгергәндә дә ул, берни аңламый, инстинкт буенча гына Гаделша артыннан чапты.

Зәй буеннан кайткач, гадәттә, ике дус Мәрданшаның ярлы гына җиһазланган өенә кайтып көмешкә эчәләр. Бу юлы да гадәткә хыянәт итмәделәр. Тик хәмерне стаканнарга салып куйгач, эчәргә ашыкмыйча, Зәй буендагы күренештән айный алмый утырдылар.

— Менә бу могҗиза ичмаса! — диде Гаделша, бер стакан «утлы суны» каплап, шатыр-шотыр суган чәйни башлагач.

Мәрданша бик озак дәшмәде. Ниһаять, ул эчеп куйды да, чыраен сытып:

— А-а-ах, бигрәк каты булган монысы,— диде.

— Тегесе дә шундый иде,— диде Гаделша, ипи кисәген тозга манып.— Син хәмерне ясый беләсен инде анысы.

Мәрданша белән Гаделшаның иң яраткан шөгыльләренең берсе (балыкчылыктан соң) тамак чылату иде.

Эчкечелекнең беркайчан да абруе булмады, аракы эчүне бездә беркайчан да хупламадылар. Ләкин бу ике дусның эчүе бөтенләй икенче төрле иде. Баш миен көмешкә белән томалау алар өчен күңелләрне бер халәттән икенчесенә күчереп тору гына иде. Бу вакытлыча үзгәрешнең беркемгә зыяны тигәне юк. Алар өчен тормышның төксе бертөрлелегеннән котылып торуның бер чарасы гына иде бу.

Вакыйганың башы 1980 елга туры килүен дә әйтсәм, Мәрданша белән Гаделшаның аракы белән дус булуы табигый хәл булып күренер. Бу вакытта аракы һәм суган исе ил өстендә куе болытлар булып эленеп тора иде.

Шуңа күрә, Мәрданша белән Гаделша минем язмамда көмешкә-самогонны бик еш куллансалар гаҗәпләнмәгез — ул вакытларда өстәл артында бераз «утлы су» кабып кую — сулыш алу кебек зарур нәрсә иде. Чөнки шул чукынчык аракы Миңлебаевлар кыскан сулышларны ачып, кан тамырларын киңәйтеп җибәрә, беразга гына булса да бәгырьләр сызлавы басылып тора иде.

Тагын яртышар стакан йотып куйгач, Гаделша бик озак тел шартлатып, аһ-ваһ итеп утырды. Мәрданша гына дәшмәде. Дусты җәен балыгыныкы кадәр зур авызын ипи һәм яшел суган белән дыңгычлап тутыргач, ниһаять, телгә килде:

— Карале, Гаделша, ул хатын чыннан да Су анасы идеме соң?..

Җавапны озак көтәргә туры килде. Авыздагы мул ризыкны тиз генә җебетерлек сәләгәе юк иде Гаделшаның. Кружкадан су йотарга туры килде. Авызында сүзләр чыгарлык ара хасил булгач, ул җавап бирде:

— Су анасы булмый... Габдулла Тукайның «Су анасы» дигән шигырен укыганың юкмыни?

— Нишләп булмасын...

— Соң, шулай булгач...

Мәрданша татлы итеп елмайды. Пеләш булганга күрә, аның елмаюдан ачылып киткән йөзе башы белән кушылып, гаҗәеп аһәңлек тәшкил итә иде. Бераз исерә төшкән булса да, Гаделша дустында ниндидер сәер үзгәрешне шәйләп алды һәм аңа шикләнеп, гаҗәпләнеп карап торды. Чөнки дустының чырае искиткеч яктылык сирпи иде. Аның сирәк тешле авызыннан көлдә мәмрәп пешкән бәрәңгедән күтәрелгән пар шикелле булып биш сүз эреп чыкты:

— Бигрәк чибәр иде... Зерә качтык...

Гаделша иптәшенә аптырап карады:

— Нишләргә иде соң тагы?..

Мәрданша тагын да татлырак итеп елмайды:

— Янына барырга иде, танышырга иде...

— Һе, акылдан яздың мәллә?!. Шәп-шәрә килеш ул синең белән танышып торыр идеме?!

Дустының сәер сүзләренә игътибар итмәгән дә булыр иде ул... Тик менә әллә нишләде бит бу Мәрди... Бөтенләй кыяфәте үзгәрде, күзгә күренеп икенче кешегә әверелде.

Әйе, Мәрданшаның эчке дөньясы актарылды. Яшүсмер вакытта гына тоелган хисләр кыймылдап куйды. Канның йөреше үзгәрде. Дәрт һәм дәрман тойды Мәрданша. Самогон шаукымы гына түгел бу! Ул Иблис суыннан исерү башкача була.

Мәрданша сикереп торды да, әрле-бирле йөренә башлады. Аннары яңадан килеп өстәл артына утырды.

— Гаделша! Зәй буендагы җәйләүдә сыер савучы хатыннар эшли бит...— диде ул, өзгәләнеп.— Шуларның берәрсе булмады микән?..

Тегесе рәхәтләнеп киерелеп көлеп җибәрде.

— Юк ла. Син, Мәрди, әллә ычкындың инде... Андый зифа буйлы сыер савучыны кайчан һәм кайда күргәнең бар? Валлаһи, Су анасы иде.

Мәрданша бер ноктага текәлеп катып калды. Пеләш башы буйлап чабып йөргән чебенгә дә исе китмәде аның.

Гаделша урыныннан кузгалды.

— Ярый, Мәрди, кайтыйм инде мин өйгә. Минем өйдә үземнең Су анасы бар бит. Тагын эчеп кайтканың дип тавыш чыгарыр инде.

Мәрданша сискәнеп китеп. Бик озак аны-моны аңышмыйча утыргач.

— Ни дисең син, Гаделша? — дип сорап куйды.

— Өйгә кайтам, — диде Гаделша күңелсез генә кыяфәттә.

Мәрданша аны, җиңеннән тартып, урынына утыртты.

— Туктале, кордаш, ашыкма син... Менә синең хатының бар... Чүкердәшеп, балалар тәрбияләп, мәгънәле тормыш белән яшисез. Ә менә мин мескен кеше... чөнки мин ялгыз-ятим... Миңа бит инде кырык яшь...

— Ник соң өйләнмисең?

— Зерә теге Су анасы белән танышмадык, — диде Мәрданша һәм кырык ел буе җыелып килгән ачу белән өстәлгә китереп сукты. Өстәлдәге шешә ауды. Гаделша урындыгында сикереп куйды. Мәрданшаның башы буйлап сәяхәт кылучы чебен бөтенләй юкка чыкты.

— Бәрәч, кордаш, әллә гашыйк булдың инде син? — дип сорарга батырчылык итте Гаделша, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп. Юаш холыклы дустының ярсыганын бик сирәк күрә иде ул.

— Белмим, Гаделша, аны күргәч әллә нишләдем мин, — диде Мәрданша бераз тынычланып. — Моңа кадәр шәрә хатын күргән кеше түгел бит мин, йөрәгем атылып чыгамы дип торам. Зәйгә балык тотарга күпме йөрдек бит... Нишләп моңарчы бер тапкыр да очраганы булмады икән аның?..

— Йә, йә шәрә хатын күрдем дип... ул кадәре шашынмыйлар инде, — диде Гаделша кырыс кына.

Мәрданша кабалана-кабалана стаканнарга көмешкә салды.

— Тот әле, туган. Мин хәзер, ахрысы, Зәйгә китәрмен.

Гаделша чүт кенә тончыкмады:

— Нәрсә?.. Тиле тәре!.. Төнләме?!. Дура-р-ак... Гашыйк... булгансың син... валлаһи... йөри күрмә! Карале моны... Шәрә хатын күрдем дигәч тә...

Мәрданша стаканындагы көмешкәне кабып йотты да караватына барып ауды. Карават шыгырдап-ыңгырашып куйды.

— Шәрәлектә мени эш, — диде ул киерелеп. — Бигрәк сылу иде бит.

Гаделша исерә башлады.

— Мәрданша! — дип дәште ул дустына.

— Нәрсә? — дип ыңгырашты караватны.

— Йоклыйсыңмы әллә?

— Юк. Нинди йоклау ди инде хәзер... — Мәрданша торып утырды.

— Җүләрләнмә инде, — диде Гаделша, караватка барып утыргач.

— Бөтен тынычлыгымны алды бу Су анасы, кордаш. Әллә нишләдем аны күргәч.

Гаделшаның күңелендә шик-шөбһә калмады — ахири дусты башаягы белән гашыйк булган. Шактый гына исерә төшсә дә, иптәшен тынычландырырга, юатырга һәм ниһаять нинди дә булса киңәш бирергә үзен бурычлы дип санады.

Алар бик озак тып-тын гына утырдылар. Теге яшел чебен генә, без-з, без-з килеп, тегендә-монда очкалады.

Кинәт Гаделша:

— Мин сиңа бер киңәш бирә алам, — дип аваз салды.

— Йә-йә, нинди киңәш?

Гаделша сүзне дәвам итәргәме, юкмы дип бераз уйланып утырды да:

— Су анасын өеңә алып кайтасың киләме? — дип шартлатып сорап куйды.

— Ник алай дисең?— диде кырык яшьлек мәхәббәт колы, куркуга калып.
— Син әйт, киләме, юкмы?
— Килә!
Гаделша авызын кыйшайтып елмайды да, мыскыллы тавыш белән:
— Һе, киләдер шул,— дип куйды.
— Әйт инде тизрәк, берәр чара уйлап таптың мәллә?— диде Мәрданша, аны җилтерәтеп.
Гаделша серле итеп елмайды.
— Тыңла алайса. Габдулла Тукай шигырен хәтерлим диең бит...
— Кайсы шигырен?
— Кайсы шигырен, кайсы шигырен...— дип ачуланып кабатлады Гаделша.— «Шүрәле»не түгел бит инде, «Су анасы» дигән шигырьне.
— Әйе, мин аны хәтта яттан да беләм.
Гаделша кабалана-кабалана дәвам итте:
— Белсәң бик әйбәт! Алайса исеңдәдер, анда бер малай Су анасының алтын тарагын урлап кача.
— Әйе, әйе, хәтерлим.
— Су анасы ул малайны куа чыга...
— Әйе, әйе...
— Көндез Су анасы авылга керергә курка. Һәм ул төнлә килә дә, теге карак малай яши торган йортның тәрәзәсен шакый.
Дуслар, берсе сөйли-сөйли, икенчесе аны тыңлап, үзләре дә сизмәстән караваттан янәдан өстәл янына күчеп утырдылар.
— Шуннан?— диде Мәрданша, түземсезләнеп.
Гаделша аптырап китте:
— Син нәрсә, берни дә аңламадыңмени әле?!
— Юк.
— Сал алайса тагын!
Бу юлысы көмешкә стаканнарга тутырып салынды.
— Син киңәшеңне әйт,— диде Мәрданша, стаканнар бушагач.
— Ачуланма, Мәрди, син үзең пеләш, үзеңнең кармак очы кадәр дә акылың юк. Югыйсә пеләш кеше акыллы булырга тиеш бит инде ул. Син, кордаш, нәкъ Тукай шигырендәге кебек эшлә.
— Ничек?
— Берәр көнне... Инде чыдамың калмаган икән, иртәгә үк, Зәй буена, шул без кармак салып утыра торган урынга барып, куак арасына кереп кач. Су анасының судан чыгып чәчен тарый башлаганын көтеп утыр.
— Әйе.
— Пажалысты, әйе дип пичәт сугып утырма, яме... ату фикер чуала — самогонның бигрәк каты.
— Ярар, ярар, гафу ит!
— Су анасы, ярга чыгып, кояшта кызынып, чәчләрен тарап утырганда, аның алтын тарагын ярга куйган моментны чамалап утыр. Кәк түлке тарагын янына куя, син нәкъ Тукай шигырендәге кебек, качып утырган урыныңнанерткыч сыман атылып чыгасың да, алтын таракны эләктерәсең... Һәм әрәмә буйлап авылга чабасың. Аңладыңмы?
— Аңладым, Гаделша, тик менә урлашу әйбәт булыр микән?..
Гаделшаның бу сүзләргә ачуы кабарды:
— И-и-и, син, кордаш, нишләптер кинәт кенә чистныйланып киттең әле. Эскерттән салам урлыйсың бит... Басудан чөгендер чәлдергәндә дә урлашу начар нәрсә дип тормыйсың...
Мәрданша аклана башлады:
— Һе, ул бит совхозныкы. Ә алтын таракның иясе, хуҗасы бар... Кеше әйберсен урлый алмыйм мин.
— Әле белгән юк — Су анасы кешеме, әллә балыкмы... Аннары, Мәрди туган, запомни, рас инде син гашыйк булгансың икән, җинаять-

мазар дип тормаска кирәк... Мәхәббәт ул — страшный нәрсә. Алдаусыз, җинаятьсез чын мәхәббәт булмый. Үзеңә кара... Бу синең бердәнбер чараң... Ихтыярың — бәрәңге!

Бу сүзләрдән соң ул, дүрт сәгатьлек лекция укып чыккан профессор кыяфәте белән, урыныннан кузгалды.

— Туктале, китмә! — дип кычкырды Мәрданша.— Әллә янына барып, йөрәгемне ачып салыйммы?

Гаделша тагын утырырга мәҗбүр булды.

— Юк, Мәрди,— диде ул ягымлы тавыш белән,— шәрәтән утырган чакта янына синең сыман шыксыз ир кеше килеп чыкса, коты алыныр аның. Син алай итеп эшне бозып ташлаячаксың.

— Ярар алайса,— диде Мәрданша түземсезләнеп,— таракны элэктердем ди...

— Әйттем бит инде: таракны алып, авылга таба йөгерәсең.

— Шуннан?

— Шуннанмы... Әгәр дә чын-чынлап Су анасы икән, ул синең артыңнан йөгерергә тиеш. Тукай шигырендәге кебек. Ничек дип чаба әле ул?.. «Бир расческаны, хайван!» — дипме?

Мәрданша кеткелдәп көлеп куйды.

— «Качма! Качма! Тукта! Тукта, и карак!

Ник аласың син аны, ул бит минем алтын тарак!» — дип кычкыра ул.

— Вәт. Авылга җиткәч, йодрык күрсәтеп янар да, ул кире Зәйгә кайтып китәр.

— Беттеме шуның белән? — диде Мәрданша, гаҗәпләнеп. Бу мизгелдә ул яраткан уенчыгыннан мәхрүм калган сабый баланы хәтерләтә иде.

— Бетмәде, сабыр ит. Аннан соң төн җиткәнне көт. Тукай шигырендәге кебек, төн җиткәч, ул синең йортың янына килер... Тәрәзәңне шакыр. Син әзерләнеп тор! Матуррак киен, ислемай сөрт, бераз өеңне җыештыр. Теге бәрәңге саткан акчага алган проигрывателең исәнме әле? Аны хәзерләп куй, патаму што хатын-кыз музыка ярата... Тәрәзә шакып, ул синнән алтын тарагын сорар.

Мәрданша, мескен, йөрәген тотты:

— Уф, килер микәнни?!

— Килә, килә, нишләп килмәсен ди... Син аңа шул чакны әйтәсең: «Кадерлем! Миңа синең тарагың кирәк түгел... миңа син үзең кирәк!» — дисең. Гашыйк булуыңны аңлатып бирәсең... Чәй эчәргә өйгә узарга тәкъдим итәсең. Ну, кыскасы, үзең җайлап-юмалап эш итәсең инде... Барысы да үзеңнән тора — өең янына килеп җиткән хатынны ничек тә чакырып кертә алырсың инде.

— Куркам! — диде гашыйк мәҗнүн.

— Син түгел, мин үзем дә курка башладым әле,— диде Гаделша дустының бәргәләнгән күңеленә шом өстәп.— Аның анда Зәй төбендә ире юк микән?.. Килеп, йортыңа ут төртмәгәе...

— Тукай шигырендә аның ире юк бит,— диде Мәрданша, үзен дә, иптәшен дә тынычландырырга тырышып.

Гаделша бу фикерне хуплады:

— Әйе шул, мужигы булса, теге малай артыннан да үзе чабып йөрмәгән булыр иде, мужигын җибәрер иде...

Мәрданша сикереп торды.

— Тәвәккәллим мин, туган! Рәхмәт сиңа! Ул дустының кулын шытырдатып кысты.

— Түлке нәкъ Тукайдагыча эшлә,— диде Гаделша, гашыйк булудан тәмам үзгәреп киткән һәм бераз исәрләнгән дустын кызганып.— Иң мөһиме — аны төнлә авылга китерү!

— Аңладым, рәхмәт!

— Кайчан барасың?

— Иртәгә үк!

— Әллә йөрмисеңме, Мәрди?
— Юк! Барам, барам!
— Ярар алайса, юлың уң булсын! — диде Гаделша, ишек төбенә килеп җиткәч. — Сау бул!
— Хуш иттек.
Үзе генә калгач, Мәрданша иң элек кулларын угалап алды. Аннары җырлап карады, ләкин җыр чыкмады.
Ярсыганда, нык дәртләнгән вакытта җырлап булмый. Мәрданшаның уенча, гашыйк кешенең ярсуы җаннан һәм тәннән иң элек башка төрле ысул белән, башка юллар белән чыгарга тиеш. Шуннан соң гына аның күңеленнән чып-чын җыр чыга ала.
Шуңа күрә, бу минутларда Мәрданшадан әле җыр көтү дөрес түгел. Аңарда бу вакытта коточкыч үзгәреш бара: күңелендә, йөрәгендә, баш миендә, җенси әгъзаларында. Җырлыйсылары алдадыр әле аның!
Ул стаканга тутырып көмешкә салды, аны голт-голт итеп эчеп бетерде һәм, чишенеп тә тормыйча, спектакль алдыннан оркестр чыгарган тавышлар белән шыгырдый торган караватка йөзтүбән капланды.

* * *

Җырыклы авылы өстендә янә галибанә яктырып таң атты.
Авыл мәш килә башлады. Кемдер эшкә китте, кемдер үзенә печән хәзерләү белән мәшгуль булды. Бала-чага кызык һәм уен эзләп, җәй кочагында ары чапты, бире чапты. Тегe сугыш чукмарларын район үзәгеннән килгән милиция машинасына Миңлебаев үзе санап төятте. Гаделша махмырдан иза чикте. Кыскасы, тормыш дәвам итте.
Мәрданша гына бу тормыштан, бу дөньядан ваз кичкән иде. Төнне ул уяулы-саташулы йокымсырау белән үткәрде. Иртәнге якта ул, нишләптер, баш төзәтү турында уйлап та карамады. Мәхәббәт хисләре шулкадәре көчле иде ки, хәтта бөтен юарга да онытып, Зәйгә ашыкты.
Чыгып килүче кояш, үзенең игезәген күргән сыман, гаҗәпләнеп, аның пеләш башын ялап-ялап алды. Бу юлы Мәрданша хәтта башына да киярга онытқан иде.
Зәйгә! Зәйгә!
Бәхете шунда аның!
Аның да бәхетле булырга хакы бар лабаса... Гаделшадан кай төше ким аның?
...Су буенда бер җан иясе дә күренмәде. Мәрданша кармагын болганчык суга селтәп салды да, күз кырые белән генә тегe тал төбен күзәтә башлады.
Бик озак утырды ул. Күзләре арып бетте, аяклары һәм арт саны оеды, башы әйләнә башлады, күңеле болганды. Инде кояш үз мөнбәренең иң югары ноктасына менеп кунаклады һәм аның нурлары Мәрданшаның пеләшеннән таеп китми, баш миенә кадалып керәләр иде. Аның башында кайнаган уйлар, нурлар тәэсирендә тагын да ныграк кызып дуамалландылар. Ул, хөкем ителгән кеше сыман, утырды да утырды. Көн кичкә авышты, ләкин мәхәббәт романы һаман да әле башланмый бимазалады.
Чү! Йә ходам!!! Бервакыт әлеге дә баягы Су анасы килеп чыкмасынмы!..
Әнә ул тал төбенә урнашты да, ниндидер матур көй көйли башлады. Мәрданшаның сулышы кысылды, йөрәге кайдадыр чигә тирәсендә кушаяклап тибә башлады. Нинди гүзәллек! Нинди аяклар, нинди күкрәкләр! Буй-сыны — ярда үскән зифа таллар көнләшерлек... Әйтерсең лә якты җәй көнендә тагын бер кояш килеп чыкты. Мондый хатын белән мазутлы су төпләрендә дә яшәргә риза буласың!
Мәрданша, куаклар арасына посып, алтын таракны урларга җайлы вакытны көтә башлады.

Озак күтәргә туры килмәде. Су анасы тарагын җиргә куйды да, онытып булса кирәк, суга чумды. Мәрданша куак арасыннан мәче сыман атылып чыкты һәм алтын таракны эләктереп, һавадагы кигәвеннәрне дә узып китеп, әрәмә буйлап авылга таба очты.

Әйе! Нәкъ Тукайдагыча бара эшләр! Борылып караган иде — артыннан Су анасы чаба! Мәрданша аның тавышын да ишетте:

«Качма! Качма! Тукта! Тукта, и карак!
Ник аласың син аны, ул бит минем алтын тарак!»

Һәр авылда этләр була. Үзен хөрмәт иткән һәрбер эт өрә белергә тиеш. Эт хуҗасына охшый, диләр... Җырыклы авылының халкы сугышчан, дуамал холыклы дигән идем инде. Димәк, аның этләре дә шундый. Авылга якынлашып килүче шәрә хатынны күргәч, улау, чинау, өрү, ырлау — бөтенесе бергә кушылып, коточкыч күкрәү булып, этләр тарафыннан чакырылмаган кунакка юнәлтелде.

Су анасы туктады һәм, сулышы бераз тигезләнгәч:

— Мин моны болай калдырмыйм, үзеңә үпкәлә! — дип кычкырды.

...Мәрданша өенә кайтып караватка ауды да, ярты сәгать чамасы хәл җыеп ятты.

«Эшнең яртысы уңышлы тәмамланды...— дип уйлады ул.— Су анасы, килеп, тәрәзәне кагарга тиеш... Мин аңа: «Миңа синең алтының кирәк түгел, үзең кирәк... Яратам мин сине! — дип әйтермен...»

Очрашуга ул бик озак һәм җентекләп әзерләнде. Сандык төбеннән әле бер тапкыр гына сабантуйда киелгән күлмәген һәм өр-яңа сатин чалбарын алып киеп, иң олы бәйрәмнәрдә генә сибенә торган арзанлы ислемай белән «коенды». Нафталин белән ислемай исе аның күзләрен әчеттерде. Ул кабаланды. Аның мыжылдавыннан, әрле-бирле чабуыннан йорт дер селкенеп торды. Түбә почмагында, оя корып яшәп ятучы күгәрченнәр дә бүген тынгысызланып, китә-кайта очкаладылар.

«...Тәк, тагын нишләргә соң инде?..» — дигән сорау Мәрданшаның пеләш башындагы иң мөһим уйларның берсе иде.

Хатын-кыз музыка ярата диде бит Гаделша... Ул караватт астыннан кәгазь тартма сөйрәп чыгарды, аның эченнән моннан җиде ел элек бәрәңге саткан акчага юнәлтелгән уйнаткычны алып, тумбочка өстенә куйды. Заманчарак күренер өчен, урыс ансамбле тәлинкәсен дә чоланнан алып керде. Бу пластинканы ул ун ел чамасы элек балыкка барыр алдыннан суалчан җыйганда чүплектә тапкан иде.

Шулай итеп, кояш баеганда «пеләш Мәрди»нең мәхәббәт кояшы әле чыгарга гына тора иде.

Габдулла Тукай шигырендәге кебек, тәрәзәне шакырга тиеш...

Мәҗнүнебез уйнаткычны кабызды һәм өй эчен җыр яулап алды. Сүзләре аңлашылмаса да, музыкага охшаган тавыш бар нәрсәне дер селкетте. Ул яңгыраган көйгә биеп алды. Тагын, аннан-моннан гына, өйне җыештырган булды. Аннан соң бик озак үзен көзгедән карап торды.

«Ничә яшь икән ул Су анасына?.. Их, чәчем генә бик иртә коелып бетте шул...»

Бу уйлар аның кәефен кырыбрак җибәрде. Ул, йөгереп барып тәрәзәдән карады, аннан соң сәгатькә... «Иртәрәктер шул әле».

Ул шкафтан бер шешә көмешкә алды — кыюлык өчен бераз капмый булмас... Тик, бераз уйланып торганнан соң, шешәне кире шкафка куйды. Юк! Көмешкә исен яратмас! Бәлки үбешергә туры килер... Эскерттән салам урлаганда да бу хәтле каты типми аның йөрәге. «Ну, Гаделша, кайлардан килде бу уй синең башкаеңа...» — дип, ул үзенең дустына эчтән генә рәхмәтләр яудырды.

Тагын тәрәзә янына барып килде, тагын әрле-бирле йөрде һәм, әлбәттә инде, тагын, гөнаһлары өчен җавап бирергә тиешле кеше сыман, көзге каршына килеп басты. Әйтерсең лә ул көзгедән карап торучы кешедән гафу үтенмәкче була иде.

Тагын карангы һәм авыр уйлар бимазалады. «Ошатыр микән соң ул мине?.. Алай бик ямьсез түгел инде түгелен... пеләш булсам да...» Ләкин Мәрданша пеләш булмаган сурәттә дә төскә-биткә шыксыз кеше булыр иде. Чәче бар вакытта да ул чибәр түгел иде. Шулай да кеше үзенең тышкы кыяфәтендә барыбер ниндидер матурлык эзләргә тырыша... һәм таба да... «Әнә Шадра Хисамның бите ат ипие төсле кытыршы, ә хатыны нинди чибәр... Әнә Югары оч Фәхриенең дә... борыны моторлы көймәнең руле хәтле... ә хатыны җиләк кебек. Минем Су анама бөтен авыл ирләре кызыгыр инде... Көнләшермен инде, шайтан... Көнче кеше бит мин...»

Берничә тапкыр тәрәзәдән карагач һәм кат-кат үзен көзгедән күзләгәч, миһербансыз бер уй аның җанын өшетеп үтте. «... Әллә килмәскә булды микән?» Бу уйдан ул кинәт хәлсезләнеп китте һәм караватка ауды.

Ләкин озак ятмады. Җанга һәм тәнгә мең шифа, йөрәккә яна дәрт-дәрман өстәп, якты һәм җылы уй аны караваттан күтәреп торгызды. «Килер!» — дигән изге уй иде ул.

Мәрданша, чиста киемнән икәнлеген дә онытып, чиләк белән су һәм чүпрәк алып керде, идән юарга керешге.

Шул вакытны авыл этләре ярсып өрә башладылар, каты итеп җил исте, ниндидер ят авазлар җәйге төнне ярып җибәрде. Ләкин Мәрданшаның күңелендәге буран дөнья давылын күмәрлек көчкә ия иде. Шуңа күрә ул, тыштагы шомлыкка игътибар итмәде һәм, лаш-лош борынын тартып, авыр итеп мышный-мышный, идән юуын дәвам итте.

Төн уртасында — авыл йокымсырап, совхоз басуыннан чөгендер, кишер урлаучылар һәм көмешкә куучылар гына йокламаган сәгатьтә тәрәзәне шакыдылар.

Актарылды дөнья! Миллиардлаган еллар буе Кояш тирәли әйләнеп йөргән Галәм дисбесенең бер төймәсе төпсез бушлыкка төшеп китте сыман.

«Килде! Бетте баш! Үләм!»

Тәрәзәне катырак шакыдылар.

Мәрданша ары сугылды, бире бәрелде. «Килде! Бик ачулы кага... Су анасы бу... Нәрсә диярга соң?.. Кер, чибәрем, өйгә, димме?... Әллә янына үзем йөгереп чыгыйммы?..»

Бераздан ишекне дөбердәтә башладылар. Бу минутта Мәрданша үзенә буйсынмый иде инде. Ул, идән чүпрәген тоткан килеш, исерек кеше сыман абына-сөртенә ишек янына барды һәм «Аллага тапшырдык! — дип, ишекне ачып җибәрде.

Шунда аның баш артында әле бераз калган чәч бөртекләре үрә торды — чөнки бусагада Тукай шигырендәге персонаж түгел, сыер савучы Халисә пәйда булды.

Мәрданша тораташ булып катып калды.

— Халисә?! — диде аның күгәргән иреннәре.

* * *

Халисә турында аерым кыйсса язып булыр иде. Чөнки ул — хатын-кыз. Җитмәсә, дояркa... Алдынгы сыер савучылар, тракторчы хатын-кызлар турында бик күп китаплар язылды инде, шуңа күрә мин коммунизм төзүче савымчы Халисә турында аерым китап язып тормыйм, ә бәлки ошбу язмамда аны бераз гына телгә алам һәм аңа шактый кызыклы мажарада катнашырга мөмкинлек бирәм.

Халисә дә кырыкка җитеп килә инде. Бик эшчән, оста куллы һәм гарип җире юк бугай. Чибәрме ул, юкмы — анысын әйтеп булмый, чөнки сыер савучының киеме һәм кыяфәте яшьне билгеләргә дә, төс-битне чамаларга да комачаулый.

Халисә фермада сыерлар карый, өйдә сырхау әнисен тәрбияли. Яшь вакытта егетләр аның тирәсендә дә чуалдылар, ләкин Халисә нишләптер кияүгә чыкмый калды. Ник алай килеп чыкканлыгын ул үзе дә белми.

Аның каравы ул хәзер инде танылган сыер савучы, аның турында район гәҗитендә дә яздылар, рәсеме дә бар иде. Шулай итеп, бөтен район Халисәнең сурәте төшкән гәҗит белән әйбер төрде, башка хаҗәтләргә дә кулланды. Танылган кеше ул хәзер. Күптән түгел әле значок та бирделәр. Тик бәхет кенә нишләптер юк. Ферма белән өйдә, җәй көне җәйләүдә гомере үтеп бара аның.

Халисә Мәрданшаны ярата. Яшь вакытта Мәрданша Халисәне бер тапкыр клубтан өенә кадәр озата барган иде. Бер сүз сөйләшмәделәр алар — икесе дә бик курыкканнар иде. Бер-берсеннән курку шулкадәре көчле иде, шуннан соң алар бөтенләй очрашмаска тырыштылар.

Егерме ел үтте инде Мәрданша озата килгән кичтән соң. Ләкин Халисәдә: «Мин Мәрданшага ошыймдыр...» — дигән фикер шулхәтле тирән уелып калган, хәтта әле бүген дә аның ялгызлыктан боегып беткән күңеленең бер почмагында өмет күмере пыскып ята.

Яшь чактагы курку юк инде хәзер... Тормыш кыюлыкка да, тупаслыкка да өйрәтеп бетерде. Халисә буйдак Мәрданша тирәсендә егерме ел инде чуалырга тырыша, ләкин теге «пеләш тәре» Халисә турында уйлап та карамый.

2000 нче елга да 20 ел гына калды бит инде. 2000 нче елны дөнья бетәчәк, диләр бит... Шулай мәгънәсез булып тәмамланыр микәнни Халисәнең тормышы?

Нинди рәхәт күрде соң ул үз гомерендә?.. Искитәрлек матур күлмәк кигәне булдымы?.. Ир назы татедеме аңа?

Хезмәт! Хезмәт! Хезмәт! Дан! Дан! Дан! Шул данлы хезмәт өчен генә килде микәнни бу дөньяга сыер савучы Халисә?!.

Мәрданшага да җиңел түгел инде анысы — ятим үсте, хәзер дә япа-ялгыз. Ичмаса ул аракы эчеп юана... Халисәгә бит эчәргә ярамый...— авыл хатыны, мөселман хатыны имеш... Бигрәк кызык — бөтен ил дөм исерек... ат кебек эшләүчеләр генә, Халисә кебекләр генә аек булырга тиеш.

Ике ялгыз кеше бергә кушылсалар, өр-яңа бәхет тумас иде мени... Әй Мәрданша, Мәрданша... Кигән киемең һәрвакыт чиста булыр иде... Балаларың тупырдашып үсәр иде...

Кырыс холыклы булса да, Халисә әнә шундый якты уй-теләкләр белән яши иде. Хәер, аның кырыслыгы шул ир рәхәте күрмәүдән киләдер дә инде. Ялгыз хатыннар явызрак булалар — моны медицина гына түгел, һәркем белә.

Халисә усал булса да бик моңлы хатын. Аның тавышы авыл хатыннарына хас әче булып чыга, ләкин бик матур яңгырый. Җырда Халисәнең күзләре дә, борыны да, күкрәкләре дә катнаша. Җаны-тәне белән җырлый ул, бигрәк тә җыр мәхәббәт турында булса.

Тирәнрәк уйлап баксаң, төкерергә ул мәхәббәт дигән нәрсәгә... Гомер үтеп бара бит, гомеркәйләр үтеп бара! Бала-чага түгел бит инде Халисә югыйсә мәхәббәт дип янып-көеп йөрергә... Гаилә корып, йорт-җир тотып, уртак тормыш алып барырдай кеше кирәк! Таяныч кирәк, иптәш кирәк!

Шулаен шулай да... Ләкин сөюсез, мәхәббәтсез булмыйдыр инде, күрәсең. Күңел ярсый бит, наз сорый, йөрәк жилкенә — әллә нәрсә таләп итә.

Теләсә кемгә ятмый шул күңел. Сайлана, эзләнә күңелләр. Әнә бит күрше авылдан Чатан Әләкси бик озак бөтерелде Халисә тирәсендә. Юк, якын китермәде. Керәшен булганга да түгел, күңел тартмады, йөрәк кабул итмәде. Ә менә Мәрданша... Мәрданшаның да «Аһ» итәрлек нәрсәсе юк югын. «Аһ» итәрлек җире булса, күптән инде гаилә корып, чын хуҗа булып кеше төсле яшәр иде. Шулай да үзенә тарта бит Мәрданша, барыбер нишләптер якын бит ул. Әллә тыйнак булганга инде... Әллә сабыйларча ихлас булганга, әллә башкаларга охшамаган кызык һәм сәер зат булганга — шайтан белгән...

Мәрданша үзе дә сизә, белә — Халисә аны ярата һәм инде күптән янып-көеп йөри. Тик Мәрданшаның аңарда хәбәре юк. «Пеләш тәре!» Бу — Халисәнең үзәкләре өзелгән вакытларда яратып һәм шул ук вакытта нәфрәтләнеп тә әйтә торган сүзләре иде. «Пеләш тәре!»

* * *

Мәрданшаның күгәргән иреннәре: «Халисә?!.» — дип пышылдады, кулындагы идән чүпрәге, лач итеп, төшеп китте. Ул, куркып, артка таба чигенде.

— Нинди бәйрәм синдә? — диде Халисә, гаҗәпләнеп. — Кая, бир, идәнеңне үзем юып бирим. — Һәм чүпрәкне алырга дип иелде. Бу вакытта Мәрданша бераз аңына килде һәм кычкырып җибәрде:

— Юк, юк! Ни йомышың бар миндә? — Ул идән чүпрәген эләктереп алды. — Нишләп йөрисең син... Тукай шигырен бозып?..

Халисә баскан урынында катып калды:

— Нәрсәне бозып дисең?

— Тукай шигырендә доярка да, Халисә дигән кеше дә юк мәйтәм... — диде Мәрданша, идән чүпрәген әвәләп.

Халисә аңа сәерсенеп карады да түргә узды, урындыкка утырды.

— Син нәрсә, алышына башладыңмы әллә?... — диде ул, чын күңелдән шикләнеп. — Синең башыңа чистый кызу капкан, ахрысы... көннәр буе кояш астында утырып. — Ул ык-мык килеп торган Мәрданшага мөлаем итеп елмайды. — Нәрсә, әллә минем киләсемне белдеңме, бәйрәмчә киенгәнсең, музыка уйный, әллә ислемай да сөртенгән инде?

Мәрданша йөгереп барып тәрәзәдән тышка күз салды, аннары каушаудан карлыккан тавыш белән:

— Ни йомышың бар миндә? — дигән сорауны кабатлады. — Оятка калдырасың бит мине хәзер...

Халисәнең йөзенә кинәт кенә ачу чыкты.

— Кемне көтәсең?

Мәрданша өзгәләнде:

— Сиңа барыбер түгелмени? Минем янга хәзер үк килергә тиешләр.

Халисәнең күзләре дымланды, куллары калтырый башлады, иреннәре дерелдәде.

— Барыбер түгел шул... Син начар уйлар уйлый күрмә, Мәрданша... Яр буенда пәкеңне онытып калдыргансың. Шуны таптым да, китердем менә. — Ул пәкене өстәлгә куйды.

Мәрданша чакырылмаган кунагы тирәсендә йөгереп йөри башлады:

— Рәхмәт, рәхмәт, Халисә... Гафу ит инде... Миңа хәзер берәү килергә тиеш... Бар кайт! Йә көнләшер...

Соңгы сүзләрне ул ишетелер-ишетелмәс кенә итеп әйтте. Халисә елап җибәрде. Мәрданша юеш идән чүпрәген шатырдатып ике куллап кысты, идәнгә тып-тып итеп Халисәнең күз яшьләре һәм чүпрәктән сыгылган су тамды.

— Кем соң ул? — диде Халисә сулкылдап.

Мәрданша кыза башлады:

— Канны кыздырма инде, чыгып кит дигәч чыгып кит! Нинди кеше соң син... аңламый торган...

Халисә әкрен генә утырган урыныннан кузгалды... һәм кинәт, нәрсәнедер исенә төшергән сыман, ялт итеп, Мәрданшага карады да, лып итеп кире урындыкка утырды.

— Мин моннан беркая да китмим, — диде ул үҗәтләнеп. — Үтерсәң дә чыгып китмим.

Әйтерсең лә Мәрданшаның берьюлы эченә китереп типтеләр, башына сукты лар һәм кул-аякларын сындырып ташладылар.

— Ничек инде китмисең?... — дип ыңгырашты ул, үзен көч-хәл белән йогәнләп. — Бу бит минем өем...

Халисә читкә карады да:

— Булсын! — диде.

Аның тавышында яңгыраган битарафлык һәм әллә нинди кыю адымнарга әзер булу Мәрданшаны таң калдырды. Шулай да йорт хуҗасы усаллык белән алдырып булмасын аңлады һәм үзенең тавышына юмалау, тынычландыру, хәтта мактау төсмерләре кертергә тырышты:

— Халисә! Син бит акыллы хатын...

— Анысын син әйтмәсәң дә беләм! — дигән коры җавап яңгырады.

— Чыгып кына китсәнә, матурым! — диде хуҗа искиткеч ягымлылык белән.

— Хатын-кыз килергә тиешме?

Мәрданша бераз буталып алды:

— Әйе... юк... әйе...

— Безнең авылныкымы?

— Соң инде, сиңа ни... теге... кайдан булса да барыбер түгелмени?..

Халисә катырак елый башлады:

— Барыбер түгел шул... Ничек инде барыбер булсын... — диде ул, авызын ямьсез итеп җәеп. — Нишләп шулкадәр каты бәгырьле соң син?..

— Нишләгән әле мин, каты бәгырьле булып? — дип акланды Мәрданша.

Ул тагын тиз генә тәрәзә янына барып килде дә, илаулап еларга тотынган мескен хатынны тынычландырырга ниятләп карады:

— Елама инде, Халисә. Бар, кайтып ял ит, тынычлан.

Халисәнең елавы көзге яңгырны хәтерләтә иде — аязырга исәбендә дә юк. Мәрданша кулындагы идән чүпрәгеннән аерыла алмыйча арлы-бирле йөренде.

— Нишләп син мине ошатмыйсың? — диде Халисә, бер ноктага карап.

Аның тынычлана башлаганын сизеп, Мәрданша сөенде. Ул аның янына йөгереп килде дә, ни әйтергә белмәгәч:

— Ошыйсың, ошыйсың... Зинһар, чыгып кына кит инде, — дип сиптерде.

— Юк, Мәрданша, чыгып китмим, чөнки минем синең сөяркәңне күрәсем килә. Халисә елаудан туктады туктавын, ләкин аның соңгы сүзләре «пеләш тәре»не шунда ук яшен булып сукты.

— Җүләрләндең мәллә?! — дип кычкырды Мәрданша. — Мине бәхетсез итәргә уйлыйсыңмы?!. — Шуннан соң ул, тиз генә йөгереп барып, тәрәзәдән тышка карады.

— Һә, кызык кына син... — диде Халисә. — Менә мин дә бәхетсез бит... мәхәббәтемә җавап бирмисең...

Мәрданша нишләргә белмәде — ярсыргамы, әллә тагы да юашрак булыргамы.

— Нәрсә сөйлисең син?.. Нинди мәхәббәт була алсын синең белән минем арада?!. Халисә, чибәрем, бар инде, кайтып кит!

— Юк! Әгәр дә менә хәзер киләсе сөяркәң чибәр, тыйнак, акыллы икән, мин берсүзсез чыгып китәрмен. Әгәр дә инде ул бәрәр пүчтәк нәмәрсә икән, мин аның үзен моннан очыртып чыгарачакмын.

Сабыр холыклы, юаш кешеләр дә кайвакыт ярсып куялар. Андыйлар арасында да җинаятьчеләр, хәтта кеше үтерүчеләр дә булгалый. Чөнки түземлекнең дә чиге бар бит. Һәрнәрсәнең ахыры, чиге булгач, түземлекнең дә бетү ихтималы гаҗәп нәрсә түгел.

Шактый озакка сузылган дулкынлану һәм күңел киеренкелеге Мәрданшаның сирәк тешле авызыннан ямьсез акыру булып бәреп чыкты:

— Ычкын моннан яхшы чакта! — Ул идән чүпрәге белән кизәнде. Халисә сикереп торды, чөнки «пеләш тәре»нең үкерүе хәйран куркыныч булып тоелды. Ни гаҗәп, Мәрданша шунда ук үзен кулга алды. — Халисә, гафу ит инде... Бар, ул килгәнче чыгып кит, оятка калдырма мине.

Халисә выжылдап ишек янына барып җиткәч:
— Ярый, бәхетле бул! — диде.
— Рәхмәт! — диде йорт хуҗасы.
Ишек шапылдап ябылыр алдыннан өй эчендә Халисәнең: «Пеләш тәре!» — дигән авазы яңгырады. Тәрәзә төбеннән үтеп киткәндә тышта аның «Тьфу!» дигәне хәтта төкерегенең «лычт» итеп рәшәткәгә сылангалы да аермачык ишетелде.
Ниһаять, «пеләш тәре» идән чүпрәген моржа артына ташлады, чиләкне чоланга чыгарып куйды. Һәм бераз ятып торды.
Уйлар баш эчендә берөзлексез тугландылар.
«Уф... Шундый вакытта килеп керүен карале син аның... Хараплар була яздым бит... Кайчан килә инде бу Су анасы, ә?.. Ярый Халисә монда чакта килеп кермәде әле... Башлар бетәр иде... Әй, Халисә, Халисә... Синең дә бәхетләрең юк инде... Син дә бер ялгызың... Һә, Гаделша әйтә, Халисә сиңа менә дигән пар булыр иде ди... Бигрәк кызык бу Гаделша... Ничек инде гомере буе сыерлар арасыннан чыкмаган Халисәгә гыйшык тотып булсын ди... Мәхәббәт бит ул бик серле, бик татлы нәрсәләр... Халисә шундый серле нәрсәнең иясе була аламы инде, йә?... Дурак син, Гаделша!.. Разве Халисә белән, кинодагы шикелле матур итеп, озак итеп үбешеп була?.. Яисә, әнә теге, мин моннан сигез ел элек укыган китаптагы кебек, су чәчрәтә-чәчрәтә куышып, уйнап йөгереп буламы Халисә белән?!. Халисә мәхәббәт иясе булырдай булса, шушы яшенә кадәр ялгыз булмас иде. Гаделша миңа да әйткән була, имеш, мин дә, җүнле булсам, кырык яшемә кадәр буйдак булып йөрмәс идем. Әй, юк Гаделша туган, мин икенче мәсьәлә... Мин бит чын мәхәббәтемне эзлим. Менә мин ул мәхәббәтемне таптым да шикелле инде. Су төбендә булган икән бит минем мәхәббәтем... Гаҗәп!»
Сикереп торды да, тагын тәрәзәдән урамны күзләде. Юк, күренми Су анасы. «Уф, килер микән, юк микән?..»
Шул вакытны авыл этләре тагын гауга куптардылар.
Бераздан тәрәзәне шакыдылар. Пәрдәне ачып карарга исәбе бар иде дә Мәрданшаның, тик курыкты.
Ул тагын ары-бире сугылды, уйнаткычны берничә тапкыр сүндереп яңадан кабызды, кат-кат үзен көзгедән карады. Тәрәзә тагын берничә тапкыр шакылдагач, ишек дөбердәтә башлады. «Су анасы бу... Бик ачулы шакый ишекне...» — дип уйлады Мәрданша.
Ул, йөгереп барып, ишекне ачып җибәрде.
Йә ходаем! Ник бетермисең бу кабахәт дөньяны?.. Ник тизрәк җиткермисең инде ахырзаманны? Ник бимазалыйсың фәкыйрь адәми затларны?.. Мәрданшабыз таң калды — папкасын култык астына кыстырып, өйгә участок инспекторы капитан Миңлебаев килеп керде.

* * *

Совет милициясе 1917 елның 28 октябрендә оештырылган. Бик күп сулар акты инде ул вакыттан соң, шакты вакыйгалар булды, бихисап кеше үлде, алар урынына яңалары туды... Кайдадыр җир тетри, янар таулар шартлый, тайгалар дөрли, шәһәрләрне су баса, таулар ишелә... Ә милициягә берни юк. «Халык милициясе» булып кешеләрнең иләс-миләс аңына сеңгән дә, кунитекләре белән бәгырьләрне таптап йөрүен дәвам иттерә.
Милициядән авыл кешесенең коты алынып тора. Чөнки милиция кешене АЛЫП КИТӘ! АЛЫП КИТҮ — тетрәндергеч, коточкыч хәл. Шәһәр кешесенә бәлки алай ук куркыныч та түгелдер... Чөнки кала кешесе, гадәттә, законны да хәйран аңлый, урысча да әйбәтләп сөйләшә белә. Ул үзен акларга сүзен дә, җаен да чамалый. Ә менә авыл кешесе милициягә килеп капса — харап. Бигрәк тә — АЛЫП КИТСӘЛӘР. Авыл

татары ни урысча юньләп сөйләшә алмый, ни законнарын аңлап бетерми...

Милиция бит ул синең белән үчтеки-үчтеки уйнамый. Ул бит влачның тәмен белә һәм кешене рәнжетүдән рәхәт таба.

Ул сине параграф белән буа, ныгытып буа, чырайларың зәңгәрләнгәнче... Ул сине статья белән богаулый — кул-аякларың йөрмәслек итеп... Ул инструкцияләр белән синең яңакларыңны чабаклый... Ул сине тиз-тиз оештырылган судның хөкем карары белән бәреп үтерә ала.

Сине яклаучы да булмый, чөнки син надан! Надан кешене аны мәңге санга сукмадылар, надан кешене аны якламыйлар да... Сине махсус рәвештә надан итеп тәрбияләгәннәр дә... Чөнки надан кешене теләсә кайчан АЛЫП КИТЕП була. Надан кеше өстеннән беркетмәләр, актлар төзүе бик җайлы. Томана кешедән сорау алулары да бик рәхәт — бер гаебе булмаган сурәттә дә, мескенне бер-ике юридик термин белән өркетеп, әллә нинди булмаган нәрсәләр мыгырдаттырып була.

Бу яктагы Сәвит милициясенең төп «клиентлары» надан, томана, куркак һәм урысча юньләп сөйләшә белмәгән кешеләр булды. Шундыйларны хөкемгә тартып, милиция дигән коточкыч җәза инструкциясенең тамагы туйды һәм шулай итеп, меңләгән ерткыч, погоннар тагып, папка кыстырып «эш күрсәтеп йөрделәр». Һәм әле бүген дә йөриләр.

Әйе, авыл кешесе АЛЫП КИТҮДӘН бик курка. Чөнки кире кайтмавың бар... Ярый ла ул авылда гына допросласалар... Авылда бәлки бик нык каушамас та идең... Үз авылың — үз авылың инде ул. Ә тегендә... районда... отделда... Анда инде авыл кешесе үзен ит комбинатына чалырга китерелгән сыер сыман хис итә.

1917 нче елның октябреннән бирле «халык милициясе» белән халык арасында рәхимсез сугыш бара. Гадел сугыш түгел, пычрак, оятсыз сугыш. Төрмәләрне, зоналарны шыплап тутырсалар да, ул сугышның ахыры күренми, киресенчә, нәфрәт көннән-көн арта, сугыш көннән-көн көчәя.

Җырыклы авылыннан алай бик ерак түгел Минзәлә каласы урнашкан. Бу кала хакында сүз чыкса, андагы аракы заводын һәм театрны телгә алалар да, шуның белән вәссәләм...

Минзәләдә тагын бер искиткеч тарихи истәлек бар лабаса!

XVIII йөзнең икенче яртысында, барокко стилен кысрыклап чыгарып, Рәсәй архитектурасына Классицизм юнәлеше бәреп керә. Шул вакытта, Әби патша[1] әмере буенча, Пугачев восстаниесе «хөрмәтенә», Минзәлә каласында ныклыгы белән Мисыр пирамидаларыннан калышмый торган архитектура корылмасы — төрмә салына.

Шул ук елларда төзелгән мәшһүр Кышкы сарайның һәм Петергофның авторы Растрелли[2] икәне дә билгеле, Кремль сараен Баженов[3] проектлаганы да мәгълүм. Ләкин, кызганыч, Минзәлә төрмәсенең архитекторы билгеле түгел. Аның исеме җинаятьче халыкның күңелендә һәм хәтерендә мәңге сакланыр иде.

Классицизм стиленә хас колонналары булмаса да, шул ук стильнең билгеләре булган җитдилек һәм салкынлык Минзәлә төрмәсендә артыгы белән җитәрлек.

Бу таш бина бик кунакчыл — аның кочагы пугачевчылардан башлап, бүгенге рэкетчыларга кадәр үзенә сыендыра ала.

---

[1] Әби патша — Екатерина II Алексей кызы (1729 — 1796), 1762 елдан — урыс патшабикәсе.

[2] Растрелли Варфоломей Варфоломеевич (1700 — 1771) — урыс архитекторы. Барокко сәнгате вәкиле. Кышкы сарай, Петергоф, Смольный монастырь һәм башка корылмаларның проектлары авторы.

[3] Баженов Василий Иванович (1737 — 1799) — урыс архитекторы, классицизм чоры эшлеклесе. Мәскәү Кремлен, Пашков йортын һәм башка танылган архитектура үрнәкләрен проектлаучы.

Тыштан бик «кычкырып» тормаса да, аның эче шактый гаугалы. Минзәлә төрмәсе — тикшерү изоляторы. Ягъни җинаятьчеләрнең тикшерү эшләре барышында һәм судтан соң этап көтеп ята торган урыны. Монда кеше үтерүчеләр, караклар, көчләүчеләр һәм бер гаепсез кешеләр утыра.

Минзәлә төрмәсеннән качучы юк.

Башка изоляторлардан бик еш качалар. Төрле сәбәп белән шылалар төрмәдән: йә ирекне артык нык яратудан, йә туганнарын сагынып, ә кайберләренең әле тагын үтерәсе кешеләре калган була. Ә менә Минзәлә төрмәсеннән нишләптер качмыйлар. Екатерина II гә, тарихка ихтирам йөзеннән качмыйлар микән әллә?.. Бәлки, Пугачевка карата мәхәббәт көчледер?.. Бу — әлегә сер. Моны әле өйрәнәсе бар.

Төрмәнең диварлары биниһая калын, нык һәм чыдам. Шуңа күрә аның эчендә яшәүче гөнаһлы бәндәләрнең язмышлары шартлап сынганы да, гаепсезләрнең җан кычкыруы да стенаның бу ягында йөрүчеләргә ишетелми.

Тугыз кешене суеп үтергән рецидивист белән исерек баштан автобуста печ иткән өчен утыртылган кешене бу төрмәдә бер камерага ябалар. Нәтиҗәдә, автобуста хаҗәтен башкарган кеше икенче мәртәбә төрмәгә эләккәндә инде «абруйлырак» статья белән килеп керә.

Монда гәрбил такта урлап тотылган бабай, атмасалар ярар иде, дип куркып ята, ә гомере буе урлап, дәүләт хисабына көн күргән капкорсак, бәлки әле дусларым коткарыр дип, юанып яши...

Төрмәдә утыручылар үзләрен гаепле дип санамыйлар. Әгәр дә берәр нечкәрәк күңеллесе үзен гаепле дисә, камерадагы иптәшләре аңа төрмә врачына мөрәҗәгать итеп, башын тикшертергә тәкъдим итәләр.

Күрәсең, кеше тоткынлык, әсирлек белән мәңге килешә алмас. Ә ирекле булуның төп шарты — гаепсез булу. Шуңа күрә төрмә халкы үзен гаепле дип санарга кыймый. Аларны көне-төне бер уй борчый: югыйсә дөнья болай да инде бик тар, нишләп соң тагын шуның өстенә төрмәгә ябып бикләп куялар?..

Ике йөз ел эчендә дөнья әллә нишләп бетте, әллә ничә төргә керде, хәтта кеше үзе дә үзгәрде. Ә Минзәләдә төрмә шул ук!

Менә бу классика ичмаса!

Менә бу классицизм!

Инде Рәсәйне ничәнче кат җимереп, яңадан төзиләр... Ә төрмә шул көе!

Җәмгыять үсешенең өч фазасы алмашынуга (феодализм, капитализм, социализм) шаһит булган таш төрмә әле моңарчы дөнья ишетмәгән яңа фазалар килеп чыкса да, үзенең «кунакчыллыгын» җуймас.

Бу булганчык Рәсәйдә төрмә генә үзгәрми торган нәрсә булып чыкты.

Чын классика, чын классицизм менә шулай була ул!

Шулай итеп, Минзәләдә спектакльләр куеп йөрүче театр гына түгел, стационар рәвештә эшләп ятучы төрмә исемле «драма һәм комедия театры»да бар. Кызганыч, бу театр спектакльләрен бик күпләр күрми... Чөнки кешеләр арасында — таш дивар!

Үзебезнең әти-әниләр, абый-апалар, балаларыбыз утырса да, төрмә әшәке урын булып аңыбызга сеңгән.

Туктагыз әле! Андый начар нәрсә булгач, нишләп соң безнең төрмәләр һәрвакыт шыгрым тулы?.. Юк, табышмак бу... Өйрәнәсе бар әле төрмәләрне. Өйрәнер өчен Минзәлә төрмәсен — классицизм үрнәген алырга кирәк. Бәлки бу сорауга җавап табып булыр: төрмәләрне кат-кат ремонтларгамы, әллә кеше аңына бер уникаль реставрация ясаргамы?..

Нишләп мин Минзәлә төрмәсе турында күп сөйлим? Моның сәбәбен хәзер үк әйтеп бирәм. Әлеге дә баягы таш төрмәдә участок инспекторы капитан Миңлебаев «ярдәме» белән бик күп кеше утырып чыкты. Төрмәләр һәм Миңлебаевлар бер бөтен механизмны тәшкил итәләр — кеше-

не изү, җәберләү механизмын. Төрмәләр булмаса, Миңлебаев та — Миңлебаев булмас иде.

Мәрданшаны да шул төрмәгә ябарга исәбе бар иде Миңлебаевның. Чөнки участковыйның эше шул. Ярты ел саен бирәр кешене утыртмаса, димәк, участокта инспектор тарафыннан эш алып барылмый.

Шуңа күрә, форсаттан файдаланып, Миңлебаев безнең Мәрданшага Минзәлә төрмәсенә «путевка» әзерли башлады. Бик җитди эштә гаепләнә «пеләш Мәрди», бик авыр җинаять кылган! Моны болай гына калдырырга ярамый!

* * *

Су анасын көтеп утырганда аның урынына милиционер килеп керсә, кем генә һушсыз калмас иде икән...

— Гафу итәрсең төнлә килүем өчен,— диде Миңлебаев, өйгә кереп фуражкасын стенадагы кадакка элеп куйгач.— Эш бик асубый, кичектерергә һич ярамый.— Ул барып проигрывательне сүндерде.— Нишләп бик озак ачмый тордың? Йоклаганың дисәм... утың яна, музыка уйный.

Мәрданша, ык-мык килеп, бер урында таптанып торды. Инспектор аңа явыз караш ташлады:

— Нәрсә син язгы ата каз сыман биеп торасың?.. Утыр да димисең...

Мәрданшаның кайсыдыр җиреннән:

— Утыр...— дигән сүз чыкты.

Миңлебаев өстәл артындагы урындыкка утырды да, бөтен авылга таныш булган күн папкасыннан берничә бит кәгазь чыгарды.

— Фу, әдикалун эчтең мәллә? — диде ул, чыраен сытып,— исе күзләрне әчеттерә...

— Юк, сибендем,— диде Мәрданша.

Авыл кешеләре өстеннән актлар, беркетмәләр төзүдән ләззәт һәм эчке канәгатьләнү табып яшәүче инспектор җитди кыяфәт белән йорт хуҗасына текәлде:

— Нишлибез?..

— Тукай шигырендә участковый юк бит,— дип җавап бирде Мәрданша.

— Кайда юк участковый? — диде Миңлебаев, каршысында басып торган кырык яшьлек сабыйның мескенлегеннән җирәнеп.— Участковый бөтен җирдә бар!.. Юкны сөйләп торма!

Мәрданша өстәл артында утыручы җанбасардан күзләрен алырга куркып, караватка барып утырды.

— Урлашу! — диде Миңлебаев, камчы белән суккандай итеп.— ...нче статья!

Мәрданша сикереп торды һәм тыныч сүз башлады:

— Туктале... Тукай шигырендә милиция бөтенләй юк бит...

Участковыйның җене кабара башлады һәм ул кычкыруга күчте:

— Нәрсә такылдыйсың син?.. Нинди Тукай шигыре?.. Кем ул? Нишләп белмим мин аны?.. Кайда милиция юк? Булмаса булыр менә... Уголовный эш башлана сиңа! Алтын таракны син урладыңмы?

Мәрданшаның бу минуттагы хәләтен сүз белән генә аңлатып булмыйдыр. Әйтерсең лә аңа кувалда белән суктылар һәм өстенә бер чиләк кайнап торган су сиптеләр. Шулай да ул бераз аңына килде һәм инспектор каршына килеп утырды.

— Иптәш капитан, тыңла әле... Без аны Гаделша белән Зәй буенда күргән идек... Мин аңа гашыйк булдым...

— Кемгә, Гаделшагамы?

— Юк, Су анасына.

— Кемгә?!.

— Су анасына. Мин аны өемә алып кайтмакчы идем... Тукай шигырендәге кебек... Революциягә кадәр яшәгән ул шагыйрь... Аның шигырен-

лә бер малай Су анасының алтын тарагын урлый... Төнлә Су анасы шул малайның өенә килә һәм тарагын сорый. Малай аңа таракны кире бирә.

— Ул малайны төрмәгә утыртмыйлармы соң?

— Юк.

— Алайса аның әтисе бирәр нәчәлник булгандыр инде.

— Белмим, шигырьдә ул хакта сүз юк. Менә мин дә, Су анасына гашыйк булдым да, аның алтын тарагын урлап йөгердем. Төнлә өемә килер дип...— Бу сүзләрне әйтеп бетергәндә Мәрданшаның бите Миңлебаевның партбилеты кебек кып-кызыл иде.

— Нишләтмәкче идең соң син аны, өенә китертеп? — диде участковый.

— Гашыйк булуымны сөйләп бирмәкче идем. Валлаһи, миңа аның алтын тарагы кирәк түгел. Карале, Миңлебаев иптәш... Син бит мине күптәннән беләсең... Арыш саламы белән тотылгач та ярты кышлык печәнемне совхозга тапшырдым бит, хәтерлисеңдер... Ә кеше әйберсенә минем гомеремдә кагылганым юк... Карак түгел лә мин...

Мәрданша, мәрхәмәт өмет итеп, күн папка иясенең яшел күзләренә карады. Ләкин ул күзләр миһербанлык вәгъдә итмиләр иде.

— Гариза язылган бит менә,— диде Миңлебаев.— Ничек дип атыйсың әле син ул хатынны? Су анасы дипме? Хе-хе-хе.

— Әйе, Су анасы...

— Бәрәч, син аның исемен дә белмисең мени?

— Су анасының исеме Су анасыдыр инде.

— Ничек?.. Ул бит аның кушаматыдыр... Исеме ничек соң аның!

— Нинди кушамат булсын... Су анасы ул.

— Ничек инде — Су анасы?..

— Су анасы бит ул,— диде Мәрданша, «Шуны да белмисең мени...» дигән шикелле.

Теге аңышып җитмәде:

— Кем?

— Шул инде... мин гашыйк булган хатын.

Миңлебаев шомлана башлады.

— Туктале, туктале, ни сөйлисең син?..— диде ул, тавышын бераз кысып.

Мәрданша ничек аңлатырга белми интекте:

— Озын чәчле, чибәр... Судан килеп чыкты да, чәчен тарый башлады. Шәрәтән иде...

Миңлебаевның күзләре акайды, борын тишекләре киңәйде, портупеясы тартылып шыгырдап куйды.

— Шул син тарагын урлап качкан хатынмы?..

— Әйе.

— Су анасымыни ул?

— Су анасы дидем бит инде.

— Да-а-а... Белая горячка түгелме соң синдә, гражданин Мәрданша?

— Юк. Нинди белая горячка булсын ди миндә... Мин бит ашап эчмәм. Ул чын-чын Су анасы иде... Әкиятләрдә генә очрый торган.

Хәзер инде инспектор да Мәрданшадан курка башлады. Шулай, бер-берсеннән куркып, алар бик озак утырдылар. Дөресрәге, участковый Мәрданшадан түгел, ә вакыйганың үзеннән куркыбрак калды. Ә йорт хуҗасының куркуы катлаулырак иде — монда инде милициядән өркү белән бергә сөйгән ярдан колак кагу куркынычы да котны ала иде.

Ниһаять, Миңлебаев үзенең участок инспекторы икәнлеген исенә төшерде һәм анарда курку дигән нәрсә шул арада юкка чыкты.

— Хатын-кыз суда да бар микәнни? — диде ул, ни әйтергә белмәгәч.

— Су анасы булгач, суда яшидер инде,— диде Мәрданша.

Инспектор торып йөри башлады.

— Әйтәм бик сәер күренгән иде ул хатын миңа... Мин үзем дә анардан шикләнгән идем. Аның башы артында яулык белән капланган чүмәләсе бар иде — чәчен җыеп куйган булгандыр инде, күрәсең. Исем-

фамилиясе, адресын сораштыргач та, бутала-бутала гына җавап бирде. Менә бу могҗиза ичмаса. Син ул су җанвары белән ничек уртак тел табалдың соң?..

— Нинди уртак тел табыйм ди... Мин аның белән сөйләшергә дә өлгермәдем. Төнлә өемә килсен дип, мин аның алтын тарагын чәлдердем дә әллү!

Миңлебаев Мәрданшаның каршысына килеп басты.

— Да-а-а, гражданин Мәрданша, минем участогымда мондый хәл беренче тапкыр, беләсең килсә...— Ул бик озак башын чайкап торды.— Ыслушай, Мәрди, син аңа ничек гашыйк булдың? Су анасы балык түгелме соң ул?..

— Балыкка охшаган идеме соң? — диде Мәрданша ачу белән.

— Юк алай... Ну шулай да... аннан бераз күл балыгы исе килеп киткәндәй булган иде.

— Юк, юк, ул дөньяда иң чибәр хатын-кыз.

— Чибәр, чибәр, сүз дә юк,— диде участковый һәм тагын Мәрданшаның каршысына утырды.— Шундый чибәр малны ничекләр үзеңнеке итә алдың син?

— Үземнеке италмадым әле мин аны! Нишләп ышанмыйсың соң син миңа?..

Миңлебаев ямьсез итеп, хахылдап көлеп куйды.

— Кая, күрсәт әле, нинди тарак соң ул?

Мәрданша сандыктан таракны алып бирде:

— Менә ул.

— Да-а-а,— дип сузды инспектор,— менә бу расческа ичмаса. Тик, амавый, синең чәчең дә юк бит... Бу алтын бөтен авыл халкының тешләренә җитәр иде. Ха-ха-ха. Ярар, тарак белән аңлашылды ди.— Таракны ул папкасына тыгып куйды.— Син менә аның язган гаризасын укып кара әле. Игътибар белән укы, җентекләп укы. Ул биргән кәгазьне укыганда Мәрданша Казан трамваенда барган сыман дыр-дыр калтырый башлады. Һәм көмешкә кугандагы шикелле шабыр тиргә батты.

— Иптәш капит... Ул... бит... м... м...монда,— дип мөгрәде ул һәм гариза кәгазен кулыннан идәнгә төшереп җибәрде.— Ул бит монда... Мәрданша өч ай буе минем белән яр буенда яшәде дип тә язган... Авырга узганымны белгәч, ташлап качты, алтын тарагымны да алып китте, дигән?! Чеп-чи ялган бит бу!

Миңлебаев рәхәтләнеп көлде.

— Мин ышанам сиңа,— диде ул, көлеп туйгач.— Тик монда шаһитлар да бар шул. Җәйләүдәге сыер савучылар синең балык тотып утырганыңны гел күреп йөргәннәр. Алар судта шаһитлар булып барачаклар. Сине яр буенда күргәннәрме? Күргәннәр! Су анасының тарагы синдәме? Синдә! Тарак — вещественный доказательство! Гариза бармы? Бар! Шул житкән, гражданин Мәрданша. Хәзер законнар хатын-кыз яклы бит, син шуны белмисеңмени?..

Мәрданша кинәт җанланып китте:

— Су буенда күргәннәр дип... Анда Гаделша да йөрде балык тотып... Шул тирәдә Саңгырау Нуретдин дә сыер көтүен көтеп йөри, аңа калса.

Миңлебаев өстәлгә китерен сукты:

— Стоп! Аларны телгә аласы булма! Групповой чәпәргә могут. Үз өстеңә генә алсаң, яхшырак булыр — үзең өчен әйтәм моны, якын итеп, якташ итеп.

Әйе, группа белән кылган җинаять өчен катырак җәза бирәләр. Ләкин бу очракта башка төрле житди сәбәп тә бар иде. Гаделшаның уртанчы малае шин заводыннан участок инспекторына ел саен берничә покрышка урлап алып кайта иде, шуңа күрә Миңлебаев Гаделшаны читтәрәк тотарга тырышты. Ә Саңгырау Нуретдингә килгәндә... Ул тинтәктән хатын-кыз белән чуалу буламы соң инде... Карчыгы белән дә тыныша алмый, этле-мәчеле яшиләр әле.

— Мин бит ул хатын белән хәтта таныш та түгел,— диде Мәрданша.

Инспектор Мәрданшага таба сузылды һәм серле итеп елмайды:

— Сөйлә әле, Мәрди, ничегрәк булды? Ничегрәк таныштыгыз?

— Иптәш капитан, иптәш Миңлебаев,— диде Мәрданша әзгәләнеп,— белмим мин ул хатынны. Танышыр өчен генә урладым мин аның тарагын да.

— Ярар, ярар, бөгештермә, менә бит гариза язылган.— Ул идәннән гариза кәгазен алып, өстәлгә куйды.— Син исеңә төшер әле... әллә соң аның чибәрлегеннән, рәхетлектән бөтенләй хәтереңне җуйдыңмы?..

— Чыннан да... әллә соң мин аның белән бераз чуалып алдым микән?..— диде Мәрданша, уйга калып.

Миңлебаевның махмырлы күзләре ялтырап куйды.

— Сөйлә әле, сөйлә. Пратакул өчен түгел монысы.

— Юк, юк, искә төшми.

— Төшәр, төшәр... Уголовный эш ачылгач, ба-а-арысы да исеңә төшәр, гражданин Мәрданша.— Аның тавышы кинәт элеккечә һәм гадәттәгечә усал яңгырады.— Кайда маташтыгыз???

Мәрданша ничек аңлатырга белми иза чикте.

— Маташмадык та, нитмәдек тә...

Миңлебаев тагын юмалауга күчте:

— Мин бит инде сиңа чит-ят кеше түгел. Сөйлә инде, башка хатыннар төсләме ул, әллә... асубыймы, ә?.. Хе, хе... Дөресен генә әйткәндә, аңардан мин үзем дә баш тартмас идем.— Мәрданша сикереп торды.— О-о-о, Мәрди, әллә көнләшәсең дә инде?.. Да-а-а, ничәмә еллар милициядә эшләп, участогымда мондый вакыйга беренче тапкыр. Утыр әле, утыр, сөйлә инде ничегрәк булды? Ну, кайнар, дәртле нәрсәдер ул чукынчык, ә?..

— Белмим,— диде Мәрданша битараф тавыш белән,— каян белим мин аның нииндилеген?

— Һе, каян белим, каян белим... Ә корсакка ничек узган соң ул алайса? Көтүче Саңгырау Нуретдиннән түгелдер бит?..

Мәрданша сискәнеп китте. Аллам сакласын! Берүк Нуретдин чуала күрмәсен Су анасы белән. Алайса Мәрданша көнләшеп үләчәк. Ул уйга батты һәм шактый вакыт шулай кукраеп утыргач:

— Туктале!— диде.— Әллә соң чыннан да миннән узды микән ул авырга?.. Бервакыт бик каты чирткән иде... Калкавыч юк булды... Кармак таягы дырылдый башлады... Әллә кармак аша бирәр ничек булды микән?..— Ул, җавап көтеп, катып калды.

Ләкин Миңлебаев сексопатолог та, гинеколог та түгел иде, шул сәбәпле бу сорауга җавап бирә алмады. Ул милиционер иде, шуңа күрә, болай диде:

— Белмим, белмим, гражданин Мәрданша, кармак ашадырмы, бармак ашадырмы, әллә башка нәрсә аркылыдырмы... Ярар, сөйләрсең әле, ба-а-арысын да төкми-чәчми сөйләп бирерсең. Һәм, нидер язмакчы булып, кәгазь өстенә иелде.

— Мин бит ул хатынга кагылмадым,— дип еламсырады Мәрданша.— Алтын таракны да аның белән танышыр өчен генә урладым. Тукай шигырендәге кебек...

— Тукай шигырендәге кебек...— дип үчекләде инспектор.— Хәзерге хатыннар Тукай заманындагы кебек түгел шул, агайне. Хатын-кыз эт белән бер ул хәзер. Хатын-кызга аңа алимент кына кирәк.

«Алимент» сүзен ишеткәч, Мәрданша, сикереп торды да, арлы-бирле йөренә башлады. Ниһаять, аның башына бөтен ир-атның котын ала торган «алимент» сүзенең чын мәгънәсе барып җитте һәм ул:

— Әлиминт? Нинди әлиминт?— диде.

Миңлебаевка рәхәт иде.

— Каптың син, брат,— диде ул.— Алиментка бирәчәк ул сине.

Мәрданшаның күңелендә кинәт кенә өмет яшене чагылып китте һәм аның агарынган йөзендә шатлык балкыгандай булды. Ул инспектор янына йөгереп килде:

— Ә өйләнсәм?.. Миңа күптән өйләнергә вакыт бит инде.

— Син гафу ит кәнишне, ну андый чибәр ханымның синең ише калхузникка кияүгә чыгасына чыра пычагы белән суйсалар да ышанычагым юк.

— Әлиминт дисең инде алайса... Иптәш капитан... егерме биш процентмы әле ул?

— Әйе, егерме биш процент,— диде инспектор, папкасын алып китәргә җыенгач. Фуражкасын кигәч ул кинәт борылды да, курыккан кыяфәт белән өстәп куйды.— Юк, Мәрди, егерме биш процент кына түгел...

— Игезәкләр булыр дисеңмени? — диде Мәрданша пышылдап.

Миңлебаевның күзләре акайды.

— Игезәкләр генәме соң, Мәрданша... Үзең уйлап кара... Су анасы булгач, ул бит... уылдык чәчәдер! Йөзәр мең уылдык!

Бу сүзләрне ишеткәч, Мәрданша аңын югалтты һәм, автоген белән кисеп төшерелгән зур тимер кисәге сыман шапылдап, идәнгә ауды.

* * *

Су анасы судка килмәде. Процессны кичектерергә булдылар. Мәрданша ябыкты, муен тамыры тирәсендәге чәч бөртекләре агарды.

Су анасы тагын күренмәде. Судны дүрт мәртәбә күчерделәр, ләкин гариза язучы юк та юк.

Зәй буена җибәрелгән тикшерү комиссиясе бик сыек җавап алып кайтты: Зәй ГЭСы суны бугач, елга инеш кебек кенә калган. Имеш, Су анасы Кама елгасына киткәндер... Ләкин Казан галимнәре Кама һәм Идел мазут белән, төрле химикатлар белән бик пычрана, шуңа күрә ул елгаларда хатын-кыз түгел, дуңгыз да яшәрлек түгел, диделәр.

«...Су анасы Каспий диңгезендәдер...» — дигән фараз өлкән суд тикшерүчесенең башында дүрт рюмка коньяк эчкәч туды һәм, машинистка тарафыннан алты данәдә басылып, дөнья күрде.

Географияне өчлегә генә белгән прокурор бик озак дөнья картасы тирәсендә йөрде һәм Африка кыйтгасыннан Кама белән Иделне эзләп җәфа чикте. Әлеге дә баягы тикшерүче аңа ярдәмгә килде — Зәй — Камага, Кама — Иделгә, Идел Каспий диңгезенә барып тоташа иде.

Прокурор бик озак, шикләнеп, картага карап торды.

— Идел Кара диңгезгә коя иде түгелме соң? — диде ул, гаҗәпләнеп.

— Юк, юк, Каспийга,— диде тикшерүче.

— Елгаларны бору турында сүз алып барганнар иде бит Брежнев заманында... Әллә Иделне Кара диңгездән Каспийга борып өлгерделәр микән? — диде прокурор, аптырап.

— Юк. Элек тә Каспийга коя иде,— дип җавап бирде тикшерүче.

Прокурор өлкән тикшерүченең зиһенлелегенә сокланып, аның хезмәтенә уңай бәя бирде һәм:

— Димәк, Су анасы Каспий диңгезендәдер! — диде.— Шунда инде аның урыны. Диңгез диңгез инде ул. Зәй кебек болганчык инеш түгел.

...Шул ук көнне өлкән тикшерүченең бүлмәсенә капитан Миңлебаев белән Мәрданша килеп керделәр.

Хөкем эше туктатыла дигәч, Мәрданша нишләргә дә белмәде сөенергәме, көенергәме... Җинаять эшенең туктатылуы әйбәт тә бит... тик менә... Су анасы юкка чыгу гына йөрәкне сыкрата...

Миңлебаев күз кыскач, Мәрданша, кесәсеннән конверт чыгарып, тикшерүчегә сузды.

— Күпме соң монда? — диде тикшерүче конвертны кабул итеп.

— Өч мең,— дип җавап бирде Миңлебаев Мәрданша өчен.

Тикшерүченең йөзе яктырып китте һәм ул дустанә рух белән болай диде:

— Ну тапкансың гашыйк булыр нәрсә... Шулай бик чибәр идемени? — Мәрданша дәшмәде.— Башка вакытта чамалап гашыйк бул! Лутчы бөтенләй гашыйк булмаска кирәк. Гашыйк булмыйча гына, мәхәббәтсез дә яшәп була бит... Шулай бит, иптәш Миңлебаев?

— Канишне,— дип җавап бирде инспектор.

Тикшерүченең бу кечкенә лекциясеннән соң Миңлебаев сүз алды:

— Моның язмышы ничегрәк булыр соң инде? — Сүз Мәрданша турында бара иде. Әйтерсең лә аның тәкъдире прокуратураның өлкән тикшерүчесе кулында иде. Ә бит чыннан да шулай! Шуның кулында!

Тикшерүче елмайгандай итте.

— Су анасының кайда икәнлеге билгеле түгел. Судка дүрт тапкыр инде килмәде. Минемчә, эшне туктатып булачак.

Мәрданша сикереп торды.

— Зинһар, туктатыгыз!

— Туктатырга булыр...— диде хөкемдар.— Тик миңа тагын бер мең чамасы кирәк булыр...

Шулай дип әйтеп бетерүгә булды, Мәрданша җәһәт кенә куен кесәсеннән соңгы мең сумын тегеңә чыгарып бирде:

— Менә... зинһар өчен... алла хакы өчен... бөтенләй туктатыгыз, бетерегез бу эшне!

Тикшерүче акчаны кесәсенә тыгып куйгач:

— Ярый, мин прокуратурада бөтенесен җайлармын,— диде.— Туктатып булыр, пожалуй, бу эшне.

Шулай итеп, бөтен булган акчасын прокуратурада калдырып, Мәрданша судтан һәм закон чытырманыннан котылган кебек булды. Ә тикшерүче исә тиз генә арада мондый кәгазьне оештырды: «...Алтын таракны урлаганны күрүче булмаган... Мәрдәншаны угрылыкта гаепләү дәлилсез...»

Алтын тарак прокуратурада калды.

Әйе, Мәрданша суд җәзасыннан котылды. Ләкин сөю газабыннан, сагынудан мәңге котылып булмас, ахрысы.

Зәй төбәген тикшерергә барган комиссия елганың хәл-әхвәле турында дөрес бәя бирде. Зәй елгага охшамаган иде инде. Бетерделәр елганы. Бетерделәр табигатьне.

Ил басарга килгән гаскәр кебек, тау артыннан калыккан кара торбалардан химкомбинатның агу-томаннары инде бик күп еллар буе тирәякны агулый. Яшьләр шәһәре дип төзелгән соп-соры, шыксыз таш каланың бөтен пычрагы, чүбе Зәй буена китереп аударыла. Һәм шул чүплек базыннан таралган яман исне иснәгәч, бу дөньяда гүзәл Су аналары, сихри тавышлы кошлар, кара урманнар, шаян Шүрәлеләр һәм, гомумән, әкият барлыгына ышанмый башлыйсың.

Шуңа күрә, Су анасы ерак диңгезгә житкәндер дигән хәбәргә барысы да ышандылар.

Мондый болганчык инештә ничек яшәмәк кирәк?!.

* * *

Сорау алулар, тикшерүләр, судка чакырулар Мәрданшаның җелеген киптерде.

Инде акча «төртеп» кайткач, милиция белән эшләр тәмамланды дип уйлаган иде ул. Әмма ялгышты.

Соңгы бер-ике ай эчендә йокысының да рәте калмаган иде, ниһаять, бүген сабыйларга гына хас булган татлы йокыга талды һәм үзе сыман җүләрләр генә күрә торган төш күрә башлады. Имеш, аның өенә Су анасы килеп кергән...

— Исәнме, Мәрданша,— диде ул искиткеч матур һәм якты тавыш белән.— Бик арыдыңмы, кадерлем?

Мәрданша аңа таба атлады.

— Исәнме, матурым! Мин сине шундый сагындым, шундый көттем. Миңа синең алтын тарагың кирәк түгел, миңа син үзең кирәк. Нишләп син юкка чыктың? Инде сине бер тапкыр гына булса да күрер өчен судларына да, җәзаларына да риза булган идем.

Су анасы да аңа таба атлады.

— Беләм, матурым, беләм, яратасың син мине... Мин дә сине өзелеп яратам бит. Мин сине күптән күзләп йөрим. Син балык тотып утырган чакларда мин сине һәрвакыт еракган күзәтә идем.

Мәрданша аның алтынсу чәчләренә кагылды.

— Чынлапмы?

— Әйе, Мәрданша, синең белән танышасым килгәнгә чыгып утырдым бит мин ярга. Мине килеп кочарсың, үбәрсең дип... Ә син башка юл белән үзеңнеке итмәкче булдың мине. Ләкин мин сиңа үпкәләмим. Мин сине өзелеп яратам, шуңа күрә сине ачулана алмыйм.

— Чибәрем, нишләп соң син мине алай бик нык яраткач, андый ямьсез гариза яздың?

— Әй, Мәрданша, минем тизрәк сине үземнең ирем итәсе килде. Сезнең законнар ул яктан бик җайлы бит. Берәрсен үзеңнең ирең итәсең килә икән — шаһитлар табасың да, гариза язасың...

— Алайса без бер-беребезне аңламаганбыз,— диде Мәрданша шатланып.— Икебез дә яхшы ният белән начар юлга басканбыз.

— Әйе шул.

— Нишләп качтың соң син?

— Әй, Мәрданша, сезнең участковыегызның да күзе төште бит миңа. Теге вакытта синең өстән ул миңа гариза яздырды да, бәйләнеп теңкәмә тиде. Мине үзенеке итмәкче булды. Үземә якын китермәгәч: «Алайса безнең елгада эзең дә булмасын! Бу минем участок!»— диде.

— Менә ничек икә-ә-ән... Ә ник шуларны судка килеп сөйләмәскә?..

Мәрданшадан читенсенеп, Су анасы башын читкә борды.

— Прокуратурада да миңа кызыгып йөрүчеләр бар шул. Мин бөтенесен үлчәп, тирән итеп уйладым да, Камага киттем. Камада, үзең беләсең, фенол... Авырый башладым. Аннан Иделгә ычкындым.

— Син хәзер Иделдә яшисең мени?

— Юк. Иделдә минем ни туганнарым, ни дусларым юк. Каспий диңгезендә яшим мин хәзер. Анда бертуган апам бар. Сине генә бик сагынам, Мәрданша!

— Кайт соң монда!

— Юк. Инде бу хәлләрдән соң кайталмыйм. Кичер... Мин сиңа килгәләп йөрермен..

Су анасының һәр әйткән сүзе өй эченә яктылык сирпеде. Йорт нигезе белән кузгалып, диңгез уртасында чайкалган кебек иде.

Мәрданша шундый рәхәт тирбәлү тойды.

Кинәт ишегалдында чыр-чу килгән бала-чага тавышы ишетелде.

— Нинди бала-чага анда?

— Синең балаларың,— диде Су анасы, серле елмаеп.— Карале, мин сиңа нинди матур Су балалары таптым.

Мәрданша тәрәзә янына барды һәм тышка карагач, чак кына авып китмәде.

— Әстәгъфирулла! Нишләп бик күп соң болар, минем өемә дә сыеп бетәрлек түгел?..

— Без, Су аналары, уылдык чәчәбез бит,— дип җавап бирде гүзәл хатын горур тавыш белән.

Мәрданша аптырашта калды.

— Матурым, ничек син миннән авырга уздың соң? Без бит синең белән бер тапкыр да... теге.. ни... нитмәдек... йокламадык?..

Су анасының тавышына үпкәләү төсе керде:

— Сез, ирләр гел шулай,— диде ул, иреннәрен турсайтып.— Яраткан
ешедән йокламыйча да авырга узып була ул... Мәхәббәтең көчле булу
ирәк. Яраткан кешең турында көне-төне уйлап йөрисең дә, корсаклы
улып куясың...

— Кызык икән,— диде Мәрданша,— бик кызык икән... Син чынлап
а мине яратасыңмы?

— Яратам!

Алар кочаклаштылар. Һәм инде йорт кына түгел, бөтен дөнья
айкала иде.

— Тарагың прокуратурада,— дип пышылдады Мәрданша.— Аны
ннан алып булмас инде.

Су анасы кинәт аның кочагыннан шуып чыкты һәм артка чигенде.

— Аһ! Ул бит минем әбиемнән калган тарак иде. Безгә, Су анала-
ына тараксыз һич ярамый. Алтын тараксыз мин Су анасы түгел бит!
Алтын тараксыз мин беркем дә түгел! Беттем мин! Үтердең син мине!

Мәрданша да өзгәләнә башлады:

— Бәгърем, гафу ит мине! Мин таракны ничек тә кире алырмын.
Мин аны сиңа кире тапшырачакмын. Ышан миңа!

Су анасы авыр сулап куйды:

— Мин бит алтын тараксыз яши алмыйм, син шуны белмәденме-
ни?..

— Белмәдем шул... Надан бит мин... Ну, син кайгырма. Тарагыңны,
ичшиксез, кайтарып бирәчәкмен. Ант итәм!

Шул вакытны гөр килеп, өйгә Су балалары тулды. Алар, чыр-чу
килеп сикерешә, уйный-шаяра башладылар. Нindидер заманча көй яң-
гырады. Су балалары Мәрданша тирәли биергә тотындылар. Аларга
Мәрданша да кушылды.

Бии торгач, ул хәлдән тайды.

Кинәт күк күкри башлады, яшен яшьнәде, Су анасы һәм балалар
юкка чыктылар.

Мәрданша, шабыр тиргә батып, уянып китте.

* * *

Күк күкрәү һәм яшен яшьнәүләр тикмәгә булмаган икән — Мәрдан-
ша күзләрен ачканда, карават янында Миңлебаев басып тора иде.

Мәрданша, йокысыннан һәм күргән төшеннән айный алмыйча, шы-
гырдый-шыгырдый, сукрана-сукрана көч-хәл белән торып утырды. Уча-
стковый аның белән янәшә урнашты һәм иреннән кочты.

— Ыслушай, Мәрди, бер идеям бар,— дип башлады ул сүзен.

Мәрданша башын чайкады:

— Юк!— Чөнки соңгы вакытта ул суд мәшәкатьләреннән һәм инс-
пекторның төрле идеяләреннән бик нык йончыган иде.

Инспектор аны тыңларга да теләмәде:

— Юк димә әле син! Тыңла иң элек. Гариза яз!

— Нинди гариза тагын?

— Тарак минеке дип яз. Балык тотканда яр буенда таптым диген.
Ике шаһит булса, эшне ерып чыгабыз. Эшне ерып чыгалсак, без аны
бүләчәкбез, шаһитларга да өлеш чыгарырбыз.

— Кирәк түгел миңа алтын,— дип мыгырдады Мәрданша.

— Дурак! Һаман шул хыялый булуыңнан арына алмыйсыңмыни
әле, пеләш тәре?

— Әйе, арыналмыйм.

— Тьфу! Шыр дивана икәнсең, валлаһи!

— Үзең яз! Минем йокым килә,— диде Мәрданша һәм, караватны
ямьсез итеп шыгырдатып, сузылып ятты.

— Тор әле, тор!— Миңлебаев аны җилтерәтеп торгызды.— Мин бит инде булачак шаһитларны да таптым. Хәзер алар монда килеп җитәләр.
— Кемнәр алар?
— Берсе синең дустың Гаделша, икенчесе — көтүче Саңгырау Нуретдин.
Мәрданша көч-хәл белән урыныннан кузгалды, бик озак чалбарын күлмәген киде.
Шул арада Гаделша да килеп керде.
— Саулармысыз!
— Уз әйдә, утыр,— диде Миңлебаев.— Онытмадыңмы нәрсә такылдарга тиеш икәнеңне?
— Онытмадым,— диде Гаделша.— Ул хәтле кабатлауга!
— Йә, кабатла әле.
— Ул сүзләрне инде мин гүрләргә кергәнче хәтеремдә саклармын. Мин әйтергә тиеш: «Әйе, балык тотканда дустым Мәрданша яр буенда алтын тарак тапты. Тарак анықы!»
— Дөрес!— диде участковый, Гаделшаның хәтере яхшы булуга чиксез куанып.— Кайда теге гыйбат?— Ул йөгереп тәрәзә янына килде.— Әнә килә, сөйрәлеп.
Курка-курка гына Саңгырау Нуретдин килеп керде һәм, исәнләшеп нитеп тормый түргә узып, урындыкка утырды да томанлы күзләрен идәнгә текәде.
Миңлебаев барып Нуретдиннең колагына кычкырды:
— Нуретдин абый! Онытмадыңмы прокуратурада ни дип әйтергә кирәклекне?
Нуретдин бик озак дәшми утырды да:
— Ә???— диде.
Тагын да катырак кычкырырга туры килде:
— Онытмадыңмы, мәйтәм, тарак турында ничек сөйләргә?
Нуретдин телгә килде:
— Юк, онытмадым. Тик менә кайсысы тапты дип әйтергә кирәклеген генә хәтерләмим — Мәрдәншамы, әллә Гаделшамы...
Миңлебаев кызып китте:
— Чукрак тәре! Дүрт сәгать буе репитиция ясадык бит инде... Мәрданша тапты, Мәрданша! Гаделша тапты дисәң, буталачакбыз... Мәрданша тапты! Аңладыңмы? Мәр-дан-ша!
— Кем?— дип кызыксынды Нуретдин.
— Мәрданша тапты!!!— дип акырды инспектор, тәрәзә пыялаларын зыңгылдатып. Аның тавышыннан хәтта түшәм ярыгыннан шыбырдап туфрак коелды.
— Аңладым,— диде көтүче, ниһаять, сакал-мыек баскан тупас чыраен сытып.— Әллә соң мине алып барып йөрмисезме? Хәтерем дә кәкәй.
Миңлебаев аның тирәсендә бөтерелә башлады:
— Юк, юк, Нуретдин абзый, алай димә... Син бит җәйләү көтүен көтәсең, ул тирәдә синнән башка кеше йөрми. Син, Нуретдин абый, давай, киреләнмә инде. Узган елны ике сыерың күбенеп үлгәнне оныттыңмыни?.. Мин сине шул ике сыер өчен подсуд җибәрә ала идем... калдырдым бит.
Тыныч кына, кычкырмыйча гына әйтелсәләр дә, Саңгырау Нуретдин бу сүзләрне ишетте.
— Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла,— дип пышылдады аның төссез иреннәре.
Миңлебаев бераз йомшара төште:
— Син, Нуретдин абый, давай, ярдәм ит инде. Онытма: Мәрданша белән Гаделша балык тотып утыралар иде, мин алар янына тәмәке сорарга бардым диген. Шунда Мәрданша миңа алтын тарак табуы турында әйтте диген. Нуретдин абый, алтын тарак безнеке булгач, валлаһи, сиңа да өлеш чыгачак.

— Ә???
— Мәйтәм, алтын тарактан сиңа да өлеш чыгачак.
— Төрмәдән өлеш чыгачакмы? — дип сорады Саңгырау Нуретдин.
— Төрмәдән түгел, алтыннан өлеш чыгачак, — дип кычкырды участковый.
Көтүче авыр сулап куйды.
Миңлебаев папкасыннан кәгазьләр алды.
— Мәрданша, кил, утыр. Гаризаны мин язган кәгазьдән күчереп яз. Әйбәтләп яз — нәкъ минемчә итеп.
Лышык-лышык борынын тартып, Мәрданша яза башлады, көтүче белән Гаделша бик яман эшкә тотынуларын сизенеп, үлле-мәлле тып-тын утырдылар...
— Ярый, дуслар, — диде Миңлебаев, ишек катына житкәч, — кайчан барырга кирәклеген хәбәр итәрмен. Әзер торыгыз, каушамагыз!
— Менә мин дә килеп эләктем бу матавыкка, — диде Гаделша милиционер чыгып киткәч.
— Бу матавыкны башлаучысы да син, — диде Мәрданша.
— Әй, Мәрди туган, гафу ит инде... Кем уйлаган менә болай килеп чыгар дип...
— Ачуланмыйм ла мин сиңа. Башымда гел икенче уйлар... Су анасын сагынам, төшләремә кереп йөдәтә.
— Әй, Мәрди, син дә бик хисле чыпчык булып чыктың. Минем бер дә бу участковый маташтырып йөргән пычрак эштә катнашасым килми.
— Мин да ничек котылу ягын табарга уйлап утырам әле. Куркам мин бу эштән.
— Мәрданша, туган, минем дә күңел тармый, миңа да андый байлык кирәк түгел.
— Әллә баш тартыйкмы?
— Юк инде, син Миңлебайны беләсең бит. Аннары гомер буе тынгылык бирмәс.
— Тынгылык бирмәс дип... Болай да аннан игелек күргән юк инде.
— Юк, Мәрди, Миңлебайга каршы килерлек көч юк инде ул бездә...
Нуретдиннең шыпырт кына өйдән чыгып киткәнен алар сизмәделәр дә. Ишегалдында аның «Иаһ-һе» дип төчкергәне ишетелгәч кенә ике дус чукрак көтүченең дә бу кәнитилгә килеп кергәнен исләренә төшерделәр.
— Нуретдин абый сөйлисе сүзләрен бутап бетермәс микән? — диде Мәрданша.
— Юк, теге күбенеп үлгән ике сыер хәтереннән чыкмаса, буталмаска тиеш, — дип җавап бирде Гаделша. — Ярый, йокла, киттем мин. Сау булып тор! Тыныч йокы!
— Йокы тыныч буламы соң инде минем...
— Ярар, ярар, бик бетеренмә әле син, кордаш.
Шулай итеп, «Алтын тарак» операциясе башланды. Аның житәкчесе — милиция капитаны Миңлебаев, ә афераны башкаручылар Мәрданша, Гаделша һәм Саңгырау Нуретдин иде.

* * *

1920 ел иде. Җырыклы авылы аша чигенүче Колчак армиясе калдыклары үтеп бара.
Нәкъ шул вакытта, чәчрәп-акырып, дөньяга Саңгырау Нуретдин килде. Туган чакта бала үзенең тууына каршы килә бугай... Шуңа акырып елый ул. Күрәсең, сизә үзе яшисе дөньяның нинди леген.
Илне коткарырга дип күтәрелгән гаскәр, өметне өзеп, көньякка — билгесезлеккә таба юл тотты. Төньяктан — Петроградтан җанны өшетерлек салкын, ачы җил исте.
Җырыклыдан Көнбатышка таба барсаң — Мәскәүгә килеп чыгасың. Ә Көнчыгышта кызыл таң атып килә иде — канлы таң! Ник кирәк

булгандыр ходайга Нуретдиннең шундый коточкыч заманда, канлы илдә һәм, ниһаять, шушы хәерче планетада тууы — белмим. Анысында минем эшем юк.

Ул туганда совит милициясенә дә өч яшь кенә иде әле.

Өч яшьлек кенә булса да, көчле иде ул. Нуретдиннең әтисен шул милиция юк итте. 1921 елгы ачлыкта бу вафасыз дөньядан әнисе дә китеп барды.

Нуретдин тырыш нәрсә булып чыкты — икенче яше белән барганда ул япь-ятим калса да, ходайның рәхмәте һәм әнисенең сеңелесе Хатимә апа ярдәме белән исән калды.

Нуретдин үзен белә-белгәннән бирле көтү көтә. Һәм үзен белә-белгәннән бирле беркемнән юньле сүз ишеткәне юк.

Аны Ватан сугышына алмадылар, ләкин сәбәбен беркем дә белми. Кемдер әйтә, ул тумыштан саңгырау иде ди, имеш, шуңа күрә солдатка ярамаган. Кемдер әйтә, юк, аның колаклары юынмаудан, колак тишекләренә пычрак тулудан гына ишетми ди. Кемдер әйтә, имеш, ул акылга бераз зәгыйфьрәк.

Әйе, җентекләбрәк күзәтсәң, барысы да бар Нуретдиндә: саңгыраулык та, шапшаклык та, бераз акыл сайлыгы да.

Ләкин аннан башка Зәй буйларын күз алдына китереп булмый. Көтүче Саңгырау Нуретдин булмаса, табигатьтә гармония-тигезлек югалып, әрәмәләрдә, Зәй буендагы мохиттә аһәңдәшлек җимерелер кебек... Аның чыбыркысы шартлап куюы, сыерларга әшәке итеп сүгенеп кычкыруы, аның резин итеге эченнән чыккан куе авыр ис, аның тәмәке төтене, аның Зәй елгасына чапор-чопыр печ итүе — болар барысы да кошлар сайравына, таллар шаулавына, су чылтыравына кушылып, бербөтен гармония тәшкил итә һәм табигатьнең һәрнәрсәсе, һәр күренеш үз урынында булуы бу очракта тагын бер мәртәбә исбатлана.

Кеше ничек бар — шулай кабул ителергә тиеш! Үзенә генә хас сыйфатлары, гадәтләре булмаса, ул Нуретдин булмас иде. Ә бу дөньяга Нуретдин кирәк. Кирәк булмаса, ул тумаган да булыр иде.

Нуретдиннең берничә ел төрмәдә утырганы бар. Сугыш вакытында булган ул хәл. Ни өчен, нинди җинаять өчен андый җәзага дучар булганын беркем дә белми, хәтта үзе дә аңламый калган.

Кемдер әйтә, Сталин турында начар сүз әйткән, ди. Үзеннән сорагач, юк, әйткәнем булмады, ди... Кемдер әйтә, Герман җиңсен иде дип теләгән, ди. Үзе әйтә, юк, алай теләгенем булмады, миңа кайсы җиңсә дә барыбер иде ди. Кемдер әйтә, сугышка бармас өчен саңгырауга сабышкан да, шуңа төрмәгә тыгып куйганнар, ди. Ә Нуретдин үзе монысы да дөрес түгел, ди.

«Ничек инде төрмәдә ни өчен утырганыңны белмәдеңмени?» — дигәч: «Каян белим мин?... Алар бит гел урысча гына сөйләштеләр», — ди.

Шулай итеп, гади генә көтүче булса да, олы гәүдәле, түгәрәк йөзле, тукмак борынлы Нуретдин шактый гына серле һәм сәер зат иде. Аның үзе шикелле үк сыңгырау карчыгы бар. Икесе дә чукрак булганга күрә алар бер-берсен аңлап яшиләр. Аларның балалары да бар. Тик дөньялар бик киңдер инде, күрәсең, — алар кайсы кая таралып беттеләр, күренмиләр.

1920 елны Нуретдиннең әтисе, гаиләсен төяп, чигенеп баручы Колчак гаскәрләренә ияреп китмәкче иде. Яңа туган бала гына аны ерак һәм авыр сәфәрдән туктатып калдырды.

Кем белә, бәлки шул вакытны китеп барган булсалар, Европага ук элэгү насыйп булыр иде. Һәм үзенең ачы итеп сүгенүе белән бөтен әрәмә җәнлекләрен өркетеп торган Саңгырау Нуретдин бүгенге көндә берәр Көнбатыш илендә танылган фермер яисә мал-туар асраучы миллионер булыр иде.

Юк шул, булмады...

Колчак гаскәре артыннан тузан гына күтәрелеп калды һәм Шүрәле каргаган төбәкнең адәми затлары, кайсы участковый булып, кайсы көтү-

че булып, кайсы тагын башка төрле хайван булып, шушы зур, пычрак һәм тынчу базда үзенә урын тапты.

Яшәп калдылар дип әйтәсем килми, чөнки яшәү — фәлсәфи һәм бөек сүз. Яшиләр дип әйтәсем килми. Ходай җан биргән икән инде — яшәлә ул... Яшәү кешедән тормый. Кеше фәкать нидер эшли генә, ул бары тик нәрсәдер кыла, кыймылдый. Яшәргә хөкем ителгәч, яшәлә инде!

1920 ел иде. Колчак гаскәренең калдыклары Көньякка таба юл тоттылар.

Шул вакытны, әлеге вакыйгалардан бихәбәр сабый — киләчәктә Саңгырау Нуретдин булып танылачы адәм баласы, бәргәләнә-бәргәләнә, шыр ярып кычкыра иде...

* * *

Нуретдин Миңлебаевның ышанычын аклады — бернәрсәне дә бутамады да, бозмады да, нәкъ алдан сөйләшенгәнчә әйтте дә бирде.

Прокуратура алтын таракны ходайдан килгән гаиб хәзинәмәсы диебрәк бәяләмәкче иде. Имеш, ул хәзер — дәүләт байлыгы.

Ләкин таракның иясе булган бит. Ул бит җирдә күмелеп ятмаган. Җайлады Миңлебаев барысын да. Процессны җиңеп чыктылар. Һәм алтын таракны Мәрданшага тапшырдылар.

Шул ук көнне аның йортында дүрт «ахири» җыелды: участок инспекторы Миңлебаев, Мәрданша, Гаделша һәм Саңгырау Нуретдин. Капканы, ишекләрне бикләделәр, тәрәзәләрне капладылар. Миңлебаев хәтта морҗаны да томаларга кушты.

— Җиңеп чыктык бит, ә...— диде участковый, караватка авып.— Молодцы! Син генә, Мәрди, ык-мык килдең... бигрәк нык каушадың. Ә менә шаһитлар үзләрен шәп тоттылар.— Ул торып утырды.— Нуретдин абый бигрәк тә маладис булды. Ха-ха-ха! Шартлатып әйтте дә бирде: «Таракны Мәрданша тапты, тарак аныкы».

Нуретдин сүзнең үзе турында барганын шәйләде һәм:

— Ә ???— диде.

— Маладис мәйтәм, син булмасаң, бу эшне җиңеп чыгалмый идек.

Нуретдин дәшмәде.

— Прокурор үзе дә кызыккан иде, ахрысы, таракка,— диде Гаделша.

— Һе, кызыкмый ни... Шуңа күрә дә бит инде ул аны хәзинә малы дип оформить итәргә маташты. Ха-ха-ха, юк шул... Закон буенча тарак Мәрданшага тиеш... Пажалысты, шаһитлар бар...— Инспектор кинәт чыраена житдилек чыгарды һәм пышылдауга күчте:— Мәрданша, Гаделша! Карагыз әле, нишләп без алтынны дүрт өлешкә бүләргә тиеш соң?!. Теге чукрактан котылырга кирәк. Ун сум житәр аңа...

Бу вакытта чукрак, суд шаукымыннан арына алмый, исәңгерәеп, котсыз калып, тып-тын гына өй почмагында утыра иде.

Мәрданша белән Гаделша дәшмәделәр.

— Ун сум житәр аңа,— дип кабатлады Миңлебаев һәм кесәләрен капшый башлады.— Ун сум... һәм бер шешә самогон житә инде аңа. Карале, минем үзем белән юк икән... Гаделша, синең юкмы?

— Юк.

— Мәрданша, бирең тор ун сум. Баедың инде хәзер барыбер.

Мәрданша шкаф тартмасыннан ун сум акча алып, инспекторга бирде. Миңлебаев акчаны һәм өстәлдә торган бер шешә көмешкәне көтүчегә тоттырды да аның колагына кычкырды:

— Нуретдин абый, хезмәтең өчен рәхмәт! Менә сиңа ярдәмең өчен... Бар кайт! Кешеләргә сөйли күрмә алтын тарак турында... Теге күбенеп үлгән ике сыер турында онытма! Бар, расчет синең белән!

Көтүче, беркемгә дә серне ачмаска ант биреп, рәхмәтләр укый-укый, акчаны чалбарының бер кесәсенә, шешәне икенчесенә урнаштырып,

ишеккә таба юнәлде. Ишек төбенә житкәч, ул тагын бер мәртәбә күкрәген тутырып:

— Рәхмәт!— диде. Чөнки былтыр ике сыер күбенеп үлгәч төрмәгә утыртмаганнары өчен ул үзен Миңлебаев алдында гына түгел, бөтен кешелек дөньясы алдында гаепле һәм бурычлы итеп саный иде. Өстәвенә, төрмәдән ул үлемгә караганда да ныграк курка иде.

Чыгып китәр алдыннан аңа ун сум, бер шешә көмешкә өстенә биш-алты папирос та бирделәр һәм бу кичне Жырыклы авылында гына түгел, бөтен районда Саңгырау Нуретдиннән дә бәхетлерәк кеше булмагандыр. Миңлебаевтан исән-сау котылу аның бәхетен бермә-бер арттырды.

Гаделшаны да өлештән мәхрүм итәргә исәбе юк түгел иде Миңлебаевның. Әмма ләкин Гаделша, биш класс белем иясе һәм берничә тапкыр Казанда булып шактый «дөнья күргән» кеше буларак, гыйлем ягыннан участок инспекторыннан калышмый һәм алдана торганнардан түгел иде. Шуңа күрә тарак өч өлешкә бүленергә тиеш булды.

Миңлебаев, кулларын угалый-угалый, әрле-бирле йөри башлады.

— Ха-ха-ха... Нишләп сезнең сөмсерегез коелды әле, ә?!. Сез хәзер таракны ничек бүлү турында уйлагыз.

Ул папкасыннан алтын таракны алды, әйләндергәләдә, бик озак сокланып карап утырды, соңыннан таракны хәтта үбеп тә алды.

— Чыннан да, ничек бүләбез соң аны, кисәбезме, сындырабызмы?— дип аваз салды Гаделша. Мәрданша тәрәзә янына барып басты да:

— Теләсә ничек бүлегез!— диде.

— Ярар, ярар, бала-чага булма!— диде Миңлебаев.— Кирелэнмә.

Гаделша да дустын тынычландырырга тырышты:

— Әйе, Мәрданша туган, бик бетеренмә инде алай. Барыбер бүтән күренмәс инде ул... Су анасын әйтәм... Кесәңә килеп кергән алтыннан баш тартма инде син.

Миңлебаевка житә калды:

— Әнә, акыллы кешедән акыллы сүз чыга. Сиңа нәрсә, алтын кирәк түгел мәллә?..

— Кирәк түгел! Кадалып китегез алтыныгыз белән!— дип ярсып кычкырды Мәрданша, кинәт борылып.

Миңлебаев тынычрак эш итәргә кирәк тапты һәм ясалма ягымлылык белән:

— Кызма әле син, Мәрданша,— диде.— Минем сиңа нинди начарлыгым тигәне бар? Оныттыңмыни, салам урлап тотылгач та җәзасыз калдырдым... Совхоз басуыннан чөгендер чәлдерүеңә дә күземне йомам... бөтен авыл урлый барыбер дип... Самогон кууыңа бөтенләй сүз әйтмим. Тынычлан! Мин сине аңлыйм, суд матавыкларыннан арыдың син. Ял ит, хәл ал...

— Бик бетеренмә, кордаш,— дип ифрат та жылы итеп өстәп куйды Гаделша.

Инспектор урыныннан кузгалды:

— Мә, таракны бик.іәп куй. Минем күрше авылга барып кайтасым бар. Иртәгә каладан инструмент алып кайтырмын, төнлә таракны аккуратно өч өлешкә кисәрбез.

Аякларын көчкә сөйрәп, Мәрданша таракны сандыкка илтеп салды.

— Арыдым мин, чынлап та...— диде ул сыкранулы тавыш белән.

— Ничего, ничего,— дип куйды Миңлебаев киерелеп.— Ярый, егетләр, киттем мин. Ызначит, иртәгә төнлә бүләбез.

Участковый артыннан ишек ябылгач, Мәрданша жан ачысы белән:

— Хайван!— дип пышылдады һәм барып караватка ауды.

Гаделша йөгереп барып караватк читенә утырды.

— Мәрданша, тынычлан, зинһар. Алтынны бүләрбез... баеп китәрбез... Жүнле кием алып киярсең, шифоньер алып жибәрерсең. Баегач, сиңа әллә нинди чибәр кызлар карый башлар әле.

Мәрданша сикереп торды да, төкереген чәчә-чәчә, кычкырырга тотынды:

— Кирәк түгел миңа башка чибәрләр! Су анасын яратам! Аның тарагын кисүгә мин риза түгел. Аның тарагын үзләштерү — минем өчен мәхәббәтемә хыянәт итү белән бер, аңладыңмы?

Соңгы сүзләрен кычкырганда ул инде дустының күлмәген түше турыннан йомарлап тоткан иде. Гыйшык мәҗнүннең калтырап торган көчле кулларыннан азат булгач, Гаделша тыныч кына сорап куйды:

— Алайса нишләмәкче буласың?..

— Минме?.. Иртәгә иртүк Зәйгә барам да, таракны суга ыргытам!

Гаделша сискәнеп китте. Аның болай да зур коңгырт күз алмалары киңәйде, башы утырып муены бөтенләй юк булды, кабарынкы иреннәре дер-дер калтырый башлады.

— Тилердеңме әллә?— диде ул, котсыз калып.

— Әйе, тилердем! Аның каравы намусым чиста килеш калачак. Алай минем җаным тынычрак булачак. Мәхәббәтем алдында да гаебем бераз кимеячәк...

— Ә Миңлебай?..

— Нәрсә Миңлебай?!.

— Миңлебай белән киңәшмичә?!.

— Төкерәм мин синең Миңлебаеңа!— диде Мәрданша, мәсхәрәле елмаю белән авызын җәеп.— Нишләп әле мин аның белән киңәшергә тиеш?..

— Алай димә. Ул — участковый... Ул сиңа моны гафу итмәячәк.

— Нишләтә ала соң ул мине? Мин аннан курыкмыйм! Мин хәзер беркемнән дә, бернәрсәдән дә курыкмыйм!

Өй эчендә бик озак вакыт тынлык хөкем сөрде.

— Теләсәң нишлә,— дип телгә килде Гаделша.— Шулай да алтынны елгага ташлау ярамас.

— Гафу ит, кордаш, бар кайт әле син.

— Ярый, киттем. Карале, миңа үпкәң юктыр бит?..

— Юк, юк, бар инде кайт.

Гаделша чыгып киткәч, Мәрданша караватына йөзтүбән капланды һәм шунда ук йокымсырап та китте. Күп тә үтмәде, саташып, берсеннән-берсе куркыныч төшләр күрә башлады.

Имеш, Су анасы килгән дә, Мәрданшаның биш-алты бөртек чәчен алтын тарак белән тарый, ә күзләрендә — нәфрәт. Шулвакыт кинәт йорт эче Су балалары белән тула: гәүдәләре Су анасыныкына охшаган, ә башлары нәкъ Мәрданшаныкы шикелле — пеләш... Балалар, ашарга сорап, илаулап еларга тотыналар. Бакча ягындагы тәрәзәдән Саңгырау Нуретдин чыбыркы сабы белән янап, ямьсез итеп ыржаеп көлеп тора. «Утыртам барыгызны да!»— ди. Шуннан соң коточкыч кыяфәтле, лайла битле, ботак-чатаклы аяк-куллы әллә нинди су җанварлары өйгә кереп тула һәм барысы да бертавыштан кычкыра башлый: «Бир таракны! Бир таракны!»

Мәрданша кара тиргә батып уянып китте һәм сикереп торып, чоланга чыкты: мискине күтәреп, салкын катык чөмерде. Кабат ул йокыга китә алмады.

«Нишләп әле мин үземә мондый зур гөнаһ алам?..— дип уйлады ул.— Нуретдин авыл кешеләренә сөйләсә... Сөйләмәсә дә инде... бик ямьсез килеп чыга бит әле бу... Нишлим мин ул алтын белән?.. Акчам, аллага шөкер, ипигә, тәмәкегә җитеп бара...»

Дөресен генә әйткәндә, Мәрданшаның Су анасына карата булган мәхәббәте элеккедән дә ныграк кайный иде. Алтын таракны ялган юл белән үзенә алуны мәхәббәткә хыянәт итүгә тиңләде ул.

Иртәнге кояш лапас түбәсенә менеп кунаклагач, Мәрданша, сандыгын ачып, сатин чалбар өстендә ялтырап яткан таракны алды да, ашыгып чыгып китте.

* * *

Матур әйбер күрсә, кеше һәрвакыт аңа якынлашырга тырыша, якынлашкач үзенеке итәргә тели. Шул матур нәрсә инде тоттым дигәндә генә кинәт ерагаеп куйса, йөрәк тагын да катырак җилкенә һәм шул гүзәл әйбер тагын да затлырак булып күренә.

Матур, гүзәл, затлы дигәннән... Мәрданша бит алтынга түгел, Су анасына кызыкты. Ул бит шул гүзәл ханымга якынаерга омтыла, үзенеке итмәк була, үзенең социализм төзи-төзи дерт-мерт тибә башлаган йөрәге белән аның йөрәген бергә кушылдырмакчы була... Хатын-кыз тәмен рәхәтләнеп татыганы булмаган кеше өчен бу халәт аеруча тетрәндергеч һәм искиткеч татлы.

Үзе кәкре аяклы, кысык күзле, «иләк» авызлы, «бәрәңге борын»лы булса да, ул гомере буе әкияти мәхәббәт турында хыялланып, чибәрлеге белән бөтен тирә-якны таң калдырырлык кыз белән уртак тормыш корырга өметләнеп йөри.

Нидән бу? Үз-үзен бик нык яратуданмы?.. Әллә үз-үзенә дөрес бәя бирә алмауданмы? Үзендә ниндидер күзгә ташланып тормаган, ләкин шулай да башкалардан үзен өстен итеп тотырдай бирәр илаһи сыйфат тоюданмы?..

Юк!!! Бу фәкать онытылып, җан-тән белән җүләрләрчә гашыйк булырга теләүдән генә.

Бәхетле кеше матур була, диләр. Дөрестән дә, төскә-биткә әллә ни булмаган сурәттә дә, андый кешедән эчке рәхәтлек тышка бәреп тора һәм шул аны күркәм итә. Бәлки, Мәрданша да, күз явын алырдай кызга өйләнгәч, бәхеттән матурланып китәрмен дип уйлыйдыр... Бәлки гүзәл хатын белән яшәп, ул да үзгәрер, чибәрләнер...

Шуңа күрә, бик гаҗәпләнергә кирәк түгелдер. Үзен Су анасына тиң ир-егет дип саный икән инде, монда бернишләп булмый... Мәхәббәт ул, Гаделша әйтмешли, «страшный нәрсә...»

Нәрсә икән ул мәхәббәт??? Инде ахырзаманга да күп калмаган, диләр, әмма ләкин әлеге сорауга җавап һаман да табылганы юк.

Мәсәлән, «Нәрсә ул кармак?» — дип сорасалар, Мәрданша чатнатып әйтеп бирер иде. «Нәрсә ул калкавыч яисә суалчан?» — дип сорасалар да, җавап бирә алыр иде. Ә «Нәрсә ул мәхәббәт?» — дигән сорауга хәтта Гаделша да башын гына кашый. «Страшный нәрсә» — һәм вәссәләм.

Анысы шулай инде, мәхәббәт бик куркыныч нәрсә... Әнә бит Мәрданшаның күзе тонган, хәтта алтынга да кызыкмый. Юкса бит таракның өчтән бер өлеше эләккәч, балда-майда гына йөзәчәк иде. Чыннан да, мәхәббәт бик страшный нәрсәдер инде, күрәсең...

Мәхәббәт хакына патшалар сугышлар игълан иткәннәр. Хатын-кызга мәхәббәт аркасында шәһәрләр җимерелгән, дәүләтләр тар-мар ителгән. Мәхәббәтне яклап кан койганнар, корбан биргәннәр, утка-суга кергәннәр.

Бәлки, бүген дә әле өзелеп ярату хакына җанын фида кылырга әзер торучылар бардыр. Бәлки, менә шушы минутта кемдер муенына кигән бау элмәген калтыранган куллары белән төзәтеп маташадыр...

Ихтимал, менә шушы минутта кайсыдыр мәҗнүне, бер уч дару кабып, чәйни башлагандыр... Бәлки, кемдер йортның тугызынчы катыннан сикереп, менә шушы мизгелдә, Җирнең тарту көченә буйсынып, башы белән атылып аска төшеп барадыр...

Дөнья бит бу! Кешеләр дөньясы бит! Сөю дигән яман чирдән бердәнбер дару, бердәнбер чара — бу дөньядан китү дип санаучылар күптер... Ләкин хатын-кыз өчен илдән илгә яу чабулар бетте инде... Чөнки бүген кеше кулында коточкыч корал бар. Хатын-кыз өчен сугыш башлап, Җирне көлгә әйләндерү ихтималы адәм баласының кулын тотып тора...

Шулай да, хатын-кыз булган җирдә асылыналар да, төрмәләргә дә утыралар, уксус та эчәләр, көндәшләренең йортларына ут төртәләр, бәреп үтерәләр, суялар...

Ләкин үлеп гашыйк булучылар арасында тагын бер хикмәтле төркем бар. Андыйлар төрен Мәрданша шикелле кешеләр тәшкил итә.

Җавапсыз мәхәббәткә дучар ителгән булса да, Мәрданша үз-үзенә кул салудан мәхрүм. Ул яна, кайный, шаша... Әмма үзенне үтерер өчен галәмәт тәвәккәллек, рухи көч кирәк.

Үз-үзеңә кул салу беркайчан да абруйлы эш дип саналмады. Шулай да бу адымны горур, батыр кешеләр генә ясый алалар. Үз гомереңне үзең туктату бәйсезлекнең, рух иреклегенең иң югары дәрәҗәсе түгелмени?!. Андый кеше — чын каһарман! Чөнки ул үзен бар иткән, үзенә Яшәү биргән Илаһи Табигатькә каршы сугыш игълан итә. Һәм бер тапкыр гына суга! Үзенә! Җиңүчеме ул, юкмы — җавап бирүе кыен.

Мәрданша андыйлардан түгел. Ул — йомшак күңелле кеше. Анарда горурлык юк. Үз-үзенә кул сала алмый ул. Ә менә сагыштан, кайгыдан аның йөрәге туктап калуы ихтимал... Ләкин андый үлем кызык түгел инде ул.

Мәрданша Су анасына бик гашыйк, ләкин шул гүзәл хатын өчен ул беркемне дә бәреп үтерә алмый, беркемнең дә өенә ут төртү аның кулыннан килми. Ә менә аның үзен тотып дөмбәсли алалар, йортын да үзе белән бергә яндырып китәргә мөмкиннәр...

Әйе, Мәрданша кебекләр гашыйк адәмнәрнең аерым бер төрен тәшкил итәләр. Бу — иң зур төркем. Асылынучыларга, дару ашаучыларга, үтерүчеләргә, ут төртүчеләргә караганда үз мәхәббәтен яклый алмаучылар күбрәктер мөгаен.

Нишлисең бит инде... Мәсәлән, шундый булуында Мәрданша үзе гаепле түгел бит... Мәрданша булуда гаепләп булмый лабаса. Үзенчә гашыйк була, үзенчә ярата, үзенчә сагышлана һәм үз хәленнән килгәнен кыла.

Туктагыз әле! Мәрданшаны көчсез кеше дип мин үземә гөнаһ алам түгелме?!. Мин аны нахакка рәнҗетә яздым бугай ла...

Әнә бит аның хәленнән нинди эш килә! — ул, җил-җил атлап, Зәйгә таба бара, алтынны суга ташламакчы була. Йә әйтегез, көчсез, рухсыз кешенең хәленнән килә торган адыммы бу?.. Юк! Җылы җанлы, чиста күңелле, көчле һәм якты мәхәббәт иясе генә сөю хакына шулкадәр алтыннан баш тартыр!

* * *

Зәй буена ул бик тиз килеп җитте. Су анасы күренмиме икән дип, як-ягына каранды.

Зәй буйларына тетрәндергеч күренешне тамаша кылырга һәм мәгънәви тирәнлеге белән Зәй суларыннан да тирәнрәк сүзләрне ишетергә насыйп булды. Мәрданша, яр читенә басты да, артист сыман киерелеп, менә мондый сүзләр әйтте:

— Нишләп мин үземә шундый зур гөнаһ алырга тиеш әле?!. Болай да бит инде бик күп яман эшләр кылдым... Салам урлау, чөгендер, кишер урлау дисеңме... Самогон куам... җитмәсә үзем шуны чөмерәм... Совхозда да юньләп эшләгәнем юк. Гаиләм юк, балалар тәрбияләмим... Адәм актыгы бит мин! Сөйгән ярымның тарагын урладым. Кабахәт бит мин! Юк! Әле соң түгел. Гафу ит мине! Тәүбәмне кабул кыл!..

Аның бу чыгышы шулкадәр хисле һәм тәэсирле булды ки, хәтта кошлар сайрамый торды, җәйләү сыерлары мөгрәмәде. Хәтта Зәй дә, туктап, акмый торды шикелле.

Үзенең чыгышы белән табигатьне таң калдыргач, Мәрданша алтын таракны суга ыргытты. Алтын, чупылдап барып төште дә, су төбенә китеп, юк булды.

Шунда Мәрданша үз күңелендә гаҗәеп җиңеллек тойды. Пычрак һәм вак тормыш ыгы-зыгысыннан бераз өскәрәк күтәрелү, чистарыну сизде. Ниндидер яман чирдән сихәтләнеп киткәндәй булды. Явыз дошманнан качып котылган кебек булды. Алай гына да түгел, бу мизгелдә ул әйтерсең лә яңадан туды.

Ул ихлас күңелдән җырлап җибәрде. Җырның сүзләре белән көе төрле җырлардан алынган иде. Шуңа карамастан, җыр матур, көчле булып яңгырады һәм Зәй сулары белән каядыр еракка акты.

— Менә шулай! — дип кычкырды Мәрданша, җыр тәмамлангач. — Барыбер яшисе килә! Барыбер дөнья матур, чукынгыры! Барыбер яшисе килә бит, ә!.. Яшисе генә түгел, яратасы да килә бит, мәхәббәтле дә буласы килә бит, зараза!

Бу вакытта Зәйнең текә яры аның өчен сәхнәгә әверелде. Һәм Мәрданша әрәмәләр каршысында гына түгел, гүяки бөтен дөнья алдында чыгыш ясый иде.

Бу минутларда Җир шары бер түгәрәк, әйләнмәле сәхнәгә әверелде һәм пеләш башлы бу диванаңың шыр ярып кычкыруын бөтен Җиһан рәхәтләнеп тыңлады.

Ниһаять, героебыз арыды һәм җиргә утырды.

Шулвакыт алагаем гәүдәсен көчкә сөйрәп, ниндидер сәер көй шыңшый-шыңшый, әрәмә эченнән Саңгырау Нуретдин килеп чыкты. Аның белән бергә таллар арасыннан юан, озын чыбыркы, таушалып беткән чүпрәк сумка, авыр ис һәм бер өер чебен безелдәп чыкты. Гомумән, Нуретдинне чыбыркысыз, сумкасыз, иссез һәм чебенсез күз алдына китереп булмый. Аларсыз ул һич тә Нуретдин булалмый. Ә мин инде бер әйткән идем: һәркем үзенчә булырга тиеш — Мәрданша — Мәрданша кебек, Нуретдин Нуретдин булырга тиеш.

— Нишләп утырасың? — дип сорады көтүче, Мәрданша янына чүгәләп.

Ә теге, яп-якты итеп елмайды да, сыерлар нәчәлниген иңеннән кочты:

— Теге алтын таракны суга ыргыттым мин.

— Нишләдең???

— Теге таракны суга ташладым дим.

— Ник?!.

— Шунда аның урыны.

— Нинди убырный?!.

— Зәйдә аның урыны, мәйтәм.

— Кемнең?

— Алтын таракның. Су анасы малын Зәйгә ыргыттым, мәйтәм.

— Участковый кушты мәллә?

— Юк, үзем...

— Ә-ә-ә, — диде Нуретдин һәм әкрен генә аягүрә басты. Аның чырасннан гына түгел, бөтен гәүдәсеннән курку аңкый иде.

Мәрданша да торып басты, рәхәтләнеп киерелеп куйды.

— Өстемнән йөк төшкәндәй булды, — диде ул, шомга баткан көтүчене дә куандырырга тырышып.

Көтүче исә Мәрданша тирәсеннән ычкыну ягын карады. Телсез, карусыз сыерлары янында аңа тынычрак һәм куркынычсызрак булыр сыман тоелды. Дөньяның матурлыгына сокланып, шул ук вакытта уйлары белән сагышлы, кайгылы, ачы һәм татлы бәхет дингезендә йөзеп, Мәрданша болганчык сулы Зәй елгасының ярында басып калды.

Шулвакытны сыерлары алдында командир кебек горур басып торган Саңгырау Нуретдин Зәйгә таба чапкан участковый мотоциклын күрде. Көтүче, тагын судларга алып бара күрмәсеннәр дип, әрәмә эченә кереп югалды.

Мотоцикл бишегендә, чүп тутырылган капчык сыман ава-түнә, Гаделша утыра иде. Мотоцикл таллык янынннан узганда Нуретдин мондый сүзләр ишетте: «Тинтәк! Хайван! Утыртам! Төрмәдә черетәм!»

Чукрак Нуретдин дә ишетерлек булгач инде, ул сүзләрнең ничегрәк әйтелгәнен чамалау кыен түгелдер. «Төрмәдә черетәм!»— дигән сүзләрне ишеткәч, хәтта сыерлар да, куркып, төрле якка дулап чаптылар.

Мәрданша да күреп алды мотоциклны.

— Килә, ерткыч,— диде ул үзалдына. Ләкин аңарда курку да, шомлану да, хәтта дулкынлану да юк иде.

Миңлебаев «тимер атыннан» сикереп төште дә, йөгереп килеп, Мәрданшаның изүеннән эләктереп алды:

— Ыргыттыңмы?

— Ыргытса?!— диде Мәрданша тыныч булырга тырышып.

— Утыртам!— дип үкерде участковый.

— Утыртып кара... Үзеңнең дә башыңнан сыйпамаслар,— дип җавап бирде Мәрданша.

Миңлебаев нишләргә белмәде.

— Кай тирәгә ыргыттың, паскуда?— диде ул, кобурасына тотынып.

Мәрданша кулларын як-якка җәйде дә, тантаналы тавыш белән:

— Зәйгә!!!— диде.

Миңлебаев кабалана-кабалана чишенә башлады.

— Чишен, эзлибез!— диде ул, кителен салып.

— Юк!— дип җавап бирде Мәрданша.— Миңа андый байлык кирәк түгел. Үзең эзлә!

Миңлебаев аны ашардай булып тешләрен шыгырдатты да, ботинкаларын салырга онытып, яр кырыена килде һәм, трусигын парашют сыман кабартып, Зәйгә чумды. Мәрданша аның артыннан суга лач итеп төкерде дә чирәмгә ятты.

Галелша, курка-курка гына, аның янына килеп утырды.

— Мин аңа әйтми булдыра алмадым инде,— диде ул, гафу үтенгән сыман.

— Тапмаса гына ярар иде,— диде Мәрданша.

— Аны агым алып киткәндер инде,— диде Галелша.— Ә бәлкем, Су анасы үзе табып алгандыр.

* * *

Яр астында Миңлебаевның сүгенүе һәм су шаулавы ишетелде. Әрәмә эченнән, өрәк сыман, Нуретдин пәйда булды.

Участковыйның алтын таракны бата-чума эзләвен өч дус ярга ятып, рәхәтләнеп тамаша кылдылар.

Миңлебаев чумган саен алар аның инде бүтән калкып чыкмавын теләделәр. Ләкин кансыз инспектор калка да чыга... һәм үзәкләрне өзеп сүгенә дә янә чума.

Менә ул тагын калкып чыкты. Кулында ниндидер тимер торба кисәге. Ул яр буйлап үрмәли башлады.

Өч дус, котлары очып, торып бастылар. Миңлебаевның кыяфәтен тасвирлап бирер өчен кәгазь белән каләм генә җитмәс. Диңгезләрдә дә, океаннарда да мондый куркыныч, ямьсез җанвар яшәмидер... Шушы кадәр яман ерткыч коры җирдә генә тереклек итәдер мөгаен.

Миңлебаев ярга менеп басты һәм артка таба чигенеп баручы авылдашларга кинәт елмайды. Милиционер чыраена елмаю килешмәсә дә, дусларга бераз җан керде.

Инспектор, ике кулы белән торба кисәген кысып, гаҗәп ягымлы һәм тыныч тавыш белән «дусларына» мөрәҗәгать итте:

— Мөхтәрәм милләттәшләрем! Әле сез исәнмени?.. Сезләрне каһәр сукмадымени әле?.. Йә ходаем... ничек Җир йотмый үзегезне?!

Әлбәттә, Мәрданша да, Нуретдин дә, Галелша да бу сорауга җавап бирә алмады. Каян белсеннәр алар ник Җир йотмаганын... Алар һаман да әкрен генә чигенделәр. Миңлебаев аларга таба атлады һәм йомшак, итагатьле тавыш белән дәвам итте:

— Кадерле кан кардәшләрем! Мәгълүм ки, мине Аллаһе Тәгалә участковый итеп яраткан. Белеп торыгыз: мин бөтен Җир шарының участковые булырга хыялланам.

Миңлебаевның тавышында ягымлылык һәм иплелек юкка чыкты, дусларның котлары да калмады. Чөнки участковыйның кыяфәте җүләр кешенеке сыман иде.

Ә инде трусиктан гына басып торучы участковый:

— Җир шары минем участок булгач, иншалла, планетадагы бөтен тараклар минеке булачак!— дип кычкыргач, шик калмады — Миңлебаев акылдан язган иде.

Иң беренче булып Гаделша әрәмә арасында юк булды. Аның артыннан Мәрданша очты. Ә Нуретдин ике-өч атлауда әрәмәлекнең теге ягында иде инде.

Миңлебаев, нишләптер, аларны куып мәшәкатьләнмәде, бары тик:

— Сезгә бер тарак та бирмим, сволочьлар!— дип кенә кычкырды. Аннан соң өстәп куйды — Утыртам барыгызны да!

Шуннан соң ул тагын, йөгереп барып, елгага чумды. Инде шактый гына су эчеп күбенеп бетсә дә, ул ду китереп Зәй төбен айкавын дәвам итте.

Хәлдән тайгач, тагын үрмәләп ярга менде дә, һавада очкан саесканга: «Утыртам!»— дип кычкырды һәм лып итеп утырды. Ул бер елады, бер шаркылдап көлде. Үзе нәрсәгәдер, кемгәдер, бармак янады. Сикереп торып трусигын салды. Мәрданшалар йөгереп киткән якка шәрә артын туңкайтты. Һәм, тагын алҗып, чирәмгә ауды.

Шулвакытны елгадан Су анасы килеп чыкты һәм, тирә-якка якты сибеп, тал төбенә урнашты.

Миңлебаев куаклар арасыннан аңа таба үрмәләде.

Су анасының кулында алтын тарак ялтырады. «Алтын тарак!»— дип шашынып пышылдады участковый.

Ул озак уйлап тормады, сикереп торды, йөгереп барды һәм Су анасының кулыннан таракны йолкып алды. Су анасы өнсез калып, катып торганда Миңлебаев инде киемнәре янында иде. Ул, киемнәрен тиз генә эләктерде дә, мотоциклына барып атланды.

Ниһаять, Су анасы да һушына килде һәм участковыйны куа чыкты:

— Качма! Качма! Тукта! Тукта, и карак!
Ник аласың син аны, ул бит минем алтын тарак!

Мотоцикл тавышы ишетелде, Су анасы зәңгәр төтен эчендә елап калды. Шуннан ул елгага таба китте һәм суда юк булды.

Ләкин тарак Миңлебаевта түгел иде. Киемнәрен ашык-пошык җыйганда ул аны ялгыш төшереп калдырды. Чирәм арасында яткан тарагын Су анасы да абайламады, теге бәндә алып китте дип уйлады.

Күпмедер вакыт үткәч, әлеге дә баягы Саңгырау Нуретдин таллар арасыннан сөйрәлеп килеп чыкты. Ул, гадәттәгечә, шикләнеп, як-ягына каранып куйды. Шуннан соң, башын аска иеп, үзалдына мыгырданамыгырдана, яр буйлап йөри башлады.

— Их, тартасы килә... Әлегрәк бу тирәдә балыкчылардан калган тәмәке төпчекләре була торгание... Тәмәке кыйммәтләнгәч, төпчек табуы да кыенлашты, авызыңны шулай итим...

Шунда ул ялтырап яткан алтын таракка юлыкты.— Әстәгъфирулла... Әстәгъфирулла... Тарак?! Бу теге... тарак түгелме соң?..

Аптырагач, ул өнеме-төшеме икәнлекне белер өчен, каты итеп чыбыркысын шартлатып куйды. Нуретдин өнендә иде. Ул таракны җәһәт кенә фуфайкысының кесәсенә тыкты да, авылга таба элдерде.

* * *

Мәрданша өендә, тиргә батып, карлыган вареньесын зур-зур кабып, чәй эчеп утыра иде. Атылып Гаделша килеп керде.

— Мәрди! Ишеттеңме, Миңлебайны ашыгыч ярдәм машинасы белән алып киткәннәр...— дип кычкырды ул килеп керүгә.

— Аны бит «скорый» белән түгел, рәшәткәле «воронок» белән алып китәргә тиешләр,— дип җавап бирде Мәрданша.— Ни булган соң аңа, авырып киткәнмени?

— Акылдан язган!

— Ә ?!.

— Җүләрләнгән. Зәй төбен айкый торгач, полный ычкынган.

— Соң инде, ул элек тә акыллы түгел иде бугай,— диде Мәрданша тыныч кына.

Гаделша ашыгып дәвам итте:

— Үз авылында, башына милиция фуражкасын киеп, култык астына папкасын кыстырып, өйдән өйгә йөргән. Һәр кешедән тарагын күрсәтүне таләп итә икән... Таракларны җентекләп тикшерә ди... тешләп карый ди... Безнең авылга да килмәкче булган.

— Ник килмәде икән?

— Җитешмәгән. Алып киткәннәр. Тракторчы Габдулла шулар авылына тракторы белән самогонга барган иде, шул кайтып сөйләде. Миңлебай өйдән өйгә йөргән ди... Хатыны, елап, артыннан ияреп йөргән, нишләдең син, дип. Миңлебай хатынына әйтә икән: «Төнлә минем янга бер шәрә хатын килергә тиеш... көнләшмәссең микән?» Алай дигәч, моның хатыны аның җүләрләнгәнен чамалаган да, скорый чакырткан. Көчкә бөкләп тыкканнар машинага. Габдулла үзе күргән...

— Алып киткәннәрме?

— Алып китми нишләсеннәр инде.

Ишек ачылды. Авызын алтылы галош кадәре җәеп, Мәрданшаның болай да шыксыз өенә тагын да төкселек өстәп, Җырыклының Халык Көтүчесе, Зәй буйларының атказанган мал-туар эшлеклесе, сыер көтү фәннәре докторы, сазлыклы әрәмәләрнең төсе һәм яме Саңгырау Нуретдин килеп керде.

Аның исәнләшә торган гадәте юк. Бу юлы да ул бер сүз дәшмичә керде дә куеныннан алтын таракны чыгарып өстәлгә куйды. Мәрданша белән Гаделша икесе дә берьюлы сикереп тордылар һәм бертавыштан:

— Та-ра-а-ак?!.— диделәр.

Нуретдин тагын да киңрәк елмайды. Тешләре булмаганлыктан аның авыз түреннән кызарып, кече теле күренеп тора иде.

— Тарак?!.— диде Мәрданша тагын бер тапкыр.

— Каян алдың?— дип кычкырды Гаделша.

— Сез балык тота торган урында таптым. Шунда, ярдан ерак түгел ята иде.

Мәрданша әле алтынга, әле Нуретдингә, әле Гаделшага карады.

— Гаҗәп... Мин бит аны суга аткан идем. Миңлебай тапкан булган микән әллә? Алай дисәң, нишләп соң ул аны ярда ташлап калдырган?..

— Кеше күрмәдеме?— диде Гаделша.

— Нигә күрмәдеңме?— дип сорады Нуретдин.

— Кеше күрмәдеме?

— Ә-ә-ә, юк, юк.

Кинәт Мәрданшаны корт чаккандай булды.

— Туктале, туктале... Миңлебай хәләл җефетенә: «Бер шәрә хатын килергә тиеш...»— дигәнме?.. Гаделша! Әллә Су анасын күргән микән ул?..

— Әй, акылдан язган бәндә ни сөйләмәс. Нуретдин абый! Анда алай-болай Су анасы күренмәдеме?

— Нәрсә күңелләме?

— Күңелләмә димим... Су анасын күрмәдеңме дим.

— Ә-ә-ә... Юк. Күрсәм дә танымыйм бит мин аны, бер тапкыр да күргәнем юк.

Мәрданша өй буйлап тыз-быз йөри башлады.

— Гаделша туган! Күңелем сизә, валлаһи, Су анасы Зәйдә! Сизә бит күңелем, кайткан ул, кайткан!

Шулай диде дә Мәрданша, таракны эләктереп, чыгып йөгерде.

* * *

Яр буйлап бик озак киләп сарып йөрде ул. Тик Су анасы күренмәде. Мондый пычрак сулы елгада, андый шапшакланган табигатьтә затлы нәрсә яши аладыр дип ышанырлык түгел иде.

Әрәмәләрнең сулышын буып, химкомбинаттан куе төтен килеп сарыла. Шәһәр чүплегеннән килгән ачы ис дөньяда әкият барлыгын, матурлык барлыгын оныттыра.

Бик озак йөгереп йөрде Мәрданша Зәй буенда. Кычкырып та карады. Ләкин аңа беркем дә җавап бирмәде.

Озак эзләде, озак көтте. Җирдә әле әкият барлыгын тагын бер кат исбатлап, табигатьнең бер сихри яктылыгы булып, Су анасы килеп чыгар төсле иде. Юк, килеп чыкмады.

Мәрданшаны курку басты. Аның башы әйләнеп китте, тез буыннары калтырый башлады.

Ул йөзтүбән капланды һәм онытылырга тырышты.

Күкрәк тирәсендә әллә йөрәк тибә... әллә өмет сулкылдый иде...

## Икенче кисәк

* * *

Зәй сулары ага торды, еллар үтә торды...

Дөньялар әллә нишләп китте — җитмеш ел киеп йөргән соры күлмәк бөтен җөйләреннән шытырдады. Имеш, дөрес юл белән бармаганбыз. Имеш, бар нәрсәне үзгәртеп корырга кирәк.

Илдәге үзгәрешләрнең җиле Җырыклы тирәсендә дә исеп куйды. Авыл халкы «үзгәртеп кору» дигән нәрсәне хуплады. Бу яңарышка һәркем булдыра алганча өлеш кертергә тиеш иде. Һәркем үзенчә өлеш кертә башлады.

Фәһимә апа сыерын, торгынлык елларындагы шикелле, уң яктан түгел, сул яктан сава башлады. Һәм сөткә суны түгел, суга сөтне куша башлады.

Агроном Фәхри кар тоту киртәләрен усактан түгел, каеннан ясарга тәкъдим итте.

Идарәдә бухгалтер Хәнифнең бүлмәсенә экономист Саимәне утырттылар, ә Саимә бүлмәсенә — Хәнифне.

Мал врачы Сабир сыерларга СПИДка каршы укол кадый башлады.

Шигырьләр язучы Нурислам да бик нык үзгәрде. Элегрәк ул шигъри дәрт өчен илһам эзләп елга буйларына чыга иде һәм, рифма тапмагач, пилорамнан такта урлап алып кайта иде. Хәзер инде, киресенчә, такта урлап кайта да утырып шигырь яза.

Партком секретаре Якуп күзгә күренеп үзгәрде. Капкасын башка төскә буятты. Аның чырае да элеккеге төсле, светофор сыман кып-кызыл түгел, бераз аксылланды.

Иң нык үзгәрүче клуб мөдире Камил булды. Беркөнне ул асылынып үлде. Клуб өстендә җилфердәп торган «Коммунистлар партиясенә

дан!» — дигән лозунгны кубарып ташлаулары аның яшәвен мәгънәсез иткән, диделәр.

Кишер басуын каравыллаучы Сәхәбетдингә дә үзгәрергә куштылар. «Ниемне үзгәртим инде мин?..— диде ул, аптырап.— Кишерне элек тә урлыйлар иде, хәзер дә урлыйлар. Алайса мин болай итәрмен: элек, урласыннар дип, күземне йома идем... Хәзер инде йомып тормыйм — урласыннар...»

Бик нык үзгәрде авыл. Беркемне, бернәрсәне санга сукмый башладылар.

Шулвакытны төрмәдән кайткан Шиһап иң абруйлы кешегә әйләнде. Чөнки сөйләшкәндә ул әллә нинди куркыныч, аңлашылмый торган сүзләр кыстыра. Ул сүзләрне инглиз теле укытучысы Гөлмәрьям апа да аңламый. Авыл советы рәисенең сарыгын урлап утырганга күрә, Шиһап үзен «палитический» дип саный һәм бүгенге көнгә кадәр реабилитация таләп итә.

Торгынлык чорында юк ителгән басу капкасы урынына яңа капка төзеп куйдылар. Аны ачканда митинг булды. Теге вакытта капканы җимерүчеләрне каргап, сукранып йөргән Хәлимә әбине митингта күтәреп алдылар. Җимерүчеләр аңа: «Бар әле, карт тәре, йөрмә монда саруны кайнатып!» — дип кычкырган булганнар. Шуңа күрә Хәлимә әби торгынлык чорында җимерек капкасын төзәтеп бирергә вәгъдә иттеләр. Хәлимә әби: «Алай озак яшәмәм шул мин...» — дигәч: «Ярар алайса, бер дә кайгырма, шул материалдан каберең өстенә бик матур рәшәткә ясап куярбыз»,— диделәр.

Авыл уртасында мәчет төзеп куйдылар. Ленин һәйкәле белән янәшә... Ленин манарага караганда биегрәк. Читтән караганда, Азанны Ленин әйтәдер шикелле.

Сыер савучы Тәслимә бик каты үзгәрде — Коммунистлар партиясеннән чыкты. Һәм фермага үзәк урамнан түгел, аръяктан йөри башлады. Чөнки авыл уртасында басып торучы Лениннан ояла икән.

Авылда тәртип болай да юк иде, өстәвенә үзгәртеп кору дигән нәрсә килеп чыкты... Беркем бернәрсәдән курыкмый башлады. Төрмәдән кайткан Шиһаптан гына бераз шүрлиләр. Ул үзе дә үзгәреп кайтты — аркасына мәчет, күкрәгенә чиркәү рәсемнәре ясаткан.

Үзгәреш җиле шулкадәр көчле исте ки, хәтта хуҗасыз калган клуб җимерелеп төште.

Яңарыш рухын тоеп, мал-туар, кош-корт күзгә күренеп үзгәрә башлады. Хәтта әтәчләр дә, кан буталмасын дип булса кирәк, күрше тавыкларын басмый башладылар.

* * *

Сыерлар арасында да гаҗәеп хәл булып алды. Гайнекамал әбинең сыеры бик ябыкты. Сөте дә кимеде, онлы башакны да теләр-теләмәс кенә чемченде, үгезләргә дә күз салмый башлады.

Гайнекамал әби яулык почмагы белән күз яшьләрен сөртеп, газиз малкаена ходайдан мәрхәмәт сорады, ә көтүче исә башка сыерлардан читкә тайпылып йөрүче бу җан иясен чыбыркысы белән ешрак «сыйлады».

Ләкин бу мәхлук күзле алла колының күңелендә ниләр кайнаганын Гайнекамал әби дә, көтүче үзе дә белмәде һәм беркайчан белмәячәкләр...

Карап торуга гап-гади булган бу имезүче хайванның соңгы вакытта үзаңы ачылып китте, яшәү сулышы белән сулаган иркен болынлы һәм җан өзгеч чыбыркылы дөньяга мөнәсәбәте үзгәрде.

«Нишләп әле мин шушы якты Җиһанда гел бертөрле сукмаклардан, һаман да бер болынга гына йөрергә тиеш?..— дип уйлады ул.— Нишләп әле йөзләгән сыерлар белән бер надан, шапшак һәм залим көтүче хакимлек итә? Җан иясе иркенлектә яшәргә тиеш!!!»

...Чалт иткән кояшлы көн иде. Сыерлар, шактый гына талчыгып, ял итәргә яттылар. Көтүче, учак ягып, чәй кайната. Менә, чәй эчкәч, ул да ятты һәм, «Урал» мотоциклы тавышы чыгарып, гырлый башлады.

Гайнекамал әбинең сыеры сикереп торды, ботны тешләргә чамалап йөргән кигәвенне койрык белән сугып төшерде һәм, танавын җәеп, мөгрәп алды да, кояш чыккан якка карап, тиз-тиз атлап китеп барды.

Азатлык турында башка сыерлар да хыялланганнар икән. Көтү, дәррәү кузгалып, кансыз көтүчене һәм туйдырып бетергән болынны ташлап ирекка чыгып китте.

...Ләкин сыерлар ireклектән файдалана белмәделәр. Мөмкинлек тә юк иде... Басу-кырларда йөрергә ярамый... Урманнан да урман каравылчысы куып чыгара... Бакчаларга якын килергә дә ярамый... Теге ярамый, бу ярамый...

Сыерлар аптырадылар: дөнья шулкадәр киң, якты... Шул ук вакытта тар, тынчу, рәхимсез...

Әй, иреклек, әй азатлык! Нинди татлы да, ачы да син!.. Нишләргә соң синең белән, азатлык?..

Моны сыерлар аңламадылар. Гайнекамал әбинең сыеры иң беренчеләрдән булып азатлык кирәклеген аңласа да, кай тарафларга юл тотарга, ничек яшәргә икәнлеген аңламады. Чөнки бу дөнья бик тә катлаулы иде.

Аптырагач, сыерлар дулап карадылар. Туйдырды дулау да...

Кичкә таба сәер иркенлек сыерларны шомландырды һәм алар теге залим көтүчене сагына башладылар.

Абзар әсирлегенә караганда ирек торкынлыгы куркынычрак булып тоелды, чөнки алар билгесезлек кочагында иде.

Шуңа күрә, көтүченең сүгенә-сүгенә кычкыруын һәм үзәккә үтә торган чыбыркы шартлатуын ишеткәч, Гайнекамал әбинең сыеры тынычланыбрак китте.

Азатлык, ирек дигән булып, кая барырга белмичә аптырап, нишләргә яраганын, нишләргә рөхсәт ителмәгәнен аңламыйча, сине урап алган шомлы билгесезлектән һәм үзеңнең ярдәмсезлегеңнән чирканып, киләчәктән котың алынып яшәүдә ни мәгънә бар?

...Якында гына чыбыркы шартлады. Чыбыркы тавышыннан да зәһәррәк булып сүгенү сүзе һаваны ярып җибәрде.

Сыер көтүе болынга таба атлады.

* * *

Халык гаҗәпләнде: «Һәммәбез үзгәртеп коруга өлеш кертте... нишләп соң үзгәреш сизелми?!.»

Беркөнне телевизордан: «...Үзгәртеп коруны киңәйтергә һәм тирәнәйтергә кирәк!» — диделәр. Бу эштә дә һәркем үзенә вазифа табарга тиеш, диелде.

Сүз тыңлаучан халык моны да хуплады.

Җырыклы авылында үзгәртеп коруны киңәйттеләр һәм тирәнәйттеләр.

Илгә яңадан капитализм килә икән, дигәч, партком секретарен тотып кыйнадылар. Дүрт сугышта, өч революциядә катнашкан, ике тапкыр раскулачивать ителгән, унбиш ел төрмәдә утырган Гарифҗан бабай кыйнаш белән җитәкчелек итте. Карт булуына карамастан, ул бик нык тырышты. Кыйный торгач, аның үзенең дә хәле бетте. Кичкә таба район хастаханәсенә партком секретарен һәм Гарифҗан бабайны ашыгыч ярдәм машинасы белән алып киттеләр — икесе дә авыр хәлдә иде.

Гарифҗан бабай әле машинада барганда да, актык көч-хәлен җыеп, партком секретареның касыгына терсәге белән бәрде — дошманлык шулкадәр көчле иде. Гарифҗан дошманының йә иңбашын, йә колагын

тешләргә ниятләп, башын бормакчы булды, ләкин баш борылмады. Чөнки партком секретарен кыйнаганда бабайның муены каймыккан иде. Башы борылмаганны тойгач, Гарифҗан, ачуыннан, аһын җуйды.

Коммунизм булмаячак, дигәч, аклар ягында сугышкан Һадиулла, урманда качып яткан урыныннан чыгып, үрмәләп авылга кайтты. Аның кайтканын ишеткәч, кызыллар ягында сугышкан Садри бабай базга төшеп качты.

Алтмыш ел буена юньле ашау күрмәгән колхоз мал-туарына күп итеп азык бирделәр. Мескен хайваннарның күбесе күбенеп, җан тәслим кылды.

Ленинның авыл уртасындагы һәйкәлен төшергәч, аны кая куярга белмәделәр. Аптырагач, аны, кибет янына йөзтүбән яткырып куйдылар. Һәм ул авыл ирләренә тәмәке көйрәтеп, гәпләшеп утырырга бик җайлы утыргыч булып чыкты.

Җир өләшә башладылар. Әмма беркемнең дә эшлисе килмәде... «Коммунистлар эшләсен!» — диде халык.

Шулай да ачлык килгәнен сизенгәч, халык кыймылдый башлады. Халык эшкә тотынган иде, шомлы хәбәр килде: коммунизмны төзеп бетерергә карар кылганнар, ди... Җитте, демократия озаккарак сузылды, дип әйтеп әйткәннәр, ди... Бу хәбәрне Сажидә карчык кала базарының идәнен себерүче хатынның полиэтилен капчык белән сыра тоткан бер исереккә сөйләгәнен ишетеп, түкми-чәчми авылга алып кайткан иде.

Җырыклы авылын шом басты.

1991 елның август көннәрендә, Сажидә карчыкның информациясен раслап, Мәскәүдә хәрби хунта башланды. ГКЧП дигән оешма влачны үзенең кулына алган, имеш...

Авылның коты алынды.

Шул ук көнне базда качып яткан кызылармеец Садри якты дөньяга чыкты һәм кулына сәнәк алды. Аның баздан чыгуын ишеткәч, аклар ягында сугышкан Һадиулла карт кире урманга ычкынды. Тик ул ярты гасыр буе качып яткан землянкада бер кеше бар иде инде. Ул — шушы тирәдәге бер совхозның партком секретаре иде. Халык хөкеменнән куркып качып ятуы иде аның. Һадиулла карт аны: «Бар кайт, тагын сезнең заман килде»,— дип куандырды. Партком секретаре шатлыгыннан, сыйнфый көрәш турында да онытып, Һадиулла бабайны лач-лоч үпте дә: «Ашарыңа җибәреп торырмын, алла боерса»,— дип вәгъдә биреп, авылына йөгерде.

Җырыклыда юлбашчы һәйкәлен торгыза алмый интектеләр. Маташа торгач, торгызып куйдылар куюын, тик, гөнаһ шомлыгына каршы, аударганда аның бер бармагы кителгән булган икән. Халык куркудан өнсез калды.

«Моның өчен безне коммунистлар, авылыбыз белән алып чыгып, үләт базында атып үтерәчәкләр»,— диде Җырыклыга зоотехник булып килеп, тарих укытып йөрүче Фәрит Иванович.

Колхоз мал-туарын нык ашатканга бик үкенделәр.

«Күбенеп үлгән мал-туар өчен безне үләт базыннан торгызып, икенче мәртәбә атачаклар»,— диде Фәрит Иванович.

Авыл кайгыга батты.

Ярар, шулаен шулай да... Тик менә, хастаханәдә ятучы партком секретаре, авылның бәхетсезлегенә, исән-имин килеш кайтып төшсә — бетте баш! Аны бит бөтен авыл кыйнады. «Аның өчен безне өченче мәртәбә атачаклар!» — диде зоотехник һәм тарих укытучысы Фәрит Иванович.

Бу вакытта район хастаханәсендә сугыш дәвам итте. Дүрт сугыш, өч революция ветераны, ике раскулачивание һәм унбиш ел төрмәне татыган Гарифҗан бабай Җырыклының партком секретаре белән бер хастаханәдә ятуны үзенә карата мәсхәрә дип кабул итте һәм дошманын үтерергә төрле юллар эзләде. Бабайны башка дәвалану йортына күчерделәр. Ул аннан партком секретарена: «Барыбер үтерәм!» — дип хат язды.

Социализм белән капитализм арасында аптырап калган авыл халкы Гарифҗан картның кайтуын зарыгып көтте. Ул исән-сау әйләнеп кайтса, хәлләр мөшкел түгел дигән сүз... Әгәр дә аны кулга алып төрмәгә ябып куймыйлар икән, димәк, илдә террор юк.

Гарифҗан карт кайтты. Берничә көн үтүгә, партком секретаре да авылда күренде. Аларның икесенең дә исән-имин кайтуы авылны тәмам исәңгерәйтте.

«Кем кулында соң влач?» — дигән сорауга җавапны зоология белән тарихны буташтырып, адашып беткән Фәрит Иванович та таба алмады.

Кемдер эчтән генә яңадан партком секретаренең хуҗа булуын теләде (алай, бәлки, тынычрак булыр дип)...

Ә кемдер, бигрәк тә урманнарда качып йөрүче Һадиулла, Гарифҗанның тизрәк муены төзәлеп, яңадан сугыш башлавын ходайдан сорады.

* * *

ГКЧП халыкка мөрәҗәгать белән чыккан көнне Җырыклының элеккеге участковые пенсиядәге милиция капитаны Миңлебаев җүләрләр йортыннан качты.

Менә ун ел буе инде ул өч-дүрт айга бер тапкыр дәваланып чыга. Бу юлысы ул чираттагы дәвалануын өзәргә мәҗбүр булды, чөнки влач алышынырга тора. Миңлебаевлар влачы яңадан килергә тора! Мондый вакытта психушкада уколлар кадатып ятып буламени?!.

...Аны автовокзалда санитарлар куып тоттылар һәм, кул-аякларын бәйләп, «скорый»га тыктылар да кире алып киттеләр. Миңлебаев бер санитарның кулын тешләде, икенчесенең эченә башы белән бәрде, өченчесенең битенә лачт иттереп төкерде.

Нәтиҗәдә, санитарлар юлда барганда машинаның идәнендә утын агачы сыман дырылдап яткан психны бераз типкәләп алдылар. Миңлебаев аларны: «Бериягә язам!» — дип куркытты. Санитарларның берсе: «Ул бит инде күптән үлде», — дигәч, ул: «Юк, исән ул! Берияләр алар үлми!» — дип кычкырды.

Носилкада чайкалып хастаханә ишегеннән кергәндә Миңлебаев: «Яшәсен ГКЧП!» — дип акырды.

Миңлебаев дәвалану курсын алып чыга да көннәр буе өендә телевизор карап утыра. Алтын тарак исенә төшкәч, Зәй буена йөгерә. Ун елдан артык инде менә шулай дәвам итә.

Пенсиядә булса да, аннан һаман да куркалар. Җырыклыга барып, ул Мәрданшадан, Гаделшадан һәм Нуретдиннән сорау ала. Дуслар аңардан участковый булып йөргән вакытында да бу кадәр курыкмыйлар иде. «Алтын таракны кая куйдыгыз?» — дип йөдәтә. Халык арасында да алтын тарак турында төрле имеш-мимешләр йөри башлады.

Миңлебаевтан соң «юньле» участковыйның булганы юк. Берничә ай эшлиләр дә юкка чыгалар. Ун ел эчендә егермеләп инспектор алышынгандыр. Кайсы эчкечегә әйләнә, кайсы үзе төрмәгә эләгә, кайсы асылына... Югыйсә, юньле участковый булса, алтын тарак белән кызыксынмый калмас иде һәм аны, һичшиксез, табар иде.

Шулай итеп, Миңлебаев майор булалмады. Акылына килгән вакытларда ул кычкырып җылый, язмышыннан ачынып, үзенең бәхетсезлегенә рәнҗеп җылый. Җылап туйгач Зәйгә чаба, алтын тарак табылмагач, Җырыклыга барып, Мәрданшалардан сорау ала. Аннары, һәр йортка кереп тарак сорый башлагач, каладан ашыгыч ярдәм машинасы чакырталар да мескенне тагын дәваланырга озаталар.

Үзен дәвалаучы психотерапевтка ул төрмә белән яный, укол кадаучы шәфкать туташларына да әллә нинди статьялар вәгъдә итә.

Мәскәүдәге хәрби фетнә уңышсыз тәмамланган, ГКЧП кулга алынган, дигән хәбәрне ишеткәч, Миңлебаевның котыруы чиктән ашты. Аны

өч укол белән генә тыйдылар, шуннан соң ул мәлҗерәдә һәм, йокылы-уяулы булып, тып-тын гына караватында ятты.

Палатада тагын биш псих ята иде: тарих укытучысы, район гәҗитендә эшләүче шагыйрь, элеккеге партия шәһәр комитеты инструкторы, мунча директоры һәм яшелчә базасы нәчәлниге.

Миңлебаевтан кала, бишесенең дә акыллары зәгыйфьләнүенең сәбәбе — илдәге үзгәрешләр иде.

Өч укол Миңлебаевны караватка ябыштырып ук куйды.

Мунча директоры, яшелчә базасы нәчәлниге саташа-саташа йоклыйлар, шагыйрь тумбочка өстендә, авыр сулап, нидер язып утыра, ара-тирә кычкырып көлеп куя. Элеккеге инструктор нindидер монсыз көй шыңшып, идәндә утыра.

Тарих укытучысы бөтенләй үк җүләр түгел, дәвалана торгач, инде үз акылына кайта башлаган иде. Ул Миңлебаевны кызганып куйды һәм аның янына барып утырды.

— Йокла, туганым! — диде тарих укытучысы, аның юрганын әйбәтләп ябып.— Мин сиңа хәзер әкият сөйләрмен.

Ул көйли-көйли сөйли башлады.

Миңлебаев күзләрен йомып, мәмрәп, рәхәтләнеп тыңлады. Бу әкият шулкадәр кызык булды, хәтта шигырьләр яза торгач исәнгерәгән шагыйрь дә язуыннан туктап, хикәяткә колак салды. Шәһәр комитеты инструкторы җырлаудан туктады, идәндә утырган килеш укытучының сөйләгәнен игътибар белән зиһенենә сеңдерә барды. Мунча директоры белән яшелчә базасы нәчәлниге дә уянып, тыңлап яттылар.

## Тарих укытучысының җүләрләр йортында Миңлебаевка сөйләгән әкияте.

Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, үрдәк урятник, илдә генсек хуҗа булып торган вакытта Яңа елны каршылаулар гел башкача булган, ди. Ел буе шыр исерек булып йөргән халыкның Яңа елны каршылаганда аракы эчкәне түпчим чырайга да чыкмаган, имеш. Дөрестерме-юктырмы, авызыннан аракы исе килмәгән кешене урамда эләктереп, «тегендә» яба торган булганнар. Аек кеше шикле вә чирле булып саналган, ди.

Бервакыт, Җирнең алтыдан бер өлешендә яшәп ятучы адәмнәрне ятим итеп, әкият башында телгә алынган генсек, бер сандык чамасы орден-медальләрен беркемгә васыять итми-нитми генә бу дөньядан китеп барган.

Бераздан халык айныган һәм... шаккаткан: ашарга беткән икән ләбаса!.. Азык-төлек запасының кай тирәгә яшереп куелганын да әйтергә өлгерми мәрхүм булган генсекка халыкның шундый нык ачуы килгән, ди. Аны, ныклап телгә ала-ала сүккәннәр, имеш. Ләкин күп еллар буе исереппирәшләнеп, аңгы-миңге йөргән күпмилләтле чуар халык генсекның яхшымы-начармы икәнлеген төгәл хәтерләмәгән. Кемдер әйткән: «Әйбәт кеше иде... түше тутырык медаль, кибет тулы кәнфит иде...» Кайберәүләр: «Бөтен яхшы кешеләрне куып бетерде дә, илдә без генә калдык...» — дигән. Өченчеләре: «Аның караvы, аякка кияргә оекбаш, эчәргә әдикалүн бар иде...» — дип кычкырган. Кыскасы, аны яманларгамы, мактаргамы — белмәгәннәр.

Еллар үткән... 1991 ел да килеп җиткән. Бу яңа елдан халык бик курыккан, ди. Һәм дә куркулар тикмәгә генә булмаган. Чөнки халыкка җир өләшә башлаганнар, ә кешеләрнең эшлиселәре килмәгән. Кайберләре исә җирне эшкәртеп, мул уңыш алгач, тагын раскулачивать итмәгәйләре дип курыккан.

Тора-бара өлеге дә баягы генсекны халык зарыгып сагына башлаган, ди. Хәтта аның сугышта Герой булганлыгына да ышанырга әзер икән-

нәр. Чөнки халык инде ялан аякка тишек ботинка киеп, кибет киштәләре янында эленке-салынкы йөргән сатучы хатыннарга кызыгып карый башлаган. Тик ул сатучы хатыннар ир-атны хатын-кыз буларак түгел, бәлки ит буларак кызыксындыра башлаганнар. Шуңа күрә алдарак кузгатылган легендар генсекны бигрәк тә сатучылар ык сагынган.

Әмма үзе үлгәч каты хурлауга, әдәпсез көлүгә дучар ителгән, ярты дистәләп Герой йолдызлары кавалеры совет халкына шундый үпкәләгән ки, хәтта кешеләр бер-берсен «ашый» башлагач та теге дөньядан моныбына кире кайтмаган. Кайту гына түгел, ике аягының берсен дә атламаган.

Бу вакытта инде хатын-кызлар бала табарга курка башлаганнар. Халык үрчергә теләми икән.

Курил утрауларын бирергә вәгъдә итеп, японнардан бихисап күп теге ни... «саклагыч» алып кайтканнар. Кооператорлар, бүген-иртәгә төрмәгә утырмагайлары дип, балаларын ятим калдырудан куркып үрчемәскә булганнар, гади халык — ярлылыктан шундый нәтиҗәгә килгән. Ә депутатларның бала табу өстендә эшләргә вакытлары калмаган. Бала табу йортларында иң кыю, оптимист хатыннар гына калган.

Аның каравы, халык ирекле, демократияле шартларда яшәгән. Кешене аз гына булса да йөгәнләп торган ике төшенчә — Намус һәм Закон — бөтенләй онытылган.

Телисең икән, төнлә чыгып берәрсен талыйсың — сиңа суд та юк, кем әйтмешли, чурт та юк. Дәртең бар икән, тотып берәрсен кычкыртакычкырта көчлисең дә качасың — сине эзләп тә мәшәкатьләнмәячәкләр.

Азатлык кешеләрне шулкадәр канатландырган, хәтта үзләренең ач икәнлекләрен дә онытып, эротика һәм секс белән бик нык кызыксына башлаганнар. Гәҗит-журналларның беренче битләре җитди сәяси, милли һәм гуманлык темалары белән тулы булса, калган битләрендә йә шәрә хатын сурәте, йә гомосексуалистлар тормышыннан күренешләр басылган. Милләтне саклап калырга өндәгән тетрәндергеч мәкаләләрне укыганнан соң ук шәрә хатынның арт санын карап утырулар бик тә рәхәт булган, ди. Халык моңа бик куанган.

Тагын әллә нинди, әллә нинди кызык хәлләр булган бу илдә.

Диниләр белән алласызлар бик нык дуслашканнар. Заманында мәчетләрне җимереп йөргән кешеләр материалист-атеистларның һәйкәлләрен җимерә башлаганнар. Поплар, муллалар митингларда коммунистлар белән кочаклашып торган. Моны күреп халык тагын да катырак сөенгән, ди. Мондый күренешләрдән мөкиббән китеп торган адәмнәр урамнарга үкереп чыккан танкларны күрми калган. Тора-бара хәрби машиналарга ияләшкәннәр һәм, акча түләп, аларга такси урынына утырып йөри башлаганнар.

Үзара талашырга, сугышырга өйрәнеп беткән халык, телевизор каршында утырып, депутатларның сугышканын бик яратып тамаша кылган. Тиздән һәрбер кеше депутат булырга әзерләнеп җиткән. Чөнки һәрбер кеше акыл ягыннан да, талашу сәләте буенча да телевизордан күрсәтелә торган депутатлардан калышмаган.

Үзәк урамнарда протест йөзеннән ачлык игълан итүчеләр күбәеп киткән. Ләкин, бөтен ил ач булу сәбәпле, алардан бары тик көлгәннәр генә.

Үзен-үзе яндыручыларны да сүндереп маташмаганнар, депутатлыкка бер кандидат кими, дип сөенгәннәр генә.

Алда әйтелгән генсек тарафыннан Көнбатышка куылган язучылар кире Көнчыгышка кайтканнар, ди. Ә мондагы язучылар, теге вакытта чит илгә китмәгәнгә оялып, кайсы кая качып беткән. Аларның исән икәнлекләрен ел саен бер үк әсәрләр белән чыга торган китапларны күреп кенә белеп булган.

Язучылар бик нык үзгәргән. Чистарыну вакыты җиткән, ди. Партияләреннән чыгуны качу дип түгел, протест дип атаганнар, ди. Аларның

язулары да үзгәргән, хәтта кыйблалары да алышынган. Аларның кыйбласы элегрәк Мәскәү ягында булган, аннары Мәккә якларына күчкән.

Шундый тиз үзгәрү сәләтенә ия язучылары булганга, халык үзен бик тә бәхетле итеп санаган. Шуңа күрә язучыларга тагын да зуррак өметләр баглаганнар, ди. Илдә әллә нинди үзгәрешләр булган сәрәттә дә ике көн эчендә шул үзгәрешләргә яраклашырдай язучылары булган милләт үзенең киләчәгенә ышанып караган. Мөгаен, шунадыр инде, теге яки бу язучының дөньяда барлыгын белеп торсыннар өчен, бөтен кеше күрсен дип, кибетләрдәге китапларны сатып алмаганнар һәм дә ул әсәрләр, тузан эчеп, шундый-шундый язучы барлыгын исбатлап, милләтнең абруен күтәреп, киштәләрдә яткан да яткан, ди.

Әмма язучыларда бер теләк һич тә үзгәрмәгән: тарихта калу нияте. Күрәсең, бу хыял-ният бик көчле буладыр — алар барысы да Мәңгелекнең кочагында кала барганнар, тик менә халык күңеленә генә бик азлары күчкән. Кайбер язучылар моны вакытында сизеп алганнар һәм, каләмнәренә генә ышанып җитмичә, трибуналарга чыгып кычкырганнар, биек урыннарга менеп утырырга омтылганнар.

Шулай итеп, яңа артистлар хасил булган.

Илдә барган пәрдәсез трагикомедиядә һәрбер рольне уйнарга актер табылган. Тик аның ни режиссеры, ни дирежеры булмаган.

Бу тамаша озак дәвам иткән. Хәзер инде теге генсекны гына түгел, «халыклар атасын» да сагына башлаганнар. Ләкин ул, астрологлар әйтүе буенча, «Кайтмыйм!» — дип әйтеп әйткән ди. «Кайтмас шул... бигрәк каты орынып ташладык бит мәрхүмгә»,— дигән халык.

Шулай да озакламый илдә: «Халыклар атасын» күргәннәр, кайткан икән...» — дигән хәбәр ишетелеп куйган. Бу хәбәргә ышанучылар күп булган, чөнки «юлбашчы»ның кире кайтырлык көче барлыгы халыкның хәтерендә әле сакланган.

Халык тагын үзгәрешләр көтә башлаган.

Соңрак нинди хәлләр булганын сөйләмим — анысы инде башка хикәят. Болай да күбрәк сөйләп ташладым бугай инде. Ахыры хәерле булсын...

...Әкият тиләләрнең һәрберсенә үзенчәлекле тәэсир ясады.

Горком инструкторы, шырык-шырык көлеп, идәндә аунады.

Мунча директоры юрган астына качты.

Яшелчә базасы нәчәлнигe карават астына кереп китте һәм аның тын алганы-сулаганы да ишетелми башлады.

Шагыйрь авызын ямьсез итеп җәеп, акырып елап җибәрде.

Миңлебаев үзен-үзе белештермичә, бәргәләнә башлады.

Нәтиҗәдә, биш авыру өстәмә икешәр әлеш укол кабул иттеләр. Ә тарих укытучысына, куркыныч нәрсәләр сөйләгәне өчен, баш врач дүртне кадарга кушты.

Биш минуттан биш авыру шып булды, палатада кабер тынлыгы урнашты.

* * *

Җырыклы авылында партком секретаре һәм тәҗрибәле участковый милициясе булмау алай зыян китермәде. Халык эшлисе эшен эшләде, урлауны, эчүне, сугышуны һаман элеккечә дәвам итте.

Мәрданша үзгәрмәде дип әйтү бөтенләй үк дөрес булмастыр. Ул бик нык ябыкты, картая төште.

Халисә бик еш килгәләп, өйләрен җыештырып, ашарына пешереп, керләрен юып торса да, ул үзенә җан тынгылыгы тапмады һәм сагыш диңгезендә чайкалуын дәвам итте.

Мәрданша җәен дә, кышын да, көн аралаш диярлек, Зәй буена йөри, Су анасын эзли. Ләкин Су анасы күренми дә күренми. Алтын таракны

Зәйгә илтеп ташларга да исәбе юк түгел аның. Тик менә шул тарак инде ун ел буена югалган Су анасы белән Мәрданша арасында нindидер бер элемтә сыман нәрсәне хәтерләтеп тора. Таракны елгага ташласа — инде мәхәббәтенең соңгы төсеннән колак кагар кебек тоела иде аңа. Шуңа күрә тарак, чүпрәккә төрелеп, баз төбендә ятты да ятты.

Мәрданшаның мәхәббәте, кем әйтмешли, сүнмәде дә сүрелмәде дә.

«Үзгәреш чоры», «яңа чор», «демократияле заман», киресенчә, аңа яңа бәла, яңа кайгы өстәде. Аның тагын бер куркынычы, дошманы артты. Соңгы вакытта аңа рэкетирлар тынгылык бирми башладылар.

Рэкет! Коточкыч сүз! Коточкыч кешеләр!

Һәр заманның җаннарны өшетерлек яңа куркыныч сүзләре була. Һәр яңа чор яңа куркыныч сүзләр уйлап чыгара. «Инквизиция», «опричнина», «жандарм», «каторга», «эшафот», «халык дошманы», «раскулачивание», «ГПУ», «НКВД», «ЧК», «милиция», «КГБ», «рэкет»...

Рэкетчылар — большевикларның оныклары. Киемнәре дә күннән тегелгән, кешеләрне талау һәм юк итү ысуллары да нәкъ большевикларча. Әшәкелек буенча оныклар бабаларыннан һич тә калышмыйлар.

Коммунист Миңлебаев талап алырга өлгермәгән алтын таракны конфискацияләү эшен большевикларның оныклары — рэкетчылар дәвам итте.

Мәрданшаның өендәге бәрәңге базында алтын яшереп куелганын рэкетчылар ничек белгәннәр? Монда бернинди табышмак юк — рэкетчылар район прокуратурасы мафиясеннән иде.

Үзгәртеп кору томаны арасында прокуратурада да үзгәрешләр булган кебек тоелды, шул ук вакытта анда яңа сәер, шикле кешеләр дә тулды. Һәм инде, әлбәттә, яңа килгән юристларның күзенә алтын тарак турындагы мәгълүматлар чагылмый калмады.

Күп тә үтмәде, Җырыклыга рэкетчылар «экспедициясе» әзерләнә башлады.

Эчке эшләр органнарында, прокуратураларда җинаятьчеләр хакимлек иткәндә, җинаятьчеләр тантана итеп йөргән илдә, шушындый болганчык заманда алтын хәтле алтынның нindидер бер пеләш Мәрданша базында ятуы белән килешәләрме соң инде?!

...Рэкетчылар өчәү һәм өчесе дә җинаятьчеләр иде. Алтын таракны Мәрданшадан талап алган очракта өчесенә дә күптән түгел кылган авыр җинаятьләре гафу ителәчәк иде.

Һәм алар әзерләнә башладылар.

Иң элек Мәрданша турында мәгълүматлар җыйдылар, холкы, гадәтләре белән кызыксындылар, тәрҗемәи хәлен белештеләр. Берничә мәртәбә Җырыклыга, бәрәңге сатып алырга дигән булып, «разведка»га да барып кайттылар.

* * *

Беркөнне төн урталарында Мәрданша тәрәзә шакылдаган тавышка уянып китте. «Халисәдер инде тагын...» — дигән уй белән ул, иренеп кенә, барып тәрәзәдән карады.

Кышкы төн яктысында затлы тунга төренгән һәм башына шулай ук зиннәтле бүрек кигән бер хатын-кыз басып тора иде. Аның төс-битен чамаларлык түгел иде, чөнки тунның күтәрелгән якасы аның йөзен бөтенләй диярлек күрсәтми иде.

Мәрданша, әлбәттә, каушады, чөнки Халисә түгел иде бу...

Йорт хуҗасының тәрәзәдән карап торуын абайлап, хатын аны кул ишарәсе белән тышка чакырды.

Мәрданша тиз генә чалбарын киде, шәрә тәне өстенә тунын элде, ялан аякларын киез итекләр эченә тыкты да, башына киярга онытып, өйдән чыкты.

Теге хатын аны ишегалдында каршы алды.
— Исәнме, Мәрданша! — диде ул тун якасы эченнән тонык кына тавыш белән.
— Исәнмесез! — дип җавап бирде Мәрданша, сәерсенеп. — Сез кем буласыз?
— Су анасы!
Гыйнвар ае булуга карамастан, Мәрданшага эссе булып китте.
— Су анасы?!.
— Әйе, Су анасы.
— Әйдә өйгә керик...— диде Мәрданша, нишләргә белмичә.
— Юк, кереп тормыйм,— диде хатын кырыс кына.
— Ник кермисең?..
— Бир таракны!
Мәрданша тезләнде. Ниһаять! Кавыштылар!
Хәйран күңелле күренеш иде бу. Ап-ак кар өстендә Ай нуры җемелди. Күктә йолдызлар, кабына-сүнә уйнаклыйлар. Тып-тын. Йөрәк кенә тынлыкны ярып дөпелди. Ишегалды уртасында чибәр хатын басып тора. Аның каршына берәү тезләнгән. Пеләш башыннан пар күтәрелә.
— Чибәрем! — дип кычкырды Мәрданша.— Мин сине шундый көттем. Мин сине шундый сагындым! Миңа синең алтын тарагың кирәк түгел, миңа син үзең кирәк! Тарагың исән, мин аны базга төшереп яшереп куйдым. Миңа алтын кирәк түгел... Мин сине яратам!
— Яратсаң, бир тарагымны!
— Кер, әйдә, өйгә... җылынырсың... Мин бит сине бик көттем. Синнән башка бик авыр бит миңа.
— Тарагымны алып чыгып бир башта...— диде хатын усал тавыш белән.
Мәрданша сикереп торды.
— Алып чыгам тарагыңны. Беркая да китми тор...
Ул, йөгереп барып, капканы бикләде һәм хатын тирәли бөтерелә башлады:
— Ник өйгә кермисең? Куркасыңмы әллә?.. Курыкма, тимим мин сиңа... Яратам мин сине. Кер өемә!
— Башка вакытта керермен,— диде хатын коры гына.
Мәрданша нишләргә дә белмәде. Әй, мәхәббәт, үтерәсең бит инде! Вакытсыз гүрләргә кертәсең бит, мәхәббәт!
Мәрданша, нишләгәнен дә аңламыйча, бер тезләнде, бер сикереп торды.
— Өйгә кер инде,— диде ул, тагын бер тапкыр өзгәләнеп.
Хатынның тавышы бу юлысы ягымлырак булып ишетелде:
— Мәрданша, кадерлем, мин иртәгә иркенләп килермен... Мин синдә бик озак кунак булырмын... Бәлки әле бөтенләйгә — синең белән яшәргә дә калып куярмын.
Мәрданша ышанды.
— Ярар,— диде ул һәм өйгә атылып кереп китте.
Баз авызын ачты һәм кинәт бер уй аның башына китереп типте: «Су анасымы соң ул? Ә бәлки берәр авантюристкадыр?»
Кинәт аның хәле бетте. Ул әкрен генә тәрәзә янына килде, ишегалдына карады. Хатын ишегалдында арлы-бирле йөренә иде. Аның йөреше дә, буй-сыны да матур түгел иде. «Юк, Су анасы түгел бу! — дип уйлады Мәрданша.— Мин Су анасының тавышын бик яхшы хәтерлим. Теге вакытта ярга чыгып утыргач, ул бик матур итеп җырлаган иде, аның тавышы чишмәдәй саф һәм чылтырап тора иде». Аннары... ул бит аның йөзен дә төсмерли. Ә бу хатын никтер битен тун якасы белән капларга тырыша. Нишләп ул иртәгә иркенләп килермен, ди?.. Бәлки бөтенләйгә килермен дигән була... Алай булгач, нишләп бүген өйгә кереп чыгудан да баш тарта?..
Нишләргә???

Мәрданша шулай да, таракны алып, әкрен генә ишегалдына чыкты. Хатын аны түземсезлек белән көтә иде, ул хәтта үзе дә тиз-тиз Мәрданшага таба атлады. Мәрданша аның битен күрергә тырышты һәм таракны тун кесәсеннән чыгарырга ашыкмады.

— Кая, алып чыктыңмы тарагымны?

— Кер инде өйгә,— диде Мәрданша, әле өметен тәмам җуймыйча.— Сөйләшәсе сүзләр бик күп ләбаса. Минем сиңа әйтер сүзләрем бихисап күп.

— Юк, юк, Мәрданша, башка вакытта, яме... Бир таракны.

«Юк. Су анасы түгел бу,— дип уйлады Мәрданша.— Су анасы мондый булмый...»

Эчке сиземләү белән аңлады ул — аның мәхәббәте түгел бу. Бу — ят, чит хатын. Яхшы ният белән килмәгән, нindидер кара эш кылырга килгән.

— Син Су анасы түгел,— диде Мәрданша, нигәдер үзен гаепле сыман тоеп.— Син ялганлыйсың.

— Ничек инде, ялгынлыйм?! Син ни сөйлисең?!

— Мин бит Су анасын таныйм. Ун ел эчендә шулай нык үзгәреп була мени?!.

— Нишләп булмасын...

— Юк, Су анасы түгел син...

— Бир тарагымны яхшы чакта. Югыйсә мин сине подсуд җибәрәм.

— Ни өчен? Гашыйк булып, мәхәббәт тәмугында янып йөргәнем өченме?..

— Карак син!

— Әйе, карак мин. Карак булмаган кеше бармы соң бу дөньяда?

— Син, әйдә, философия чәйнәп торма... дөньяда... Бир минем алтын тарагымны!

— Бирмим! — диде Мәрданша, башын иеп.— Ул синең тарак түгел, ул — Су анасыныкы.

— Менә бит инде, Су анасы синең каршыңда басып тора,— дип ысылдады хатын.

— Син Су анасы түгел!

Хатын каушый башлады. Көчсезлеген сизгән кеше (бигрәк тә хатын-кыз) агрессиягә күчә башлый. Монда да шул күренеш чагылды.

— Минме Су анасы түгел? — дип кычкырды хатын. Аның кычкыруыннан авыл этләре өрә башлады.— Ярар, күрсәтермен әле мин сиңа, Су анасымы мин, юкмы... Су анасымы мин, юкмы...

Мәрданша капканы ачты. Хатын, җил-җил атлап, карны шыгырдатып, авыл башына китте. Мәрданша аңламый калды: әллә кар шыгырдады, әллә төнге кунакның аяклары аның болай да әрнегән күңелен таптап, бәгырьләрне шытырдатып үтте.

Аякларын көчкә сөйрәп, ул өйгә керде һәм әле яңа гына булып узган вакыйганы башында эшкәртә алмыйча изаланып утырды.

Бу вакытта авыл башыннан җиңел машина кузгалды. Машинада өч рэкетчы һәм аларның ярдәмчесе «Су анасы» утыра иде.

Шулай итеп, рэкетчыларның беренче операцияләре уңышсыз тәмамланды. Хәер, уңышсыз дип әйтү бигүк дөрес тә булмас инде, чөнки бүгенге «экспедиция» — әле эшнең башы гына, чиркәнчек алу гына иде. Бу беренче тәҗрибә Мәрданшаны «тере килеш бераз капшап карау» өчен кирәк иде...

* * *

Шул төннән соң Мәрданша курка башлады.

Заманасы да бик болганчык, мәхәббәт һәм сагыш утында янып нервылары да какшады, күңел дә нindидер бәла киләсен сизә дә сизә генә бит.

Ул һаман да әле ферма каравылчысы булып эшли иде. Атнасына бер-ике тапкыр барып, ферма янындагы агач будкада йоклап кайту — аның бөтен шөгыле шул иде.

Беркөнне, каравылда чакта, ферма тирәсендә кемдер йөргән кебек тоелды. Кемдер будканы күзәтеп йөргәндәй булды. Будка эчендә кызып утырган тимер мичтән эссе бәреп торуга карамастан, Мәрданша төн буе дер-дер калтырап утырды.

Таң беленгәч, ул өенә йөгерде.

Йорт янына җиткәч, ни күрсен... Капка шар ачык. Мәрданша ишегалдына атылды. Өй йозагын каерып ачканнар!

...Өйнең асты өскә килгән иде. Урыныннан кузгалмаган әйбер калмаган.

Базны да ачык килеш калдырганнар.

Барысы да аңлашылды. Каравылда чакта аның өен тентегәннәр, алтын таракны эзләгәннәр. Алай-болай Мәрданша өенә төнлә кайта калса, хәбәр бирер өчен, ферма янында күзәтчеләре дә йөргән...

Аның башы әйләнеп китте. Таракны тапканнардыр инде!.. Алып киткәннәрдер. Аның эчтән бугазы буыла башлады. Тамак төбендә йодрык хәтле төер хасил булды, күз аллары караңгыланды һәм шул караңгылыкта сап-сары бөҗәкләр, кызыл тараканнар йөгерешә башлады.

Хараплар булды! Урлатты сөйгәненең тарагын!

Ул базга сикереп төште дә шырпы сызды.

Бәрәңгене актарып бетергәннәр. Ашыга-ашыга тарак яшерелгән почмакны бәрәңгедән арындыра башлады. Эш тизрәк барсын өчен җәһәт кенә шәм алып төшеп кабызды, аны баз бурасының ярыгына кыстырды.

Бәрәңгене бер якка өя торгач, ниһаять, сайгак күренде. Калтыранган куллары белән баз идәненең тактасын кузгатты, кулын аска тыкты.

Кинәт тынчу базга Кояш кергәндәй булды. Дөньялар яктырды. Мәрданшага җан керде — тарак урынында иде!

Полиэтилен капчыкка төренеп, баз идәненең чери башлаган сайгагы астында алтын тарак, беркемгә комачауламыйча, тып-тын гына ята иде.

Тапмаганнар! Базны айкап бетергәннәр. Бура бүрәнәләренең араларын да чөшкенләп сыдырып бетергәннәр. Әлбәттә бәрәңге астындагы идәнне дә капшап караганнар... Ә менә шул идәннең астын каезларга әллә башлары, әллә вакытлары җитмәгән, рәхмәт яугыры...

Мәрданша, баз тутырып, шаркылдап көләргә тотынды. Таракны күкрәгенә кысты, җырлап җибәрде. Аның җырының, гадәттәгечә, сүзләре бер җырдан, ә көе икенче җырдан иде. Озак җырламады ул — әллә нервы киеренкелеге кимүдән, әллә үзенең моңлы итеп җырлавыннан кинәт күңеле тулды һәм ихлас күңелдән җылап җибәрде.

— Мәрданша!

Бу — Гаделша тавышы иде. Мәрданша сикереп торды, пычрак куллары белән битендәге күз яшьләрен сыпырды.

— Мәрданша! — Баз авызында, өстән, Гаделшаның агарынган һәм шөбһәле чырае күренде. — Ни булды синең йортта?

Астан, шулай ук баз авызында, Мәрданшаның шешенеп, юешләнеп, пычранып беткән башы күренде.

— Нәрсә булганын аңламыйсыңмыни? — диде ул сулкылдап.

— Елама әле... Җегет кеше бит син... Нишлисең анда? Чык баздан.

— Чыкмыйм.

— Базда каласыңмыни?

— Калам.

— Һәй, Мәрданша. Шушындый якты дөньядан качып, базда ятмассың инде.

— Нәрсә дидең?! Якты дөнья?!. Кайсы дөньяны якты дип әйткән буласың син? — Баз төбеннән Мәрданшаның нәфрәт чәчрәп торган күзләре елтырашты. — Син якты дигән кабәхәт дөньяга чыкканчы, караңгы базда ятуың лутчырак...

— Тынычлан әле, Мәрданша... Чык әле. Җүләр сатып утырма анда!
— Нишләп утырмаска! — диде Мәрданша киреләнеп.— Ул «якты дөнья»да нинди рәхәт күрәбез соң без синең белән?.. Аның яктылыгыннан миңа, мәсәлән, ни файда?
— Чык, туган, чык,— диде Гаделша, дустын кызганып.— Шәменне сүндерергә онытма.— Һәм Мәрдаршага кулын сузды.
Мәрданша «якты дөнья»га чыгарга булды.
— Караклар кергән,— диде ул, баздан чыккач.— Күрәсеңме, өйне актарып бетергәннәр.
— Күрәм.
— Таракны табалмаганнар.
— Тапкан булсалар, синең өчен яхшырак булмас иде микән?..
— Тагын нәрсә сөйлисең инде?!
— Соң, Мәрди, алар сиңа барыбер тынгылык бирмәячәкләр... Әллә биреп котыласыңмы?..
— Нәрсәне биреп?..
— Нәрсәне дип... Таракны бир шул бандитларга... кадалып китсеннәр.
— Юк, Гаделша, бирмим. Үлсәм үләм, әмма ләкин Су анасының милкен беркемгә дә бирмим.
— Үзең кара инде алайса... Минем сүзне тыңла син...
— Синең сүзне тыңлаганга шушы хәлгә калдым да инде мин...
— Ничек инде?!.
— Ничек дип тора бит әле... Таракны урларга кем котыртты соң мине? Син түгелме?
— Шулайрак булды шул, Мәрди туган... Кем уйлаган болай килеп чыгар дип... Карале, теге төнлә килгән хатын тәки шул бандитларның разведчигы булып чыкты бит, ә... Мин сиңа әйттем бит башта ук.
— Мин үзем дә сизеп алган идем инде аны... Ярый әле таракны бирмәдем. Башта мин, каушап, таракны алып чыккан идем бит...
— Тарактан котылсаң, бәлки төрле бәла-казалардан да котылыр идең.
— Тик кенә утыр, Гаделша!
— Ярар, ярар, үзеңә кара.
— Нишләргә икән?
— Дурак син, Мәрди? Әнә теге вакытта таракны бүлгән булсак, череп баер идек, Миңлебай да бәлки җүләрләнмәгән булыр иде, чит кешеләр дә белми калырлар иде...
Мәрданша бик озак башын чайкап торды:
— Юк, Гаделша, мин бу таракны беркемгә дә бирмәячәкмен, мин аны Су анасының үзенә кире кайтарачакмын.
Гаделша баз капкачын шапылдатып япты да, куркыныч төштән айный алмаган кыяфәт белән утыручы кордашы янына килеп басты.
— Карале, Мәрди, син җүләрләнә башламадың микән, ә?
— Ник алай дисең?
— Соң инде... Үзең уйлап кара... Инде күпме вакыт үтте бит... Көннәр түгел, еллар үтте бит... Ул Су анасы дигәнең әллә исән, әллә юк, дигәндәй...
Мәрданша сикереп торды:
— Җитте! Дәшмә! Исән ул! Бар ул! Мин аны барыбер очратачакмын!
Гаделша кул селтәде:
— Миңлебай янына кереп ятып, бераз дәвалансаң әйбәт булыр иде кәнишне... Ун ел вакыт узды бит инде... Су җанварлары озак яшәмиләр бит алар...
Мәрданша сикереп торды да дустын буа башлады.
— Җиттеме сиңа, кабәхәт! Исән ул, исән! Мин аны барыбер очратачакмын.

Бу сүзләрдән соң ул Гаделшаның бугазын җибәрде һәм, хәлсезләнеп, идәнгә ауды.

Гаделша, гафу үтенә-үтенә, ягымлы сүзләр әйтә-әйтә, ахирәтен караватка сөйрәп яткырды.

...Халисә килде. Аңа нилар булганын сөйләмәделәр. Халисә тарак хакында хәбәрдар булса да, бу турыда ул Мәрданшадан бер авыз сүз ишеткәне юк иде. Һәм ишетәсе дә килмәде.

— Ни булды? — дип сорады Халисә.

— Гаделша белән сугыштык,— дип җавап бирде Мәрданша.— Юк кына, пүчтәк нәрсәдән эләгешеп киттек.

Халисә өйләрне җыештырды, ике дусны татулаштырды, аларга бәрәңге пешереп ашатты.

Шулай итеп, өйгә тагын җан керде һәм иминлек урнашты.

...Әйе, йозакны ватып, өйне тентү — рэкетчыларның икенче адымнары булды. Монысы да әле аның уен-шаяру кебек кенә иде.

Гаделшаның Мәрданшага сөйләгәне бар рэкет турында. Бик куркыныч нәрсә икән ул... Үз максатларына ирешер өчен алар өйләргә ут төртәләр икән. Көчләү, үтерү, кайнар үтүк белән корсакны пешерү, тырнак астына энә кадау, кешегә бензин сибеп ут төртү кебек ысулларны бик еш кулланалар икән алар. Шуңа күрә Гаделша: «Рэкетчылар тынгылык бирмәячәкләр сиңа»,— дигәч, аның йөрәге чалбар балагында тибә башлады.

Әмма аңы белән курыкса да, аң астында галәмәт көчле импульс саклана иде. Бу импульс чын-чынлап гашыйк булган кешеләргә генә хас, диләр. Кирәк чакта шул импульс, инстинктив рәвештә, үзеннән-үзе эшкә җигелә һәм кешегә искиткеч дәрман бирә икән. Гади аңга гына сыймый торган шул халәт сихри көч, батырлык бирә. Ул кеше, нәтиҗәдә, утка да суга да керергә әзер була. Һәм ул керә дә...

Юк! Бирмәячәк ул сөйгәненең төсе булып сакланган алтын таракны бернинди рэкетчыга! Миңлебайга бирмәгәнне, ниндидер килмешәкләргә бирәме соң инде?!.

* * *

Рэкетчыларның өченче адымы хатлар язудан гыйбарәт иде.

Иң элек матур гына итеп, итагатьле төстә, алтын таракның яртысын өлешен сорап хат килде. Бу хатны алгач, Мәрданша таракны Гаделшаларда яшермәкче булды. Тик ахири дусты курыкты — өйгә ут төртмәгәйләре дип.

Икенче хаттан янау, куркыту бөркелеп тора иде. Фәлән сәгатьтә, фәлән урында очрашыйк, дип язылган иде монысында. Таракны да үзең белән алып кил, диелгән иде.

Мәрданша фәлән сәгатьтә фәлән урынга да бармады, җавап хаты да язып тормады.

Икенче хатны алып укыгач, ул киез итегенең эченә олтырак кисеп салды, таракны шуның астына кыстырды һәм йоклаганда да итеген салмый башлады.

Өченче хатта Мәрданшага мондый җәзалар вәгъдә ителә иде:

1. Өенә ут төртү.
2. Атып үтерү.
3. Мотопила белән урталай кисеп ташлау.
4. Пеләш башын кисеп алып футбол уйнау.
5. Өстенә бензин сибеп ут төртү.

Әлбәттә, бу җәзалар бер кешегә генә күбрәк... Шуңа күрә Мәрданша сугышка әзерләнә башлады.

Ит кисә торган пычакны әйбәтләп кайрады, балтаны үткенләде, кувалданы яңадан саплады. Шушы өч коралны караватт астына урнаштырды.

Ләкин гел-гел өйдә генә утырып та булмый шул.

Беркөнне ул төнлә зур хаҗәтен башкарырга дип чыккан иде.

Тик изге эшен башкарырга өлгерми калды. Аның өстенә арттан сикерделәр, кулларын каерып бәйләделәр, авызына төзүчеләр кия торган брезент бияләй тыктылар. Шуннан соң аны өенә сөйрәп алып керделәр.

Мәрдәнша тыпырчынды, мөгрәде... Аның гомерендәге иң коточкыч, иң кабатланмас мизгелләр бер-бер артлы тезелделәр.

Капканы һәм ишекләрне эчтән бикләделәр. Рэкетчылар өчесе дә маскадан иде. Берсе озын буйлы, икесе аннан тәбәнәгрәк таза, тыгыз бәдәнле егетләр иде.

Мәрданшаны урындыкка утырттылар, авызыннан бияләйне йолкып чыгардылар.

Озын гәүдәлесе:

— Бир таракны, козел! — диде.

Бу вакытта Мәрданша шушы вәхши дөньяга кәҗә тәкәсе булып тумаганына үкенеп куйды.

— Тарак юк миндә,— диде ул, рэкетчының куркыныч кыяфәтен күрмәс өчен башын читкә борып.— Прокуратурага илтеп тапшырдым мин аны.

Рэкетчыларның шул прокуратурадагы берничә кеше белән бергә эш итүләрен, аларның бер үк мафиядән икәнлекләрен Мәрданша кайлардан белсен?!.

— Ялганлыйсың,— диде таза бәдәнлеләрнең берсе, Мәрданшага якын килеп.— Бир таракны! Чмо!

Әгәр дә кинәт могҗиза булып, табан астындагы алтын тарак эреп юкка чыкса, Мәрданша бу участковыйлы, рэкетлы, социализмлы-капитализмлы, колхозлы, үзгәртеп корулы, базар мөнәсәбәтле төксе дөньядан җан тынычлыгы белән китеп барыр иде.

Кинәт ул курыкмый башлады. Кыйнасыннар, үтерсеннәр. Тик итек эчендәге таракны гына сизә күрмәсеннәр...

— Тарак прокуратурада,— дип кабатлады ул тыныч кына.

— Алдыйсың, чухан! — дип җикерде өченче бандит һәм корбанның ияк астына бар көче белән тондырды.

Мәрданша урындыгы-ние белән өй почмагына очып барып төште. Авыздан кан китте һәм шунда Мәрданшада курку дигән нәрсә бөтенләй калмады.

Аны караватка сузып салдылар, күлмәген җыерып корсагын шәрә калдырдылар. Сандык өстендә торган үтүкне алып корсагына куйдылар, һәм... шнурны электрга тоташтырдылар.

Өч рэкетчы операция өстәле янында торучы хирургларны хәтерләтәләр иде. Аерма шунда гына — гадәттә, хирурглар пациент тирәсендә мәж килеп, тиргә батып аны савыктыру өчен бөтереләләр, ә болар — әҗәл фәрештәләре кебек бик тыныч, сабыр эш иттеләр.

Ә Мәрданша исә, «ике дөнья — бер моржа» дигән сыман, бик озак яман авырудан иза чиккән кешене хәтерләтеп, тып-тын ятты.

Бәлки, аның яман авыруы — шул бәхетсез тормышыдыр. Бәлки, бу минутларда рэкетчыларга шул чарасыз авырудан, чиксез бимазаланудан коткаручы рәхимсез хирургларга караган кебек карагандыр...

Үтүк җылына башлады. Шул ук сорау яңгырады:

— Тарак кайда?

Мәрданша дәшмәде. Үтүк кайнар иде инде.

— Бир таракны!

Мәрданшаның чырае сытылды, чөнки үтүк эчне яндыра башлады. Аның күзләре акайды, маңгаена тир бәреп чыкты. Ул кычкыра башлады һәм аның авызына теге бияләйне яңадан тутырдылар.

Бераздан ул аңын җуйды.

Аны бик озак аңына китерә алмый интектеләр. Рэкетчылар үзләре белән төрле дарулар да йөртәләр икән. Төрле сыекчалар иснәтә торгач,

Мәрданша күзләрен ачты, корсак тиресе үтереп әрнүдән ыңгырашып куйды.

— Кайда тарак?— дип сорады аның өстенә иелгән маскалы баш.

— Тарак юк миндә,— дип ыңгырашты Мәрданша һәм шул мизгелдә: «Үтерерләр болар мине»,— дип уйлап куйды.

Аны бик озак типкәләделәр.

Әйе, үтерергә маташалар. Таракны бирмәсәң, үтерәчәкләр.

...Мәрданша инде өч тапкыр аңын югалтып, өч тапкыр айнырды. Ләкин ни гаҗәп — бирми генә бит таракны! Тырнак асларына инәләр тыгып карадылар, буып, тынын бетереп җәфаладылар. Канга батырып таптадылар, изделәр.

Мәрданшаның итекләрен салдырырга дигәй уй берсенең дә башына килмәде, итек эчендәге киез астында алтын ятадыр, дип кем уйласын. Мәрданша:

— Тарак прокуратурада,— дип һаман үз сүзендә торгач, бандитлар шикләнә башладылар: әллә соң прокуратурадыгалар аларны алдадылар микән?.. Әллә аларны алтыннан өлешсез калдырмакчы булалар микән?.. Булыр да ул имансызлардан!

Шулай итеп, рэкетчылар икеләнә башладылар — прокуратурадамы тарак, әллә Мәрданшадамы?.. Мәрданша тагын аңын җуйгач, озын гәүдәле җанбасар үзенең иптәшләренә:

— Тарак чынлап та юктыр моңарда, бу кадәре җәзалауга түзмәс иде,— диде.

Таң беленгәнче алар чыгып киттеләр.

Әлегә Мәрданшаны үтерергә кирәк дип тапмадылар, чөнки бу садистларга аның җаны түгел, алтын тарак кыйммәтрәк иде. Аларга Мәрданшаның үлеме түгел, алтын кирәк!

* * *

Мәрданша өч көн буе уяулы-саташулы булып, ыңгырашып, караватында аунады. Халисә белән Гаделша аны, «скорый» чакыртып, сырхауханәгә озатырга булдылар. Гаделша башта моңа каршы килгән иде, чөнки сырхауханәгә яткыргач, милициягә хәбәр итми калмаячаклар. Тагын милиция... тагын допрослар, тагын төпченүләр — әллә нинди яңа матавыклар килеп чыгуы бар.

Ләкин, тәнендәге җәрәхәте бик авыр, куркыныч булу сәбәпле, аны сырхауханәгә җибәрми дә булмый иде.

Халисәгә дә хәзер бөтенесе мәгълүм булды — Су анасы турында да, алтын тарак турында да, Мәрданшаның инде бик күп еллар мәхәббәт утында янганы да...

Мәрданшаны ашыгыч ярдәм машинасы белән кала сырхауханәсенә озаттылар. Аягында итекләр иде. Итек олтырагы астында, Мәрданшага яшәү дәрте биреп, алтын тарак ята иде. Хәле бик авыр булуга карамастан, таракның үзе белән булуы, үзе белән сырхауханәгә баруы аңа мең шифалардан да дәвалырак иде.

...Озак ятты ул дәваланып — дүрт ай. Гаделша белән Халисә килгәләп тордылар. Берничә тапкыр, аларга ияреп, Саңгырау Нуретдин дә килде.

Ләкин Мәрданшага җан тынычлыгы язмагандыр инде... Тарак бит итек эчендә калды, ә итекләр сырхауханәнең подвалында саклау камерасында яталар. Әллә исән тарак, әллә юк...

Җырыклыда инде тарак турында да, Су анасы хакында да беләләр иде. Инде Мәрданшаның юклыгыннан файдаланып, өенә керүчеләр дә булды, каралты тирәсендә дә бик еш чуалдылар.

Аларның берсен дә Су анасы һәм аның белән бәйләнгән әкияти могҗиза кызыксындырмады. Күрәсең, заманы шундыйдыр, беркем дә су

иясенә шаккатмады. Әллә бар аларга матур әкият, әллә юк... Һи, Су анасы дип... Булса ни... Аның ниенә гаҗәпләнергә?!. Әнә коммерческий кибетләрдә мыеклы презервативлар сата башлаганнар ди! Менә бу могҗиза, менә бу чыннан да кызык ичмаса! Менә монысы сенсация! Имеш, Су анасы шәп-шәрә икән... Булса ни... Әнә «видик» дигән нәрсәдән секс карасаң, андагы хатыннар синең Су анасын орып бирәләр! Аларны фәкать алтын гына кызыксындыра иде.

Мәрданшаның гына, тәне төзәлеп килсә дә, җан җәрәхәте төзелмәде, бәгыре савыкмады. Су анасын ул һаман ярата иде. «Тарак исән микән, урынында микән?..» — дигән уй аны хәсрәткә тагын да тирәнрәк батырды.

...Инде яз җитте. Сырхауханәдән чыгарга тагын атна-ун көн калды, диделәр.

Мондагы аштан аның ашказаны, бөерләре, бавыры авырткалый башлады. Шуңа күрә иреккә чыгуны ул зур түземсезлек белән көтте.

Берничә сырхауханәдән торган биналар рәте әшәке ис, чүп-чар, пычрак белән тулы иде. Монда ашказаны авыруы белән кергән кеше дәвалану курсы беткәндә йөрәк авырулыга да әйләнә. Ревматизм белән ятучы дизентерия белән дә авырып ала.

Монда дүрт-биш төрле чирдән берүк дарулар бирәләр, нәтиҗәдә, бер диагноз белән кергән кеше дүрт-биш төрле чир иясе була.

Монда бөтен невротикларга да амитриптилин каптыралар, һәм, нәтиҗәдә, барысы да мәлҗерәп, селәгәйләрен агызып, йокылы-уяулы булып, нинди бәхетле илдә яшәүләрен дә аңлаудан мәхрүм булып йөриләр.

Шул больницаларның берсенә Җырыклы авылының тагын бер кешесен — Гайнетдин бабайны алып килделәр.

Болайрак булды ул хәл.

* * *

Бөере авыртып сырхауханәгә баргач, Гайнетдин бабайдан төрле анализлар алдылар да, алдагы атнада килерсең дип, авылына кайтарып җибәрделәр.

Тик икенче көнне үк Җырыклыга «Ашыгыч ярдәм» машинасы килеп керде һәм Гайнетдиннең йорты каршына килеп туктады. Ак халат кигән ике кеше җирәнеп кенә бабайның кул-аякларыннан тотып, машинага селкеп салдылар да, калага юл тоттылар.

«Сиксән җиде яшьлек Гайни картта СПИД тапканнар!» — дигән хәбәр авылга минуты белән таралды.

Кешеләр бабайның яман авыру эләктерүенә түгел, ә аның туксан яшенә җитеп килсә дә, җенси мөнәсәбәтләргә керә алуына гаҗәпләнделәр. Бу вакыйгадан авылдашлары гына түгел, бөтен сырхауханә гөж килде, тирә-як аһ-ваһ итте.

Кичкә таба Америкадан, Франциядән һәм тагын башка илләрдән профессорлар килеп төште.

Аерым палатага ябып бикләп куйгач, Гайни карт бик курыкты. Шәфкать туташы СПИДның нәрсә икәнен аңлаткач, бабай сөенде, чөнки ул СПИДның коточкыч авыру икәнлеген бөтенләй үк аңлап бетермәде. Җитмәсә, ул, Җырыклы авылы кешесе буларак, бераз мактанчыграк та кеше иде. Һәм бу вакыйга авылдашлары алдында, бигрәк тә үзе кебек карт-коры алдында шапырынырга әйбәт булды.

Врачлар сорашканда Гайнетдин бабай болай дип ялганлады:

— Көз көне авылыбызга заводтан эшчеләр килгән ие... бәрәңге алырга... Шулар арасыннан бер маржа белән чуалган идем шул, гөнаһ шомлыгы...

Ә инде хәлен белергә дип ахириләре Шәрәфетдин белән Хәсәншә килгәч:

— Кала базарында карлыган саткан чакта бер унсигез яшьлек кыз белән танышканием... Төнне шуның белән апасының фатирында уздырдык,— диде.

Әйтергә кирәк, бабайлар Гайни картны кызгансалар да, күбрәк аңардан көнләштеләр.

— Ну маладис,— диде Хәсәнша, сырхауханәнең өченче катындагы тәрәзәдән карап торган Гайнетдингә.— Бүгенге гәҗитләр барысы да синең хакта язганнар бит.

Бу вакытта инде оператив рәвештә төзелгән медицина комиссиясе пыр туздырып, шәһәр халкын тикшерә иде.

Гайнетдиннең абруе тагын да югарырак күтәрелгән булыр иде дә бит, ләкин эшне чит илдән килгән врачлар бозып ташлады.

Бер көтү врачлар кереп, Гайни карттан гафу үтенделәр:

— Гафу ит, бабай, теге микроскопта күренгән вирус СПИДныкы түгел икән,— диде Америка табибы.— Ялгышканнар сезнең врачлар.

Франция профессоры өстәп куйды:

— Ул вирус зарарлы түгел, андый гына микроблар белән сезнең илдә һәр кешенең эче тулган.

Гайни картның кәефе кырылды.

Сырхауханәнең баш врачы Наданов, аны тынычландырырга ниятләп:

— Бабай, зинһар борчылма,— диде.— Врачларыбызның хата җибәргәнен, вирусның СПИДныкы түгел икәнен гәҗитләрдә язарбыз.

Гайнетдин бабай өзгәләнеп врачларга ялынды:

— Балакайларым, алла хакы өчен мәсхәрәләмәгез. СПИД булгач, СПИД килеш калсын инде. Алайса Шәрәфетдин белән Хәсәнша алдында ялганым тотылачак бит.

Врачлар башта берни аңламый тордылар һәм эшнең нәрсәдә икәнлегенә төшенгәч, рәхәтләнеп көлделәр.

— Ярар, язмабыз,— диде Наданов.

* * *

Май аеның чәчәк атуына да игътибар итмичә, иң кадерле нәрсәсен югалткан кеше кыяфәте белән, Гайнетдин бабай «Кожновенерологический диспансер» ягыннан Мәрданша дәвалана торган бина янына килеп җитте.

Сиксән җиде яшьтә булса да, аның күз, колак һәм тагын кайбер әгъзалары әле әйбәт эшли иде. Шуңа күрә, үзенең исемен ул ишетте һәм борылып карады.

Аңа таба, җил-җил атлап, буй-буй сызыклы кием кигән Мәрданша килә иде. Үзе елмая.

— Нихәл, Гайнетдин бабай!

— Аллага шөкер. Үзең исән-саумы?

— Исән әле... Нишләп йөрисең монда, Гайни бабай?

— Теш куйдыртырга килдем,— дип ялганлады Гайни карт.

— Куйдырдыңмы соң?

— Юк, киләсе атнада килергә куштылар... Алтыннары юк икән, үземнең алтынымны алып килергә туры килер инде...

Мәрданша әле бабайның маҗараларын белми иде.

— Авылда яңалыклар юкмы соң? — дип сорады Мәрданша.

— Юк бугай... барысы да беркөе. Төзәләсеңме инде?

— Әй, белмим, төзәлеп булырмы инде, юкмы,— диде Мәрданша авыр сулап.

— Кайчан чыгаралар соң инде?

— Тагын бер атнадан. Туйдым инде монда ятып... Ярый әле яз җитте, саф һава суларга чыгаралар.

Гайнетдин картның Мәрданшага әйтер сүзләре бар иде.
— Син очратуым әйбәт булды әле,— дип башлады ул сүзен һәм як-ягына каранып куйды.
— Ни әйтмәкче буласың?
Алар сырхауханә каршындагы эскәмиягә барып утырдылар.
— Сиңа бик важный сүз әйтәсем бар.
— Тыңлыйм, Гайнетдин бабай.
— Менә нәрсә, Мәрданша... Мин, Зәйдә боз киткәч, җәтмә белән төшкәнием... Мин синең матавыкларыңны беләм... Мин генә түгел, бөтен авыл белә... Су анасы турында да, алтын тарак турында да... Синең җүләрләнеп гашыйк булып йөрүең дә билгеле бит инде... Халык ул бөтенесен белеп тора...
Бабай тынып калды.
Мәрданша түзмәде:
— Бабай, шуннан?..
— Шуннанмы? Нәрсәдә тукталдым әле мин?
— Халык бөтенесен белеп тора, дидең.
— Әйе, халык бөтенесен белә... Мин Зәйгә төшкәнием... җәтмә белән... Чуртан тотып булмасмы дип... Әле күптән түгел... Су бик нык арткан, әрәмә бөтенләй диярлек су астында калган... Җәтмәм дә начар инде. Җеп юк бит, малай, әйбәт җәтмә үрергә. Элек барие... Элек җеп тә, бау да бар ие...
Ул тагын тынып калды.
Мәрданша аны кымшатып куйды:
— Миңа әйтәсе сүзеңне әйт инде.
— Ашыкма әле... Нәрсә дип туктаган ием әле мин?..
— Элек җеп тә, бау да бар иде, дидең.
— Барие, кәнишне. Боз киткәч Зәйгә төшкәнием... Җәтмә белән... чуртан тотарга... Су анасын күрдем бит мин!
Мәрданша урыныннан сикереп торды.
— Су анасын?!.
— Әйе, Су анасын. Син, Мәрданша, тыпырчынма әле, утыр урыныңа, сиңа дулкынланырга ярамый... Савыгып җит әле башта...
— Чынлап та күрдеңме Су анасын, Гайнетдин бабай?
— Минем ялганлый торган гадәтем юк,— диде Гайни карт.
— Ничек итеп күрдең?
— Мин аны бер мәртәбә генә түгел, өч көн рәттән күрдем. Яр читенә чыга да утыра.
Мәрданша бабайның иңнәреннән тотып җилтерәтте:
— Берәр сүз әйтмәдеме?
— Юк. Мине күрмәде бугай ул... Менә шул сиңа әйтәсе сүзем. Су анасы юкка чыкты дип уйлыйсыз бит сез барыгыз да. Ялгышасыз! Беркая да китмәгән ул. Урынында. Зәй елгасы Су анасыннан башка Зәй була димени?!
Мәрданша нишләргә белмәде. Хәзер үк йөгерсә — подвалда итек эчендә тарак кала... Ә сырхауханәдән чыгарга тагын бер атна бар әле.
— Гайнетдин бабай,— диде ул.— Сиңа минем бер гозерем бар.
— Әйт.
— Үтәрсеңме?
— Әйт әле башта, мин үти алырлык микән.
— Гайнетдин бабай, алла хакы өчен, кайткач Зәй буена төш.
— Шуннан?
— Су анасын күрергә тырыш.
— Күрсәм?
— Күрсәң, син аңа дәш.
— Ярар.
— Курыкмассыңмы?
— Кемнән?

— Су анасыннан.

— Гайнетдиннең гомерендә хатын-кыздан курыкканы юк,— дип горур итеп җавап бирде бабай.

— Сина ана дәш... Сөйләшә белерсең микән?..

— Һи, нишләп хатын-кыз белән сөйләшә белмәскә мин...

— Син аңа әйт, борчылмасын. Тарагың исән, Мәрданшада диген. Мәрданша сине бик сагынган дип әйт, яме. Больницадан чыккач, таракны китереп бирер, дип әйт. Алла хакы өчен, Гайнетдин бабай, үтә инде бу йомышымны.

— Ярар,— диде бабай, риза булып.— Борчылма, син әйткәнчә булыр. Алтын тарак дөрес нәрсә булып чыкты алайса... Халык сөйләшә башлагач, мин баштарак ышанмаган идем.

— Дөрес шул... Миндә ул тарак,— диде Мәрданша, итек эчендәге тарак язмышы өчен борчылып.

Алар саубуллаштылар. Гайни карт авылга кайтып китте.

Мәрданша бер шатланды, бер көенде. Аны ярсу хисләр биләп алды. Кайткан Су анасы! Исән Су анасы! Зәйдә ул!

... Тик Гайнетдин бабай Мәрданшаның гозерен үти алмады. Насыйп булмады.

Авылга кайткан көнне горур кыяфәтле Гайнетдин кич белән койма буенда яткан бүрәнәгә чыгып утырды.

Күп тә үтмәде, шул тирәгә авыл халкы җыелды.

Гайнетдин бабайга якын килергә курыктылар, шуңа күрә сораулар һәм җаваплар бер егерме адым аша бирелде.

— Гайни бабай, нишләп бик тиз чыгардылар?

— Андый вирус карт кешедә озак яшәми икән ул, тиздән үләчәк ул,— дип җавап бирде Гайнетдин.

Өлкәнрәк яшьтәгеләрнең Гайнетдингә бер зур үтенечләре дә бар иде:

— Син, Гайнетдин, пажалысты, безнең үзебезнең авыл хатыннарына тимә инде, йоктыра күрмә чиренне.

Гайни карт бик серле итеп елмайды да:

— Юк, юк, вирусым үлгәч кенә чамалармын, чамаласам,— диде.— Вирусым үлмичә, хатын-кызга тотынмыйм, аллаһе боерса.

Авыл кешеләре Гайнетдиндәге СПИД вирусының тизрәк үлүен теләп йөргәндә, бабайның салкын тигән бөерләренә тагын өянәк булды һәм ул үзе үлеп китте.

Шулай итеп, бүтән ул беркемне «чамалый алмады». Су анасына әйтәсе сүзләрне дә әйтергә өлгермәде.

... Гайнетдинне җирләп кайтканда аның ахири дуслары Шәрәфетдин белән Хәсәнша бергә кайттылар.

— Хатын-кыз белән бәйләнешүнең бер дә яхшылыкка илткәне юк шул,— диде Шәрәфетдин.

— Хатын-кыздан инде бөтен бәла,— дип җөпләде аның сүзен Хәсәнша.— Шул маржа белән буталмаган булса, тагын бераз яшәгән дә булыр иде әле...— Хәсәнша авыр сулап куйды.— Врачларын да әйтер идем инде...

* * *

Бу дөньяда могҗизалар юк, дигән сүз дөрес түгел. Киресенчә, дөнья, яшәеш гел могҗизалардан гына үрелгән.

Мәрданшаның дөньяга килүе дә могҗиза! Су анасын очратуы да — могҗиза! Шул кадәрле кыйналып та исән калу — үзе бер могҗиза! Минлебаев хәтле Минлебаевның алтын таракны электерә алмавы могҗиза түгелмени?!

Дүрт ай буена сырхауханә подвалында киез итекләрнең исән-имин ятуы — иң зур могҗизаларның берсе иде. Ничек урламаганнар ул итек-

ләрне! Ә инде шул итекнең эчендә алтын таракның сакланып ятуы бөтенләй адәм ышанырлык нәрсә түгел.

... Өенә кайткач, Мәрданша бер атна Зәйгә барырга әзерләнде. Су анасына әйтәсе сүзләрен күзгә каршына килеп кат-кат кабатлады.

Көн саен килеп йөргән Халисә белән дә, Гаделша белән дә юньләп сөйләшмәде.

Рэкетчылар да тик ятмадылар. Мәрданша көн саен, хәтта сырхауханәдә яткан чакта да гел күзәтү астында булды. Авылга кайткач та аның һәр нияте, һәр шөгыле сизгер һәм житез рэкетка мәгълүм булып торды.

Авыл кешеләре дә аның белән алтын тарак турында төрттереп сөйләшә башладылар.

Төрмәдән кайткан Шиһап: «Алтын тарагыңның бер-ике тешен миңа сындырып бирсәң, валлаһагазим, сиңа җил-яңгыр тигезмәм»,— диде.

Совхоз директоры идарәгә чакыртты һәм бик озак шул тарак турында төпченде.

Һәм көтмәгәндә, Миңлебай бүлнистән чыккан икән, дигән хәбәр сасы ис булып авылга таралды.

Мәрданша аңлады: алтын тарактан колак кагуы ихтимал. Бик күп кеше кызыга, бик күпләргә тынгы бирми алтын.

Заманы да бит аның... Бәяләр гел артып тора, ил хәерчелек сазлыгына төшеп килә... Кем генә кызыкмас икән алтынга...

Тизрәк Су анасының үзенә тапшырырга кирәк таракны!

...Җәйнең беренче көне иде. Мәрданша иртүк барып Гаделшаны уятты да, алар икәүләшеп, таракны Су анасына бирергә дип, Зәйгә киттеләр.

Гаделша аны әрәмәгә чаклы озата барырга тиеш иде. Саклык кирәк. Заманалар бик болганчык!

Әрәмәлеккә килеп җитәргә бер йөз адым чамасы ара калгач, ике дус шып туктадылар — таллар арасыннан өч кеше килеп чыкты.

Бу — теге рэкетчылар иде. Бу юлысы алар битләрен маскалар белән каплап мәшәкатьләнмәгәннәр иде. Өчесе дә ямьсез, куркыныч. Болар, бисмилланы да әйтмичә, теләсә кемне тып-тын гына яткырып суя торганнардан иде.

Мәрданша белән Гаделша каушап, нишләргә белми аптырып торганда, тау ягыннан берәүнең йөгергәне күренде. Монысы Миңлебаев иде.

Нәкъ шул вакытны әрәмәлекнең читеннән, алагаем гәүдәсе белән хәтта рэкетчыларны да сискәндереп, мәшһүр көтүче Саңгырау Нуретдин хасил булды.

Рэкетчылар Мәрданша белән Гаделшага якынлашканда Нуретдин, мингерәү зат булса да, бу юлысы эшнең нәрсәдә икәнлеген тиз аңлады һәм дуслары янына барып басты.

Шулай итеп, җәйге иртәдә әрәмәлек янында ике гаскәр очрашты.

Кигәвеннәрдән качар өчен дулаган сыер сыман сикергәли-сикергәли чабып килүче пенсиядәге легендар участковыйның кайсы якта сугышырга теләгәнен киләчәктә тарихчылар әйтә алырлармы, юкмы — белмим. Мәрданша ягында сугышыр идеме, әллә теге юлбасарлар ягындамы, әллә күзәтүче вазифасын гына үтәр идеме — моны үзе генә әйтә алыр, мөгаен.

Әрәмә буендагы хәрби кампаниядә Миңлебаев катнаша алмады. Тау итәгеннән йөгергәндә аны врачлар машинасы куып җитте һәм ак халатлы кешеләр белән шактый вакыт көрәшкәч, ул буйсындырылды, әсир төште һәм яңадан психушкага озатылды.

Бу вакытта инде бөек сугыш башланырга тора иде.

— Бир таракны! — диде озын буйлы рэкетчы.

— Бирмим! — диде Мәрданша.

— Бир! — дип кабатлады бандит.

— ...ны тот! — дип җавап бирде Мәрданша.

Мәрданшаның кыйналып сырхауханәләрдә ятуы, шәһәр бандитларының әшәкелеге, замананың буталчыклыгы, тормышның авырлыгы, тартырга тәмәкенең кыйммәтләнүе, аракының талонга гына сатылуы, әллә нинди өч урысның Зәй буена килеп алтын тарак дәгъвалаулары — бөтенесе бергә җыйналып, авылдашларда кинәт чиксез нәфрәт уятты. Һәм Гаделша белән Нуретдин Мәрданшаны актык сулышка кадәр яклап, аны бүтән җәберләттермәскә әзер тордылар.

... Иң элек Мәрданшаны сугып аудардылар. Аннан соң Гаделшаның эченә типтеләр.

Ләкин авылдашлар гаскәренең резервында торган Нуретдин һөҗүмгә күчкәч, яу кырында көчләр тигезләнебрәк китте. Аның чыбыркысы рэкетчыларны өтеп-өтеп алган арада Мәрданша белән Гаделша җирдән күтәрелеп, дошманнарына ташландылар.

Алты кешедән укмашкан олы түмгәк бик озак җирдә тәгәрәп йөрде. Бу түмгәк, урысчалы-татарчалы сүгенеп, мышнап, акырып, тирә-якка коткы таратты.

Пычак ялтырады. Пычак чыгарган бандитның башы өстендә Нуретдиннең ат башы хәтле йодрыгы ялтырады һәм рэкетчы аңын югалтты.

Бервакыт төрлесе төрле якка сибелделәр. Бер бандит һәм Гаделша җирдә ятып калдылар. Мәрданша белән Нуретдингә каршы ике рэкетчы калды. Берсенең кулында пистолет иде!

— Бир таракны! — диде пистолет тотканы ысылдап.— Барыгызны да атып үтерәм!

Шуннан соң, җирдә ыңгырашып ятучыларның өстеннән атлап чыгып, юлбасарлар Мәрданша белән Нуретдингә таба атладылар.

Шул вакытны Гаделша кинәт яткан урыныннан сикереп торды да, пистолетлы дошманга арттан ташланды.

Гаделшаның:

— Авызыңны шулай итим!..— дип кычкыруы авылдашларга яңа дәрман өстәде һәм алар һөҗүмгә ыргылдылар.

Гаделша дошманын арттан буып маташканда Нуретдин пистолетны каерып алды һәм әрәмә эченә ыргытты. Шуннан соң ул Мәрданша белән көрәшеп ятучы рэкетчының касыгына китереп типте.

Ике бандит тынсыз яталар иде инде, ә пистолеттан мәхрүм калганын читтәрәк Гаделша буып азаплана иде. Дошманының бите зәңгәрләнә башлагач, Гаделша буудан туктады.

Сугыш кырында өч дошман ятып калды. Җырыклы каһарманнары аларның исәнме-юкмы икәнлекләре белән кызыксынырга да онытмадылар. Өчесе дә исән иде.

Авылдашлар, үзләренең дә ерткычларга әйләнүләренә гаҗәпләнеп, хәйран калып, уфылдап хәл җыеп утырдылар. Аларның сөйләшерлек тә хәлләре калмаган иде.

Әрәмә аша үтеп, Зәй ярына чыктылар. Ярдан ерак түгел рэкетчыларның машинасы тора иде.

Дуслар Зәй суы белән битләрендәге канны, балчыкны юып төшерделәр. Бер-берсенең кыяфәтеннән бик озак көлештеләр. Мәрданшаның өске ирене кабартма шикелле күпергән иде. Гаделшаның ике күз төбе дә күгәргән һәм алдагы бер тешe сынган иде. Нуретдиннең борынына каты эләккән булган, шул сәбәпле, бераз кыйгайган иде. Өчесенең дә киемнәре ертылып, пычранып беткән.

Яр өстендә тәмәке көйрәтеп утырганда таллар арасыннан бер-бер артлы теге юлбасарлар сөйрәлеп килеп чыктылар. Алар көч-хәл белән машинага төялделәр. Машина кузгалып китте һәм, әле уңга, әле сулга каерыла-каерыла, тау артында күздән гаип булды.

— Иманым камил, болар бездән үч алмый калмаячаклар,— диде Гаделша.

Нуретдин ишетмәде, Мәрданша ишетсә дә дәшмәде.

Алар бик озак чирәмдә хәл җыеп яттылар.

Кинәт тау өстеннән сузылган юлда әлеге дә баягы машина күренде.
— Карале, карале,— диде Гаделша.
— Болар калага туры юлдан, тау өстеннән кайтмакчы булалар,— диде Мәрданша.
Машина бормаланып барды-барды да, таудан түбән мәтәлеп төшеп китте.
Дуслар сикереп тордылар.
— Беттеләр болар...— диделәр өчесе дә бертавыштан.
Машина шалтор-шолтыр тәгәрәп төште дә, кайдадыр таллар арасында шартлады. Шул урында ялкын, кара төтен күтәрелде.
Кем каргышы төшкәндер рэкетчыларга — Мәрданшаныкымы, Су анасыныкымы, әллә башка рәнҗетелгән адәмнәрнекеме — әйтүе кыен.
Бу вакыйгадан өнсез калган дуслар авылга кайтып киттеләр.

* * *

Таудан мәтәлеп төшеп шартлаган һәм аның эчендә һәлак булган өч кеше турында тирә-як бераз гөҗләп алды да, ул вакыйганы тиз оныттылар. Чөнки заманы шундый... Көн саен кемнедер үтерәләр, көн дә машина урлыйлар, кешеләр бер-берсен көчлиләр, рэкетчылар, мафияләр көн-төн үзара сугышалар. Шуңа күрә, монда артык гаҗәпләнер нәрсә юк иде...
Бер ай чамасы вакыт узгач, Мәрданша Зәй буена килде. Таракны елгага атмакчы иде, туктап калды — иң элек кычкырып карарга булды.
— Әһә-һә-һәй! Чык, чибәрем, бу мин — Мәрданша!
Шул вакытны куаклар селкенде, нәрсәдер кыштырдады. Мәрданша суларга да куркып, катып торды. Куаклар арасыннан кулына чиләк тотып, Халисә килеп чыкты. Яулыгы кыек бәйләнгән, бите кояштан каралып беткән, өстендә иске кара халат. Резин итекләрен лоштырдатып, ул Мәрданшага якынлашты.
— Миңа әйтәсеңме син?
Мәрданшаның эчләре куырылып килде.
— Нишләп йөрисең монда? — дип кычкырды ул.— Бар кит! Сиңа ни калган монда? Бар сыерларыңны сау!
Халисә аңа таба атлады.
— Мәрданша, ник җенләнәсең инде тагын?
— Җенләнсә, анда синең ни эшең бар?!
— Нәрсә, миңа әрәмәлектә йөрергә дә ярамыймыни?
— Ярамый шул.
— Кызык икән.
— Бар, ычкын моннан!
— Ник кычкырасың син миңа, дурак тәре! — диде Халисә аптырагач.— Ник акырасың?! Нинди начарлыгым тиде минем сиңа? Нинди начарлык эшләдем мин сиңа?
— Эшләмәдең... бернинди начарлык та...— диде Мәрданша, башын аска иеп.
Кинәт елгадан Су анасы килеп чыкты. Халисә чәрелдәп кычкырды да, табанын ялтыратты.
Мәрданшаны әйтерсең лә ток сукты.
— Исәнме, матурым! — диде ул, үзен көчкә кулга алып.
Су анасы ярга менде.
— Сәлам! — диде ул.
Мәрданша ни әйтергә белми торды. Ниһаять, ул таракны сузды:
— Менә тарагың... Миңа синең тарагың кирәк түгел.
Су анасы аңа таба атлады:
— Нәрсә, кирәк соң миннән сиңа?
— Миңа син үзең кирәк!

Су анасы шаркылдап көлеп җибәрде:
— Нишләрсең соң син минем белән, хәчтерүш?
Мәрданша артка таба чигенде.
— Яратам мин сине!
— Шуннан? — диде Су анасы.
— Кияүгә чык миңа.
— Таракны бир башта...
— Мә!
Су анасы туктады.
— Әй, юк. Җиргә куй, ә үзең читкәрәк кит.
Мәрданша, буйсынып, таракны җиргә куйды һәм артка таба чигенде.
— Миңа синең тарагың кирәк түгел! — дип кычкырды ул.
Су анасы таракны иелеп алды да:
— Кирәк булмагач, ник урладың соң? — диде.
Мәрданша сыкы-быкы аңлата башлады:
— Чибәрем... Мин сиңа хәзер барысын да сөйләп бирәм... Синең белән танышыр өчен генә урлаган идем мин тарагыңны. Төнлә өемә килерсең дип... Тукай шигырендәге кебек... Син бит аның шигырендә каракның өенә килгәнсең...
— Ә-ә-ә... Ул бит мин түгел идем, — диде Су анасы, елмаеп. — Ул минем әбием иде, теге малайның артыннан килүче.
— Мин бит сине дә өемә килерсең дип уйладым, — диде Мәрданша, оялып.
— Мине җүләр дип белдең мәллә?
— Юк, юк, мондый гүзәл хатын җүләр була димени...
Су анасы йөзен чытты:
— Фу, зинһар өчен комплиментлар әйтмә, яме. Ир-атның төче сүзләреннән минем инде күңелләрем болгана.
— Гафу ит. Син хәзер кайда яшисең соң? — диде Мәрданша, сүзне тизрәк икенчегә борырга теләп.
— Анда синең ни эшең бар? — диде Су анасы кырыс кына.
— Болай гына, — диде Мәрданша, башын иеп.
— Карак син! — диде Су анасы һәм елгага таба атлады.
— Тукtale, китмә! — дип кычкырды Мәрданша. — Мин синнән башка яши алмыйм лабаса!
Су анасы туктады, борылды, Мәрданшаны башыннан аягына кадәр күзләде.
— Ә минем белән яши алырсыңмы?
— Тукта! Китмә! Әгәр балаларың... әгәр маймычларың булса... аларны үземнеке итәрмен. Үз фамилиямә яздырырмын... Үзем тәрбияләрмен!
Су анасы рәхәтләнеп көлде.
— Үз акылыңдамы соң син? — диде ул, көлеп туйгач. — Ни сөйлисең син? Җүләр мәллә син?
— Белмим.
— Ярый киттем мин.
— Әйт инде берәр сүз! — диде Мәрданша, ачынып.
— Яратасыңмы мине? — диде Су анасы.
— Яратам!
— Чынлапмы?
— Менә шушы басып торган урынымда чукынып катыйм, үлеп яратам!
Су анасы авыр сулап куйды да:
— Яратсаң, минем сиңа бер үтенечем бар, — диде.
Мәрданша тезләнде:
— Әйт, бар теләкләреңне дә үтәрмен.
— Минем сиңа бер генә үтенечем бар.
— Әйт, нинди? — Мәрданша бераз өметләнә башлады.

Су анасы, әйтергәме-юкмы дигән сыман уйланып торгач:

— Ярар инде, алайса әйтәм,— диде.— Теге Чукрак Нуретдинегезгә әйт әле, елгага бүтән сыерларын кертмәсен... Зәй болай да бик болганчык... Сыерларын ярдан гына эчертсен.

— Шул гынамыни үтенечең?— диде Мәрданша, иреннәрен турсайтып.

— Ә-ә-ә, тагын бер үтенечем бар икән сиңа... Анысын әйтергә оялам.

Мәрданша, өметләнеп, тезләре белән аңа таба шуышты:

— Әйт, әйт, оялма! Мин бит сиңа ят кеше түгел! Әйт инде, оялма!

Су анасы бу үтенечен дә әйтергә батырчылык итте:

— Нуретдинегезгә әйт, елгага бүтән печ итмәсен! Хуш!

Бу вакытта таллар арасыннан Халисә, Нуретдин һәм Гаделша килеп чыктылар. Гаделшаның кулында җәтмә иде. Алар, читтәрәк туктап, күзәтә башладылар.

Мәрданша аларны күрмәде. Ул тезләнеп торган урыныннан сикереп торды да, Су анасы артыннан атлады.

— Туктале, шушы гынамыни үтенечләрең, әйтәсе сүзләрең?

— Әйе,— диде су анасы, борылып та карамыйча.

— Мин бит сиңа әле бик күп нәрсәне аңлатырга тиешмен... Мин бит әле сиңа үземнең хисләремне белдермәдем дә... Мин бит сине ун ел көттем. Тукта инде!

— Вакытым юк,— диде Су анасы һәм елгага чумды.

Мәрданша яр өстенә йөгереп килде, чак кына чайкалып суга егылып төшмәде. Җиргә йөзтүбән капланып, елый башлады.

Гаделша белән Нуретдин йөгерешеп килделәр дә, янына чүгәләп, аны юатырга тотындылар.

— Кордаш, тор әле, тор,— дип ялынды Гаделша, дустын җиңелчә генә селкетеп.

Мәрданша торып утырды. Аның бите кып-кызыл һәм юеш, яңакларына үлән ябышкан иде.

— Мин аны күрдем...— диде ул, таллар өстеннән каядыр чиксез ераклыкка карап.

— Без дә күрдек,— диде Гаделша, аның белән янәшә утырып.

— Ул минем белән сөйләште,— диде Мәрданша, күз карашын һаман да Галәм үзәгенә төбәп.

— Чынлапмы?!—дигән булды Гаделша.

Нуретдин дә Мәрданша янына утырды һәм нидер әйтергә теләп, сыер мөгрәвенә охшаган аваз чыгарды.

Мәрданша тагын мышкылдый башлагач, Гаделша:

— Елама инде, елама,— дигән булды.— Аның бүтән әйтер сүзе юк иде.

— Нишләп болай бәхетсез соң мин?!—диде Мәрданша.

— Кайсыбыз бәхетле соң безнең арабызда?—дип җавап бирде Гаделша.— Дөньяда да бәхетле кеше юктыр әле ул. Таракны бирдеңме?

— Бирдем.

— Нәрсә диде?

— Димәде.

— Гашыйк булуыңны әйттеңме соң?

— Әйттем,— диде Мәрданша, авыр сулап.

— Ә ул ни диде?

— Димәде.

— Ничек инде?— дип гаҗәпләнде Гаделша.— Ул бит синең белән сөйләште.

— Сөйләште шул...— диде Мәрданша кинәт татлы елмаеп.— Миңа бик нык үпкәләгән, ахрысы, ул. Рәнҗетмәскә иде аны шул кадәре... Тарагын урламаска иде... Шуңа күрә минем яратуыма ышанып бетми бугай ул...

Мәрданша, кинәт кенә сикереп торып, суга чуммакчы булды. Гаделша белән Нуретдин җәһәт кенә бичара гашыйкны эләктереп алдылар, ярдан читкәрәк алып китеп, чирәмгә яткырдылар. Бераз тынычлангач, утыртып куйдылар.

— Җибәрегез мине! — дип елады Мәрданша.— Ул яши торган елгада батып үләсем килә...

Гаделша ялынды:

— Кордаш, берүк үзеңне кулга ал! Сикерә күрмә! Син бит йөзә дә белмисең.

Мәрданша ычкынмакчы булды. Дуслар аны ике яктан ныгытып тоттылар.

— Нуретдин абый, алай каты кысма кулны,— дип ыңгырашты Мәрданша.— Каерма кулны, сикермим, курыкмагыз...

Гаделша дустының аркасыннан сөеп куйды:

— Тынычлан, туган, тынычлан... Хатын-кыз өчен үләләр ди мени, дивана...

Ниһаять, Мәрданша бераз тынычлангандай булды.

— Нишләп мин берәр су җанвары булып тумаганмын икән,— дип көрсенде ул.— Кая, тәмәке бир әле.

Гаделша кесәсеннән папирос кабы чыгарды, дуслар тәмләп тәмәке кабыздылар.

— Тынычландыңмы инде? — диде Гаделша шактый вакыт сөйләшмичә утыргач.

— Ничек тынычланыйм инде... Җанда тынгылык юк.— Ул кинәт елмайды.— Карале, кордаш, ул бит мине алай бик дошман итми.

— Кем?

— Су анасы.

— Нишләп инде ул сине дошман итсен ди?!. Син бигрәк инде тагын...

— Минем әле өметем бар,— дип дәвам итте Мәрданша.— Ышанмый ул миңа... Үзең уйлап кара — тарагын да урла... шуннан соң яратам да диген... Миннән дә әшәке кеше бар микән бу дөньяда?!. Ничек ышансын ди инде ул миңа... Аны аңлап була...

— Шулай, шулай,— дигән булды Гаделша, дустының тынычланып барганын сизеп, тыпырчынмавына куанып.

Мәрданша Нуретдингә мөрәҗәгать итте:

— Нуретдин абый, пажалысты, бүгеннән башлап сыерларыңны елгага кертмә, яме!

— Нишләмә? — диде чукрак.

— Сыерларыңны елгага кертмә, дим. Мин сиңа шуның өчен калага барган саен тәмәке алып кайтырмын.

— Тәмәке?! Ниндине? — дип кызыксынды көтүче.

— Син ярата торганны — «Актаныш таңнары» дигәнне.

— «Сарман болыннары» дигәне юкмы соң аның? Мин бит үзем Сарман ягында тудым...

— Белмим,— дип кычкырды Мәрданша.— Андые булса, алып кайтырмын анысын да. Түлке, зинһар, сыерларыңны Зәйгә кертмә, яме.

— Ник???

— Соң инде... Ник дип... Су анасы яши торган елгага сыер кертәләр димени?!

— Ярар, ярар,— диде Нуретдин, ризалык белдереп.— Калага кайчан барасың?

— Шушы көннәрдә.

— «Астра» булмасмы,— диде Нуретдин.

— Ярар, карармын. Нуретдин абый, тагын бер гозерем бар сиңа.

— Нисең бар???

Мәрданша көтүченең колагына кычкырырга мәҗбүр булды:

— Тагын бер гозерем бар мәйтәм. Син, Нуретдин абый, олы кеше бит инде... Алла хакы өчен, син елгага печ итүеңне ташла инде!

— Ниемне ташлыйм елгага? — диде чукрак, аңламыйча.
— Елгага печ итмә! — дип кычкырды Мәрданша. — Шундый затлы хатын яши торган суга печ итү бер дә матур түгел, Нуретдин абый... Оят түгелме сиңа?..
Гаделша да пичәт сугып куйды:
— Әйе, беткәнмени сиңа башка урын...
— Ярар, ярар, барыгыз да грамытный... — дип мыгырдады Нуретдин.
Мәрданша авызын күнитек куныч кадәр итеп җәеп елмайды:
— Их, Гаделша, мин бит Аның белән сөйләштем.
— Әйбәт булган, — диде Гаделша, дустының артык хисләргә бирелеп утыруыннан туя башлап. — Суга гына чума күрмә... йә муеныңны сындырырсың...
— Нишләргә соң инде миңа хәзер? — диде Мәрданша.
— Уйларга кирәк... — диде Гаделша.
Шулвакытны гына Мәрданша Халисәне күреп алды.
Мескен хатын ярты сәгать буе, куакларга сыенып, күзәтеп тора иде. Мәрданша аңа дәште.
— Халисә, кил әле якынрак.
Халисә курка-курка гына атлады, берничә адымнан соң туктады.
— Кая... борыл әле, — диде Мәрданша, репетициядәге режиссерга охшатып.
Халисә борылды.
— Йөреп күрсәт! — дип боерды «режиссер» һәм Халисәне җентекләп күзәтә башлады.
Халисә көтмәгәндә чәчрәп чыкты:
— Тагын нәрсә эшләп күрсәтим?.. Син нәрсә... Әллә мине шул сасый башлаган балык белән чагыштырып карамакчы буласыңмы?!. Мин барысын да күреп, ишетеп тордым. Тьфү! Әй, Мәрданша, Мәрданша... Чистый акылың юк икән!..
Ул тагын өч-дүрт тапкыр төкерде дә җәйләү фермасы ягына китеп барды.
Мәрданша башын чайкады:
— Ай-яй-яй... Менә сиңа, Гаделша, Халисә әйбәт, Халисә матур, дисең... Йә әйт әле, шушындый хатын матур буламы инде?!. Су анасын сасый башлаган балык ди бит... Ай-яй-яй...
— Соң инде, Мәрди туган, Халисәне дә аңларга кирәк, — диде Гаделша. — Ул бит сине ярата, көнләшә... Син дә бит, Су анасын яраткач, урлашуга кадәр барып җиттең... Барыбер Халисә әйбәт хатын.
— Әй, ачуымны китереп утырма әле, — диде Мәрданша һәм Нуретдингә дәште. — Нуретдин абый, Халисә матурмы, теге хатынмы?..
Нуретдин аңламады:
— Нинди хатынны???
Мәрданша тагын да катырак кычкырды:
— Мәйтәм, кайсысы чибәррәк — теге хатынмы, әллә Халисәме?
— Теге судагысы лутчырак, — диде Нуретдин.
Мәрданшаның йөзе яктырып китте.
— Әйтәм бит... — Ул Гаделшаның җилкәсенә шапылдатып сукты. — Ишеттеңме, дөнья күргән кеше нәрсә диде?..
Гаделша пырхылдап көлде.
— Дөнья күргән дип... Менә шушы әрәмәлек инде аның күргән дөньясы. Ул Су анасы белән син барыбер рәхәт күрмәячәксең... Ул гомер буе шулай кайта-китә йөрәячәк. То Иделгә... то диңгезгә... Халисә ышанычлы, ул кусаң да китмәячәк.
— Аптыраттың инде — Халисә дә Халисә... — диде Мәрданша, төкерекләрен чәчеп.
Гаделша кул селтәде:
— Теләсәң нишлә...

Мәрданша Нуретдин белән киңәшләшеп карарга булды:
— Нуретдин абый, нишлим икән?
Көтүче чыраен чытты, кыяфәтенә акыллы төс кертте:
— Закидушкага капмас ул,— диде житди тавыш белән,— ятьмә белән кереп карарга кирәк...
Гаделша шатланып әйтә куйды.
— Минем башыма тагын бер хәйлә килде!
— Тагын нәрсә уйлап таптың инде?— диде Мәрданша битарафлык белән.
— Мәрди туган, беләсеңме ничек итеп Су анасын синеке итеп була...
— Ничек итеп?
Гаделша як-ягына каранып пышылдады:
— Аның үзен урларга кирәк!
— Кемне?— диде Мәрданша, куркып.
— Су анасын... урларга кирәк!
— Нәрсә-ә-ә?!.
Гаделша кызып китте:
— Син күзләреңне акайтмый тор әле... Кыз урлау безнең татарда бар бит ул... Берәр көнне киләбез дә, судан чыкканын көтеп торабыз... Өстенә сикерәбез дә, бәйләп капчыкка салабыз... Аннары синең өеңә алып кайтабыз. Анда инде калганын үзең карыйсың. Бу — бердәнбер чара... Миңлебай бүлнистә чакта моны эшләп калырга кирәк. Син әле ишетмәгәнсеңдер: анда Миңлебай тик кенә ятмый, ди... Аның шикелле участковыйлар психбольницада бик күп, ди... Врачлардан, санитарлардан качып, Миңлебай шуларны совещаниеләргә җыя икән... Бөтендөнья участковыйлар корылтаен уздырырга карар кылганнар, ди... Илдә участковыйлар влачка килгәч, иң беренче чиратта, Зәй елгасын корытып киптерү күздә тотыла, ди... Аннан соң халыкның таракларын, расческаларын конфискацияләү булачак, ди... Әле тагын әллә ниләр булып бетүе ихтимал. Тизрәк Су анасы белән закон кушканча никахлашырга кирәк сиңа. Ул вакытта инде Миңлебай да, беркем дә бернишли алмаячак... Ул бүлнистә чакта бу эшне тәмамлыйк без... Урлыйк Су анасын!

* * *

Мәрданша да җанланып китте.
— Урлыйк дисеңме?!.
— Урлыйк!
— Ничек итеп?
— Анысын уйлашырбыз.
Мәрданша Нуретдин белән дә киңәшләшергә кирәк тапты:
— Нуретдин абый! Су анасын урлыйбызмы?
«Урлыйбызмы» сүзен ишеткәч, Нуретдин сикереп торды, башын чайкады:
— Юк, җегетләр, мин катнашмыйм! Мине бүтән урлашуга да, судлашуга да катыштырмагыз инде.
Гаделша яр өстендә яткан ятьмәгә күз салды.
— Мәрди!— диде ул, күзләрен акайтып.— Әйдә хәзер үк ятьмә белән кереп карыйбыз!
Шуны гына көткән диярсең — Мәрданша сикереп торды да чишенә башлады.
— Нуретдин абый, әйдә син дә чишен!— диде Гаделша чалбарын салгач.
— Чишен, давай, эзләш,— диде Мәрданша,— трусиктан гына калгач.— Мин сиңа шуның өчен ай саен талонга алган шырпымны бирер барырмын. Син бит гел шырпыга интегеп йөрисең.
Шырпы дигәч Нуретдин дә чишенде.

... Бик озак айкадылар алар Зәйне.

Су төбеннән тимерчыбыклар, консервы калайлары, тагын әллә ниләр, әллә ниләр чыкты. Хәтта Миңлебайның таракны эзләгәндә төшеп калган сыңар ботинкасын да ятьмәгә эләктерделәр.

Су анасы гына койрыгын да күрсәтмәде.

... Алар хәлдән таеп, ярга чыгып утырдылар.

— Шылган бу моннан... соңгарак калдык,— диде Гаделша, көчкә сулыш алып.

Мәрданша өметен тәмам җуярга теләмәде.

— Әллә тагын кереп карыйкмы?

— Тукта, хәл алыйк әле бераз.

— Ятьмә бәләкәйрәк...

Шулвакыт Гаделша чак кычкырып җибәрмәде.

— Әнә ул!

Чыннан да, илле адым чамасы читтәрәк, Су анасы күренде. Ул ирләрне шәйләмәде, тал төбенә барып утырды.

— Әйдә, бәйләп алып кайтып китәбез,— диде Гаделша.

Мәрданша кырт кисте:

— Юк. Ярамый. Җүләрләнден мәллә?!. Кычкыра башласа нишләрбез?!. Көчләргә маташтылар дип, төрмәгә тыгып куячаклар бит... Барыгыз, сез югалып торыгыз! Өчәү булгач, куркыр ул бездән.

Гаделша белән Нуретдинне әрәмәлек йотты.

Мәрданша, үзенең трусиктан гына икәнлеген дә онытып, аягүрә басты һәм Су анасына дәште:

— Матурым!

Су анасы сискәнеп китте.

— Суны сез болгатып бетердегезме?— диде ул, ачу белән.

— Әйе.

— Ни эзләдегез соң сез су төбендә?

Мәрданша, ни әйтергә белмәгәч:

— Миңлебаевның ботинкасын,— диде.

— Таптыгызмы соң?

— Берсен генә.

Мәрданша Су анасына таба атлады.

— Якын килмә!— дип боерды Су анасы.

Мәрданша шып туктады.

— Яратам мин сине, гүзәлем!— диде ул, еламсырап.

Су анасы авыр сулап куйды.

— Әй, кешеләр... Нишләп сез гүзәллекне әкиятләрдән генә эзлисез? Нишләп сез көн саен очрап торган матурлыкны инкарь итәсез?

— Миңа син кирәк!— дип кычкырды Мәрданша.

Су анасы елмайгандай итте.

— Миңа синең бер сыйфатың ошады, Мәрданша. Элек-электән кешеләр минем алтын тарагыма кызыктылар. Хәер, аңа хәзер дә күзләре бик кыза. Ә менә син алтынга түгел, үземә гашыйк булдың. Матурлыгыма сокландың. Ләкин мин әкият бит... Ә Халисә әкият түгел...

— Әй, Халисә— Халисә инде ул...— диде Мәрданша ачуланып.— Халисә Су анасы булалмый бит...

— Резин итек киеп, кояшта каралып, ферма тирәсендә йөрсәм, миңа да гашыйк булмас идең... Ярый, киттем мин!

— Туктале! Әйт инде тагын бер генә сүз булса да! Җүләрләнәм бугай бит инде мин... Җүләрләр йортына җибәрсәләр, нишләрмен... Миңлебаев шунда ята бит. Дөньяда иң куркыныч кеше Миңлебаев бит...

— Теге, сезнең участковыйммы?

— Әйе. Шул инде. Акылдан язды бит.

— Сезне аерым юләрләр йортына ябып интектерергә кирәк түгел инде,— диде Су анасы, елмаеп.— Сез бит барыгыз да тулар-тулмас...

Япкач, барыгызны да ябып куярга кирәк. Ачуланма, ярым шаярып әйтәм мин бу сүзләрне.

— Юк, юк, ниткән ачулану ди ул... Син үзең миңа ачуланма, гафу ит мине,— диде Мәрданша.

Су анасының сылу йөзенә моңсулык йөгерде.

— Ачуланмыйм, Мәрданша. Минем дә сине ачуланырга хакым юк. Дөньяның буталчыклыгында синең дә, минем дә гаебебез юк. Буталып бетте бөтен нәрсә, адашып беттек барыбыз да. Тик шуны беләсе иде — кем гаепле икән?..

Су анасы елгага таба атлады.

— Ташлама мине! — дигән сүзләр Мәрданшаның кай төшеннән чыкканын әйтүе кыен.— Китмә!

Су анасы тукталып бик озак Мәрданшага карап торды.

— Мин бит бөтенләйгә китмим,— диде ул.— Кызганыч, мин мәңгегә кешеләр белән булырга хөкем ителгән.

— Ник... Сиңа кешеләр белән читенмени?

— Мондый табигатьтә әкият яши аламы соң?.. Сез үзегез дөньяны төрле әкиятләр белән бизәргә тырышасыз, ә үзегез әкият кебек саф дөньягызны пычратып яшисез. Болай булса, кешеләрдә әкиятнең үлүе дә ихтимал.

— Анысы шулай инде,— дигән булды Мәрданша.

— Сау бул, Мәрданша!

Су анасы елгага чумды.

— Ташлама мине! — дигән авазны Мәрданша гына түгел, бөтен Зәй төбәге кычкырды.

* * *

Теләгенә ирешә алмаса да, Су анасы белән очрашу Мәрданшаны билгесезлекнең салкын кочагыннан йолкып алды. Мәхәббәте бөтенләй үк сүрелеп бетмәсә дә, ул тынычланды диярлек.

Гаделша дустының күктән җиргә төшүенә куанды. Дөрес, алтын таракны булмаганга аның бераз үпкәсе дә юк түгел иде, ләкин ахиренең ихтыярына каршы килүне мөмкин дип санамады.

Нуретдингә, кем әйтмешли, ике дөнья — бер морҗа дигәндәй. Су анасы да, алтын да кирәк түгел иде.

Миңлебаев тынычланмады. Аның алтын тарак турында авыз кырыйларын күбекләндереп сөйләгәннәренә җүләрләр йортында беркем дә ышанмады. Җүләр тек җүләр!.. Ул больницадан чыга да, Зәй буенда исәнәеп йөри. Аннары барып Җырыклы халкына, бигрәк тә Мәрданшага бәйләнә. Шуннан соң аны яңадан дәваланырга алып китәләр.

Халисә Мәрданшаны барыбер «ташламады». Мәрданша да аңа карата җылынды, бигүк каты орынмый башлады.

Авыл халкы тик ятмады. Зәйне ятьмәләр белән айкап карадылар, кәрҗиннәр белән дә сөзделәр, хәтта каяндыр динамит табып, шартлатып та карадылар. Динамит шартлагач су төбеннән Миңлебаевның икенче ботинкасы да калкып чыкты.

Тоталмадылар Су анасын. Һәм бу эшкә кул селтәделәр.

Каладан да ниндидер сәер кешеләр килеп йөрделәр Зәй буена. Алар да нәрсәнедер, кемнедер бик озак эзләделәр. Бераздан алар да күренми башлады.

Тормыш ыгы-зыгысында, дөнья куып, Су анасы турында оныттылар. Су анасын Мәрданша гына онытaлмады. Аның күңелендә ул тормышка ашмаган якты хыял булып, үкенү-офтану булып, беркайчан да гафу ителмәслек гаеп-хата булып, мәңгегә сеңеп калды.

* * *

Әйе, Су анасы турында, бер кешедән башка, барысы да оныттылар.

Зәйнең суы тагын да ныграк пычранды.

Тирә-яктагы болыннарны сукалап бетерделәр.

Химкомбинаттан сирпелгән агулы томан куерак һәм ачырак булып чыга башлады.

Тау өстендәге шәһәр чүплеге болытларга кадәр күтәрелде. Аның исеннән хәтта сыерлар да борыннарын кысып уза башладылар, хәтта аларның мөгрәү тавышлары үзгәрде.

Табигатьнең җанны иркәләрдәй авазлары да әрәмәлек эченнән ишетелмәс булды.

Бик сирәк кенә куе әрәмә эченнән Саңгырау Нуретдиннең әшәке итеп сүгенгәне табигый тавыш булып ишетелеп куя. Көтүченең галәмәт көчкә ия булган сүгенүе дә табигатьне буып үтерергә килгән заман сулышына бәрелеп каядыр юк була.

Ләкин ни гаҗәп: әле һаман күңелләргә өмет биреп, Зәй буйларын яктыртырга тырышып адәм балаларына җылылык вәгъдә итеп, көн саен тау артыннан Кояш килеп чыга...

*1990—1992.*



## Харрас Әюп



### Бишексезләр өчен бишек җыры

Шигырь укып йөрер заманмыни! —
Акыл керер чактыр миңа да:
Ни гомерләр яшәп,
Бишегемнән
Чыгалмыйча калдым, дивана...

Сезне дә мин тирбәтмәкче булам:
Юанырсыз, димен, ничек сез?
Сиртмәсенә кагыласы итсәм —
Күбегезнең жаны бишексез...

Кем күтәреп алыр, кем юатыр? —
Җаннарыгыз һаман сабый ла!
Сарыла ул...
Тирбәтмиләр генә —
Тирбәләсе килгән чагында.

Сиртмәсенә кагыласы итсәм,
Күпләрегез бүген бишексез.
Бәгырегез катыланып беткән,
Таш өстенә егылып төшеп сез.

Мин бит һаман тирбәтмәкче сезне,
Җырларыма салып, дивана,
Чыгалмыйча калдым бишекләрдән...
Тирбәтүче юк шул миңа да!

---

Харрас ӘЮП (1946) — *шагыйрь, «Ышаныч», «Коңшылы яңгыр», «Төнге кояшлар» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## «Мич» янында

Бер биюче булган:
Биеп китә
Алган, имеш, мич янышнан гына...
Каләм төртелгәндә мин дә кайтып
Егыламын туган туфрагыма.

Яшел чирәменә егыламын...
Үзем кайталмасам, җаным кайта:
Тып-тын гына керә урманнарга...
Сыза йөрәк...
Бар илһамым кайта!

Елга ничә урый торганмындыр —
Исәпләре генә исемдә юк.
«Биеп» китәм шулай...
Ә бит юкса
Ул авылда инде мичем дә юк.

Миче булмаса да, уты яна...
Үзәкләргә үтеп яна уты!
Судан алып, утка сала икән,
Сала икән бер көн анаң йорты...

* * *

...Авыл ачлы-туклы.
Кырда — ачы кукы.
Агач башларында — күкеләр.
Алар ничә кабат
Гомерләрне санап,
Очын-очка ялгап үттеләр...

Өзелмәде өмет.
Ачынмаган идек,
Ул кукылар ачы булса да.
Язлар белән килеп,
Сөрән салыр кебек
Яшьтәшләрнең кайсы булса да.

Заманнардан барлап,
Язмышларны ялгап
Йөри микән — күке кычкыра...
— Сиңа күпме, күке,
Кемнәр болай итте? —
Чыгалырсың микән очына!

Чорлар кара-каршы —
Кычкырадыр кайсы,
Бармы агач — моңнар кунмаган?
Искә төшә барсы:
Ачы, бигрәк ачы...
Ә кукылар...
Ә кукылар ачы булмаган!

## Печән чабу

Чалгы тотып яланнарга чыктым.
Үлән өсләренә чыклар яткан.
Печән чабу — теле авылымның,
Сагындырган икән, тансыклаткан.

Бер тамчы да онытылмаган ул,
Җиңел аңлашыла, сүзләр нигә?
Изүемне чишеп, чалгымны бер
Элеккечә янап җибәрим дә,

Сөйлә миңа, авыл, моң-зарыңны,
Читкә китеп беткән кызларыңны.
Селтәним дә, ялан түрләреннән
Каерып алыйм әле узганыңны!

...Әткәй печән чапкан җирләр бит бу,
Яланаяк йөргән яланнарым...
Үлән өсләрендә чыклар җем-җем —
Энҗе булып калган заманнарың.

Печән чабу — теле авылымның:
Ала кыеп, җиргә егып сала.
Мин үзем дә беләм гаебемне,
Чыраема берүк бәрмә сана!

Алдымдагы пакусымны чыгып,
Чалгымны бер янап җибәрим дә,
Уйларымны селтәп ташлыйм әле
Кендек каным тамган җирләремә.

Бу туфракта без бит җиләк идек,
Тансык идек аңа, кирәк идек.
Суырып алып киткәннәр шул инде —
Туган җирдә без бит йөрәк идек!..

Үлән өсләрендә чыклар җем-җем...
Элек белмәгәнбез — хәзер белдем:
Үткәннәргә чумып алалмыйсың,
Төпләренә төшеп киткәч энҗең.

...Чалгымны бер янап җибәрим дә,
Хәсрәтләрем минем монда сеңсен.
Гаҗизлектән иза чиккән җаннар
Туган туфрагының телен белсен!

## Әнкәемнең биш бөртеге

Без биш кенә бөртек идек.
Әллә кая сипте җилләр...
Сулар кипте, ауды урман,
Бездән башка бетте өйләр.

Килеп төште бу якларга
Әнкәемнең бер бөртеге.
Ничек итеп тамырланыр?—
Су сибәргә юк беркеме.

Таш өстенә килеп төште—
Яра алса гына ташны!
Туфрак кирәк икән, туфрак—
Күтәрәлер өчен башны...

Без биш кенә бөртек идек,
Сибелештек биш тарафка.
Кемнәр кемнең бөртегедер—
Тарата ла җил, тарата.

Калаларда, далаларда—
Берәм-берәм, бөртек-бөртек.
Кемдер эзләп табар төсле:
Анда бер төп, монда бер төп.

Илдә җилләр исеп калды,
Бәрәкәтләр күчеп калды,—
Әнкәемнең учларыннан
Биш бөртеге төшеп калды...

## Тел күрсәтә...

*Улым, сиңа әйтәм...*

Мәкальдән

Исем китеп торам кайчак:
Минем йортмы, бу—кем йорты?—
Балаларда—урыс теле,
Үз телләре—ярым-йорты.

«Бисмиллаң әйт,—диләр иде,—
Авызыңа шайтан керер...»
Кайчан керде балаларга?—
Без күрмәгәч, кемнәр күрер?!

Терсәк якын—тешләп булмый,
Җитми икән буй терсәккә.
Үз балаңның авызыннан
Явыз Иван тел күрсәтә...

* * *

Булыр-булмас мулла дин бозар, ди,
Булыр-булмас арба юл бозар...
Без дөньядан узып барган чакта
Карап тора күктән йолдызлар.

Сиңа кадәр күптән бозылган юл
Син узганга ничек төзәлсен?
Дөньялардан узып барган чакта
Кычкырмыйча ничек түзәрсең?!

Барчабызга жирдә юл бер генә:
Кемнәр төзәтер дә, кем бозар...
Мин дөньядан узып барган чакта
Карап калды күктә йолдызлар...

* * *

Бу дөньяда мине яраттылар.
Дөньяларын мин дә яраттым:
Ак җанымны җилләренә җәеп,
Шул дөньяда йөзеп каралттым.

Дөньяларын мин дә яраттым ла,
Яраттым ла азга булса да,—
Яратканнар — кала...
И җир йөзе!
Миннән соң да назга сусама...

* * *

Үз талына кунып сайрый кошлар...
Миңа гына ходай кушмаганмы?—
Гомерем буе учларымда йөртәм
Очыралмый калган кош баламны.

Йөрәгеңнән егылып төшеп калды...
Талды кулым, кая куйыйм икән?
Нинди генә мәхәббәт юк җирдә—
Мондые да аның булыр икән!

Гомерем буе учларымда йөртәм,
Белә торып әйләнәсен утка.
Яна кулым, яна кошлы килеш...
Саргаялар таллар кошы юкка!

* * *

Бер — яшьлектә, бер — картлыкта, диләр,
Калды берәү, калды яшьлектә:
Йөгереп тә баралмыйсың икән,
Алалмыйсың икән дәшеп тә.

Бер — картлыкта.....
Тик нигәдер монсы
Картайганны көтеп тормады:
Чынлап килеп керде җаннарыма,
Әйләндереп салды дөньямны.

Исәрләнгән саен исләремдә,—
Картлар сүзен тыңла икән ул!

Бер — яшьлектә, бер — картлыкта түгел,
Кайчан сөйсәң — шунда икән ул...

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



*Зәки Лотфулла улы Зәйнуллин 1933 елның 10 июлендә Башкортстанның Эстәрлебаш авылында крәстиян гаиләсендә туган. 1940—50 елларда Эстәрлебаш татар урта мәктәбендә укый. 1950—52 елларда үз авылларында колхозда эшли, күрше Куганакбаш җидееллык мәктәбендә математика укыта.*

*1952—55 елларда Иркутск шәһәрендә хәрби авиация техник училищесендә укый, аны тәмамлап техник-лейтенант дәрәҗәсе ала.*

*1955—58 елларда Ленинград хәрби округында авиация технигы булып хезмәт итә. 1958—63 елларда Рига шәһәрендә Югары хәрби ракета училищесендә укый һәм инженер-механик булып чыга. 1963 елда Казагыстанда махсус белем алып, атом һәм водород бомбалары буенча белгеч була һәм шул юнәлештә 1967 елның февраленә кадәр хәрби частьләрдә эшли.*

*1967—70 елларда Рига Югары хәрби инженер-ракета училищесендә аспирантурага (адъюнктурага) укырга керә һәм аны уңышлы тәмамлап, 1970 елның апрелендә кандидатлык диссертациясе яклый.*

*1970—88 елларда Югары хәрби ракета училищеләрендә өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли һәм курсантлар укыта. 1981 елда полковник дәрәҗәсенә ия була. 1985 елда докторлык диссертациясе яклый. Оча торган аппаратларның ныклыгы буенча язылган алтмыштан артык фәнни хезмәтләре бар.*

*1989 елдан бирле — запастагы полковник.*

*«Мыжык» исемле беренче хикәясе 1978 елда «Чаян» журналында басыла. Шул вакыттан бирле актив иҗат эше белән шөгыльләнә. Хикәяләре һәм повестьлары тупланган өч китабы дөнья күрде: «Үрләр аша», «Сугыш алды малайлары», «Полковникны озату» һәм башка әсәрләрен китап укучылар бик җылы каршылады.*

*Бүгенге көндә ул яңа роман төгәлләп килә. З. Зәйнуллин — Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Июль аенда язучыга 60 яшь тула. Шул уңай белән каләмдәшебезне кайнар котлыйбыз һәм яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез.*

## Зәки Зәйнуллин

# ГАЛИНУР АБЗЫЙ ЯЗМЫШЫ

Автобус маршрутлары кассасында Чаллыга билетлар беткән иде. Ринат бинадан уйлана-уйлана чыкты. Ничек барып җитәргә? Иртәгә иртүк аңа Минзәләдә булырга кирәк бит. Кичен Казан — Уфа поездына утырырга карар кылды ул. Автовокзалдан чыгып барганда кинәт кемдер аңа дәште:

— Син грузинмы?

Сорау бик сәер янгырады. Ничек инде татар егете Ринат грузин булсын. Аннан соң, синең кем булуыңда автовокзалда кемнең ни эше булырга тиеш ди! Ринат сорау бирүчегә күтәрелеп карады. Өстендә кара эш плащы, аягында калын резин итекләр, башында колакчыннары күтәртеп бәйләнгән күн тышлы бүрек. Үзе берничә көн кырынмаган, тик эчкече түгеллеге күренеп тора.

— Грузин түгел мин,— диде Ринат, сорау бирүчене урап үтәргә тырышып. Сорау бирүче абзый кеше алтмыштан узган булырга тиеш. Төптән юан чыккан, уртача гәүдәле көчле зат.

— Юк инде,— диде агай,— китми тор әле син. Грузинлыгыңны нигә яшерәсең? Грузин син. Грузин булмагач, нигә дип андый зур фуражка киясең, ә?

Ринат көлеп җибәрде:

— Бер дус скульптор тегеп биргән иде. Истәлек итеп киярсең дип. Альфред исемле.

Агайның күзләре очкынланды:

— Ул скульптор грузинмы?

— Түгел лә, минем кебек үк татар.

Агай татарчага күчте:

— Әллә миңа син үзеңне татар димәкче буласынмы?

Ринат авызын ерып татарчалап җавап бирде:

— Соң татар булмыйча, тагын кем булыйм ди инде мин. Татар.

Агайның кәефе күзгә күренеп бозылды. Ул сүлпән генә тавыш белән әйтә куйды:

— Син болай да грузинга охшаган, өстәвенә аларныкы кебек кипке дә киеп куйгансың әнә...

Ул өмете өзелгән кешедәй кулын селтәде дә китә башлады. Шулчак яңа гына килеп туктаган Әлмәт автобусыннан зур кипкеләр кигән ике кавказлы килеп чыкты. Агай, Ринатның барлыгын да онытып, алар каршына ташланды. Кавказлыларга шул ук сорауны бирде:

— Сез грузиннармы?

Кылыч борынлы, таза гәүдәле ике кеше аңарга күз дә сирпемичә китеп бардылар. Тик агай аларның юлына тиз аркылы төште:

— Нигә җавап бирмисез! Сез грузиннармы?

Кавказлыларның берсе туктамый гына җавап бирде:

— Слюш-шай, дарагуй! Зачем аскарбляеш, а? Разве ми пахужи на грузина-таргаша? Уди з даруги, а то секим башка будет. Аситин ми, аситин. Пунял?!

Сәер абзый аларга юлны ачты да, кулына тоткан тартмасын күтәреп, автобуслар туктый торган җирдәге эскәмияләргә таба китеп барды. «Нинди әкәмәт кеше булды әле бу бәндә? Нәстәмә хәҗәт икән аңарга грузиннар?» — дип уйлады Ринат кызыксынып. Һәм баскан урыныннан кузгалмыйча теге кешене күзәтә башлады.

Абзый кеше, эскәмиягә барып утырды да, кулындагы кара тартманы ачып, аннан кечерәк кенә тальян гармун тартып чыгарды. Гармуны кара һәм кызыл төстә икән. Матурлап бизәлгән ике тынлы гармун иде. Абзый кабаланмый гына гармун каешына кулын тыгып уң як кулбашына киде дә, көттермичә гармунны сузып та җибәрде...

Автовокзалның көзге пычрак мәйданы күз алдында кинәт үзгәрде дә куйды! Көпә-көндез Казан каласында, сугышка кадәр һәм сугыштан соң авыл урамнарында кичләрен башланып, таң атканчы йөрәкләрне өзгәли торган урам көе моңы агыла башлады. Гармунның тавышы моңлы, көе тирән, ә гармунчысы үтә дә оста уйный иде. Тальянда үзе дә азрак уйный белгән Ринат әлеге агайның искиткеч матур итеп уйнавын көй башлангында ук сизеп алды. Гармуннан агылган авыл көенә сихерләнеп, уйнаучы янына барып басканын үзе дә сизми калды. Доньясын онытып тыңлый. Аның өчен хәзер алынмаган билет та, Әлмәт тә, Минзәлә дә, автобуспоездлар да юк иде. Ә кырынмаган агай беркемне күрми дә, ишетми дә.

Барлык яшәеше белән гармунга ике куллап ябышып алган да уйный да уйный. Бер татар көеннән икенчесенә күчә, өченчесенә... Бар да урам көйләре, бар да авыл көйләре. Тальяннан агылган татар моңнарында — җан тетрәткеч кайгы, сагыш... Әйтерсең лә инде гармун еламый, ә абзый үзе бөтен галәмне тутырып кайгысын сөйли.

Азлап-азлап халык җыйналды. Таралды. Тагын җыйналды, тагын таралды. Кешеләр сүзсез генә моңнарны тыңлый да, һәркем үз юлы белән салмак кына китеп бара. Кемдә, кемнең кайгысы! Мондагы кешеләрнең күбесе юлчылар. Юлчының юлда булганы хәерле!

Байтак кына уйнагач, агай, һич көтмәгәндә, аз гына карлыкканрак тавыш белән, үзе уйнаганга кушылып җырлап җибәрде:

Әй, егетләр, егетләр,
Кайда безнең өметләр?
Тирә-як тулы бәхетсез,
Бар да минем кебекләр.

Җырның сүзләре, җырлаучы агайның кара күзләре тулы сагыш Ринатны тетрәндерде. Ул аңлады: бу гармунчы абзыйның башкаена кеше йөрәге күтәрә алмаслык кайгы төшкәндер.

Абзый җырын ничек капылт башласа, шулай ук капылт туктатты да башын күтәреп Ринатка карады:

— Син, энекәш, миңа нәрсәдер әйтергә телисең бугай?

Абзыйның бу сүзләре, син, энекәш, минем кайгым турында сораш, дигән кебегрәк яңгырады.

— Юк,— диде Ринат,— мин болай гына. Бик моңлы уйныйсың. Китеп булмый яныңнан, абзый.

Гармунчы тамагындагы төерне авыр итеп йотты да зур учлары белән ике куллап тальянын сыйпады:

— Шушы сандугачны алырга дип килдем мин Казанга. Пропадаю мин, энем...

Ринат иплəп кенә сорыйсы итте:

— Нәрсә булды, абзый? Кайгың бик зур, ахрысы?

Гармунчы кан баскан, кайгылы, сагышлы күзләре белән бер ноктага карап торды, әчке бер зур авырлык белән көрсенде:

— Бердәнбер оныгымны үтерделәр минем. Үткән айда гына. Грузиядә...

— Ничек инде үтерделәр?

— Кем белсен инде ничек икәнен?! Атыптыр, бәлки. Бәлки, танк астына тыкканнардыр. Солдат бит. Абхазларга ярдәмгә дип, Ельцин генераллары җибәргәннәр аны Грузиягә.

Ринат абзыйга якынрак килеп утырды. Ә тегесе, ике куллап тальянын кочаклаган хәлдә, сүзсез генә утыра һәм аның һәр күзәнәгеннән кайгы, хәсрәт агыла сыман.

— Бәлки, исәндер әле... Төрле хәлләр була бит...

Абзый Ринат әйткәнне әллә ишетте, әллә юк. Тагын азрак дәшми утырды да, ниһаять телгә килде:

— Исемем Галинур минем. Егерме алтынчы елгы үзем. Унсигезем тулмас борын алып киттеләр мине сугышка. Кызлар кулы да тотып карамаган идем әле. Немецкә каршы чыкмастан ел ярым сугыштым. Ике орденым, өч медалем, өч җәрәхәтем бар. Берсе каты җәрәхәт. Ярты кеше инде мин, тыштан бөтен күренсәм дә... Авылга кайттым. Сугыш бетеп ике ел үткәч кенә. Госпитальдән чыгып. Илле беренче елны гына өйләнерлек хәлгә җиттем. Кайтуын кайттым. Белем юк, һөнәр юк. Киттем чыгып калхуз эшенә, сәнәк, балта күтәреп. Шулай менә, энем, тормышлар... Илле икенче елны, декабрьдә хатын бәләкәч кенә бер малай табып бирде. Хатын болай әйбәт булды минем. Ашка-суга дигәндәй. Ир итеп саный, хөрмәт итә белә. Гомере буена каршы бер сүз әйтмәде миңа. Тик бер ягы гына...

Галинур абзый азрак эндәшмичә утырды да, сөйләргә була ахрысы дигәндәй, сүзен дәвам итте:

— Хатын сугыш елларында торф чыгаруда эшләгән булган. Сазлыктан кәржин белән күтәреп торф ташыганнар. Ат керерлек җиргә кадәр. Саулыгы бик зәгыйфь иде. Малай да, шунлыктандыр инде, кечкенә булды, бик еш авырды. Иллә дә акыра иде инде елап. Көн-төн. Хатын бүтәнчә бала китерәлмәде дөньяга. Күренмәгән врачлар, әби-сәби калмады. Полтавага кадәр алып бардым бер карчыкка. Шул хахул карчыгы әйтте. Башкача баласы булмас, диде.

Малайны бик зур яфалар белән үстердек. Үсә торгач, аннан соң ныгып китте. Үзем кебек төптән юан чыккан егеткә әйләнде. Унтугызы тулар-тулмаста өйләндердем мин моны. Күрше кызына. Малай тракторист иде минем. Китте әрмиягә. Кайтуын көтеп алдык. Әй, киткән кебек иде дөньялар ямьләнеп, күзләр ачылып. Юк, булмады...

Галинур абзыйның йөзе каралып чыкты. Иреннәре күгәрде. Ул калтырый башлаган куллары белән чытырдап тальянына ябышты.

— Кайткач, малай ярты ел чамасы гына яшәде дә, үлеп китте. Исеме Шаһинур иде. Ә оныкның исеме Хаҗинур. Без барыбыз да Нурлар. Әрмиядән кайткач, малай бер генә көн дә эшкә чыкмады. Барды да ятты, барды да ятты. Малайны күмеп өч ел үткәч, килен булган кеше икенчегә кияүгә чыкты. Яшь бит. Үлгән артыннан үлеп булмый. Кияүгә киткәндә минем хатынга:

— Шаһинурны әрмиядән кыйнап, имгәтеп кайтарганнар. Һавага чөеп, артына утыртканнар. Шуңардан үлде ул,— дигән. Да-а, мала-а-ай! Менә шулай, энем, эшләр!

Килен авылдан ук китте чыгып икенче ире белән. Мин яңа кияүдән, елый-елый, тезләнеп, үтенеп дигәндәй оныгымны сорап алдым. Бөтенләйгә, үзебезгә үк, хатын белән икебезгә. Бирде бу кеше безнең малайны үзебезгә. Гомерем буена рәхмәтләр укып, мин аңарга бары яхшылык кына телим...

Үстердек оныкны хатын белән икәүләшеп. Шәп булып үсте Хаҗинур. Үсте бу малай, унны бетерде. Зур укуга китмәде. Ә укуы шәп иде. Бик тә тарихны ярата торган иде...

КамАЗ машинасында шофер булып эшләде. Ике ел. Без инде картлар, китмә әрмиягә, дип караган идем, тыңламады. «Дөнья күреп кайтам да, аннан соң авылдан беркая да китмичә сезне карап яшәрмен»,— диде бу. Әрмиягә киткәнче өйлән, дип тә карадык. Юк, тыңламады. Солдаттан кайткач кызлар белән йөрисе бар әле, дип көлде. Иртә өйләндерсәгез, йә кызлар белән йөрисе килә башлар, дигән була бу. Үзе көлә. Уенкөлкегә шәп иде малай...

Үтерделәр грузиннар малайны. Ә без карчык белән кемгә калдык инде хәзер? Карт белән карчыкны кем карар?! Үзем малай көенә сугыштым, улымны имгәтеп үтерделәр, оныгымны читтә үтерттеләр. Берәр грузинны бугазыннан алыйммы әллә, дип, шуларны эзләп йөредем бүген. Шуны эшләсәм, бәлки, йөрәк басылыр кебек. Син ничек уйлыйсың, энекәш? Дәшмисең. Барыбыз да дәшмибез шул. Кыйныйлар, аталар безне, үтерәләр. Без дәшмибез. Саталар, кисәләр, талыйлар — дәшмибез. Ә бит безнең улларыбызны, оныкларыбызны үтертүчеләрдән бүген без кан костырырга тиешбез!

Абзый ике куллап, малаен сыйпаган кебек итеп, тальянын сыйпый. Аның йөзендә күңелсез генә елмаюга охшаш нәрсә пәйда була.

— Бу тальянны баҗайдан сатып алырга дип килгән идем. Бир, мин әйтәм, яңа алган гармуныңны. Синең бирәү бар бит инде. Өч хакын түлим, мин әйтәм... Акча алмыйча гына тоттырды. Түләрдәй булсаң, бирмим, ди. Ходайның рәхмәте төшкере! Инде менә үзем уйныйм, ә җылап булмый...

Галинур абзый тальянына кушылып тагын җырлый башлады:

Әй, егетләр, егетләр,
Кайда безнең өметләр?..

# ӨЗЕЛГӘН КЫЛЛАР

Кече капка шыгырдаганга Мәргүбә әби, утырган җиреннән кузгалмыйча гына, тәрәзәдән үрелеп карады. Ишек алдына күрше хатын Рабига, нindидер таныш булмаган икенче хатынны ияртеп кереп килә икән.

Кулына юл сумкасы тоткан, шәһәрчә киенгән, урта яшьләрдәге бу хатын әбигә таныш түгел иде. «Кем булыр икән?» — дип уйлады әби. Шул уйлары белән бергә кузгалып, чоланга чыга торган ишекне ачып эндәште:

— Әйдүк, хуш киләсез! Үтегез өйгә!

Мәргүбә әбинең пөхтәлеген яхшы белгән Рабига, болдырны узмас борын ук аягындагы галошларын салып, оекбаштан гына атлады... Болдырны узгач, кунак хатынга борылды:

— Әйдә, апа, үт! Син сораган кешеләрне белсә Мәргүбә әби белә инде. Нигъмәтулла бабайны җирләгәннән соң, безнең урам хакында иң күпне белгән кеше булып ул калды инде. Үт әйдә, үт!

Кыстауга Мәргүбә әби дә кушылды:

— Узыгыз түрдән, рәхим итегез!

Кунакка түрдән, дивар янында торган диваннан урын күрсәтте.

— Утырыгыз. Юлдан килгән күренәсез.

— Рәхмәт,— диде хатын,— юлдан шул мин. Ерактанмын, инде юлга чыкканга бүген бишенче көн.

Мәргүбә әби урыннан торды:

— Кая, чәй әзерлим әле. Син, туганым, юынып ал. Рабига, бар, кайда юынырга икәнен күрсәтче үзенә!

Юынып кергән хатын тагын диваннан урын алгач, Рабига сөйли башлады:

— Син тыңлале, Мәргүбә әби. Әллә кемне сораша ул. Ә мин белмим икән. Аты белән үтеп барган Сәлимҗанны туктаткан идем, ул да белми.

Мәргүбә әбинең бернәрсә дә аңламаганын сизде дә, тагын аңлатырга тырыша башлады.

— Колонкага суга дип чыккан идем. Халморза ике машина белән урманга утынга китте. Эшләгән кешеләрне ашатырга кирәк бит. Шулар кайтуга аш салырмын дигән идем. Су алып торганда менә бу хатын минем янымa килеп исәнләште дә сораша башлады. Ике сәгать инде йөрим авылыгызда, белгән кешене таба алмадым, ди. Инде менә таптым бугай, менә бу тыкрык белән киткән юлның исеме Чуаш юлымы, ди. Шул Чуаш юлы авылдан чыккан җирдә яшәгән Габдерафыйк бабайның йорты кайда, ди. Нигә ул йорт сиңа, дим. Ә ул әйтә, мин шул Габдерафыйк бабайның улы Зиннәтулланың кызы Венера булам, ди. Уйлап-уйлап карадым, Габдерафыйк бабайның андый исемле улы юк иде бит. Читтә йөргән теге свирсручник Гайнулласы да, аннан әле өендә дөнья көткән теге төпчеге Рәвил бит инде. Бүтән Габдерафыйкне мин белмим.

Мәргүбә әби Рабиганың сүзен бүлде:

— Ярар, Рабига иркәм, син бар, ашыңны кара. Эштән кайткан кешене иң башта ашатырга кирәк. Кичен чәйгә кер, шунда сөйләшеп бетерербез.

— Әй, чыннан да, аш саласым бар бит әле минем. Кеше белән сөйләшә башласам, дөньямны оныта торган гадәтем бар шул...

Ишектән кабаланып чыгып киткән күршесе артыннан Мәргүбә әби елмаеп карап калды да, диванда утырган хатынга борылды.

— Тартынып торма, сеңлем, иркенләп утыр. Улым бик әйбәт минем, улымнан да киленем шәп. Иркенләп утыр, көтелмәгән кунак бит син безнең өчен...

Нәрсәдер әйтергә дигән җиреннән азрак үзен тыйды да, эчке бер җылылык белән өстәп куйды:

— Кунакның да кадерлесе син безгә... Исемең Венера бит әле?
— Әйе.
— Әниең исәнме?
— Юк шул. Җирләгәнгә ел тулып үтте инде.
— Ә-ә, шулаймыни?! Урыны җәннәттә булсын инде.
— Әллә белә идегезме?
— Әтиеңне бик яхшы белә идем, иркәм. Әниең безнең авылга бер генә кайтып китте бугай. Ул бит әтиеңнең икенче хатыны иде. Ә монда авылда Зиннәтулла абзыйның тәүге хатынының туганнары бик күпләр иде. Шунлыктан кайтмады. Зиннәтулла абзыйның әнисе үгәй иде. Камун булганга, әтиең бик өнәп тә бетерми иде. Онытылган инде, бар да истә торамыни инде. Әниең миннән ике-өч яшькә генә зуррак иде шикелле...
— Уникенче елгы иде ул.
— Үзең генәме, тагын туганнарың бармы?
— Бер энем бар. Марс исемле. Алмалык дигән үзбәк каласында яши. Әтине алып киткәндә яңа гына туган бала иде ул...
— Без монда ишетеп кенә белдек инде аны алганнарын. Аннан соң китте, аннан соң китте. Дус-ишләрен дә җыйдылар аннан. Минем әти сугыш беткәнче утырды. Аннан соң гына чыгардылар...
Венера сорау катыш күз карашын Мәргубәдән алмады:
— Апа, сез, чыннан да, белә идегезме минем әтине. Әнә бит Рабига белми.
— Син, иркәм, аңарга аптырама. Кай вакытта белгәне дә белмәгән булып кылана. Ә Рабига, чыннан да, белми ул. Читтән төшкән килен бит ул, безнең авылныкы түгел. Күңеленә авыр алма, синең әтиеңне белгән кеше бик аз калды авылда. Белгәне дә онытырга тырыша. Әле хәзер менә азрак йомшарды дөнья, ай-һай, элекләре хәтәр иде бит.
Картәтиең Габдерафыйк бабай кырык алтынчы елны үлде. Бик-ик йончып китте мәрхүм. Үлер алдыннан бер атна кала, минем әтине чакырткан. Әти минем сугыш беткән елны көзен кайтты. Синең әтиең Зиннәтулла абзый белән минем әти егерменче еллар башында, синең әтиең Гражданнар сугышыннан кайткач, берничә ел бергә эшләгәннәр ие. Картәтиең, үләрен белептер инде, әтигә әйтеп калдырган: Зиннәтулламның балалары табылып авылга кайтып күренсәләр, син, Ибраһим, аларга сөйлә инде безнең кем булганны, дигән.
— Әтиегез юктыр инде хәзер?
— Алтмыш бишенче елны язын үлде. Сиксәннең өстендә иде. Күңеләңә авыр алма, туганым, сорыйм әле синнән...
— Сора, апа, сора.
— Синең кайтуыңның сәбәбе нәрсәдә?
— Әнием үлер алдыннан әйтте. Кайтыгыз, әтиегезнең туган авылына, туганнарын табыгыз, йөрешегез, диде. Япа-ялгыз читтә йөремәгез, туган илегез, әтиегезнең авылы бар, туганнарын табыгыз, диде. Балаларыгызга күрсәтегез, диде. Энем Марс белән сөйләштем дә, башта мин кайтып килергә булдым...
— Әтиең туып үскән йорт урынын күрсәтербез, иркәм. Бүгенге көнне анда әтиеңнең ата бер, әнкә башка булган энесе яши. Төп йортта сезнең нәсел дөнья көтә. Утызынчы елны туган кеше ул. Мин бу йортка килен булып төшкәндә ике яшьлек кенә ыштансыз малай иде әле ул.
— Әле дә исәнме?
— Исәнлеккә исән инде, кая булсын. Шул йортта яши...
Мәргубә әби тиз генә ишегалдына чыгып керде.
— Рабига керә алмый. Ирләр утын алып кайтканнар. Әйдә, чәй эчик әле. Утыр якынрак.
Венера сумкасыннан бер төргәк чыгарды:
— Менә, Мәргубә апа, Ташкент күчтәнәче сиңа. Өрек, җимешләр...
— И-и, рәхмәт төшкере. Борын кычытып тора иде, шуңа булган икән.

Чәй эчкәндә карчык үзенең белгәннәрен исенә төшерә-төшерә сөйләде.

— ...әтиең синең ябык кына чырайлы, озынча гәүдәле, чандыр кеше иде. Минем әти силсәвиттә сикритар ие, әтиең безгә еш кына кереп йөри иде. Сугыштан ул камисар, бәлшәвик булып кайтты. Ливәрвире дә бар ие. Сул кулының ике бармагы юк иде.

— Уфа төрмәсендә сорау алганда, тимер ишеккә кыстырып, аклар изгән аларны. Әни сөйли торган иде...

— И-и бичара-а! Ул бахыр гомере буена күргән инде. Аклардан да, кызыллардан да. Бер безгә килгәндә, энем белән миңа зу-ур сары шикәр биргән иде. Һич онытмыйм шуны. Шуннан бирле сары шикәр күргәнем юк минем. Төштә кебек кенә булып калды. Миңа ун яшьләр чамасында, әтиеңне эш белән каядыр кучерделәр. Әти әйтә торган иде, Зиннәт калага күчеп китте, дип.

Картәтиең Габдерафыйк бабай калхузда эшләде. Тырмалар ясап, чабаталар үреп базарда сата торган иде мәрхүм. Каравылда торды. Мал тота торган иде инде, сыердан да өзелмәделәр...

— Өйләре еракмы моннан?

— Түгел, ерак түгел. Күрсәтермен өйләрен дә, урамнарын да. Энесе Рәвилне дә күрергә язсын. Әйдә, чәй эчик әле әйбәтләп, ял иткәндәй бул. Әтиеңне хәтерлисеңме соң?

Мәргүбә әби Венераның күзләренә карамаска тырыша. Инде иллене узган бу хатынның күзләрендә сагыш-кайгыдан башка бернәрсә дә юк, ахрысы.

— Әтине алырга төнлә килделәр. Яңарак кына биш яшем тулып узган иде. Идәндә шак-шок килеп басып йөргәнгә, китапларны шапылдатып-шапылдатып идәнгә алып ыргытканга куркып уянып киттем. Елый башладым. Шуннан китап ыргытучыларның берсе миңа кәгазьгә төрелгән конфет бирде. Елама, дип башымнан сыйпады. Әтием ап-ак күлмәктән, кара чалбардан өстәле янында урындыкта утыра. Бер ноктага карап каткан. Мин елаганга да кузгалмады. Ә әнием караватта дүрт айлык энемне кочаклаган хәлдә утыра. Ап-ак булып агарынган. Шуннан мин әтием янына барып, аның ике тезе арасына кердем. Кулымдагы конфетны аңарга күрсәтәм. Ә аның ике күзләре тулы яшь. Менә тама, менә тама дип асылынып тора керфекләрендә.

Алып чыгып киткәндә күтәреп үпте дә, бәхетле бул, кызым, диде. Ай тулар-тулмаста «халык дошманы» дип атканнар үзен.

1956 елны тәүге хатыны юллап акландырды. Ул апа үзе дә утырган булган әти аркасында. Әнием, әтине башта Испаниядә сугыша, дип алдалаган безне. Аннан соң Ватан сугышында һәлак булды дип сөйләде. Ә мин берсенә дә ышанмадым. Чөнки безне фатирыбыздан куалап чыгардылар. Аннан соң Ташкентка, әниемнең абыйсы янына киттек. Шунда ярлылыкта, кимсетелүдә яшәдек. Үзем бер украин кешесенә кияүгә чыктым. Бер улым, бер кызым бар. Әтиемнең бер генә фотосы бар. Беренче хатыны җибәрде безгә. Ул Гражданнар сугышы елларында кызыл командир булган. Аннан соң зур партработник булып эшләгән...

Мәргүбә әби Венераның сөйләгәннәрен эчке бер тетрәнү белән тынлый. Зиннәтулла абый атылган елны аның икенче улы туган иде. Шул бала бүген төп йортта хуҗа кеше. «Халык дошманы» Искәндәров Зиннәтулланы күп сүктеләр ул елларны җыелышларда, урамнарда, базарларда. Имеш-мимешләрнең иге-чиге булмады. Әтисе Габдерафыйк бабай күзгә күренеп картайды, бөкерәйде, кечеләнеп калды. Урамнарга чыгып йөрмәс булды. Аннан берничә елдан соң сугыш башланды. Кешеләрдә «халык дошманы Зиннәт» кайгысы калмады. Инде менә аны кулга алганда туган балалар иллене узып киттеләр. Зиннәтулла абыйны белгәннәр аз авылда. Яшьләр аны белмиләр дә. Ә Венера нужалы үскән бала чагын, әтисен сагынганнарын, әтисенең ничек һәлак булганын энесе Марстан яшерүләрен сөйли...

Каладан әллә кемнәрнең явызлыгы аркасында биш яшендә атасыз, ятим калып, инде чит-ят җирләрдән әтисе туып үскән төп йортны эзләп кайткан, чәчләре агарып, инде картая башлаган бу хатынны башыннан сыйпыйсы, аңарга җылы сүзләр әйтеп юатасы килә. Тамагына килеп өелгән төерне Мәргубә әби көчкә-көчкә йотып җибәрде дә Венера алдындагы чинаякка үрелде:

— Кая, чәеңне кайнарлыйм әле!

— Рәхмәт, апа, житте миңа. Апа, әтинең туганнарыннан кемнәре бар?

— Юк диярлек ярый инде. Үзеннән зур кыз туганнары бар иде, үлеп беттеләр. Нәфисә түти үлгәнгә бер ун ел бардыр инде. Ә Мәрфугалары аңардан да алдарак үлде. Яшь әнкәдән ике энесе бар. Берсе хезмәт иткән җирендә калды. Шунда яши. Төп йортта төпчекләре яши.

— Барып күрәсе иде шунысын. Мин бит шуларны эзләп кайткан идем...

— Алай теләгең зур булгач, барырбыз. Тик мин сиңа авыр булса да әйтим инде, иркәм. Атаңның ул энесе бик каты эчә. Кара эчү белән эчә. Аннан соң сине признавайт итмәс ул.

— Мин бит аның абыйсының сеңелесе. Туганы бит.

— Шулайлыкта шулай да ул. Бер бәхетсез кеше инде ул бичара. Исеме Рәвил үзенең. Мәктәптә чакта бик шәп укыган иде ул. Абыйсы «халык дошманы» булмаса, алтын мидәл бирерләр иде. Шуны бирмәс өчен урыс теленнән язганына, бер хатасыз булса да, өчле билгесе куйдылар. Пучырыгың ямьсез дигән булып. Шуннан институтка барды, керәлмәде. Сынауларын гел бишкә биргән — алмадылар. Икенче елны тагын барды, тагын алмадылар. Шуннан өченче елны барырга әзерләнгәндә ныкывыда эшләгән берәү әйттергән боларга: бармасын, керә алмый. Абыйсы шулай-шулай булганга дип. Бармады башкача. Гомере буена калхузда кара эштә йөреде. Әтисен, әнисен карады инде, карамады дип булмый. Габдерафыйк бабай үлгәндә аңарга ундүрт-унбиш яшь иде. Әтисен күтәреп мунчаларга йөретә торган иде инде бичара. Аннан соң тора-бара эчә башлады. Эчсә, холкы бик яман. Хатыны да бер китеп, бер килеп яши инде шунда. Балалары алтау шикелле. Күрәм дисәң, аз гына сабыр ит, иркәм. Улым Марат кайтсын инде. Аның белән барырсыз. Минем улымны ярата ул, аңарга тими дә, каршы сүз дә әйтми. Аннан минем улым кешедән тидертә дә торган түгел ул.

Әбинең улы, чыннан да, таза, ныклыгы күренеп тора торган ир иде. Ул өйгә кайтып кергәндә, аның белән бергә тынычлык, сабырлык, иминлек килеп кергәндәй булды.

— Исәнмесез! Кунак бар икән бездә, рәхмәт төшкере! Шатлык бүген.

Әнисе аңарга кыскача гына кунакның теләген аңлатты.

Марат сүзсез генә әнисен тыңлады да Венерага мөрәҗәгать итте:

— Белмим шул, апа, нәрсә эшләрбез икән. Ул Дидү ягында айдан артык шабашта йөреп кайткан. Шул шабашниклар кичә дүртәүләшеп матай коляскасына аракы тутыралар иде. Кеше танырлык түгелдер дип уйлыйм мин аны...

— Туктале, улым, — диде аның сүзен бүлеп әнисе. — Син алып барып, йортларын күрсәт. Өйләре Зиннәт абый туган йорт түгел инде хәзер. Рәвилнең кулы бик оста аның, үзе салган йорт. Ә менә тәрәзәләре каршында ике зур, юан тирәк бар. Менә алары инде Зиннәт абзый заманыннан ук килгән тирәкләр.

— Нәрсә ул тирәк?

— Тупыл агачының татарча исеме. Алар Зиннәт абый үскәндә үк булганнардыр. Мин килен булып төшкәндә үк би-ик юаннар иде. Барыгыз, һич югы йорт урынын, шул тирәкләрне карап кайтыгыз...

Бер сәгать чамасы үтүгә, Венера белән улы кире кайттылар. Анасының сораулы карашына Марат кулын гына селтәде. Мәргубә әби боеккан Венераның күңелен табарга тырышты:

— Мунча яккан идем, хәзер өлгереп килә инде. Бик әйбәт итеп чабынып керерсең. Себеркесе, әтиең йөргән урман себеркесе.

Венера елмайды:

— Мин бит чабына белмим, апа. Без яшәгән якларда мунча юк, ванна гына.

— Ы-ы, шулай бит әле, чыннан да. Ярар алайса, икәүләп керербез. Үзем чабармын әйбәтләп. Йә киленне кертермен. Ул яшьрәк кеше, сиңа кулайрак булыр...

— Зур рәхмәт инде сезгә. Миңа китәргә кирәк. Таныш булмаган көемә сезгә күпме мәшәкать ясадым.

Мәргубә әби аны тынычландырырга тырышты:

— Бер мәшәкате дә юк. Син үз авылыңа, әтиең туып-үскән авылга кайткансың. Бар да әйбәтләнер, иншалла. Кунып китәрсең. Иртәнге юл хәерле була ул. Киләчәктә үзебезгә кайтып йөрерсез. Чит кешеләр түгел — әтиләр бергә дус булып яшәгәннәр, эшләгәннәр...

Төнлә белән Мәргубә әби нәрсәгәдер сискәнеп уянып китте. Аның колагына күрше бүлмәдән нинди дер ят авазлар ишетелде. Азрак тыңлап яткач, әбинең йөрәгеп кысу билэп алды. Күрше бүлмәдә Венера, тавыш чыгармаска тырышып, мышык-мышык килеп кенә җылап ята иде...

Иртән чәй эчәргә утырдылар.

— Марат эштәдер инде, күренми,— дип сорады Венера.

— Әйе, бер йомыш белән чыгып киткән иде. Мин кайтмыйча китмәсен, диде сине. Хәзер кайтып җитә ул. Матае белән чыгып ычкынган иде таң тишеге белән. Чак кына сабыр ит инде син. Озатасы киләдер...

Әбинең тавышында Венера ниндидер тынычсызлык авазлары сизгәндәй булды. Тик төпченмәде. Шуның өстенә әби еш-еш кына урам якка да карап ала, нәрсәдер көтә иде.

Чәй эчеп беткән чакта урамда матай тавышы ишетелде. Ишек алдына ук килеп кергән матай коляскасыннан кожан кигән чандыр, озын гәүдәле бер кеше төште. Аны күргәч, Венераны ниндидер тынгысызлык биләп алды һәм ул, йөрәге белән сизенеп, үзе өчен бер яхшы хәбәр көтә башлады.

— Әй, шәп бала да инде бу Маратым! Тәки тапкан кирәк кешене,— диде Мәргубә әби, килгәннәргә каршы атлап.— Үзе тиз дә йөрегән бит әле, рәхмәт төшкере.

Ишектән Маратка ияреп алтмыш яшьләр чамасындагы теге чандыр кеше күренде. Көр, ныклы ирләр тавышы белән сөйләшә дә башлады:

— Исәннәрмесез! Сездәме безнең өчен кадерле кунак!

Кергән ир, көрәктәй зур кулларын исәнләшер өчен алга сузып, Венерага табан атлады. Тик исәнләшү урынына Венераны кочаклап алды:

— И-и-и туганкаем мине-ем! Мин бит синең әтиеңнең бертуган апасының улы Сәхипгәрәй булам. Абзаң мин синең. Әнине Зәйпә диган авылга кияүгә биргән булган Габдерафыйк бабай. Шул авылдан мин. Таң аткач та Марат килеп җиткән. Урам тутырып эзләп йөри безне. Киттек, иркәм, безгә, Зәйпәгә. Җиңгәң анда әллә күктә калды, әллә җирдә. Син килүгә әзерләнә, йөгерә. Әйдә, киен!

* * *

Венераны Сәхипгәрәй абзасы Зәйпәгә алып киткәнгә атна үткәч, бер иртәдә Мәргубә әбинең ишеген шакыдылар.

— Керегез, кер, кем бар анда! Ишек бикле түгел.

Ишектән Югары оч Әптер Габделхай күренде:

— Исәнлекме, Мәргубә апа!

— Аллага шөкер! Син нәстә, урында эшләгән кеше кебек ишекләр шакып йөрегән буласың?

— Шакымыйча! Мин дә урында эшлим бит хәзер.
— Кайда тагын?
— Пажарныйга, төнге каравылга кердем. Сиңа йомыш белән килгән идем әле мин.
— Нинди йомыш, әйтеп кара.
— Сиңа теге утыз җиденче елны атылган Зиннәт Камунның кызы кайткан, кунакка дип ишеттем. Дөресме?
— Кайтты да ди. Синең ни катнашың бар соң әле анарда?
— Бә-әй, булмыйча. Зиннәт абый да Искәндәров, мин дә Искәндәров бит. Без туганнар аның белән.
— И-и Габделхә-әй! Мин бер дә ишеткәнем юк иде сезнең туганлыкны. Ничә буын?
— Соң син ишетергә! Син бит Түбән очта үскән кеше. Ә без Югары очлар. Безнең фамилия нинди, сорале син! Буындамени эш?
— Нинди фамилиягез?
Габделхәй матур итеп елмайган Мәргубә әбигә шулай ук елмаеп карап җавап бирде:
— Искәндәров безнең фамилияләр. Аларныкы да, безнеке дә. Борыннан, Искәндәр бабайдан килә ул фамилиянең башы. Озын сүзнең кыскасы: кая куйдың кунакны?
— Кунакка алып киттеләр, Зәйпәгә.
— Кем?
— Зиннәт абзыйның бертуган апасының улы Сәхипгәрәй дигән кеше.
Габделхай башындагы кипкәсен арткарак этәреп куйды:
— Туганлыгы минекеннән өстенрәк, ахрысы. Ярар. Аның каравы минем фамилиям Искәндәров. Рәхмәт хәбәрләвеңә. Мин машина табып шул Зәйпәгә барып кайтыйм әле. Танышырга, әр-яңадан туганлашырга кирәк безгә. Өзгәләделәр безне дистәләгән еллар буенча... Туздырдылар...

## УРМАН АША ЮЛЛАРЫМ...

Сугыш башланырга биш ел калган булган. Мине, дүрт яше тулмаган малайны, әнием кайда күтәреп, кайда атлатып дигәндәй, колхоз бәйгесенә алып барды. Хәзер аңлавымча, ул бәйге — сабан туй алдыннан уздырыла торган бәйрәм булган. Ягъни, сабан туена репетиция.

Авылдан өч чакрымда таулар арасында урнашкан Гөмбазы дип йөртелгән бик матур урын иде. Тирәк, карама, шомырт, зирек, өянке, усаклар белән уратылып алынган тау итәгендә булды ул бәйге. Минем искә кереп калганнардан — көянтә асып, мөлдерәмә тулы чиләкләр күтәреп йөгерешкән, буйлы ыштан кигән ак сакаллы бабайлар булды. Ә инде иң кызыгы — «катыкка чуму»ны карау...

Безнең авылда Гражданнар сугышыннан калган «полковой котел»лар бар иде. Утызар чиләк сыешлы ул зур казаннарны әллә аклар, әллә кызыллар ташлап киткән — анысы билгесез. Колхозда биш бригад һәм һәр бригадта дүрт-биш шундый казан бар. Аларда эшләгән кешеләргә аш пешерәләр. «Полковой котел»ларның берничәсе авылда әле дә булса саклана.

Менә шул «полковой котел»га яртыдан өстәрәк итеп катык тутырганнар. Авыл китмәсен өчен аз гына җиргә казып утыртканнар. Бер ап-ак сакаллы бабай шул катыкка зур биш тиенлек бакыр акча ташлый. Шул бакыр биш тиенне, катыкка баш белән кереп, авыз белән эләктереп алып чыгарга кирәк. Теләгән кеше бил тиңентен ялангач кала да, ике кулы

белән казан читенә тотынып, башы белән катыкка кереп китә. Аннан соң авызы белән теге биш тиенне таба, теле белән урыныннан кузгата, тешләре белән эләктерә дә алып чыга. Шуның өчен бер зур кабартма белән ике кукәй биреләр икән. Безнең күрше, Папей Рәхиме теге биш тиенне эләктереп алып чыкты! Ап-ак катыкка баткан Рәхим абыйны танырлык та түгел. Бер күкәйне энесе Нимигә тоттырды, икенчесен миңа бирде. Шул яшелгә буялган күкәйне мин көне буена кулыма тотып йөреп, үзем дә яшелгә буялып бетә яздым.

Көн кичкә табарак авыша башлагач, кайтырга чыктык. Җәяү атлыйбыз. Авыл ерак түгел, өч чакрым чамасы гына. Тик көне буена эссе кояш астында йөргән кечкенә малайга күпме кенә кирәк соң. Бик нык арыткан. Авыл ягына алып кайткан үрне менү белән мин әнидән күтәрүен сорап елыйм, аның итәгенә ябышып, аякларына уралып, атларга комачаулыйм. Ул, бәлки, авырлы да булгандыр әле. Миннән соң бер малай белән бер кыз туды. Әни мине үгетләп тә, әрләп тә, артыма биргәләп тә ала. Тик мин «бирешмим», акыруымны дәвам итәм. Атларга көч юк. Әнине тыңлата алмагач, юл тузанына ятып, аякларым белән тузан туздырып акырам. Файдасы юк.

Әни куркытып та карый:

— Ят шунда, торып кал берүзең, төнлә белән үзеңне бүреләр ашап китсен менә!

Тик үзе китми. Мин бер күзем белән генә әнине күзәтәм. Ташлап китсә дип шүрлим дә үзем.

Шулчак без килгән яктан бер атлы арба күренде. Арба тулы хатын-кыз, бала-чага. Арбада өздереп-өздереп гармунда уйныйлар. Безнең янга килеп җиткәч, дилбегә тоткан ир атын туктатты да әнидән көлеп сорый:

— Нәрсә, җиңги! Кайтмаска тартышамы әллә? Баш күтәрәме?

— Әйтмә инде, туганым! Ятыплар җылый! Арыды бик нык!

— Үзсүзле инде ул. Безнең нәсел бит. Әйдә, урын тапсаң, утыр!

Тик арбадагылар безнең утыруга риза түгелләр һәм безне урын юк дип утыртмаска тырышалар. Шулчак, сары җиз белән бизәкләп эшләгән гармун тоткан абзый безгә ярдәмгә килде:

— Кысылыгыз, кысыл! Инде бер кешелек урын табылыр. Кил, Мәрьям түти, утыр минем янга!

Кысылып, урын табып әнине гармунчы егетнең уң ягына утырталар.

Мин, ялгыз торып калудан куркып, әнинең итәгенә ике куллап ябышканмын. Гармунчы егет, әни утыра башлагач, уң кулы белән үрелеп минем күлмәктән эләктереп һавага күтәрә. Әни утырганчы, мин шул килеш ялан аякларны тырпайтып, һавада асылынып торам. Җылау, акыру дигән нәрсә онытылды. Әни үзе утыргач, мине алдына утыртты да, шуннан соң ат кузгалып та китте. Гармунчы егет гармунын сузып җибәрде. Гармунын өздереп-өздереп бик моңлы көй уйнады. Мин андый моңлы көйне башкача үз гомеремдә ишетмәдем. Өстәвенә, гармунчы абый гармунга кушылып җырлый да иде. Ул җырдан бары өч кенә сүз истә калган:

. . . . . . . . . . . .

Урман аша юлларым...

Гармунчы абый минем исемдә гомерлеккә калды. Аны сугыш башланганчы еш кына атлы арбага утырып йөргән чагында күрә идем һәм ул минем өчен бик якын бер кеше кебек тоела иде. Сугыш башлангач, ул шул ук җәйне фронтка китте. Мәктәп йортында гармунында соңгы тапкыр уйнады да, гармунын бөкерәеп беткән бер карт әбигә тоттырып китте. Ул әби аның дәү әнисе булды, ахрысы. Бик карт иде ул. Шул китүеннән гармунчы абый сугыштан кире әйләнеп кайтмады...

Гармунын алып калган әби сугыш елларында авыл өйләре саен кереп, каен себеркеләре сатып йөреде, дару үләннәре бирә торган иде.

Кечкенә, бөкре гәүдәле ул әби ачыктан-ачык хәер сорамыйча, кәсеп иткән булып, ил өстендә тамак туйдырган икән. 1945 елның декабрендә әби исән иде әле. Хәтеремдә юк, аннан соң күргәнмендерме аны, юкмы?

Ул еллардан соң инде алтмыш елга якын гомер узды. Шул вакыттагы кешеләрнең күбесе диярлек теге дөньяда инде...

Гомерем буена мин шул гармунчы абый уйнаган көйне исемә төшерә алмый интегәм. Төшемдә берничә тапкыр ап-ачык ишеттем ишетүен ул көйне. Тик уянганда тагын онытылган була. Менә-менә яңгырый башлар кебек булып, күңелнең әллә кайсы бер почмагында ишетелер-ишетелмәс кенә чыңлап та куя. Моң булып кузгала, йөрәк тибешен акрынайта һәм өзек-өзек кенә булып ишетелә дә кебек. Мин тын алуымны да туктатып, Ходайдан ярдәмнәр сорап, көйне дөньяга тартып чыгарырга тырышам. Ә ул аз гына ишетелгәндәй була да тына. Тагын ишетелеп калгандай була, тагын тынып кала. Ә мин һаман аны тыңлап, эзләп йөрим. Гомер буена шулай.

Күпме генә көйләп, моңланып, сыктап йөрсәм дә, ул җыр минем исемә төшми. Бары тик гармунчы абыйның кара күлмәк изүенә берберсенә тәрәп, тезеп таккан ап-ак сәдәфләре, күн итеге һәм кап-кара төстәге, почмаклары сары җиз белән матур итеп бизәкләнгән моңлы гармуны гына истә калган. Һәм... теге җырның өч сүзе:

. . . . . . . . .

Урман аша юлларым...

## МӨНӘСӘБӘТ НИЧЕК БУЛАЧАК?

«Тегеләр» яңа партия төзиләр икән, дигән хәбәр район үзәге булган зур авыл урамнары буйлап таралып, кибетләрдә, киоск яннарында, су колонкалары тирәсендә, автобус тукталышларында байтак көннәр тикшерелә иде инде. Исемнәрен турыдан әйтмичә генә, «тегеләр» дип аталганнарны халык яхшы белә. Алар: күптән түгел эшләүдән туктаган КПСС райкомының Беренче секретаре булып халыкны байтак тапаган, инде яше җитмешкә җитеп барган кечкенә буйлы пенсионер Булат Юлбарысов, аның белән Икенче булып эшләгән Тимерхан Гыйбадулин, сугыш елларында сугышка китмәс өчен тәмәке суы эчеп саргайган, хәзер инде капка төбендә тун, пима киеп, җәйге эсселәрдә дә үлә алмыйча утыручы Шадра Галимдар иделәр. Сөйләнгән дөрескә чыкты — яңа партия төзү өчен җыелыш та җыйдылар. Элекке райкомның утырышлар залында. Азрак халык та бар. Яшь кыз чагында ук райкомда кәгазьләр актара башлап, бик күп Беренче секретарьларне күргән, ГКЧП килеп чыкканчы пенсиягә китеп өлгергән Кара Зөһрә, райкомда утыз елдан артык төнге каравылда йоклап гомер уздырган Лотфый абзый, чуаш Микалай белән Мукшы Микита иделәр. Барысы да татарча яхшы белсәләр дә, җыелышны урысча алып барырга булганнар иде, барып чыкмады. Чуаш белән Мукшы килешмәделәр.

— Барлык җирдән урысларны куган заманда,— диделәр алар,— без нилектән аларча сөйләшергә тиешбез әле! Әйдәгез, уртак телдә — татар телендә алып барабыз...

Киттеләр татарчалап.

Җыелышны элекке Беренче ачты:

— Иптәшләр! Яңа партия төзү өчен җыелган җыелышны ачык дип игълан итәм. Кул күтәрәбез, иптәшләр! Төшерегез! Каршылар? Юк! Битарафлар? Юк! Син, иптәш Яруллин, нигә тавыш бирмәдең?

Бу сүзләр каравылчы Лотфи абзыйга юнәлтелгән иде.

— Мин бит партийный түгел идем, энем. Шунлыктан тавыш бирергә хокукым юк. Аннан соң бит минем мәрхүм әти дә заманында кыстыбый, сумса сатып кәсеп иткән. Шуның өчен утырып та кайткан булган...

Беренче кулын селкеп туктатты.

— Ярар, алай булгач. Тик яңа партия создавать иткәндә без ул нәрсәләргә карап тормабыз дип уйлыйм. Шулай бит, иптәшләр?!

Аста утырганнар бертавыштан «шулай, шулай» дип шаулашып алдылар.

— Җыелышны дәвам итәбез! Минем уемча, без президиум сайлап тормыйк инде, үзем генә алып барырмын дип уйлыйм.

Залның иң ерак почмагында утырган Лотфый абзый уйлап куйды: «Вәт бит кешенең шәплеге! Китәкәненә сигез елдан артты, ник берәр җире үзгәрсен! Үзем алып барам, ди бит. Әллә бу коммунистлар картаймыйлар да, үлмиләр дә микән? Алай дисәң, соңгы елларда үлгәннәре дә күренгәли».

Аңа истәлекләргә чумып китәргә комачаулык итеп, Беренченең тавышы көчәйгәннән-көчәя:

— Лотфый абзый! Син алгарак күченеп утыр инде! Хәзер бит теге коммунистлар заманы түгел. Бар җирдә дә тигезлек һәм демократия...

— Рәхмәт, рәхмәт, энем! Синең тавышыңны сәхнәдән ишеткәч җылыйсыларым килеп китте. И-и-э-эх, мин әйтәм, бар иде бит заманалар! Кая китте икән, мин әйтә-әм, теге җимереп паюклар алып яшәгән чакла-а-ар!..

Беренче аның зар-моңын тиз бүлде:

— Сүз Тимерхан Гыйбадуллинга бирелә. Ул булачак яңа партия турында сөйләячәк.

Берничә ел инде сүзгә сусап яшәгән Тимерхан Гыйбадуллин элеккедән дә салмаграк итеп сөйләп алып китте. Нотыгының башы болай иде:

— Әфәнделәр!!! Үзегез күреп торасыз, компартия ябылганнан соң, авылда вакуум барлыкка килде. Ә авыл картлары шул вакуумнан файдаланып, мәчет салабыз дип акча җыя башлаганнар. Торна Хаҗибе җыя ул акчаны. Халык бик күп бирә. Тик, безгә мәчет кирәкме, әллә яңа партияме? Яңа партия, иптәш-әфәнделәр! Яңа партия — һәм ул социал-демократлар партиясе булырга тиеш! Да! Программасы төзелеп ята. Тик әле төзелеп бетмәсә дә, партия үзенең эшен башларга тиеш, дип уйлыйбыз.

Лотфый абзыйдан башкалары, кирәк-кирәк, диделәр. Элекке вакытларны исенә төшереп, халык күп һәм шаулыйлар дигәнне аңлатып, элекке Беренче, алдында торган элекке райком графинына кулындагы элекке райкомнан калган каләм белән берничә тапкыр кыска-кыска гына итеп суккалап алды. Графин тач элекке райком авазлары чыгарып чыңлады. Ул да чыңлыйсы килеп яшәгән, ахрысы — тавышы яңгыравыклы һәм моңлы иде.

Кара Зөһрәне, картаеп бетеп барса да, киләчәк күбрәк кызыксындыра иде. Нотык беткәч, ул беренче булып сорау бирде:

— Гыйбадуллин ип... э-э, әйе, әфәнде, диюем! Инде коммунизм төзүне дөрес түгел һәм аны төзеп тә булмый, диләр. Яңа партия нәрсә төзиячәк соң киләчәктә?

Гыйбадуллинның җавабы томанлы һәм ачык түгел иде. Ул үзе дә аңлап бетермәгән хәлдә, нәрсәнедер байтак кына бутады да, Беренченең тамак кырганын шәйләп алып, сүзен болай диеп бетерде:

— Французлар, немецлар, итальяннар, англиянекеләр белмичә генә социал-демократлар булып йөрмиләрдер әле. Нәрсә төзергә кирәк — аларга барып өйрәнербез.

Кара Зөһрәнең, анда барырга кем акча бирер, дигәнен Гыйбадуллин җавапсыз калдырып, почмакта кул күтәреп утырган Лотфый абзыйга сорау бирергә рөхсәт итте.

— Энем! Син вакым дигән кебегрәк бер сүз әйттең. Нәстәне аңлата соң ул? Шуның эчтәлеген мина аңлатып бирсәгез иде. Үзе вакыф дигәнгә дә тартымрак яңгырый.

— Вакуум ул, Лотфый абзый, ваку-ум.

— Ай, мина нәрсәгә соң аның исеме! Нәстәне аңлата соң ул?

— Бушлык дигән сүз ул. Һавасы беткән дигән мәгънәдә.

— Алай булгач, авыл картлары мәчетне бушлыкка салалар булып чыгамыни инде? Минем ишетүемчә, Әлмәчләр очындагы элекке библәтик урнын сорап йөриләр ди бит. Ул нишләп һавасыз урын булсын инде?

Беренче графинга сукты:

— Ярар, Лотфый абзый! Сиңа җыелыш беткәч, аерым аңлатырлар. Хәзер сүзне партиянең инструкторына..., эһһем, эһһем, яңа партиянең идеологына бирәбез.

Элекке инструктор, сугыш елларында тәмәке суы эчеп, тун, пима киеп, сугышка китүдән качып утырган шадра Галимдар сүз алды:

— Мин, иптәшләр, яңа партиянең рәисе итеп үземне тәкъдим итәр идем...

Өстәл артында утырган Беренче урыннан сикереп торды. Ул кызарып чыккан иде:

— Ничек инде ул алай, син үз-үзеңне придлагать итәсең. Без бит башкача сөйләшкән идек кичәгенәк...

Галимдарның шадра бите шомарды. Ул сүзне кискен тотты:

— Җитте сиңа. Коммунистлар райкомында Беренче булып, безнең җанны күп ашадың, канны күп эчтең...

Сөйләшеп килгәннәр ахрысы, чуаш Микалай белән Мукшы Микита да икесе бер булып татарчалап кычкырдылар:

— Далуй, далуй Юлбарысовны. Күп эчте каныбызны! Далуй!!!

Кычкырыш китте, бер-берсен мәсхәрәләү китте. Шул чакта ишек ачылып, аннан дәү гәүдәле ике кеше күренде. Әхмәт Тәкәч белән Капар Варис иделәр алар. Берсе җитмешне, икенчесе күптән инде алтмышны узган бу ике кеше — бер эчә башласалар, авыл буйлап парлашып унунбиш көннәр буена туктамастан эчеп йөрүләре белән дан тоткан кешеләр иде. «Мине эзләп керде инде болар»,— дип уйлады Лотфый абзый, утырган урындыгына сеңеп юк булырга тырышып. Чөнки өч көн алдан гына, авылның уртасына салынган Таш күпер янындагы киоск артында ул аларның бер ярты аракысын эчешергә ярдәм иткән иде. Шуңлыктан Лотфый абзаң болар алдында «бурычлы» кеше булып тора.

Әхмәт Тәкәч белән Капар Варис, беркемгә дә игътибар итмичә, зур авылның алгы рәтендәге урындыкларга барып утырдылар. Утырган уңайга тиз генә нәрсәдер турында үзара ике-өч сүз әйтешеп алдылар. Пышылдашып кына. Залдагылар бернәрсә дә аңламады. Аптыраган Беренче аларга сорау бирде. Аның хәтер шәп иде, кергәннәрнең фамилияләренә кадәр исенә төшерде:

— Иптәш Фаткуллин белән иптәш Рафиков! Сез кая кергәнегезне белеп кердегезме? Сезгә монда нәрсә кирәк?

Әхмәт Тәкәч белән Капар Варис син дә, син, дип үзара азрак тарткалашып алдылар да, шуннан соң Тәкәч Әхмәт аякка басты:

— Мине монда Варис алып килде. Ә үзе сөйләргә теләми. Миңа куша. Әйдә барыйк, ди, тыңлыйк әле шуларны, ди. Элекке чи коммунистларны ди. Бүген нәстә уйлыйлар икән, белик әле, ди. Яңа партия төзиләр икән алар, ди. Ошаса, бәлки, без дә керербез, ди. Капар-капар бит инде ул, нәрсә генә эшләтмәк кирәк аны! Йөз грамм өмет итеп, мина иярә йөри. Бүген әле җитмәсә акчасы да юк...

Әхмәт Тәкәч кәефе кырылган ахириенә карап алды да дәвам итте:

— Монда утырганнарны әйтәм, сез барыгыз да безне яхшы беләсез инде. Теге каһәр төшкән коммунистлар райкомы исән-имин чагында, син Юлбарысов энем, безне эчкечелектә гаепләп авылдан кудыртырга бу-

лышкан идең. Тик ул нумирың барып чыкмады. Теге гыкачыпы килеп чыгып, Ельцин сезне үзе куып таратты. Безнең брат ул Ельцин, кемне ничек итеп куарга белә ул үзе...

Беренченең йөзе каралып чыкты:

— Син, иптәш Фаткуллин, кыскарак тот!

— Тотты ди, тотмыйни! Көтеп тор! Аннан соң ни өчен миңа «син» дип дәшәсең син, ә? Мин синең белән мөселман авылларында син салдырган чучка фермаларындагы чучкаларны синең белән бергәләшеп көткәнем юк...

Хәтәрләнгән күзләрен Беренчегә зәһәр итеп текәде:

— Кыскасы шул! Сез нинди яңа партия, нәрсә төзергә уйлыйсыз, дип сорамыйм мин. Сез төзи торган кешеләр түгелсез! Варис дус белән сезгә безнең соравыбыз бераү генә: яңа партиягезнең аракыга мөнәсәбәте нинди булачак? Варис белән мине шул вапрус кызыксындыра. Теге бик каты пахмилдән ничек итеп мучит ителсәң, менә шулай яфаланабыз белә алмыйча. Тагын бер кат сорыйм: сезнең яңа партиягезнең аракыга мөнәсәбәте нинди булачак?!

## УЙМАК УЙЛАР

*(Яшәү мәгънәсе турында)*

Гомер безгә шулкадәр кыска бирелгән ки, аңлаган кешегә ул үзеннән-үзе иң зур хәзинә кебек тоела башлый.

С. СЕРГЕЕВ-ЦЕНСКИЙ.

Кешеләргә һәм якыннарыңа үзеңнең кирәклегеңне тою — иң зур бәхет, яшәүнең татлы бер мәгънәсе.

М. ГОРЬКИЙ.

Тормыш үзе генә бер ни түгел, хикмәт аны ничек итеп яши һәм куллана белүдә.

Ж. РУССО.

Өч төрле башлангычка йөз тотарга кирәк: хакыйкать, намус һәм яхшылык.

Ж. МАРМОНТЕЛЬ.

Ике тапкыр яшәп булмый, ләкин бер тапкыр да яши белмәгәннәр кызганыч.

Ф. РЮККЕРТ.

Күпләр бүгенге көн белән яши, талантлыларның акылы исә киләчәккә төбәлгән.

Д. СВИФТ.

Акча кыйммәт, кеше гомере кыйммәт, ә вакыт барыннан да кыйммәтлерәк.

А. СУВОРОВ.

# ШИГЪРИЯТ



## Лена Шагыйрьҗан

### Иҗат бакчам

(«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНА БАГЫШЛЫЙМ.)

Тәүге тапкыр, төнлә, ут кабызып,
Битләреңне үбеп ачканда,
Кем уйлаган, әйләнерсең, диеп
Сине изге иҗат бакчама...

Буразналар түгел, бер түтәлдән
Һәм бүтәннән мәхрүм чагында...
Сабый хисләремнең өметләнеп,
Ачылам-ачылам, дигән таңында,

Кирәгең юк, диеп беркемгә дә,
Кырыс, кыргый җилләр куганда,
Борнап яткан үксез орлыкларым
Җир-туфраксыз өшеп туңганда,—

Син ачылдың миңа бакчам булып,
Түгәл бирдең — үс дип, яшьнә, дип...
Һәр кешегә тиеш үз бакчасы,
Шигырь бакчасында яшә, дип...

Син балкыттың тар урамнарымны,
Утларыңа рәхмәт яугыры!
Синдә ләйсән булып тамган идем,
Синдә койсын яшен-яңгырым...

Без синеке, диеп сарыла бүген
Шигъри сәйләннәрем муйныма...

---

Лена ШАГЫЙРЬҖАН — *шагыйрә, «Мөлдерәмә күңел», «Ышанам йөрәгемә» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Тәүге жырым синдә дөнья күрде,
Соңгы жырым керсен куйныңа!..

*1992, май.*

## Шигырь сулап яшәсәң...

Аккош канат кагынган
Минем тәүге адымнан...
Шул мизгелдәме җаныма
«Шигырь җене» кагылган...

Үзе бер сихер кебек ул,
Үзе бер дәва сыман.
Аккошка — күл, миңа жыр-моң
Кирәк гел һава сыман...

Җил дә шигырь, ил дә шигырь,
Колак салсаң өненә...
Күкләр миңа боергандыр
Кал, дип, шагыйрь көненә...

Мин ризамын, шигырь саен
Кабат борнап яшьнәсәм...
Ике гомер кичерәсең,
Шигырь сулап яшәсәң...

*1989*

* * *

Саумы, Яшьлек Йолдызлыгы!..
Вакыт тизлегендә
Очып барган көйгә
Мин дә Сиңа сугылып үткән идем.
Мәхәббәтне кочып үпкән идем —
Эзе калды Галәм иренендә...
Булсам әгәр тик үз ирегемдә,
Китәр идемме соң
ул җәннәттән?!.
Синең Йолдызлыкта гына икән
Тигезләнеш таба
ул Җан вә Тән...
Аннан инде күпме очма син,
Нинди үлчәнешләр очрасын! —
Тигезләнеш беткән...
Тәнеңне —
гел үзеннән читкә кага җан...
Тартышалар:
берсе — чик-сызыкка,
берсе — чиксезлеккә...

*1991*

## Сагыш диңгезе

...Ярсу чабыш атларыдай,
берсен-берсе куа-куа,
яр-су чите ташларыннан
кояш табын юа-юа,
тирәнлеккә һәм киңлеккә
дучар булган дулкыннарның
үзе моңлы, үзе шомлы,
дымлы шавын мин тыңладым...

Ал җилкәнле нәни кораб,
алсу офыкларга карап,
чайкаламы шуңа күрә
минем хәтер дәрьясында...

Ал яулыгым болгыйм аңа,
яралы яр буйларыннан,
Күзем алмыйм үзем һаман
кыргый дулкын туйларыннан...
Бәгыремә утырып калган
тормыш диңгезенең тозы,
яр буенда утырып калган
хыял диңгезенең кызы...

Ал җилкәнле нәни кораб,
зәңгәр офыкларга карап,
чайкаламы шуңа күрә
минем язмыш дәрьясында...

Шул җилкәннәр арасыннан
җиләк кебек — тулып пешкән,
алма кебек — өзелеп төшкән,
гүзәл — болан баласыдай,
карап торам үз-үземә,
шаһит булып һәр сүземә...
Дәрдмәнд моңы тамып калган
зәгъфран төсле — ак бүземә...

Ал җилкәнле нәни кораб,
ерак офыкларга карап,
чайкаламы шуңа күрә
минем сагыш дәрьясында...

*1993*

## Фәрештәләр кыры

*«Фәрештәләр аяк басарга кыймый торган җиргә шайтаннар атылып керә...»*

Инглиз мәкале

Фәрештәләр кыры... Кыяр-кыймас
Колак салам: — Әллә былбыл җыры?..

Канатларым җәеп бастым сакка.
Кара белән язып куйчы акка:
Зинһар, чүпли күрмә, пычратма!
Таптый күрмә, берүк, безнең хакка!!
Шайтан халкы тулса, таптап изәр,
Барча кошлары Ходайның бизәр...
Зинһар, куркытмагыз,
өркеп качмасыннар...
Шайтаннарга капка ачмасыннар!..
Фәрештәләр кыры — изге җыры.
Кара белән язып куйчы акка:
Таптамагыз, зинһар, безнең хакка!
Канатларым җәеп, бастым сакка...

*1985*

## Шагыйрь һәм капитал

Елыйсыңмы, Капитал?
Көләсеңме, Капитал? —
Банкротка чыкты Шагыйрь —
беләсеңме, Капитал?..

Базар түгел, кибеткә
бармас булды, Капитал!
Бу уенда иң оттырган
Парнас булды, Капитал!

Шигырь үзе зур байлык,
түләсәләр, Капитал!
Шагыйрьләр дә яшәр әле
үлмәсәләр, Капитал!

Шагыйрь халкы чыдам ул,
«Әмма»се бар, Капитал! —
«Каләм ташламаслар» микән
Һәммәсе дә, Капитал?..

Сүз остасы кесәгә
керми сүзгә, Капитал!
Шигъри табышлар да «табыш»
бирми безгә, Капитал!

Шагыйрь ләкин — язудан
барыбер бизми, Капитал!
Милләт манарасын бизи
Айлы ТукАй, Капитал!

Миллионер Дәрдмәнд тә
җырчылардан, Капитал!
Үзе алтын чыгарса да,
җыр чыгарган, Капитал!

Чыгар дибез безгә дә
бер җай әле, Капитал!

Тукайлы, Дәрдмәндле булгач,
без бай әле, Капитал!

*1992*

## Көнләшәсез...

Күнелле түгел безгә,
Күнелләме соң сезгә?!
Безгә тагын да күнелсез
Сезләргә күнелсезгә...

Бездә ник читен хәлләр? —
Сезгә дә читен мәллә?..
Читеннән читән үрергә
Читләргә китик мәллә?..

Китсәм дә эчем поша,
Кайтсам да эчем поша.
Җыр язырга Ходай куша,
Җырламаска — кем куша?..

Сезгә ул кызык сыман —
Үз-үземне юксынам...
Эчең поша, сәер икән,
Чәйнең тозы юк сыман...

Күнелле түгел безгә,
Күнелләме соң сезгә?! —
Сизәм: сезгә дә күнелсез
Безләргә күнелсезгә...

*1991*

## Ностальгия

Бушап калган хушбуй савыты.
Яшел су кук — тоньк пыяла...
Айкалдырып җанны яшьлек төсе
Тонып калган төпсез хыялда...
Бик сак кына ачсам бөкесен:
Җанга килеп сарыла таң исе...
...Җитез-йөгерек адым...
Их, бер тагын
ничек шундый очыш ясыйсы!!.
Сирень исе сеңгән җиңел җил...
Адым акрын — авыр никтер җиң...
Яшьлек төсе — хушбуй шешәсендә,
Яшьле яулык — күлмәк кесәсендә...

*1988*

## Китек күңел

Мин түгел бу — минем шәүләм,
аксый-туксый, интегеп,
көч-хәл белән бара атлап...
Асыл бәллүр китеге
юл читендә ята аунап...
Сагынамы үткәнен?..
Нәфис кулда мөлдерәвен,
иреннәрнең — үпкәнен...
...Калай табак калҗайса да,
каралса да ярый эшкә.
Булмаса да затлы табын,
урын таба берәр төштә...
Колагымда — калай чыңы,
йөрәгемдә — бәллүр моңы...
Рәнҗүме бу, үпкәме —
Бәллүр гомере —
күпкәме?..

*1980, Кекин йорты.*

## Иң соңыннан әйтеп китәрмен...

Инде нинди чагың дисезме?
Ниләр булды тагын, дисезме?
Гомер буе истә сакларлык
Иң бәхетле, серле чакларым.

Толымнарның бушрак үрелгән,
Күңелләрнең ешрак сүрелгән,
Җанның мең кат үлеп терелгән
Иң нәзберек, нечкә чаклары...

Бу җиһанда хатын-кыз җанын
Аңлатырга сүзләр җитәрме?
Шундый көнгә килеп җитәрмен,—
Бер сер сезгә бүләк итәрмен,
Иң соңыннан әйтеп китәрмен...

*1987*



## Шәмсия Җиһангирова

# АЧЫ БАЛ

хикәя

Шәрифә карчык, битенә кемнеңдер чалт-чолт суккалавыннан аңына килеп, күз кабакларын ачмакчы булды. Хәле житмәде. Көч-хәл белән генә кул-аякларын селкеткәләп, кузгалырга итте. Кая ул! Кыйналып ташланган кебек авыр гәүдә кымшанырга уйламады да. Башы чатный. Колаклары гөжли. Күңеле болгана.

— Ята күр берүк, кузгалма гына, зинһар! — дигән шелтәлерәк төсмерле ягымлы тавыш ишетелде.

Каршы як күршесе Сәрбиҗамал тавышы иде ул.

— Вәт син, ә! Әйтми-нитми генә үләргә җыенган бит! Мин соң сиңа теге җыгылганыңда ук әйткән идем. Бар да тор киявең белән кызыңа, дигән идем. Чакырмасалар, бер хәл иде. Чакырып торалар бит, чакырып торалар...— Сәрбиҗамал шулай сөйләнә-сөйләнә, мич буендагы сандык өстеннән мамык мендәр күтәреп килде дә, идәндә егылып яткан Шәрифәнең баш астына салды. Шәрифәнең чабулары, яка буйлары кыршылып беткән пәлтәсен чөйдән алып, өстенә китереп япты.

— Кузгалырга ярамый сиңа. Духтыр шулай куша бит. Җөрәк булса, селкенергә дә ярамый, дигән булалар. Синең җөрәктәдер инде. Гомер буе нужа йөге тартып, исәркәйгенәм, җөрәк булмый, ни булсын соң... Ятып тор шулай җылынып. Хәзер мичеңә ягып җибәрәм. Өең суынып беткән бит, менәтерә! Озак яткансың инде болай булгач. Шикләнгәнием аны моржасыннан төтен чыкмый моның, дип. Саз ярып урам аша чыгулары үлем белән бер бит прәме... Өялды ишегең шар ачык, әй. Җил ачкандыр инде. Сарыкларың керен тулган. Теге он капчыгыңның бер почмагын җырткалнар, он ашап яталарые. Борыннары тегермәнче Солтан абзыйныкыннан да аграк. Онга буялып беткәннәр. Сарык дигәнең әйтер ием инде! Син монда тәгәрәп киттең ни, аяк суздың ни. Тамак өчен тәмугка керерләр, иблис кавеме. Мин әшәке сүзләр белән куа торам, алар ыжламый да. Утын яркасы белән теге галаунаеның сыртына мангач кына... Нәрсә дип асраган буласыңдыр шуларны бер башыңа. Ит ашарлык теше бармы аның. Иткә түгел, чәйгә дә теш үтмәс вакыт житкән. Шул балалар, балалар дип үләсең инде...

Сәрбиямал карчыкның теле сөйләде, кулы эшләде. Гөлбәчтән алып, мал суя торган пычак йөзе кебек юка гына итеп чыра телде. Мич эченә аркылы-торкылы ике утын ташлап, төтен юлының тимерен тартты, чырага ут төртте. Чарт-чортлап янып киткән чыра өстенә мич башыннан коры утын алып салды. Өйалдыннан биш-алты ярка чи утын алып кереп өстәде. Ут дөрләп киткәч, Шәрифә янына килеп тезләнде.

— Менә, аллаһы боерса...— дип куйды. Әйтәсе сүзенең азагын оныткандай бераз тынып торгач, һаман күзен ачмыйча, ләм-мим бер сүз дәшмичә яткан Шәрифә карчыкка карап, шомланып китте.

— Менәтрә, кирәк булса, ачып кара әле күзеңне. Әйтәле берәр сүз. Ятмале болай, йөрәк шомландырып. Үлеп китә күрмә тагын. Теге юлы да куркыттың... Син мине дә кызган әзрәк. Минем бит синнән башка бер терәгем дә юк. Бүген прәме шытырдатып туңдырган җирне, ходайның рәхмәте димә инде син бу хәлне. Шул салкын җир астына керергә!.. Җылы вакыт булса бер хәлие... Болай катырмаса синең якка чыгып та булмыйдырые әле. Теге тирән гәлүшем табан кырыеннан гына җыртылган да чыккан, мөртәт. Кызыл эчле алтылы гәлүш җибәр дип ни яздым хат Галимҗаныма, тәки салмады шуны. Акчалары булмаса дип, хат эченә кәгазь акча да тыкканыем югыйсә. Вакыткае җуктыр инде, эш кешесе бит... Бу җаңа прсидәтельнең дә рәте булмады. Төзәттерми бит шул урамны. Чуерташ Савытлы тавында гына бит. Колхоз ишегалдындагы машинаның саны юк. Яз көнге карга көтүе дип торырсың. Һәрберсе берәр җөк китереп аударса да, безнең авыл урамы гөл булачак бит. Урам аша чыгып җан ахирәтеңә керәлми тилмер инде син, ә! Үзенең чучка тота торган абзарларына хәтле җәйдергән икән теге әсвәлт дигән нәмәрсәне дип, шакката инде ихатасына кереп күргән кеше. Ибрай чишмәсенең суын өенә үткәрттергән диеме, тимер торба белән... Тимер торба дигәннән, гел башымнан чыгып тора икән. Килеп керүгә үк сиңа әйтермен дип, кичә үк план корып җатканыем югыйсә. Эшләмәгәч, эшләми инде, баш дигән нәмәрсәсен әйтерием... Теге Бүре Гыйльмиенең күмердән кайткан кече малаен беләдериеңме?! Беләдериеңме дип торган булам тагын, белмәскә инде син аны, безнең балалар белән бергә укыды лабаса. Ай-һай салып та караган инде җортны, курчак өе прәме. Тәрәзә кәрнизләрен сырлап-сырлап, күз күрмәгән төсләргә буяп бетергән. Бәхете булса да була икән Гыйльминең. Эче сыеклаган сарык кебек җолкыш кына бер малайые. И-ии, әйтмәсәм дә булмады, әйтсәм дә җан тынмады, дигәндәй, синекен әйтерием дә, минекен әйтерием...

Сәрбиямал карчык татылдый бирде. Шәрифә дәшмәде. Теле әйләнми аның. Юкса шушы гомер түзеп ятар идеме соң?! Әллә кайчан, «Киявең белән кызыңа бар да тор» дигәннән соң ук:

— Син, алай бик рәхәт булгач, ни дип барып тормыйсың соң үз малаеңа. Бар да тор. Элекке кеше «Киявең кычкырса — ишек бавын тот, малаең кычкырса — түр башына менеп утыр»,— дип белми генә әйтмәгән инде аны. Син малаеңа сыймаганны, мин киявемә сыярмын дип уйлыйсыңмы? — дияр иде. Аннары сарыкларын тиргәр иде. Харап иткәннәр ди бит күз яше кебек күргән онын. Коймакка гына тотарга дип алган оны бит югыйсә. Әле аны да көч-хәл белән, җан чыкканчы ялынгач кына эләктерде.

— Йөрмә әле, Шәрифәттәй, кипкән тизәк кебек аяк астында буталып. Ниткән сиңа он бирү ди тагын. Сыер савучыларга дип кенә кайтартылган нәстә ул,— дип, бирми йөдәтте кибетче Сәлих. Шәрифә карчыкның авызыннан: «Ярар инде алай булгач, ярамагач — ярамый торгандыр шул... Бер яртым да барые югыйсә...» дигән сүз чыккач, карчыга чебине тоткан кебек ялт кына эләктереп алды Сәлих ул сүзләрне. Күзләре төнге ябалакныкы кебек яна башлады. Салырга ярата, шайтан кавеме. Он капчыгын Шәрифә карчыкның кул очына да тидермичә, җилтерәтеп кибет ишеге төбенә чыгарып та сөяде.

— Түлке тиз ычкын бу тирәдән, Шәрифәттәй, мин кире борылып чыкканчы капчыгыңнан да, үзеңнән дә җилләр искән булсын,— дип сөйләнә-сөйләнә кире кереп тә шылды.

Шәрифә карчык як-ягына карангалап алырга да өлгермәде, әллә кайдан аты белән Мөхлис килеп чыкты. Җәен-кышын ферма сыерларына азык ташый ул. Монысы бөтенләй урыс туны кебек шомарып беткән нәмәрсә. Эчәсе килсә: «Түтәй, бер капчык фураж оны барые, сораучы күп аны күбен дә, ну, үзең беләсең, күрше хакы — алла хакы, сиңа бирми хәлем юк. Давай, тамак чылатырга бирәр нәрсә юнәт»,— ди дә, шыплап тутырылган фураж онын бакча артлатып кына кертә дә куя Шәрифәнең абзарына. Алай бик Шәрифә карчык өчен җанын фида кылырга әзер кеше кебек сөйләшмәс иде дә, Шәрифә карчыкта аракы барын белә. Булмас иде дә, Шәрифә карчык кирәк-яракка дип елның-елына кызыннан, каладан аракы кайтарта. Кыз кайтып китү була, Мөхлис Шәрифә карчыкның сарыкларын «кайгырта» да башлый. Әйтсәң, колхозның бөтен мөлкәтен Шәрифә карчыкның ишегалдына ташып өеп куярга да әзер инде ул андый чакта. Бу юлы да он капчыгы янында аптырап басып торучы Шәрифә карчыкны күргәч, күзләре майланып китте иманын саткан нәрсәнең.

— Нәрсә, тагын мин кирәкме? — дип, борын астыннан гына мыгырданып атын туктатты да, капчыкны көч-хәл белән җирдән күтәреп, арбага таба алып та китте. Кичә фураж оны саткандыр күрәсең берәрсенә, кәефе шәп түгел, башының рәте юк булса кирәк.

— Майлармын, майлармын...— диде Шәрифә карчык,— җәй көне кызым кайтарганның берсен кыстырып калдырганыем.

Мөхлиснең шәмәхәләнгән йөзенә кинәт кенә якты нур йөгерде, авызы колагына җитте. Капчык артыннан Шәрифә карчыкның үзен дә җилтерәтеп печән салган арбасына күтәреп утыртты.

— Кайгырма, Шәрифәттәй, җанкисәгем, миндәй күршең булганда бернәрсәдән дә курыкма! Ни булса да, тот та үземә кер. Ялт иттереп куябыз без аны эш дигән нәрсәне...

Печән астына силос яшергән күрәсең, мөртәт, җылысы бәреп тора, исе борынны яра. Җәй-кыш өстеннән каткан фуфайкасы төшмәс, мәңге айнымас, барлы-юклы тешләренә тәмәке сарысы коелып, йонга батып беткән бәләкәй генә адәм бит югыйсә. Шул да бит колхоз милкен саткалап, арба төбенә печән-силосын салгалап кайтып, шуның белән малларын туйдырып, дөнья көтеп ята. Шулай шул. Юкка гына ир-ир дими шул хатын-кыз дигәнең. Ире булса, әллә шушы сасыкка ялыныр идеме Шәрифә. Бер арбада янәшә утырып кайту түгел, төсен-битен күрмәс өчен генә дә урамны әйләнеп узар иде.

Менә шулай хәйран да кыйммәткә төшереп юнәткән иде ул әлеге сарыклар ашаган ак онны. Тагын шул Питке эшедер инде! Ул булмый, кем булсын? Әй ул имансызның күрсәткән зыяны инде Шәрифә карчыкка! Саный китсәң, кул-аяк бармакларың гына да җитмәс. Башка зыяннарын әйткән дә юк, сабын ашый бит, тәресенә чукынган нәрсә. Әле беркөнне генә, өйалды ишеген борыны белән этеп ачып, ике кисәк кер сабынын ашап чыгып киткән иде. Еламады гына инде Шәрифә карчык. Әллә нинди тел әйләнмәс сүзләр белән иллә дә каты каргады Питкене. Төшмәсә дә төшми икән каргыш дигәнең дә. Шулай булмый ни! Бер айга кеше башына ярты сабын тия бит. Шәрифә карчык берүзе генә булгач, ай саен пычак белән сабын бүлеп интегә кибетче Сәлих.

Шушылай нужаланасын белгән булса, аяк алҗытып алты чакрым җирдән барып алыр идеме соң ул сарыкны. Өч бәрән китерә дигәненә кызыгып, берүзе өч сарыкка тора дигән булып, күрше урыс авылындагы Питер дигән кешедән сатып алган иде аны Шәрифә. Кушаматын да шуңа Питке дип кушты. Өч бәрән китерә дигәне хак булып чыкты анысы. Шуның өчен дә суймый тота инде ул аны. Ничек кенә куркытсаң да сабын ашавын ташлатып булмый. Карчык кешенең хәтер капчыгы тишек шул! Онытa да калдыра Шәрифә карчык сабынын коймага беркеткән юынгыч

буенда. Ә Питкегә шул гына кирәк — ялт, каба да йота! Егылыплар үләр хәлгә житә инде Шәрифә ачуыннан. Шулай булмыйни! Элек бит аның унике тиенлек сабыны тулып ятарые. Хәзер әллә нәрсәгә әйләнде бит дөньясы! Шөкер итәр нәрсәсе калмады. Кая ул унике тиен?! Утыз-кырык сум хәзер. Каян житкерсен ди ул пинсә акчасын. Сабын аласыңмы шуңа, аракысынмы, башкасынмы? Чәп итәргә дә житә торган түгел. Абзарыңда чиләкләп сөт бирә торган сыерың булса да бер хәер иде. Хәзерге әбиләр аракы жыя, дип көлгән булалар бит әле, авызларын ыржайтып. Жыярсың да шул башыңа төшсә, жыймый кая барырсың. Шул нәмәрсәсез, әллә нинди алтын акчалар бирәм дисәң дә, эшләми ир-ат халкы синең эшеңне. Аракы дисәң, егыла да төшә инде менә?! Ә каян табасың ди аны? Саттырмаган була бит шуны прсидәтел кибеттә. Ир-атны эштән биздерә дигән була. Әллә кайчан эштән бизгән бәндәләрне өйрәттең ди алай итеп кенә эшкә, тот капчыгыңны! Ә үзе ала шыпырт кына кешедән качып шул шайтан суын. Бервакыт үзе тап булды Шәрифә карчык прсидәтелнең шундый вакытына.

— Миңа да бер генә ярты бирчәле, салам китертәсем бар, — дип күпме ялынды Сәлихка. Бер яртылыктан артык акчасы да юк иде. Прсидәтел яклап сүз әйтерме әллә дип өметләнгән булды тагын. Кая ул!

— Сиңа нәрсәгә аракы? Аягыңны бөкләп намазлык өстендә генә утырырга кирәк. Аракы эзләп йөрергә түгел! — дип чыгып китте.

Әй гарьләнеп тә карады Шәрифә! Өстенә шау кайнар су китереп сиптеләрмени! Ни эшләмәк кирәк? Аңа ни әйтсә дә килешә дип уйлыйдыр күрәсең. Укыган кеше бит. Зур кеше. Кешенең яшен олылау бетте шул хәзер. Олыны олы итү бетте. Синең аһ-зарыңны тыңлап башы авыртмый. Жавабы кыска: «Кайтарт малаеңны йә кызыңны каладан кире авылга, ныгытсын абзар-кураңны, карасын малыңны...» Ә үзе «Булга» дигән машинада гына утырып йөри авылның сикәлтәле юлларыннан. Әле менә, Сәрбижамал әйтмешли, чишмә суын өенә кертеп бирделәр...

Шәрифә карчык шулай уйланып яткан арада мичтәге утыннар янып бетеп, гүр суыгы иңгән өйгә, ниһаять, жылы төште. Сәрбижамал әби:

— Менә, аллаһы боерса, бөтнек-мәтрүшкәләр белән чәй эчеп жибәрербез, — дип, булары бөркеп торган самавырны өстәл өстенә китереп утыртты. Чынаяк-тәлинкәләрне күңелле чылтыратып, табын көйләргә кереште. Ярата Шәрифә шул чылтырауларны, өйгә тереклек нуры индерә, жан өретеп жибәрә бит алар!

Сәрбижамал карчык өйалдыннан ялт итеп кенә ике төенчек күтәреп керде. Өстәл өстенә куеп сүткәч, «Шулайдыр дигән идем аны-ыы!» — дип сузып торды да Шәрифәне тиргәргә кереште.

— Дивана ук дип әйтсәм инде, хәтерең калыр. Карап торышка акыллы гына кебек күренәсең. Нигә дип бу жимешләреңне житмеш төенчеккә төйнәп, ашамыйча асрыйсыңдыр. Үз-үзеңнән жәлләвең түгелдер бит. Тегә кергәнемдә дә күреп хәйраннарга калган идем мин синең ул төенчекләреңә. Кызың син ашасын дип базардан алып жибәргән була бит аларны. Менә бу күрәгә дигәнен бик тә файдалы икән диләр инде менә жөрәккә. Әйбәтләнеп, сихәтләнеп китмәс идеңме шуларны ашасаң...

Шәрифә карчык өстенә ябылган иске пәлтәне авыр итеп ачып жибәрде дә әллә нинди эчке бер горгылдык белән «у-у-уф-ф» дип сулап куйды. Сәрбижамал, шунда гына аның бу өй эчендә барлыгын искәргәндәй, дертләп-сискәнеп китте.

— Менә бит, биргәненә шөкер, эчеңнән әжәл тыныңны чыгарып ташладың ласа, хәзер терелерсең, боерган булса, — дип такмаклый-такмаклый, Шәрифә карчыкны сак кына торгызып сөяп утыртты да алдына чәйле чынаякны этебрәк куйды: — Берәр нәрсә әйт инде ичмасам, миңа да кызык булып китәрие. Исәр Вәлиәхмәт кебек үзалдыма сөйләнәм дә сөйләнәм бит кайчаннан бирле, ходайның рәхмәте. Ниткән нәрсәләр уйлап ятасың тора салып?! Ник дәшмисең?

Шулай тинтерәтә-орыша торгач, ниһаять, Шәрифә карчык телгә килде:

— Теге мич башындагы ачы балны уйлап ятам әле,— диде ул.— Бик кызу булып, пешеп китмәс микән дим. Карап яттым, утынны алагаем күп яктың инде менә. Миңа ике көнгә житәрлек утын китте бер ягуда... Балы харап булып куймасын. Кирәге чыгарга тора бит... Питкене, мәйтәм, мур кырган нәмәрсәне, суйдырмый булмас болай дуамал кылангач... Утырып еласаң да бушлай гына суеп бирми инде аны беркем. Әле, ачы бал ялына суйсалар, бик рәхмәт диярсең.

— Кит аннан, булмаганны! Тора салып, кыш кермәс борын дүрт аяклы мал чалалар ди микәнни?!

— Нишләп тора салып булсын? Үзең әйттең бит капчыкны ертып он ашаган дип. Алтын бәһасенә төшкән, күз карасы кебек онымны...

— Бер Питкең генә түгелие бит анда, өч сарыгыңның өчесе тиң шундаларые. Ак эт баласе кара эткә дигән сыман... Урыстан алдым дигәч тә... Аннары килеп, ай алла, ашаса соң инде! Берәр соскы онынны ашагандыр, күп булса. Шуның өчен, беткә ачу итеп, дүрт аяклы мал әрәм итәләр диме?

— Күрсәткән зыяны ул гына булмады инде, тәресен таккан нәмәрсәнең. Өйалды ишеген шул җен ача бит, ыргак борын. Тегеләре җимерү-бетерү дигәнне белмиләр аның. Бу чукынганга иярeп кенә җөриләр...

— И алла, гелләрем дә исемнән чыгып киткән, керү белән әйтермен дип кердем юкса. Каз урамы Кәҗә Сәпәенең фләг белән ачы балын табып алган сәвитләр мич башыннан. Тентү белән җөриләр диеме?! Ачы балың өчен бер җавап бирсән, ферма фләге өчен икенче җавап бирерсең дип, урам сасыткannар ди инде менә, гөж килешкәннәр ди...

Шәрифә карчык урыныннан сикереп торганын сизми дә калды:

— Баядан бирле мине дивана да исәр дигән булып сүгеп азапланган буласың бит әле, тавык мие эчкән нәмәрсә, тити баш. Башкайны бетертәсең бит син болай булгач. Нигә сүзеңне килеп керү белән шуннан башламыйсың!

— Син, ходайның рәхмәте, мин кергәндә үлеп жатадырсың түгелме соң, күзләрең гаршегә терәлгән иде бит. Үлгән кешегә кем ачы бал белән фләг сөйләп торсын. Мин сине борчымыйм, жай белән генә әйтим дип азапланган булам тагын...

— Борчымый, жай белән генә әйтә, имеш. Булмаган жайны каян аласың аны! Ай-һай шәп тә жайладың шул! Ип-исән кеше жыгылып үләр синең ул жайлавыңнан. Өйалды ишегеңне жил ачкан, онынны сарык ашаган... Теге дә бу, фәлән дә төгән. Анысы гына бер хәлие әле. Киявең белән кызыңа гына бар да тор дип жанны ашый бит әле, куыпмы куа прәме. Син үз малаеның таш пулатына сыймаганны, мин ни битем белән киявемнең каладагы уч төбе кадәрле фатирына сыя алыйм ди.

— Ай алла соң инде, әйттем исә кайттым... Мин сине, бөкрәеп яткач, чынлап авыргандыр дигән идем. Кая ул! Авырыйсыңмы соң! Каз маенда пешкән коймак кебек чаж да чож килеп торасың әле. Тәнең чирләсә дә, телең чирләмәгән. Юрамалый гына ятуың булган икән. Мин, дивана, урам аркылы чыгалмагач, тышкы моржаңнан күземне дә алмый утырган булдым көннең көн буе, нишләп төтене чыкмый микән дигән булып, жан атып. Әйттем исә кайттым...

Сәрбижамал, эчә башлаган чәен ташлап, ишеккә юнәлде. Чыгып китәргә ишек ачкач кына: — Сәвитләр, тотса, сине тотар, минем мич башымда ачы бал чыжлап утырмый,— диде.

Ишек ябылырга өлгергәнче, аны Шәрифәнең җавабы куып житте:

— Балы минеке булса, фләгесе синеке бит аның...

Чыннан да фләгне әлеге дә баягы шул Мөхлис бер ярты аракыга Сәрбижамалга фермадан алып кайтып биргән иде. Сәрбижамалга гына дию бик үк дөрес тә булмас, уртак байлыклары ул аларның. Урланган икәнен белә торып алмаган да булырлар иде, ләкин чарасызлык алдырды. Ни өчен дисәң, Сәрбижамалның түбән очтагы малаеның кече кызы үз урамнарындагы ерак чишмәдән атнага бер мәртәбә, ял көне су ташып

китә аңа. Икешәр-өчәр көянтә су китерә. Ә Сәрбиҗамалның ул кадәр күп суны салырлык зур савыты юк. Кирәккән саен гына суын төшеп алырлык чишмәсе юк. Тау астындагы якын чишмәне корытты шул силсәвит Гыйлемханы торба утырттырып. Ул суның тәмлелекләрен әйтеп кенә аңлатырлык түгел иде инде менә! Иске салам салып пешерсәң дә чәй тәме килер иде, билләһи! Шул чишмә корыганнан бирле интегә әби-чәби бер чәйлек чишмә суына. Машина, мотоциклы бар кешеләр ерак дип тормый, фләг белән генә ташый да бит суны. Рәхәтләнгән иделәр ике карчык суга шул фләгне алгач. Шәрифә дә чиләк төбенә салып кына шуннан алып чыга иде чәйлек суны. Гөнаһ шомлыгына каршы, көннәрдән беркөнне көчле җил вакытында Сәрбиҗамалның бакча коймасы җимерелеп төшмәсенме! Таба алмадылар гына бит төзәтеп бирер кеше. Ир-атның кайсына гына әйтмә — ярты сорый. «Аракы юк, күпме сорасаң да акча бирермен»,— дигәнне колакларына да элмиләр. Җаваплары бер: «Акча минем үземдә дә бер букча, кирәк булса, үзем бирермен»,— дип кенә җибәрәләр. Көтү кайтты исә, бөтен авыл малы Сәрбиҗамал бакчасына тула. Ярый әле, ялына торгач, әлеге дә баягы шул Мөхлис бер чирек балга төзәтеп бирергә булды. Балны Кәҗә Сәпәе хатыныннан бурычка алдылар. Ул ара да булмады, Шәрифәнең өйгә керә торган тышкы баскычы җимерелеп төште. Тагын бал кирәк булды. Менә шулай, бичарадан ни чара дигәндәй, ике карчык, утырып уйлаштылар да, ай саен кадерләп җыя килгән шикәр комнарын бергә кушып, берсенең фләгесе белән икенчесенең мич башына бал ачытырга куйдылар...

Сәрбиҗамал дулап чыгып китүгә, Шәрифә кая барырга, ни кылырга белмичә, кабаланырга тотынды. Нидер эшләргә кирәк иде. Ахирәтенең холкын белә Шәрифә, шул китүдән бер атнасыз да бусагасын атлап кермәячәк. Гөнаһ шомлыгына каршы, сәвитләр тентү белән килеп керсә, эш харап, картлык көнендә рисвай буласыңны көт тә тор. Баш вата торгач, Шәрифә карчык балны чиләкләп чыгарып түгәргә булды. Әйбәт кенә өлгереп килә торган булган икән, мөртәт! Фләг капкачын ачып җибәрүгә, әчкелтем-төчкелтем исе борынына килеп бәрелүе булды, Шәрифә карчыкның күзләре әлҗе-мөлҗе килеп, башы әйләнеп китте хәтта.

Чүмечләп бүлеп бер чиләкне тутырды да күтәреп ишегалдына чыкты. Кая куярга, кайда түгәргә белмичә, берара аптырап торды. Ачы бал исе бөтен урамга таралудан шүрләп, монда, ишегалдына гына түгәргә курыкты. Ниһаять, башында яктырып киткән дөрес уена куанып, чиләкне абзар почмагына кертеп аударды...

Шулай азаплана-азаплана төбендәге апараларына кадәр чистартып чыгарып түккәч, буш фләгне иске капчыкка салып, су буена төшеп китте. Килеп керсәләр, кемнеке дип сорап тормаслар. Сорамасалар да, капкачына тырнап «Гайнетдинова» дип язып куелган фамилиясе мин дип тора. Бу Мөхлисен дә әйтерең бармы инде, тәмам эт каешына әйләнеп беткән икән мөртәт, урлаша торгач. Кемнекен чәлдергән бит! Ул хатын белә калса, чәчеңне йолкып бетерер, туганкаем, мир алдында адәм рисвае итәр. Бәләкәй генә хатын югыйсә, ә явызлыгы синең авылны гына түгел, тагын әллә ничә авылны дер селкетергә җитәрлек. Каян, эт тә эзләп табалмаслык җәһәннәмдәге Чирмешән ягыннан, килен булып төшә белгән диген син аны бу якларга...

Бәрәңге бакчасы артлатып кына су буена төшеп җиткәч, уйларыннан кинәт айнып китеп, Шәрифә карчык кулындагы капчыгын кай җиргә куярга белмичә бераз гына нәүмизләнеп басып торды. Инеш аша салынган тар басмадан чайкала-сыгыла урыс ягына чыкты, авылның искемоскы, чүп-чарларын ыргыта торган чүплек базы ягына таба китте. Баз янына килеп җиткәнче капчыксыз гына ыргытырмын дип уйлап килгән уеннан кире кайтып, фләгне базның тирәнрәк җиренә капчыгы-ние белән ташлады. Алдырыр көн яздырыр, дигәндәй, аллам сакласын, берәр имансыз җаны артыңнан күзәтеп калган булса, иһ дияргә өлгергәнче килеп җитеп табып алулары да бар. Су төбендәге көмеш тәңкә кебек

ялтырап ятмас ичмасам, капчыкта булса. Өстенә таяк-саяк, тимер-томыр ыргыткалап, капчык тәмам күренмәслек булгач, килгән юлыннан өенә кайтып китте.

Ходай сакласа да саклый икән, кирәк бит шулай туры килергә: бакча капкасыннан Шәрифә, урам капкадан сәвитләр шау-гөр килеп ишегалдына килеп керделәр. Шәрифә карчыкның сәвитләр дигәне авыл Советы рәисе Гыйлемхан, кибетче Сәлих, бригадир Имай иде. Кызыл борыч кебек чым кызыл битле, олы корсаклы Гыйлемхан, кирә-керешли үк, ишегалдын янгыратып:

— Йә, ничек, ярык тагараклар, чымырдыймы мич башында...— диде дә, әйтәсе сүзен очлый алмыйча, үз сүзеннән үзе тәм табып, шаркылдап көлеп җибәрде.

Каушавыннан Гыйлемханның аркылы-торкылы сүзләрен бик төшенеп өлгермәсә дә, Шәрифә карчык аның тел төбен бик шәп аңлады, әмма сер бирмәде:

— Нәрсәгә дип баткан яктан кояш чыгарасың, сүзеңнең атасы-анасы юк,— дигән булды.

Гыйлемхан, олы корсагын тагын да киерәрәк төшеп, тавышына тамак гыргылдавы да өстәп җибәрде:

— Кирәк икән, кояшын гына түгел, кояшы белән бергә аен да баткан яктан чыгарырбыз. Анысы синең эш түгел. Син нитмичә генә нит. И һәм прәме әйт: ачытасызмы бал?

— Әстәгъфирулла тәүбә диген, тфү-тфү, ниткән бал ди ул. Картаймыш көндә... Ни хаҗәте бар аның безгә...

— Бөгештермә, Шәрифәттәй, кәкрәйтмә пажалысты. Беләбез без. Кеше ишетмәгәнне ишетәбез, кеше күрмәгәнне күрәбез. Безне зрә генә шундый отбитстбенный урында тотмыйлар. Беркөнне мин урамнан үткәндә Сәрбиҗамалттәй белән икәүләп миннән көлеп калган булдыгыз.— Гыйлемхан, сүзен җөпләтергә теләгәндәй, үзе белән кергән иптәшләре ягына борылды.— Панимаеш, Сәрбиҗамалы, мин булып корсагын киергән булып, урамның икенче ягына, менә монсы янына чыгып барган була. Эч тирегез ертылганчы тырышсагыз да киерелми инде сезнең корсак. Комыгыз коелган патамушты, капчыгыгыз ертык.— Ул тагын баягыча алаша кешнәгән тавыш чыгарып акырып көлеп куйды. Аңа иптәшләре дә кушылгандай иттеләр. Гыйлемханның йөзе баягыдан битәр усалланып китте:— Так шту, ачытасыз булгач ачытасыз инде сез ул балны, и баста! Сәпәй хатыны да, ниткән бал да ниткән ачу дип, баш диваналатып азапланган иде дә бит, ни тут-ты была! Җырлап утыра базында «урыс малае»... Әйдәле, өеңне әйләнеп чыгыйк әле...

Олы итекләре белән сары гәрәбәдәй идәнгә лас-лос басып, өйгә үттеләр. Кибетче Сәлих туп-туры мич арасына таба китте. Күптәннән инде аракы, бал иседән башканың исен аера белми башлаган борынын лыш-лыш тартып исненде дә:

— Һм-м, да-а-а, нидер булган монда... бал исе дә килә, мич башына җәелгән чүпрәк тә бар,— дип куйды.

Имай баз капкачын ачты. Идәнгә тезләнеп, ярты гәүдәсен баз авызыннан эчкә төшереп җибәрде...

Шәрифә карчык бөтенләй коелып төште. Чирдән ныгырга өлгермәгән бәләкәй гәүдәсе тагын да кечерәеп, бөкшәеп калды. Менә-менә нindидер могҗиза булыр да, бу мөртәтләр идән йә карават астыннанмы, мич башыннанмы «Гайнетдинова» дигән флаг белән ачы бал тартып чыгарырлар кебек тоела башлады аңа. Белмим ни эшләп беткән булыр иде Шәрифә карчык болар белән, кинәт өй ишеге ачылып китте дә, тавышы белән кемнедер өркетергә теләгәндәй шау-шу килеп, кулларын як-якка бутый-бутый Сәрбиҗамал килеп керде.

— Әә-әә, менә тагын сезгә бер көмешкәче үзе килеп капты кармакка!— дип шаркылдады Гыйлемхан, аны күргәч.

— Син, Гыйлемхан энем, эчеңдә әз генә иман әсәре сакланып калган булса, сүзеңне адәм белән исәнләшүдән башла. Ни эшләр бетереп ятасыз,

әбекәйләр, моң-зарларыгыз юкмы, диген. Ялгыз башкайларыгызга авыр түгелме дөнья көтүләре, тегесен-монысын ничек юнәтәсез, диген. Яхшы сүздән телең корымас. Прит кеше өенә кергәндә аягыңны салып кера торган бул.

— Син, түтәй, мине ничек яшәргә, ничек сөйләшергә өйрәтмә инде пажалысты. Анлык кына грамыт бар бездә слава бут. Зрә генә ничә еллар укып йөрмәдек совет мәктәбендә... Карт кеше дип хәл сорый китсәң монда... авылда карт-корыдан күп нәрсә юк, көне-төне хәл генә сорашып йөрергә кала.

— Һи-һи-һи, грамытыңны әйтерием... Синең грамытылы башың кадәр алтын бирәбез дисәләр дә мин үземнең грамытысыз башымны синекенә алмашмыйм! Билләһи дип әйтәм, алмашмыйм! Беләбез, аллага шөкер, синең грамытны. Минем малай белән бер сыйныфта укып йөрдегез бит. Беләм мин синең нинди сабак алганыңны. Гел минем малайдан күчерер идең... Бер җылны утырып та калдың әле... Дәфтәрдән күчергәнне башка күчереп булмый шул. Инсафлык, әдәп дигәнен дә кешедән күчереп булмый тагын, аннан килеп...

— Синең малай яхшы укып нәрсә майтарды соң ул кадәр?! Кем булды? Шәрифәттәйнең кызы отличник булып ни кырды? Академик булдымы әллә?! Алай бик яхшылар булгач, нигә балаларыгыз карамый соң сезне? Чит кешедән хәл белдермәкче буласыз.

— Безнең балалар, синең сыман түрәләргә тишек чиләк тотып, төчкергәннәре саен «Ярхәамикалла!» дип, мәртәбәгә ирешмәделәр шул, аллага мең шөкер, үз көчләре белән дөнья көтәләр...

Бәхәс күпме барыр, кемнең кемне җиңүе белән беткән булыр иде, сүзгә кибетче Сәлих кушылды:

— Куегыз әле пүчтәк сүзегезне... Болай да авырткан башны катырмагыз. Һәркем үз белгәненчә яши... Яшәсеннәр сезнекеләр калада, юсыннар ниләрен кайнар су белән... Әйт әле менә син, Шәрифәттәй, ни дип аракы җыеп ятасың, ә?!

Шәрифә: «Соң... ни дип инде, ни бит инде...» дип нинеләп тора башлаган гына иде, Сәрбиҗамал Сәлихнең авызына да бик тиз генә йозак элде.

— Ни дип булсын! Эчәргә дип! Без дә бит синең кебек җан иясе, яралган туфрагыбыз төрле булса да... Нәрсә! Безнең авызыбыз юкмыни? Йә булмаса җаныбыз юкмы? Сиңа яраган әйбер ник дип әле безгә ярамаска тиеш. Син көн саен диярлек сәрхүш йөрисең — сиңа килешә! Ә безгә юкмыни?..

— Туктале, түтәй, чытыр-пытыр килмә әле чи утын кебек. Синең белән сөйләшмиләр бит! — Монысы Имай тавышы иде.

Шул сүзне генә көтеп торган диярсең, Сәрбиҗамал аның да авызын тиз япты:

— Ии-һи, бөтенләй вәлиманҗегә алмый да торам икән — син дә мондамыни, җанкисәккәем? Ә син корысын кайтарт утынның, ник кайтартмыйсың?! Нигә гел үзеңә генә ташыйсың? Кайчан түгәрәкләнә инде синең ул нәфсе дигән бирәнең? Безнең аракы бирә-бирә кеше яллатып кайтартканнан көлеп йөрү ансат анысы. Анысын аның кем дә булдыра. Анысына аның акыл кирәкми. Син менә үз гомереңдә бер генә мәртәбә булса да кешегә түләүсез изгелек эшләп кара. Син бит бригадир кеше. Ә без гомер буе шул колхозга көч түккән бәндәләр түгелмени?! Колхозга кирәгебез беткәч, кадеребез дә киттемени инде? Ник безнең моң-зарны белешеп прсидәтелгә әйтмисең? Прсидәтел чит як кешесе, килгән кеше булса, син бит безнең авылныкы, кая кергән, кайдан чыкканны белеп торырга тиеш...

— Туктат әле, түтәй, юкка тегермән ташы әйләндерүеңне. Монда башка мәсьәлә бит...

— Мәсьәләсе башка булса да, мәгънәсе бер аның...

— Я, ярар, егетләр, әйдәгез киттек, — диде Гыйлемхан, мич араларын, өстәл асларын тагын бер кат карап чыккач, ни дә булса табылырына

өмете өзелгән тавыш белән.— Булмас монда болардан... Ну, матрите, карагыз аны, бал куя күрмәгез. Сразы өч йөз тәңкә штраф. Аракы түгел, шырпы алырга да акчагыз житмәс аннары...

Тегеләр артыннан ишек ябылуга, Сәрбиҗамал карчык кинәт кенә йомшарып киткән тавыш белән, бераз аклангандай:

— Мин сиңа сәвитләр кереп киткәнен күреп, яклашыйм дип кенә керүемие...— диде.— Үпкәм бетмәгәние әле... Тиз генә керәсе түгелием... Миңа гына каты әйтәсең син... Сәвитләргә, әнә, ни актан, ни карадан бер кәлимә сүз әйтә алмадың. Нишләп бетериең мин булмасам... Үзең дә инде, кая яшереп өлгердең соң шул арада теге шайтан суын?

— Кая булсын, абзарга чыгарып түктем.

— Ай аллам икән, йә раббым! Юләр белән тапма да, өләшмә дә димәсләр иде аны! Хараплар гына иткәнсең икән! Бурыч булмаса да бер хәлие. Кәҗә Сәпәс хатынын ничек бәхилләтербез соң болай булгач?! Башкаең эшләмәгәч, акыллыдан сорарга да бит...

— Син, алай башың иллә дә шәп эшли торган булгач, уйлап кара шул яхшы башың белән: акыллар сорап йөрсәм, түкмәгән булсам, сәвитләр тота иде бит. Харап була идек икәүләп... Фләг бит синеке...

— Үләсең инде, бичара, фләг тә фләг дип! Туктале, фләг дигәннән, фләген кая яшердең?

— Урыс ягындагы чүплеккә илтеп ташладым.

Моңарчы кабыныр-кабынмас торган Сәрбиҗамал дөртләп кабынды:

— Бу кадәр дә аңгыра булырсың икән, билләһи! Кем инде аракы бирә-бирә алган җан күек нәрсәне чүплеккә илтеп ташлый?! Һи! Синең белән сүз алышкан мин юләр! Ник керәмдер шушыңа?!

— Кермәсәң! Бик җыладым ди. Иртәгә үк алып кайтып бирермен «Гайнетдинова» дигән фләгеңне хуҗасына, алай бик ачуымны китереп торсаң...

— Кайтарып бир, бир... Шунда берочтан абзарыңдагы фураж оннарын да күрсәтерсең!..

Сәрбиҗамал карчык тагын бусарынып, тузына-тузына чыгып китте. Ул да балмады, ишегалдыннан тагын аның баягыдан да битәррәк йомшара башлаган тавышы ишетелде:

— Карале, чыгале, сиңа әйтәм. Монда Питкең үлеп ята түгелме соң?

Шәрифәнең йөрәге жу итеп китте. Йөгереп чыкса, чыннан да ишегалды уртасында бөтен буена сузылып Питке ята. Башы бер якка уңайсыз салынып төшкән иде. Түзмәде Шәрифә, такмаклый-такмаклый еларга тотынды:

— Ии-и газиз бер ходаем, ниләргә дип аерасың мине иң газиз, җаным кебек күргән малымнан. Монысы бигрәкләр дә әйбәт ие бит, малкаем. Ишегалдында гәүдәм күренүгә, мәэлдәп ул йөгереп килеп җитәр иде, малкаем, яныма... Адәм акыллары бар иде инде менә, әүлияләр кебек иде. Көтүдән туп-туры өйгә кайтырые малкаем, тегеләрне аңгыраеп торган арада капканы танавы белән генә этеп ачып килеп керерие, ишегалдына ямьнәр кереп китәрие...— Үзе сөйләнә, үзе янына тезләнеп, һаман саен катырак елый-елый Питкесенең хәрәкәтсез башыннан сыйпый.

Ул ара да булмады, Питке кинәт кенә күзен ачты, башын көч-хәл күтәреп, кызганыч тавыш белән мәэлдәп алды да тагын күзен йомды. Шәрифә эшнең нидә икәнен аңлап өлгергәнче, ахирәтенең аһ-зарын бер читтән генә күзәтеп торучы Сәрбиҗамал сүз башлады:

— Әттәгенәсе, менә сиңа кирәк булса, ахыр заман димә инде син моны... Үлмәгән бит бу синең... Үлмәгән бу!

— Үлмәгән ди сиңа, бар! Үлмәгән мал шушындый була ди микәнни?! Үлгән булгач, үлгән инде...

Шәрифә карчык тагын ачыргаланып еларга тотынды.

— Туктале, еламале! Әйт әле, балыңны кая түктем дидең әле бая?

Берсен-берсе узыша-узыша дигәндәй, абзар эченә, Шәрифә карчык ачы балны түккән почмакка йөгерешеп керделәр дә, күз алларында

ачылып киткән манзарадан шаккатып, баскан урыннарында тораташтай катып калдылар.

Җирдә Шәрифә карчыкның унлап тавыгы тәгәрәшеп ята, араларында алпан-тилпән атлап, бер авып, бер торып әтәч йөри. Бераз арырак ике сарык егылган. Бал түккән урында өелеп калган чүпрә абзар почмагының кара җире чыгарлык итеп яланып алынган иде...

Эшнең нидә икәненә үз күзләре белән күреп төшенгән ике карчык эчләрен тота-тота, бер-берсенә тәрткәли-тәрткәли, тәгәрәшеп көлергә тотындылар...

Бер-берсенә ачулары ничек тиз кабарган булса, көлке белән шулай ук бик тиз генә чыгып та беткән иде күрәсең, бераздан алар чөкердәшә-чөкердәшә, булары чыгып торган самавыр артында икәүләп чәй эчеп утыралар иде инде...

* * *

Авылга кичке караңгылык иңеп килгән бер мәлдә, иске-москы ыргыта торган чүплек базы ягыннан ике кеше кузгалды. Аларның берсе аркасына капчык аскан, икенчесе янәшәдән атлый. Бераз баргач, капчык янәшәсендәгесенең аркасына күчте. Шулай алмаш-тилмәш күтәрә-күтәрә, бакча артлатып кына кайтып җиттеләр дә, ул ара да булмады, Шәрифә карчыкның тәбәнәк өендә ялт итеп ут кабынды. Ике карчык төн йокламый, нормалап бирелгән шикәр комнарын бергә кушып, Сәрбиҗамал карчык фләгесе белән Шәрифә карчыкның мич башына бал ачытырга куйдылар. Чөнки кичә бригадир Имай үзенә печән алып кайтканда КамАЗ машинасы белән бәрдереп Сәрбиҗамал карчыкның капка баганасын аударды. Мөхлискә әйтеп караганнар иде дә, ул, мөртәт, әзмикуймый ачы бал сорый. Акчага якын да килми...

## Зыя Мәүлидов

# ГАЛӘЙ

КЫЙССА

Күптән, бик күптән булган хәл бу. Аны миңа бала чагымда әбием сөйләгән иде. Аңа да әбисе сөйләгән булган, ә ул әбигә шулай ук әбисе сөйләгән, анысына да әбисе... Әнә шулай борын-борын заманнардан килә баһадирларыбыз турындагы бу кыйсса...

Инде мин дә картайдым, туксаным якынлаша. Тәңремнән җанымны үз янына алуын кат-кат сорасам да, минем үтенечемне үтәргә нигәдер әмерен бирми ул. Шунысы, шөт, тәгаендер — бу назлы вә гыйбрәтле хикәятне сезгә ирештерүемне тели булыр Тәңрем. Тыңлагыз, оланнар...

Гап-гади татар авылының иң кырый йортында яшәгәннәр алар. Зур булмаган бу гаилә — әтисе дә әнисе һәм Сания исемле кызлары. Сания мәрхәмәтле һәм житез, булдыклы һәм акыллы булып үскән. Ә ундүрт яшендә инде ул гүзәллеге белән бөтен тирә-юньне таң калдырган. Чибәрлектә аңа тиңләшерлек берәү дә юк икән. Бу матурлыкны сөйләп аңлатырлык түгел икән, аны күреп кенә аңлап була икән. Авылдашлары Саниягә сокланып туймаганнар. Һәм кызның даны ерак-еракларга таралган. Гаилә бай булмаган, әмма Сания аның дөньяда тиңдәшсез энҗесе булып балкыган. Күп егетләр өйләнергә теләгән Саниягә, яучыларны бер-бер артлы җибәргәннәр алар. Ләкин кызның әти-әнисе ризалык бирмәгән.

— Кызыбыз бик яшь әле, — дигәннәр алар. — Яшьлек рәхәтен күрсен. Ире артына посарга һәм бала чүпрәге юарга өлгерер...

Вакыт уза, көннәр атнага, атналар айга, айлар елларга тәйнәлә. Болыннар чәчәкләргә төренә дә аннары аларга ак карлар түшәлә, кырлар яшелләнеп дулкынлана да аннары алар моңсуланып карая, елгалар бозга ката да аннары алар тагын шаулап ага — тормыш та әнә шул шашкын елгалардай кодрәтенә горурланып ага да ага...

Бервакыт авылга ерак Казан каласыннан бай сәүдәгәр килә, авыл башындагы иң беренче йортка сәламен бирә. Һәм Санияне күреп таң кала. «Без бу энҗекәйгә лаеклы хуҗасын табарбыз! Бар андый акыллы һәм баһадир егет!» — дип сөенеп уйлый ул. Эшне озакка сузмастан, йорт хуҗасы Әхмәдуллага — Саниянең әтисенең исеме шулай — шушы хакта сүз куша. Әхмәдулла хатыны белән киңәшә. Ата-ана мондый карарга киләләр:

— Асыл кош, гел читлектә тотсаң, тамырына дым тимәгән чәчәктәй сула. Кызыбызга инде уналты яшь. Аллага тапшырдык... Хәерле белән...

Кыз белән егетне таныштыралар. Рәшид — егетнең исеме шулай — белән Сания, беренче күрешүдә үк бер-берсенә мәңге-мәңгегә гашыйк булалар, алар моңарчы бер-берсен көтеп яшәгән ике тугры җан икән!..

Тиздән шаулатып-гөрләтеп туй ясыйлар. Туй түрендәге Рәшид белән Сания бу олы мәҗлеснең якты сибүче ике тиң энҗесе була. Алар матур яши башлыйлар. Тик тормышның ваемнарын да онытырга ярамый бит әле, тормыш гамь итүчене ярата. Ә яшь кияү Рәшид — эшчән кеше, тормыш тоткасын җайлап һәм кысып тотарга җыенучы сәүдәгәр ул.

Ширбәтле ай узгач, Рәшид сәүдә эшләре белән сәфәр чыга, Саниясен авылына илтеп куя. Шактый озак вакыт хәбәре булмый Рәшиднең. Сания ирен сагынып борчыла башлый. Авыру тигән кебек тоя да, аннары, әй-й, чир түгелдер лә, дип тынычландыра үзен, мөгаен генә... бәби алып кайтырга җыенамдыр ла... Шушы изге өмет аның куркуын баса төшә. Шулай да әнисенә:

— Кыз чакта рәхәтрәк тә, күңеллерәк тә булган икән, кичке уеннарда жырлый-бии, шаяра-көлә идем,— дип моң-зарын сөйли.— Ә хәзер... ирем кайда кемнәр белән йөри икән, дип кайгырып көтәргә мәҗбүрмен... Мөгаен, Рәшиднең бүтән сөйгәне бардыр... Их-х, кызлар нигә кияүгә чыгарга ашкыналар икән... Рәшидем миңа хыянәт итәдер...

— Ни сөйләвең бу?— дип туктата Санияне әнисе.— Аллаһы Тәгаләнең ачуын чыгарудан куркыр идең? Түзем булырга кирәк. Тормыш шулай корылган инде, аның иң авыр мәшәкатьләре башлап ирләр җилкәсенә төшә. Ярата сине Рәшидең, бердәнбере итеп ярата! Бөтен йөрәгем белән сизеп торам шуны. Тиздән кайтыр ул. Борчылма. Эш белән йөри Рәшид кияү, кайтырга әлегә җае чыкмыйдыр. Аның әти-әнисе дә әйбәт кешеләр, Рәшидкә азып-тузып йөрергә беркайчан да ирек куймаслар. Казанда зур һәм уңайлы йорт сатып алырга җыеналар алар. Мәркәздә яшәячәксең. Сине янымнан җибәрәсем килмәсә дә, нишләмәк кирәк... Ир — кайда, хатын — шунда. Тормыш итү кануны шундый. Кайтыр, тиздән кайтыр Рәшидең. Кайтыр да сине — минем йөрәгем парәсен алып та китәр...

Рәшидтән озакламыйча хат килеп төшә. Ул Санияне өзелеп-өзелеп сагынуы, аны мәңге-мәңге яратачагы турында язган. Казанда зиннәтле йорт сатып алган, шуны тагын да матурлап бизәгәч, Санияне кайтып алачак икән. Шуннан соң алар беркайчан да болай озакка аерылышып тормаячаклар икән.

Әтисе-әнисе Санияне юлга әзерли башлыйлар. Әнисе кызның «оясын бөтенләйгә калдырып очачагына» кайгыра да, сөенә дә, аңа йортны алып бару, кунак каршылау һәм башка-башка нәрсәләр турында киңәшләрен кабатлый. Әтисе югында хатын-кыз серен дә чишә.

— Кызыкаем,— ди ул,— ирләр бездән башка берни дә майтара алмыйлар. Алар кырыс һәм бездән бәйсез булып күренергә тырышалар гына, чынлыкта гаилә тоткасы безнең кулда, ирләр үзләре безгә хезмәтче кебек. Ләкин алар — безнең ышанычлы саклаучыларыбыз, туендыручыларыбыз, киендерүчеләребез. Әйе, атасыз бала — ятим, ә анасыз бала — икеләтә ятим. Кызым, син бер нәрсәне беркайчан да онытма: хатын-кызның олылыгы һәм көче — ирен һәм балаларын яратуда. Әгәр ир эчүчелеккә сабыша яки гаиләсен ташлап китә икән, димәк, хатыны аны кадерли белмәгән, яратмаган. Гаиләне бәхетле итү хатыннан тора. Шуны гел исеңдә тот, балакаем...

Барысы да әйбәт кенә бара. Әмма явыз көчләр дә мәкерле тозаклар коралар икән...

Санияләрнең авылыннан ерак түгел генә рус гаскәрләре тора. Аларның ныгытмалары артык зур түгел, ләкин анда керергә берәүгә дә рөхсәт ителми, солдатлар аны сизгер саклыйлар. Тик шунысы билгеле — анда хезмәт авыр түгел, солдатларның буш вакытлары күп кала. Офицерлар кәрт сугарга яраталар, акчага уйныйлар. Кәеф-сафа коруда, кәрт уйнауда ике офицер бигрәк тә ашып узган. Аларны зур шәһәрдә хезмәт иткәндәге гөнаһлары өчен шушы караңгы почмакка җибәргәннәр. Яшьрәк офицер еш оттырган. Ә беркөнне аның уены бөтенләй бармаган. Кесәсендәге акчасы беткәч, алдагы ай хезмәт хакын оттырган, кулындагы балдагын салган, әр-яна күнитекләреннән колак каккан. Аннары чиркәү атакаеннан бурычка алган акчасы да очкан. Болары гына да җитмәгән, бурычка да күп оттырган.

Инде төн уртасы узган. Өлкән офицер уенда уңмас яшенә мондый шарт куйган.

— Өч көндә күрше авылдагы татар чибәркәе Санияне тотып китерсәң, мин синең барлык бурычларыңны кайтарганга саныйм!

Уйга калган яшь офицер. Һәм, ниһаять, килешкән. «Әгәр фаш ителә калсам да,— дип фикер йөрткән ул,— миңа зур җәза бирелмәячәк. Христиан динендә түгел ич ул Сания дигәннәре. Басурманны яки мәҗүсине үтерү дә олы гөнаһ саналмый хәтта. Тәңре дөньяны шулай яраткан — җир йөзендә башка диндәгеләр азрак булган саен православныйлар

рәхәтрәк тормыш итәчәк. Аннары мин Сания дигәннәрен үтерергә җыенмыйм бит. Тотып китерәм дә — минем эш бетте. Аны нишләтүләрендә минем дәхелем юк. Дворян затка хатын-кыз урлау килешми, дип кинаяләүләре мөмкин. Хәер, минем дворянлыгымнан исеме генә калган инде. Әти мәрхүм бөтен байлыгын кәрттә оттырып, хатын-кызларга исраф итеп бетергән, әнигә ике баласын да җимерелергә торган йортын, аксак ат та картайган кучер гына калдырган. Әлбәттә, әрләгән булырлар, җәза биргән итеп, бүтән полкка күчерерләр. Шулай да Санияне тавыш-тынсыз гына урларга иде. Көч кулланмыйча булмастыр булуын. Шөкер, кул каера гына беләбез... Бурычлар күп, офицерның шартын үтәмичә булмый. Ул әшәке җанның моннан да зуррак шартлар куюы ихтимал...»

Һәм кәрт уенына хирыс яшь офицер Саниянең кая баруын, кем белән аралашуын, нәрсәләр эшләвен ике көн буе күзәтә. Санияне урлау өчен бер генә көн кала.

Әнә шул өченче көндә дә Сания болында печән чабучы әтисенә ашарга илтә бара. Ярты юлны узгач, Санияне тарантаска җигелгән ат куып җитә. Анда әлеге яшь кәртче утырган була.

— Рәхим итеп, утырыгыз,— ди ул.— Барасы җирегезгә илтеп куям.

Яшь хатын бу игелекле тәкъдимгә килешә. Сания тарантаска утыруга ук ат чаптырып алып китә, мондый кинәтлектән Сания хәтта егылып төшеп кала яза.

— Алай каты кумагыз,— дип кисәтә Сания.— Инде урман борылышын узабыз, андагы болында әтием печән чаба, мин аңарга ашарга илтәм.

Саниянең сүзләреннән соң, офицер атын чыбыркылый, һәм ат җилдәй җитез оча башлый. Сания сикереп төшеп калмакчы була, әмма офицер дилбегәне бер кулына күчерә, икенче кулы белән Санияне эләктереп өлгерә. Сания ычкынмакчы булып талпына, тик офицер аны каты каптырган икән. Саниянең кулындагы ризыклар юлга чәчелеп кала. Сания кычкырырга тотына, ләкин тавышын тояк тавышлары күмеп китә. Аннары тирә-юньдә беркем дә булмый бит.

... Әхмәдуллага иртәдән үк гел кире килеп тора — эчәргә дигән суын ялгышып түгә, түбәтәе башыннан төшеп китә дә аны чалгысы белән кисә яза, өстәвенә чалгы кайрагының да җайсызын алган икән. Хатыны белән кызына ачуы кубып ала, иртә таңнан, Рәшид тә Рәшид, дип кабатлап йөреп, юлга юньләп әзерләшмәделәр. Күңеле тыныч түгел Әхмәдулланың. Һәм өенә кайтып килергә була ул. Чалгысын яшереп куя да ау пычагын кынысына тыгып биленә тага, бишмәтен аты сыртына бәйләгәч, атына сикереп атлана, чаптырып китеп тә бара. Юлга чыккач, чәчелеп яткан ризыкларны күреп ала.

— Саниягә нидер булган! — дип кычкырып җибәрә Әхмәдулла.— Ни булды?! Әлерәк кенә чаптырып узган ат тояклары тавышы ишетелгән иде...

Әхмәдулла куа китмәкче була, ләкин олы юлдан узган атлы ерак китеп өлгергәндер, шуңа күрә сукмактан турыга кистереп чыгарга ниятли. Алмачуар атын моңарчы беркайчан да болай каты куалаганы булмый аның. Шулай да алар тарантаска җигелгән атның юлын кисәргә өлгермиләр. Әхмәдулла солдатлар крепостена килеп җиткәндә, читтәге йорт янышнан тарантаслы атны бер солдат алып китеп бара, ә анда Сания булмый инде. Әхмәдулла йортның ишеген шакый, кызын шунда яшергәннәр, дип уйлый ул. Яшь офицер, атны туарырга илтергә тиешле солдат дөбердәтә дип белеп, ачуланып ишекне ача һәм селтәнеп торып суга. Искәрмәстән сугуга Әхмәдулла егыла башлый, ләкин дворян нәселе калдыгының җиңеннән эләктереп өлгерә. Һәм алар баскычтан әүмәкләшеп тәгәрәп төшәләр. Офицерның кулында пычак ялтырап китә, әмма Әхмәдулла өлгеррәк икән — ау пычагын кынысыннан чыгарып, кәртче һәм угры офицерга кадый...

Әхмәдулла һәм хатыны төн буе йокламыйлар. Иртәгесен иртүк солдатлар Әхмәдулланы алып китәләр. Аны берничә көн ябып тоталар.

Офицер исән калса, хәлнең ничек булганы ачыкланып, бәлки, Әхмәдулланы җибәргән дә булырлар иде. Ләкин офицер, атна узгач, теленә килә алмыйча ярадан үлә. Вафаты алдыннан йөзенә кемнәндер бик ялварып гафу үтенү кыяфәте төшкән һәм, әни, әни, дип еш кабатлаган икән...

Тиздән суд була. Русча начар белүче Әхмәдулла судта сөйләгән сүзләрне төшенеп тә җитми. Тик бер нәрсәне анык белә ул — әгәр офицер алданрак кадаса, Әхмәдулла исән калачак түгел иде. Әхмәдулла явыз ният белән кеше үтерергә теләмәде бит, ул сакланмакчы гына иде. Судта кәртче рус офицерының бизәкләп-сурәтләп сөйләвенең мәгънәсенә дә төшенеп җитмәде Әхмәдулла. Бактың исә, имеш, Нефедов — яшь офицерның фамилиясе шулай иде — белән Сания бер-берсен бик яратканнар һәм еш очрашканнар икән. Кызның әтисе ике яшь йөрәкнең мәхәббәтен кабул итмәгән, шуңа күрә гөнаһсыз Нефедовны ерткычларча үтергән. Гаепсез булып кыланмасын Әхмәдулла, аңа җәзадан котылу мөмкин түгел, аның ау пычагы җинаять урынында табылды, тикшерү бу канлы пычакның Әхмәдулланыкы булуын раслады. Шулай булгач, Әхмәдуллага иң каты җәза бирелергә тиеш...

Ялганлап сөйли дә сөйли офицер, ә Әхмәдулланың башында уз уйлары кайнаша...

Кызымны рәнҗеттеләр. Аның ире моннан еракта, мондагы хәлләрне белми. Мине ни көтә? Кеше үтердем... Ә бит мин гаиләмнең, кызымның намусын һәм тормышымны сакламакчы идем...

Суд аны озак елларга каторгага җибәрергә хөкем итә...

Бәла ялгызы йөрми, аның берсенә икенчесе ялгана, диләр...

Сания әтисен япканнан соң беркая да чыкмады, берәү белән дә аралашмады. Авылда, Сания намусын җуйган, иренә тугры буласы урында, кяфер белән чуалган, дигән хәбәр бик тиз таралган иде. Һәм Саниягә чара күрергә уйлыйлар. Аксакаллар җыела, анда мулла да килә. Өлкәннәр мондый карар кылалар: «Авылга бәла төште. Яшь хатын, ире югында денсез белән чуалып, Коръәнгә хыянәт итте. Хөрмәтле Әхмәдуллабыз кызының гөнаһы өчен сөргенгә җибәрелде. Ә азгын хатынның кемне тудырасын белгән юк. Судта өлкән офицер, алар күптән кети-кети уйнадылар, дигән бит. Әгәр Әхмәдулла бер уңайдан азгын кызын да үтергән булса, ичмасам авылыбыз кешеләренә хурлыгы азрак булыр иде. Саниягә бу коточкыч гөнаһы өчен җәза бирергә кирәк. Мондый аянычны гафу итәргә ярамый. Аңа ияреп, бүтәннәрнең дә шәригатьне санга сукмаулары ихтимал. Саниягә бик каты җәза бирелергә тиеш! Ә нинди җәза бирәсен авыл җыены хәл итсен!»

Җыенын җыен да, әмма Санияне ничек җәзалауны аксакаллар алдан ук хәл итеп куйганнар булса кирәк шул.

... Картларның киңәшүеннән ике көн элек, Сания янына яшьтәше Ибраһим керде. Ул Санияне күптән ярата һәм Саниянең кияүгә чыгасын да беренчеләрдән булып ишеткән иде. Саниягә пар булмаячагын белде Ибраһим — көчләп яраттырып булмый бит. Әйе, әйе, авылда, хәер, бөтен тирә-юньдә Саниягә күз атучылар бихисап иде, аңа гыйшкы төшмәгән егет калмагандыр. Ибраһим да Санияне чын күңеленнән яратты. Көчкуәттә, акыл-фигыльдә Ибраһим башка егетләр янәшәсендә сынатмый иде, тик менә бер кимчелеге күзгә күренеп тора — ике калак сөяге арасында калку төше бар. Әллә ни зур да түгел инде ул үзе, әмма Бөкре кушаматы тагулары өчен җитеп ашты. Шулай да егет кушаматы өчен кешеләргә үпкәләмәде. Нишләмәк кирәк — бөкре икәнсең, аны яшереп булмый, кешеләр кушаматны хак такканнар. Ибраһим тыныч холыклы, киң күңелле егет, тәкәбберлекне белми ул.

Сания Ибраһим керүенә бик сөенде һәм егеткә барысын да ничек булганча сөйләп бирде. Ибраһимнан ире Рәшид янына Казан каласына баруын елый-елый үтенде.

— Ибраһим, дим, Рәшидкә берүк җиткерә күр, килеп йөрмәсен ул монда! Аллаһы Тәгаләм шаһит, минем аның алдында тырнак очы хәтле

дә гаебем юк! Әмма мина яла ягып, ана әләкләячәкләр. Йөрәгем сизә, Ибраһим, безнең тормышыбыз барып чыкмаячак. Яратам мин Рәшидемне! Ләкин без бергә була алмаячакбыз... Мин үземне кызганмыйм, әтием кызганыч, минем өчен җәфа чигә бит ул. Мине мәсхәрә итмәкче булган бәндә үлгән диләр. Инде Алла гафу итсә генә аны, ләкин мин гафу итә алмыйм!.. Әнием әйтә, авыл аксакаллары нидер кылмакчы булалар икән, ди. Юньлегә түгел бу! Йөрәгем сизеп тора — юньлегә түгел... Ә минем намусым чиста. Чиста!..

Шул ук кичне Ибраһим атына атлана да Казан ягына сәфәр чыга, аның китүен авылдашлары сизмичә дә калалар. Ибраһимның колак төбендә Саниянең ачынулы сүзләре юл буе яңгырый:

— Мин гаепле түгел! Минем намусым тапсыз!..

Әйе, матур булып тумасаң да, бәхетле булып туарга кирәк икән. Сания матур, ләкин бәхете юк, күрәсең. Ә бәхет дигәннәре нәрсә икән соң ул? Аны ничек аңларга да каян эзләп табарга?..

Ибраһимга шундый уйлар юлдаш була. Һәм ул икенче көнне кичке эңгер-меңгердә шәһәргә барып та җитә. Базар янындагы юлаучылар йортында туктый. Арыган атына ашарга биргәч, каршыдагы хәрчәүнәгә керә. Анда кешеләр күп түгел икән. Ике салмыш агай, кочаклашып чыгып barганда, Ибраһимга ым кагалар, дөньяның рәхәтен инде син таты янәсе. Ә-ә, әнә, түрдәге өстәл артында дүрт офицер кәеф-сафа коралар икән. Башка кеше юк. Хезмәтче малай Ибраһимга ашарга китерә.

Гадәттә, Ибраһимның авылыннан Казанга ике көндә килеп җитәләр иде, ә ул бу араны тәүлек чамасында узды. Ардырган, карыны да ачкан. Үзе ашый, ә башында төрле уйлар кайнаша — авылда нинди хәлләр бар икән, җыен җыймадылармы икән, Рәшидне ничек эзләп табарга булыр, Саниянең хәле ничек икән...

Нәкъ шул чакта бер офицер Сания исемен әйтеп куя, һәм Ибраһим офицерларның сөйләшүен дикъкать итеп тыңлый башлый. Шөкер, егет русчаны әйбәт аңлый һәм Сания исемен әйткән офицерларның вафат Нефедов белән бәхәсләшкән кеше булуын төшенеп ала. Нефедов, бик күп оттыргач, бурычын кайтару өчен, мактанып сөйләүче офицерга татар гүзәле Санияне тотып китерергә ризалашкан икән. Тик исерекбаш Нефедовны Саниянең әтисе Әхмәдулла куып җиткән, кызын коткармакчы булып... Әйе, Әхмәдулла ясаган ярадан кәртүжник җан тәслим кылган...

— Суд мәсьәләнең асылына төшмәсен, тирәнтен төпченмәсен өчен,— дип тәмамлый әлеге офицер сүзен,— Нефедов белән Сания берберсен бик яраталар иде, дип сөйләргә мәҗбүр булдым. Ә Санияне судка чакырып та тормадылар. Минем сүзләремне башкалар да расләды. Аларның да бүтән чарасы юк иде, чөнки күбесе Нефедовка бурычка акча биреп торганнар иде алар. Билгеле инде, Нефедов миңа Санияне тотып китереп кенә бурычларыннан арына ала иде. Судта, Нефедов белән Сания әлек тә гел очрашалар иде, дип күрсәтмәсәк, без дә җинаять кылуда катнашучылар була идек бит...

Яшь офицерлар кәртүжникнең сөйләвен авызларын ачып тыңладылар. «Менә чын офицер нинди була икән, куркуның нәрсә икәнлеген дә белми»,— дип таң калганнар иде алар. Һәм арадан берсе:

— Әнә теге татар безнең сүзләрне тыңлый бугай,— дип кисәтеп куйды.

— Тыңлый бирсен, барыбер бернәрсә дә аңламый ул! — дип масайды кәртүжник.— Башында сарык мие бит ул татарның! Дуңгыз ите ашарга татарларны барыбер өйрәтәчәкбез!..

Офицер боларны әйткәндә, Ибраһим урыныннан кузгалды. Хәрчәүнәдән чыккач, ул, офицер әйткәннәрнең мәгънәсен уйлап, бер читтәрәк озак басып торды. Инде офицерлар да китеп барды, ә Ибраһим тирән уйларга чумып, һаман тора иде әле.

... Димәк... Димәк, Санияне кәрттә оттырганнар. Аны хайван, хәтта җансыз әйбер итеп санаганнар. Йа Аллам! Нишли бу дөнья? Ходаем,

синең ихтыярың белән эшләнми ич инде болар, кем гаепле соң бу әшәкелекләрне кылуда?!. Әхмәдулла агай каторгада... Саниянең киләчәк тормышы нинди булачагы билгесез... Авылда җыенның нинди карарга киләсен белгән юк... Хәер, иң киме — имгәткәнче кыйнаячаклар инде Санияне... Күптән түгел генә Таң авылында шундый хәл булды бит... Ә бу офицер кисәкләре мыек асларыннан гына көлеп йөриячәкләр. Юк, Санияне мәсхәрәләүгә юл куярга ярамый! Ниндидер әмәлен табарга кирәк... Иртәгә үк казый янына барып, ишеткәннәремне сөйләп бирсәм? Шаһитларым юк шул. Кәртүжник офицерның мактануын ишетүем генә аның гаебен расламый бит. Әмма коточкыч бәлане булдырмау чарасын тизрәк күрергә кирәк! Хәзер үк! Рәшид! Кайда син? Йокыга чумып баручы шәһәрдә сине кайдан эзләп табарга икән?..

Ибраһим Рәшидне эзләп тапканда, вакыт бик соң иде инде. Ибраһим Саниянең сүзләрен-әманәтен түкмичә-чәчмичә җиткерде, кәртүжникнең мактануын да бәйнә-бәйнә сөйләде. Алар, Санияне коткару, гаделсез хөкемне булдырмау өчен, тизрәк авылга кайтырга кирәк, дигән карарга килделәр.

Төн уртасы узган инде. Рәшид белән Ибраһим ике тәгәрмәчле тарантаска иң шәп ике юртакны җигәләр дә юлга чыгалар. Тарантаста бер үк кешене яратучы Рәшид белән Ибраһим утыра. Әмма Сания аларның берсенә дә мәңгелеккә булмаячактыр. Рәшид Саниянең бер кулын тотты тотуын, ләкин аның икенче кулын да мәңгелеккә учына алу насыйп түгелдер. Барлык хыяллары җимерелде, киләчәге челпәрәмә ватылды.

... Их-х, Сания, нигә шул исерекбашның тарантасына утырдың соң... Мин синең гөнаһсыз булуыңа ышанырга тырышырмын, ышанырмын да, әмма кешеләр яман сүзләр сөйләячәкләр бит.

— Рәшид кяфер тешләгән алманы суыра, — диячәкләр.

Шулай да ашыгырга кирәк. Усал көчләргә тантана иттерергә ярамый, Санияне коткарырга һәм явызлардан ерак яшерергә кирәк. Казанга Санияне хәзергә алып кайтып булмый, авылдашлары аны моннан эзләп табачаклар. Авыл җыенын, аксакалларны Саниянең гөнаһсызлыгына ышандырып булмаса, бүтән яшерер урын тапмаганда, Санияне Казанга алып кайтудан башка чара юк...

Алар атларны каты кудылар. Һәм тәүлектән артык вакыт узгач, таңда, авылга җиттеләр. Рәшид атларны ял иттереп авыл читендә калырга, ә Ибраһим Саниянең гөнаһсызлыгы турында муллага барып сөйләргә килештеләр.

Мулла егетнең сөйләвен бүлдермичә тыңлады. Беравык уйланып торды һәм хөкем карарына, шаһитлар раславына ышанмау мөмкин түгеллеген әйтте, ә Ибраһимның дәлилләрен расларга шаһитлар булмавын искәртте. Өстәвенә, билгеләнгән чараны булдырмыйча калу мөмкин түгел икән...

Ибраһим өмете өзелеп чыгып китте. Шулай да аның хәбәрләре мулланы бераз шиккә төшерде. «Бәлки, чыннан да, Ибраһим сөйләгәнчә булгандыр, Саниянең гаебе бөтенләй юктыр, — дип уйлады ул. — Вәләкин Саниядә генә түгел бит әле эш. Халыкны куркытып, берсүзсез буйсындырып тотарга кирәк. Югыйсә әхлак җимереләчәк, халык юлдан язачак, динен җуячак, — дип катгый фикергә килде мулла. — Ә динсез халык бетәчәк. Моны булдырмау өчен кечкенә генә хата кылу зур гөнаһ саналмас. Аллаһы Тәгалә моны гафу итәр...»

Рәшид Ибраһимның куанычлы хәбәр алып килүенә өметләнгән иде. Ләкин алай булмады. Һәм Рәшид авылга үзе китте. Җыен буласы урынны ул сорашмыйча да белде — әле иртә булуга карамастан, халык шунда агыла иде инде. Рәшид кешеләрдән читтәрәк барды, хәер, аңа игътибар да итмәделәр, аларны кызыксындырганы җыен иде, аннары — авыл аша кем узмас, ә бу адәм таныш түгел бугай, мондыен да затлы киемле ыспай егетнең авылда күренгәне юк кебек...

Тиздән гади халык мәйданга җыелып бетте. Аксакаллар да килде, староста килде. Мәйданга иң соңгы кеше булып мулла керде. Бәхетсез Санияне алып килергә йомышчыларны җибәрделәр. Санияне бу төнне, качмасын өчен, базга япканнар һәм саклап чыкканнар иде. Алып килделәр Санияне. Кача алмасын өчен, кулларын артка каерып, баганага бәйләделәр. Староста Санияне хурлап-гаепләп сөйләде. Аннары мулла яшь хатынга кылмаган гөнаһны ябыштырырга тырышты.

... Санияне күргәч, Рәшиднең йөрәге ярсып тибәргә тотынды. Аның Саниясе, мәсхәрә баганасына бәйләнгән булса да, туры карап, горур басып тора. Гаебе-гөнаһы юклыгын белә ул, шуңа күрә мәрхәмәт сорарга җыенмый. Аның йокысызлыктан эчкә баткан күзләре үзенә газаплы үлем теләүчеләргә нәфрәт чәчә...

Рәшиднең кая һәм кайчан китүен берәү дә күрмичә кала, барысының да игътибары хурлык баганасына бәйләнгән Саниядә була. Сания исә Рәшидне күрә, башта, Рәшидме соң бу, дип шикләнеп кала. «Әгәр Рәшид булса, нигә мине яклап сыңар сүз дә әйтми ул? Бәлки, ул минем канымны эчәргә җыенган шушы кешеләргә ышанадыр? Ибраһим иректергән хәбәргә ышанмады микәнни? Димәк, ул да ышанмаган... Әгәр шушы шашкан кешеләр яныннан качып китеп баручы адәм син икәнсең, бел, Рәшид, мине генә үтереп калмаячаклар бит... Шуны бел, без икәү хәзер... Ул минем карынымда, ул әлегә исән, аның дөньяга туасы килә, аның якты дөньяны күрәсе килә. Бел, ул — синең балаң! Аның атасы — син! Башка беркем дә түгел!»

Сания һаман ерагаеп баручы Рәшидкә кычкырырга теләде, ләкин Рәшиднең ярдәм кулы сузмыйча китеп баруына рәнҗүе аның тынын кысты, аяклары хәлен җуйды да гәүдәсе сыгыла башлады. Ике ягында саклап торучы ике әзмәвер ир Саниянең хәлсез гәүдәсен турайтып бастырдылар.

— Туры басып тор! Намусыңны югалткан бәндә калдыгы! — дип кычкырды староста. — Кылган гөнаһларың өчен тиздән Алла каршында җавап тотачаксың! Кылган гөнаһларың өчен ичмасам үлә бел!..

Һәм ул бәхетсез Саниягә таба кәс кисәге алып ыргытты — җәзаны башларга вакыт җиткәнне. Шушы ишарәне генә көтеп торган кешеләр Саниягә ташлар атарга керештеләр. Туры аталар — ташлар яшь хатынның бөтен гәүдәсен күз ачып йомганчы җәрәхәтләп бетерделәр. Куллары артка каерып бәйләнгән Сания йөзен дә каплый алмый иде.

Шулчак җыенга җигүле пар ат өермәдәй бәреп керде. Кузлада Ибраһим, ә артта Рәшид утыра иде. Рәшид сикереп төште дә, хатынының алдына басып, гәүдәсе белән аны ташлардан ышыклады.

— Туктагыз! — дип кычкырды ул. — Шашмагыз! Сания — минем хатыным! Минем ризалыгымнан башка сезнең аңа җәза бирергә хакыгыз юк! Бу гамәлегез шәригатьчә түгел!

Җыен бер мәлгә тынып калды, кешеләр ташлар атудан туктадылар. Мулла сүз башлады.

— Син, килмешәк, шәригатькә тел тидермә! Син булмаганда, бу фахишәнең безнең авылны ничек пычратуын белмисең. Ир хатыны була торып, ул кяферләр белән уйнаш иткән. Хөкемдә рус офицерларе шуны раслап сөйләгәннәр. Шәригатькә кабат тел тидерәсе булма! Кит, юлыңа уз! Югыйса икегезне дә иң каты җәзага тартачакбыз! Монда җыелган таш тавы икегезгә дә җитәрлек!

Ул җәзалауны дәвам итәргә кушып ым какканчы, Ибраһим кузладан сикереп төште, җыен халкы иңке-миңке торган арада Санияне бәйләгән бауларны җәһәт кенә кисте һәм, тоткынны тарантаска күтәреп салып, атларны куалады. Рәшид тә, ярсыган кешеләр үзенә ташланганчы, тарантаска сикереп утырып өлгерде. Әлләрдә генә җитез атлар! Җыендагы явыз кешеләргә Ибраһим белән Рәшидкә каһәр укудан бүтән чара калмады...

Берничә көннән Санияне мәсхәрәләү җыены турында сөйләүләр тына төште. Иң башлап Санияне һәм Ибраһимны әйбәт белүче яшьләр

яшь хатынның гаебе булмавына ышандылар. Өлкәннәр аларны шәригатьне бозуда, әдәпсезлектә гаепләмәкче булып сукранганнар иде дә, бу гамәл барып чыкмады. Яшьләр Ибраһимның гаделлеккә тугърылыгын һәм батырлыгын мисал иттеләр — Бөкере Ибраһим начарлык кылуны белми!

Ә Ибраһим, Рәшид һәм Сания, авылдан ерак киткәч һәм куып килүчеләр күренмәгәч, ялга туктадылар, кая барырга, нишләргә, дип киңәш-табыш иттеләр. Җәрәхәтләнеп беткән Санияне кайда яшерергә икән? Казанда Рәшиднең йорты әзер диярлек, әмма калада күренергә ярамый — яшь сәүдәгәрне тиз эзләп табачаклар һәм гөнаһсыз Санияне тагын җәзага тартачаклар. Бу юлы инде Рәшид белән Ибраһимны да гафу итмәячәкләр. Авылга кире кайту турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Ниһаять, әмәлен тугъры җан Ибраһим тапты...

Икенче көнне кичкырын алар Ибраһимның апасы яши торган авылга барып керделәр. Егет инде тол калып ялгызы гына яшәүче өлкән туганына Сания һәм үзләре белән булган хәлләрне ачыктан-ачык сөйләде. Һәм мәрхәмәтле ялгыз хатын Саниягә әнисе кебек булырга ышандырды. Рәшид һәм Ибраһим, Санияне калдырып — монда аларга кешеләр күзенә чалынырга ярамый бит, китеп бардылар...

Моннан соң күп сулар аккан...

Ибраһим башта, күп михнәтләр күрсәткәне өчен, кәртүжник офицердан үч алмакчы булган. Исерекбашны ул хәрчәүнә тирәсендә күп сагалаган. Җае туры килгәч кенә, офицерны үтерү уеннан кире кайткан — җан кыеп өстенә гөнаһ алырга ярамавын колагына Аллаһы Тәгалә пышылдаган. Һәм авылы кешеләрен Саниянең бөтенләй гөнаһсызлыгына ышандырган. Шуннан соң авылдашлары Саниянең әтисе Әхмәдулланы коткару өчен күмәкләшеп йөргәннәр. Кайткан Әхмәдулла, хатыны белән шактый озак гомер иткән. Алар оныкларын сөеп сөенгәннәр...

Сания белән Рәшид тә Казандагы мәһабәт йортта бәхетле яшәгәннәр. Рәшиднең сәүдә эшләре гөрләп барган. Сания Ибраһимның мәрхәмәтле апасында качып ятканда ук аларның улы туган. Мөхәммәд пәйгамбәр туган көндә булган ул. Малайга шул хөрмәткә Мәүлид-Галәй исеме кушканнар. Рәшид, малае тууына сөенеп, Саниясе авылында зур мәчет салдырган, бу изге эштә башлап йөрүче тугры җанлы, Санияне гомере буе яратучы, әмма моны бирәүгә дә сиздермәүче Ибраһим булган...

Батыр һәм кыю, әзмәвер гәүдәле һәм әдәпле булып үскән Галәй. Хаксызга берәүне дә рәнҗетмәгән ул, явыз кешеләргә усал була белгән, мохтаҗларга ярдәмен кызганмаган. Галәй пәһлеван гомере буе туган халкының иреге өчен көрәшкән. Әйе, бәхетен ул азатлыгы өчен көрәштә тапкан. Кулга богау салыну фаҗигасен, азатлык кадерен ана карынында чагында ук татыган Галәй...

*Кырым.*

# ШИГЪРИЯТ



## Газинур Морат

### Мин әкият кебек дөрес идем

* * *

Мин әкият кебек дөрес идем,
Дөрес иде яшәү-гамәлем.
Бер гүзәлнең матур тезләренә
Төртелде дә сынды каләмем.

Мин бу чынлык кебек ялган идем,
Ялган идем үзем, сүзләрем.
Ә мин хәзер әкият тә түгел,
Хикәят тә түгел —
Үзгәрдем.

### Мәңгелек үкенеч

Күпме ярлар үкенечкә калды,
Уйлыйлардыр инде: пешмәгән.
Сискәнепләр кайчак уянасың
Аягүрә күргән төшләрдән.

Күпме ярлар сөелмичә калды,
Калды, әйе, үбелмичә дә.
Юкса, күктән йолдыз өзеп бирер
Чаклар иде — үрелмичә дә.

---

Газинур МОРАТ (1959) — *шагыйрь, «Җир хәтере», «Мин дөньяны тыңлыйм» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Күпме ярлар безгә болдырлардан,
Балконнардан калды кул изәп.
Без хан булалмадык.
Кай ханнарга
Булды икән алар кәнизәк?

Күпме ярлар перроннарда калды,
Ә без, имеш, дөнья куганбыз.
Бер кайтырбыз, дидек.
Ә үзебез
Кайтмаска дип киткән булганбыз.

Күпме ярлар калды ятлар белән,
Күпме ярлар калды... сазап та.
Ә үз ярың гел ят була барды,
Әверелдe яшәү газапка.

Күпме ярлар йөрәкләрдә калды,
Исемнәрен куштык җырларга.
Бездән соң да, бәлки, яшәр алар
Без юксынып көткән чорларда.

Күпме ярлар сөелмичә калды,
Калды, әйе, үбелмичә дә.
Юкса, күктән йолдыз өзеп бирер
Чаклар иде —
Үрелмичә дә...

## Элегия

Син җәйләрдә калдың...
Ә мин менә
Синсез генә китеп адаштым.
Һәрчак тугры юлдаш булды миңа
Бәхетсезлек атлы адашым.

Син җәйләрдә калдың...
Арабызда
Упкын булып инде көз ята.
Күңелләрең нигә бикле һаман,
Күңелләрең нигә йозакта?

Юк, шакымыйм ишек-тәрәзәңне,
Ачмасыңны беләм болай да.
Арабызда — упкын.
Ике ярда
Сак-Сок булып Сөю моңая.

Син җәйләрдә калдың.
Ник соң әле
Тәрәзәңне синең боз сарган.
Кем ул анда бозлы тәрәзәңә
Безнең сөю рәсмен ясаган?

Кемдер, бәлки, безне кызганадыр,
Кем телидер, бәлки, көләргә.

Мине көтеп күшеккәннәр гүя
Тәрәз төбендәге гөлләр дә.

Куеныма алып җылытсам да,
Эремәс күк бозлы карашың.
Тәүбә итү кирәк —
Үткән чакта
Сөю белән Нәфрәт арасын.

Ятим калган Сөю каршысында
Тәүбә итү кирәк безгә дә...
Тапканыңны җуя күрмә икән,
Ә җуйгансың икән —
Эзләмә.

## Мине шагыйрь иткән кызга

Коймаларга акбур белән язып
Тутырдылар безнең исемне.
Сабый идек... Канат очларыбыз
Сабый чакта ук шул киселде.

Сабый гына идек...
Ә аннары
Өстебезгә тормыш ишелде.
Ак кәгазьгә бүген каным белән
Язып куйдым синең исемне.

Исемеңне кабат яд иткәнгә
Үпкәләрсең, бәлки, каргарсың.
Тик барыбер син җырыма минем...
Тугзак ана булып каласың.

## Әллә...

Әллә мин сиңа гашыйкмы,
Әллә син миңа гашыйк...
Икәү генә белгән җырны
Йә, булмаса, башлыйк.

Әллә син телсез калгансың,
Әллә мин өнсез инде...
Икәү генә белгән серне
Күккә күмдем, тиле...

## Ялгызлык

Бүлмәмә килеп кердең дә
Имәнеп китте бүлмәм.

«Ул килде», дип пышын гына
Сукранып алды күгән.

«Ул килде», дип серле генә
Кеткелдәп куйды ишек.
«Ул килде», дип баш очымда
Тирбәлде үксез бишек.

Килгәнсең икән — уз, әйдә,
Йөрәгемдә юк бигем.
Сагайма да — бишегемдә
Хәтер ул ауный минем.

Тартынма, чиңен, кил миңа,
Юк уемда азгынлык.
Кем башыннан үтмәгән ул,—
Түремнән уз... ялгызлык.

## Без адаштык бугай...

*Ф. Д.*

Адаштык та өнсез калдык,
Өнсез калды төн, урман.
Бу төн, ахры, безне кабат
Кавыштырмаска туган.

Тыпырчына җанда — мәңге
Әйтелми калыр сүзләр.
Ябалдашлар арасыннан
Йолдызлар тора күзләп.

Керфегеңә кунган Ай да
Бармак яный күк безгә.
Төнге күбәләкләр генә
Оча үз күгебездә.

Көн күзеннән яшеренеп,
Каптык төн тозагына.
Ә мизгелләр кабатланмый,
Мизгелләр уза гына.

Ә гомерләр уза безнең
Тыелган бәхет эзләп.
Бәхетсез бәхетлеләр без,
Бәхетле бәхетсезләр.

Йөрибез төнге урманда
Ике җан — качкын кебек.
Артыбыздан пар күләгә
Шаркылдап кала көлеп.

## Хәтердә калган сурәт

Укылган китап күк ханым,
Кырын ятып ятагына,
Китап укый. Мәче белән
Эте ауный як-ягында.

Китапта — яшьлеге аның,
Үз яшьлеге — узмаганы,—
Үз бәхете, үз тәхете,
Үз базары, үз заманы...

Дөнья инде йоклый күптән,
Тик йокысы килми аның.
Таушалган бетселләр кебек,
Ятагында ауный ханым...

## Ә мин сине яратмаска булдым

...Ә мин сине яратмаска булдым,
Яңартмаска булдым үткәнне.
Мәңге әрнер яраң булып калсын
Күзләреңнән сөеп үпкәнем.

Мәңге әрнер ярам булып калсын
Иренемә тамган яшьләрең.
Син үзеңчә дөрес сөеп кара,
Мин үземчә дөрес яшәрмен.

Мине көтеп тик ялгыша күрмә,
Йөрәгеңнән ташла чыгарып.
Ходай сиңа сабырлыклар бирсен
Сак-Сок сагышына чыдарлык.

Мин дә сине сагынмаска булдым,
Табынмаска булдым мәңгегә...
Сөюгә мин ясин чыктым бүген,
Кем озата барыр кабергә.

Озатучы, беләм, табылачак,
Кем ябышыр, беләм, көрәккә...
Тик мин сине борчымаска булдым,
Мин Сөюне күмдем йөрәккә.

## Нәтиҗә

*Урман биргән аңа матурлыгын,*
*Күлләр саф суларын сипкәннәр.*

Һ. ТАКТАШ. «Урман кызы»

Зиләйлүкләр, Гөлҗамаллар булып
Ул җырларда яши һаман да...

Табигатьтә урман кызы иде,
Урам кызы итте замана.

## Сөю атлы чаптарга алдан язылган мәрсия

Дөнья бит — минем дә
Гөнаһлар булгандыр.
Гөнаһлы бу дөнья
Миңа да тугандыр.

Булгандыр минем дә
Чыгымчы чакларым...
Сөю атлы чая
Ак яллы чаптарым

Аранда күптәннән,
Күптәннән — яралы.
Камытлы кайгыдан
Каралды яллары.

Канатлы иде ул —
Кистеләр канатын.
Яралы җаныннан
Кан акты... кан акты...

Аннары ыңгырчак
Салдылар биленә.
Чыбыркы чыжлады
Сыртында: «Тибенмә».

Колынлы иде ул —
Чалдылар колынын.
Төшендә күрә тик
Колынлы болынын.

Төшендә күрә тик
Ак яллы чакларын.
Җанара, тәнара
Бәйгедә чапканын.

Бәхетле иде ул —
Тапты да... югалтты...
Көнчеләр — җанына
Хөсетле ук атты.

Ирекле иде ул,—
Ә хәзер — йөгәнле...
Бигайбә —
Ярылса
Йөгәнсез йөрәге.
Бигайбә...

# ПУБЛИЦИСТИКА

*«Канатлы барс» конкурсына*

**Рашат Низамиев**

## САУМЫСЕЗ, ТАТАР ГЕНЕРАЛЛАРЫ!

Татар халкыдай сибелгән, төрле төбәкләргә һәм илләргә чәчелгән халык сирәктер. Тарих тегермәннәрендә рәхимсез уалып та, милләт буларак үзен бүгенге көнгә кадәр ничек саклап кала алган ул? Әгәр уйласак, бу хакта аерым мәкалә язу кирәк булыр иде. Дөрес анысы, тарихыбыз, ачы язмышыбыз, табу һәм югалтуларыбыз хакында фәндә инде байтак язылган. Ә менә татардан чыккан хәрбиләр турында юньле-башлы мәгълүматны без тиз генә таба алмабыздыр, мөгаен. Юк андый хезмәтләр һәм Совет хакимияте чорында алар була да алмас иде. Әйтик, патша армиясендә татардан чыккан генераллар булганмы, булса — ничәү? Шәхсән, мин үзем андый фактларны белмим диярлек. Ләкин кайбер нәрсәләр хакында укыган-ишеткәнем бар: күренекле полководецлардан Суворов (Сувар нәселе), Кутузов (Котдусов) адмирал Нахимов (Нәгыймов) — нәсел-нәсәпләре ягыннан төрки-татар затлары икән... Бик ихтимал дип саныйм. Чөнки дәүләтчелеген югалткач, татарның исән калган, йогынтылы нәселдән булган зыялы вәкилләре алдында ике генә юл кала: йә ахыргача бөлгенлеккә төшү, яисә ныгып килгән рус самодержавиесенә ирексездән хезмәт итү... Акыллы башлар кайда да кирәк — андыйларны, әлбәттә, хезмәткә алырга тырышканнар. Менә шундыйлар нәселеннән акрынлап күренекле хәрбиләр чыгуы һәм аларның тора-бара рус мөхитендә «эреп», фамилиясе-ние белән «урыслашып» китүе тарихи яктан аңлашыла.

Ярый, инде якындагырак елларга әйләнеп кайтыйк. Бөек Ватан сугышы көннәрендә татар да уртак Ватанны, ягъни Советлар Союзын яклар өчен утлы җәһәннәм эченә җибәрелде. Әйе, фашизмга каршы батырларча сугыша белде безнекеләр. Элегрәк, безнең фәлән Советлар Союзы Геройларыбыз бар, дип мактанырга ярата идек. Ә инде әлеге канкойгыч, рәхимсез сугышта ничә татар егете һәлак булды — моны безгә хәзергә төгәл санап бирүче булмады. Статистика бездә халык, дөресрәге, хөкүмәт күңеленә хуш килердәй саннар белән эш йөртүчән иде. Батыр, куркусыз, фидакарь дип йөртелгән халкыбыз арасыннан ул дәһшәтле елларда, минем белүемчә, нибары дүрт-биш татар генералы бар иде: Гани Сафиуллин, Фатих Булатов, Якуб Чанышев, Хәбиб Ганиев, Зәки Котлин... Белмәссең: әллә талантлы хәрбиләребез генофонды шуның белән чикләнгән иде ул чакта, әллә инде «хәтәр» дип тамга салынган татарны үстермәскәрәк тырыштылармы? Соңгы фаразыбыз дөреслеккә күбрәк туры килә дип уйлыйм.

Әйдәгез, хакыйкатьне таныйк: СССР дип аталган элекке державага без — хәрбиләр дә, хәрби булмаганнар да — тугрылык белән хезмәт итә килдек. Бүтәнчә мөмкин түгел иде. Инде дә сүзебез хәрбиләр тирәсендәрәк бара икән, табигый бер сорау туа: «күкрәп» яшәп яткан Советлар Союзы биләмәсендә ничә татар генералы үсеп чыкты икән соң? Элегрәк бу сорау белән кызыксына башлаган кешене, «милләтче» мөһере сугып, бик тиз генә юлдан алып ташларлар иде. Бүген исә чынбарлык бөтенләй бүтәнчә: ясалма юл белән төзелгән СССР таркалды, тоталитар режим сүтелде, шуның җимерекләре астыннан күтәрелгән яңь-яшь,

әмма борынгы тарихлы дәүләтләр мөстәкыйльлек юлына аяк басты. Татарстан Республикасы да, табигый ки, мөстәкыйльлек юлын сайлады. Инде хәзер янача шартларда «ничә татар генералы бар икән соң?» дигән сорауга ачыктан-ачык җавап бирү мөмкинлеге ачылды.

Хәер, монда бармак бөгә-бөгә хәрби эшлекләләребезне барлау, аларның төгәл санын ачыклау төп максат түгел. Мәсьәләне болай гадиләштерү дөрес булмас иде. Мәсьәлә шунда ки: тарихы, яшәеш гореф-гадәтләре төрле булуга карамастан, империя кинлекләрендә «бертөслерәк» яшәүгә дучар ителгән халыкларның, ниһаять, милли үзаңы уянды! Милли горурлык, үз халкының язмышын аңларга тырышу хисе өскә калыкты. Шулай булгач, тарихларда тирән эз калдырган татарның да рухи тупланугa, үзара җыйналып аңлашуга омтылышы гаҗәпмени? Мондый хис-омтылыш хәрбиләр арасына да үтеп кергән икән, бу күренеш бары хуплауга лаек.

Аңлашылса кирәк, татар хәрбиләренең очрашуын абруйлы, йогынтылы кеше генә оештыра ала иде. Безнең исә андый кешебез бар: ул — Союздагы төркиләрдән беренче буларак армия генералы дәрәҗәсен алган кеше, хәрби фәннәр докторы, академик Мәхмүт Әхмәтдин улы Гәрәев. Бүгенге көндә Рәсәй Оборона министрлыгында хәрби киңәшче. Ягымлы карашы, үз халкына мәхәббәте белән генерал киемнәреннән дә өстенрәк торган бу шәхес узган ел Казанда үткәрелгән Бөтендөнья татарлары конгрессында катнашты һәм саф татар телендә чыгыш ясады. Президентыбыз, дәүләт җитәкчеләре һәм аксакаллар белән Каен урманлыгында халкыбызның иң күренекле бәйрәмен — Сабан туен карады. Менә шундый кешенең татар хәрбиләре җыенын оештырудагы роле аңлашылса кирәк.

Очрашу Мәскәүдә булачак. Әлеге очрашуга Казаннан дүртәү сәфәр чыктык: отставкадагы генерал-майор Гайнулла Шакиров, «Татар-информ» агентлыгының генераль директоры Гомәр Богдалов, журналист Нургали Булатов һәм мин. Иртән «Татарстан» поездыннан төшү белән безне яшь, чибәр, ачык йөзле полковник Васил Вәгыйзь улы Шәрипов каршы алды. Авиация кешесе икәнен әйтеп торган хәрби кием бик тә килешле үзенә. Очучы буларак, заманында ул байтак кына стратегик бомбардировщикларны һава киңлекләренә алып чыккан. Бүгенге көндә Генеральный штабта фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнә. Тагын да күңеллесе — якташыбыз икән: Балык Бистәсе районының Юлсубино авылында туып үскән. Өстәвенә, шагыйрь Равил Фәйзуллинның авылдашы, сабакташы... «Бер парта артында утырып укыган, бер чирәмдә уйнап үскән татар егетләренең кайсы шигърияткә, кайсы авиациягә китеп барган икән...» — дип уйлап алдым шул мәлдә. (Җәяләр эчендә булса да әйтеп китим, болай уйлавымның үзем генә белгән сәбәпләре бар: 1946 елгы бертуган абыем хәрби очучы иде, яшь-яшь лейтенант килеш самолетта янып һәлак булды...)

Фатир ягыннан мәшәкатьләр булмады, без Генштаб кунакханәсенә урнаштык. Кичке яктарак Санкт-Петербургтан тагын дүрт кунак килеп төште: вице-адмирал Марс Җамал улы Искәндәров; генерал-лейтенант Мөнир Хәлил улы Кулахметов; генерал-майор-инженер, РФ Академиясенең Информатика һәм автоматлаштыру институты директоры Рафаэль Мидхәт улы Юсупов; генерал-майор Марсель Мотыйгулла улы Әһлиуллин. Билгеле инде, туганнарча күрештек, таныштык, шундук чәй хәстәренә керештек. Ул көнне кунакханәдә ни сәбәпледер буфет эшләми иде. Шулай да Казан һәм Питер кунакларыннан уртак табынга байтак күчтәнәч куелды. Чәй янында үзеннән-үзе җанлы әңгәмә куерып китте. Питер кунаклары, аңлашылса кирәк, беренче сүзләреннән үк Татарстан турында сораша башладылар. Аларны бездәге сәяси һәм икътисади хәлләр кызыксындыра иде.

Болар ашказаны темасыннан ерак китә алмаган икән, дип нәтиҗә ясарга ашыкмагыз. Юк, зур темалар хакында да зурдан кубып әңгәмәләштек.

— Сезнең дәүләт җитәкчеләре, Татарстаннан икенче Кувейт ясыйбыз, дип әйтәләр икән. Дөресме бу? — дип сорады чал чәчле генералларның берсе.

— Ил башындагыларның рәсми төстә андый белдерү ясаганнары юк, — дидем мин, үзем белгәннәр кадәресенә таянып. — Әмма бу фикер митингларда, мәйданнарда һәм шулай ук көндәлек матбугатта еш әйтелә килә. Бу фикердә тирән дөреслек бар. Татарстан, чыннан да, зур нефть запасларына ия һәм ул аны дистә еллар буе, бушка диярлек, һаман Россия кесәсенә агыза килде. Инде менә үзеңдәге табигый байлыкларга үзең хуҗа булыр көннәр җитте. Шуны эшли алабыз икән, бу — чыннан да, Татарстан халкы файдасына булачак. Моның өчен бары вакыт кирәк.

— Ә Россиягә нефть барыбер биреләчәктер ич?

— Әлбәттә. Ләкин үзара тигезлекне тәэмин итәрдәй килешү, сөйләшүләр нигезендә.

Җае чыгып, хәрби кунакларга «Казан утлары»ның 70 еллыгына багышланган юбилей саннарын тапшырам. Укучыларыбыз хәтерлидер: журнал тышлыгына Татарстан гербы сурәте урнаштырылган иде. Кызыл фонда канатлы ак барс, түгәрәк гербнын чит-читләре исә милли нәкышлы яшел тасма белән әйләндереп алынган. Журналыбызны кулына тоткач та, тышлыктагы герб сурәтен күргәч тә Марсель Әһлиуллин сокланудан балаларча куанып, ләкин олыларча житдилек белән әйтеп куймасынмы:

— Менә моны безнең кительләрнең жинсәсенә ябыштырсаң да ярый икән!

Әлеге сүзләр барыбызның да күңеленә хуш килде, билгеле. Елмаештык. Бу теләк, фикер һәммәбезгә сүзсез дә аңлашыла иде...

20 февраль көнне татар генераллары-адмираллары, ниһаять, «Президент-отель» дигән гүзәл бинада очрашуга жыйналдылар[1]. Исемлеккә 40 лап хәрбиләрнең исем-фамилияләре теркәлгән иде. Аларның барысы да диярлек СССРның элекке төбәкләреннән очрашуга килеп житкәннәр. Парадный формада, ягъни бәйрәмчә киенгәнгә күрә, яшьме-картмы, аларның һәммәсе матур, күркәм, затлы күренә. Һәрхәлдә, генерал погоннары, чалбардагы буй-буй кызыл лампаслар һәм пөхтә кительләр күңелдә күтәренке бер халәт тудырды. Мондый атмосфераны минем Чехов һәм Толстой әсәрләре яисә кинофильмнар аша күпмедер тойганым бар барын. Әмма бүгенге вакыйгалар барысы да күз алдында бара, заман гына бүтән, геройлар бүтән...

Мәхмүт ага Гәрәев, очрашуның хужасы буларак, иң элек кунакларны истәлек өчен фоторәсемгә төшәргә чакырды. Өсте гөмбәзләп эшләнгән зур, мәһабәт залның уртасына мәрмәр плитәләрдән зодиак картасының унике йолдызлыгын түшәп ясаганнар. Андый йолдызлык икән, түгәрәкнең бер өлешендә барс сурәте дә бар, билгеле. Фотографларның «черт-черт» итеп төшерүләренә карамастан, игътибарым зодиак божрасына, барыннан да битрәк барс сурәтенә йотылды гына бит, шайтан алгыры! Ни өчен икәнен аңлыйсыздыр: әле кичә генә без Санкт-Петербургтан килгән татар генераллары белән республикабыз гербындагы барс турында сөйләшкән идек. Алар безнең гербтагы тарихи символны бик тә ошаттылар, яраттылар. Бу очракта кем һәм ни өчен шулай ясагандыр, белмим, әмма зодиактагы кара барс шулкадәр ябык һәм шөкатьсез иде, мин аны ничектер кызганып куйдым. Ни канаты юк, ни гайрәте сизелми тегенең...

Ярый, хыялый бу чигенешне читкәрәк куеп торыйк булмаса. Ә менә бина эчендәге гүзәллек, архитектура казанышының соклангыч үрнәкләре, чебен таеп егылырдай итеп шомартылган мәрмәр баскычлар, андагы затлы келәмнәр, диварларның сәнгатьчә бизәлеше, тирә-юньдә яшеллекнең табигый бер төстә балкып утыруы һәм башкалар — болар бар да искиткеч гажәп һәм күңелгә хуш килердәй манзара иде. Биредә үзеннән-үзе әдәп, югары культура һәм ихлас мөнәсәбәтләр сорала кебек. Бу әллә ничә катлы йортта, бәлки, әллә ничаклы сәяси уеннар, хәйләләр эшләнәдер. (Мәсәлән, матбугат хәбәрләренә караганда, мартта андагы банкет залларының берсендә «законлы караклар» үзләренең жыенын үткәргәннәр...) Әмма без ихластан, яхшы нийт белән жыйналдык. Шунысы кыйммәт дип саныйм.

Фотосурәткә төшкәннән соң кунак залына үттек. Ватанны саклаучылар көне уңаеннан үткәрелгән очрашу-мәжлесне татар телендә кереш сүз белән Мәхмүт ага Гәрәев ачып жибәрде. Аннары сүз Татарстан Республикасының вице-президенты Василий Лихачевка бирелә. Ул Татарстан халкы һәм аның Президенты Минтимер Шәймиев исеменнән очрашуга жыйналган татар хәрбиләренә үзебезнең Чистайда эшләнгән «Командирские» сәгатьләре тапшыра. Моның мәгънәсе бик тирән дип аңладым: дәрәжәле командирлар Казан вакыты белән Мәскәү вакытының бер замандарак агышын, дуслык-тынычлыкның кыйммәтен, корал белән шаярырга ярамаслыгын һәрвакыт тоеп-сиземләп торырга тиешләр!

Барс дигәнем сәхнәгә яңадан бер тапкыр калкып чыкты. «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире шагыйрь Ренат Харис Татарстан Югары Советы Президиумы исеменнән хәрби эшлекләләрне котлады һәм аларга Татарстан гербы сурәтләнгән тамга-значоклар бүләк итте. Кунаклар Р. Харисның үзе укыган шигырьләрен дә яратып тыңладылар.

---

[1] Бу бинаның хикмәтен, колачын шуннардан чамаларга мөмкин: безнең әлеге очрашулардан соң диярлек бирелә Б. Ельцин 2 мартта Мәскәүнең «Демократик сайлау» вәкилләре белән очрашты. (Автор искәрмәсе.)

Һәркемнең әйтер сүзе бар. Мәҗлес кызды, кайнады. Сүзләр сүзгә, фикерләр фикергә ялгана барды, күңелләр күңелгә якынайды. Таныш йөзләр, танышбелешләр байтак иде мәҗлестә. Язучылардан Миргазиян Юныс, Зөфәр Фәтхетдинов, Җәмил Мостафин, Әхмәт Саттар әңгәмәләрнең уртасында кайнаша. Советлар Союзы Герое, мәгълүм язучы Владимир Карповның татар һәм үзбәк сүзләрен катнаштырып сөйләгән чыгышы да безнеңчә, безнең файдага яңгырады. Ул хәтта бик үтемле итеп болайрак шаярта да белде: «Я тут среди вас единственный аксакал!» Баксаң, ап-ак сакал үстергән кеше арада ул гына икән шул! Чынлап та шулай: сүз чыгар әдипләрдән хикмәт белән...

Казан компрессорлар заводы директоры, әдәбият-сәнгатьне ярата торган, бик тә милләт җанлы Әхмәт Галиев белән дә кул биреп таныштык. Аның, вице-президент В. Лихачев белән бергә, Парижга барышы икән. Озак еллар буе ул җитәкләгән завод, коммерция эшчәнлеген уңышлы оештырганы өчен, Халыкара премиягә лаек булган. Безгә завод эшчәннәре җитештергән продукциянең чит илләрдә шулай танылуына сокланырга гына кала!

Очрашуда катнашкан һәр генерал һәм адмиралның исем-фамилияләрен санап чыгу мөмкин түгел. Аларның һәркайсы хакында очерклар сериясе язу кирәк булыр иде, мөгаен. Шулай да бер-икесенең сүзләрен укучылар игътибарына җиткерәсе килә. Хәрби Һава Көчләрендә корпус командиры буларак хезмәт итүче якташыбыз генерал-майор Таһир Сәйфетдинов — тумышы белән Азнакай районының Югары Стәрле авылыннан. «Казан утлары» журналын бүләк иткәч, ул тәмам яктырып, сөенеп китте.

— Моны бит Азнакайдагы апам шулкадәр яратып укый. Мин дә укырмын. Рәхмәт сезгә! — диде татарчалап.

Төньяк флотта хезмәт иткән иң яшь контр-адмирал, Рәсәй парламентындагы актив депутатларның берсе — Рәфкать Заһидулла улы Чеботаревский да әңгәмәне турыдан-туры Татарстанга китереп ялгады:

— Сездәге хәлләрне укып, ишетеп торам. Татарстан егетләрен үз территориясендә генә хезмәткә алу мәсьәләсен күтәрәсез. Моны бүген-иртәгә генә кистереп хәл итеп булмыйдыр, мөгаен. Шуңа күрә иң әүвәл сездәге егетләрне Татарстан хөкүмәте дәрәҗәсендә үзләре теләгән төбәккә юллау мәсьәләсен хәл итү дә кирәктер.

Шулай итеп, хәрбиләрнең кайсы белән генә сөйләшеп китсәң дә, милли хисләр, милли горурлык өскә калкып чыга. Шуңа күрәдер, бәлки, мәҗлес залының төрле почмагында ыспай киенгән, бөркет карашлы чибәр егетләр дә күзгә чалынды. Гөнаһсына керәсе килми, шулай да үзалдыма уйлап куйдым: мөгаен, КГБ тирәсеннән ишелеп төшкән егетләрдер бу...

Җырсыз табын, җырсыз очрашу була димени! «Москонцерт» артисты Роза Хәбибуллина татар халык көйләрен һәм композиторларыбыз әсәрләрен кунаклар күңелен яулардай итеп башкарды. Күренеп тора: БДБ илләренең төрле почмакларыннан җыйналган кунаклар милли җырга, халык моңнарына шулкадәр сусаган, аларның басып торышлары хәрбиләр сафына түгел, хорга тезелеп баскан ансамбль вәкилләрен хәтерләтә иде бу минутта. Болай уйлап ялгышмаганмын икән. Берзаман татарның дәрәҗәле хәрбиләре халкыбызның «Сарман» көен күтәреп алмасыннармы! Артык көчәнмичә, ләкин көчле күкрәк тавышы белән Габдулла Тукайның «Туган тел» көен дә моңсу катыш шатлык белән җырлап күрсәттеләр... Әлек булсамы? Кая инде шулай бергәләп җырлау, хәтта татарча сөйләшергә, валлаһи, «уңайсызланып» торырлар иде әле...

Мин монда буяуларны артык «кызартырга» яисә күргәннәремне үтә ялтыратырга теләмим. Әмма һәммәбезнең күз алдында шундый хәлләр булды һәм күңелләргә хуш килде. Кайларга гына сибелсәк тә, тамырлар өзелми икән. Күренмәс җепләр белән безне, бәлки, нәкъ менә балачакта ишетеп үскән моңнар, аерылу сагышлары, бердәмлеккә омтылу хисе бәйләп торадыр да әле. Һәрхәлдә, туплар тавышына караганда, җыр авазы мең тапкыр көчлерәк вә хушрак тоелды миңа.

Шушындый колачлы һәм тарихта беренче тапкыр диярлек очрашуның матди ягын кем кайгыртты соң? Хәзерге кыен заманда кем соң шундый очрашу мөмкинлегенә капка ачты? Искә төшерик, татарның булдыклы егетләрен элекэлектән сәүдәгәр яисә тагын да дәрәҗәлерәк итеп эшмәкәр дип атаганнар. Совет хакимиятенең 70 еллык дәвереннән соң кешедәге шушы сыйфатларны янадан торгызу мөмкинлеге туды, икътисади мәйданга яңа көчләр килде. Шуларның берсе — «МКН INTER SERVICE» компаниясе президенты, күренекле экономист һәм эшмәкәр Наил Корбан улы Халикеев. Очрашуның барлык чыгымнарын ул үз өстенә алды. Рәхмәт аңа! Мондый затлы, булдыклы егетләр барында без тарих мәйданында югалмабыз, көчле милләт булып калырбыз, иншалла.

Кырыклап татар генераллары һәм адмиралларының җыелуы, һичшиксез, зур вакыйга. Аның бер канаты үткәннәргә барып ялганса, икенче канаты барыбер киләчәккә төбәлгән, дип әйтәсе килә. «Советская Татария» газетасының быелгы 23 февраль санында юкка гына мондый сүзләр язылмагандыр: «Ходай безне генераллардан да мәрхүм итмәгән икән. Узган шимбәдә Мәскәүнең «Президент-отель»ендә очрашкан хәрби җитәкчеләр Европадагы берәр илнең армиясе һәм флоты өчен рәхәтләнеп җитәр иде». Бу сүзләргә аңлатма бирү кирәкмәстер кебек...

* * *

Шундый күркәм очрашуда катнашкан да, моның бите-башы тәмам чүлмәк булган икән, дип нәтиҗә ясарга ашыкма, укучым! Очрашу матурлыгы белән бергә, минем күңелдә, һичшиксез, күп кенә сораулар да кайнады. Уйларым бәхәсләште. Татарлыгын югалтмаганмы болар дисәм — күрәсездер, югалтуга бирешмәгәннәр. Шушы кырыклап хәрби җитәкче арасында нибары берничәсе генә исемен «урыслаштырып» өлгергән. Гаепләргә ашыкмыйк. Яһүдләрнең дә бик күбесе, мәгълүм сәбәпләр аркасында, урыстагы исем-фамилияләргә күчеп бетсә дә, асыл кыйммәтен һәм максатларын югалтмады ич, милләтенә хыянәт итмәде. Дөрес аңысы, бездә манкортлык процессы аларга караганда көчлерәк булды. Шәрехли китсән, моның да тирән сәбәпләре бар. Ләкин мәкаләмнең максаты бу түгел. Мин иң элек очрашудан туган тәэсирләремне уртаклашырга телим. Бу хөрмәтле хәрби җитәкчеләребез Татарстанга ни дәрәҗәдә бәйле, республикабызны һәм аның суверенитетын ни дәрәҗәдә хөрмәт итәләр? Хатыннары кайсы милләттән? Гаиләдә балаларына татар рухын, тәрбиясен бирә беләләр микән? Дөрес, шушы кыска гына очрашуда аларны мондый сораулар белән күмеп ташлау әдәпсезлек булыр иде. Кунак булсаң, тыйнак бул, дип өйрәтә бит халык мәкале.

Мин шунысын да ачык аңладым: отставкага чыккан, инде чәчләренә чал кергән бу генерал һәм адмирал абыйларның байтагы — минем өчен әтием яшендәге өлкән кешеләр, хөрмәткә лаек шәхесләр. Аларның сөлектәй егет чаклары, таза-гайрәтле ир чаклары Совет Армиясенә хезмәт итеп узган. Акыл-зиһеннәре бай булганга күрә, әллә ничаклы яшьтәшләре арасыннан әнә шундый югары дәрәҗәгә ирешкәннәр. СССР яисә Россия дәүләтенә хезмәт итеп, ни оттылар икән соң? дигән сорау да туа. Хәзер бит аларның хезмәтенә күрә рәхмәтен әйтердәй юньле шартлар Россиядә бетеп бара, социаль яклау механизмы бик тә какшаулы.

Инде сорауларның тагын да зуррагын, өлгергәнрәген куярга да ярыйдыр. Мөстәкыйльлеккә юл яргаң Татарстан Республикасының үз армиясе, үз генераллары кайчан булыр? Мөстәкыйльлекне югары дәрәҗәдә игълан итәбез икән, андый дәүләтнең Иминлек министрлыгы да булырга тиештер ич. Республика хәрби комиссариаты башында кайчан татар генералы яисә Татарстан мәнфәгатьләрен кайгыртучы хәрби җитәкче утырыр икән? Сүз уңаеннан әйтим, әгәр бик мөстәкыйль фикер йөртә башласа, устав кысаларына сыймаса, хәрбиләрнең карьерасын югарыдагылыр бик тиз «хәл итәләр». Моның ачык мисалы — хәрби фәннәр докторы, отставкадагы полковник Зәки Зәйнуллин язмышы. Әгәр ул милли хәрәкәтне яклау һәм шуның өчен көрәш юлына басмаса, минем ышануымча, инде әллә кайчан генерал погоннары тагып йөргән булыр иде, бәлки. Зәки абый — минем яхшы танышым, каләмдәшем. Шуңа күрә турысын әйтеп сөйләшкәнгә ачуланмас: кызганычка күрә, аңарда кайчакта дипломатик һәм сәяси хәйләкәрлек җитенкерәми шикелле...

Инде килеп, Татарстанда милли гвардия төзү турындагы сүзләр күптәннән куера килә. Әйе, бик тә кирәкле шәйдер. Ләкин, төзелгән очракта, тоташ броняга төренгән Россия каршында җитди көч була алырмы соң ул? Рәсәй армиясе бер яктан череп таркала кебек тоелса, икенче яктан ул кораллы казаклар исәбенә өр-яңадан туып ята... Нәрсә, балта-кылыч күтәреп, ике якны да канга батырыйкмы? Татар ишләргә тиеш бүгенге көндә? Аның Россия армиясендәге күренекле хәрбиләре ни гамәл кылырга тиеш? Сораулар күп. Мәсьәлә архикатлаулы. Әзер чишелешләр юк. Мин үзем күпләрнең фикеренә кушылам: милли гвардия төзегәнгә кадәр, иң элек Татарстан Республикасын нейтраль дәүләт итү, аның милиция һәм прокуратурасын җөмһүриятебез карамагына буйсындыру кирәк! Шушыларны уңай хәл иткәннән соң гына чын милли гвардиягә ихтыяҗ туачак. Ә болай, әйткәнемчә, татарның талантлы егетләре хәрби юлны сайларга тели икән, алар

һаман да Рәсәй уку йортларына юл тотачак әле. Аннары инде аның язмышы, киләчәге дә шактый дәрәҗәдә Рәсәй мәнфәгатьләренә бәйләп куелачак. Әйдәгез, реалист булыйк: Татарстан чын мөстәкыйльлек алмый торып, аның ни милли гвардиясе, ни хәрби эшлекләләре тиз генә туачак түгел.

Тагын бер мәсьәләдә үпкәм бар икән әле. Бөек Ватан сугышында катнашкан татар егетләре турында русның күренекле полководецлары иң матур сүзләр әйтеп калдырган, моны күпләр яхшы беләдер. Әмма әйтегез әле: рус совет әдәбиятының кайсы әсәрендә яисә киносында татар сугышчысының юньләп күрсәтелгәне бар? Юк, мин андый мисалны хәтерләмим. Әгәр роман яисә кинофильмга татар егете килеп керә икән, ул, һичшиксез, йә куркак, йә полицай сыйфатында сурәтләнә. Бу очракта белорус язучысы Иван Чигриновның «Бытбылдык елавы» романын, шуның нигезендә эшләнгән кинофильмны искә төшерү дә җитәдер. Мондый хурлыкка без әле дә ничек түзәбез икән — шаккатырлык хәл!.. Мәскәүдәге очрашудан соң шактый уйланып, гаҗәпләнеп йөрдем: баксаң, Рәсәй армиясенең иң җаваплы участокларында — ягъни атом су асты флотында, һава һөҗүменнән саклану һәм зенит-ракета гаскәрләрендә татар егетләре, татарның генерал-адмираллары иң җаваплы постларны биләп торган яисә һаман да биләп тора икән! Менә шундый хәлләр. Үзегез нәтиҗә ясагыз...

Күз тимәсен: СССР таркалып, аның төрле төбәкләрендә канлы бәрелешләр кабынып киткәч тә, Татарстан ызгыш-талашлар, милли низаглар мәйданына әверелмәде, шөкер. Бу, чын дөресен әйткәндә, татар халкының сабырлыгына, зирәклегенә, башка халыкларны да хөрмәт итеп яши белү һәм тагын бик күп әхлак сыйфатларына бәйле иде. Аның шушы сыйфатлары көннәрнең берендә Татарстанның тулы мөстәкыйльлегенә, халыкара танылуга китерсен иде. Амин, шулай булсын!

*Март, 1983 ел.*

# ҮЗ АСЫЛЫБЫЗГА КАЙТЫЙК

Адәм баласы, китапта әйтелгәнчә, бу дөньяга сыналу өчен генә килгән алла бәндәсе, еллар үткән саен, балачагын, яшьлеген, татлы мизгелләрен сагына. Шул турыда китаплар укый, җырлар тыңлый. Әйтемнәр, мәкальләр, әкиятләр, хикәятләр ана үткәнен күзалларга булыша. Олыгая барган саен, кеше халкының чал тарихы, борынгы ата-бабаларының үткән юллары белән ныграк кызыксына башлый, үзен шул кавемнең бер өлеше итеп сиземли. Аның бүгенгесе белән җан ата, иртәгәсен кайгырта. Бу хисләр мин фәкыйрегезгә ят түгел...

Тумышым белән мин — Урал буе татары, язмыш шул якка «ыргыткан» бер кеше. Урыс патшасы һәм миссионерлары золымына түзә алмыйча, 1759 елның 9 мартында 11 татар гаиләсе Көньяк Урал итәгенә күчеп килә. Шул тирәдәге башкортлардан җир сатып алып, Нисе дигән елга буена авыл корырга тотына. Авылның тарихы, кешеләре кызыклы, үзенчәлекле, алар турында берничә китап язып булыр иде.

Бу очракта мин бер нәрсәгә — авылым тормышын күз алдына тотып, халык традицияләре нигезендә яшь буынга тәрбия бирүнең кайбер якларына тукталмакчы, шул уңайдан фикерләрем белән уртаклашмакчы булам.

Һәркем игътибар итәдер, бүгенге шәһәр урамнарында йөрү хәвефле була башлады. Көпә-көндез чишендерәләр, хатын-кызга алка, беләзек, балдак ише нәрсә киеп йөрү куркынычка әверелде. Талау, өй басу, урлашу, яндыру, кыйнау, көчләү, фәхишәлек кылу гадәти бер күренешкә әйләнде. Авылда хәлләр алай ук түгел, ләкин хәзер анда да урлашу, эчүчелек арта бара.

Элегрәк ничек булган соң? Моны белү өчен тирән тарихка да керәп торасы юк; күпләр, моннан 30—40 еллар элек андый нәрсә юк иде, диярләр. Әүвәлгерәк дәвер хакында безгә кабер ташлары, орхын-енисей язмалары, кытай, уйгыр, гарәп, фарсы чыганаклары, Европа галимнәре, сәяхәтчеләре язмалары мәгълүмат бирә. Мәсәлән, кытай чыганакларында мондый юллар бар: «Татарлар зур һәм мөһабәт гәүдәле, киң маңгайлы, озын чәчлеләр... Буй-сыннары зифа, үзләре тәртипле, һәм ата-аналарын ихтирам итәләр». Әйтерсең лә сугышка кадәрге безнең авыл кешеләре турында язганнар инде!

Татарлар монголлардан антропологик яктан гына түгел, гадәтләре, көнкүрешләре, диннәре белән дә аерылып торган. Мәсәлән, монголларда элек-электән авыруларны, картларны ерακка, чүлгә, тау араларына илтеп ташлау гадәте яшәгән. Янәсе, кеше үлә дә, аның җаны хайваннарга күчеп тора, яңа бала туганда, әлеге җан хайваннардан яңа туган бәбигә күчә. Шуңа күрә шакаллар һ. б. авыруларны, картларны ашап, вакытлыча аларның җанын саклап торалар икән. Тагын укыганым бар: 1922 елда Монголиянең башкаласында ламалар башлыгы ике шәрә хатынны җигеп урамда коляскада йөри икән. Халык моңа гаҗәпләнгәч, ул: «Күзегезгә генә шулай күренә ул», дип җавап биргән.

Мин бер диннән дә, башкаларның гадәтләреннән дә көлмим. Ләкин шунсы хак: һәр халык үзенә яраклы динне сайлый, ошаткан алласына табына. Ләкин сорау туа: нигә бу татар халкы христианлыкны, буддизмны яки башка берәр динне кабул итмәде икән? Мөгаен, пакьлыкка өйрәнгән татарга ислам диненең төһарәтләре, белемгә, гаделлеккә өндәүләре хуш килгәндер...

Татар тарихының соңгы мең дә бер йөз елы эчендә ислам дине гаять зур роль уйнаган. Ул татарны пакь, саф, гадел, кешелекле, киң күңелле, эш сөючән, тәртипле, намуслы, кунакчыл, туган җанлы, белемгә омтылучы, горур, батыр кеше иткән. Шуңадыр инде Бөек Ватан сугышында татарлар куркусызлыгы белән күпләргә үрнәк булып торган. Чөнки татар Мөхәммәт пәйгамбәрнең кылычына язылган сүзләр йогынтысында тәрбияләнгән: пәйгамбәр Мәдинәдән Мәккәгә барганда, гаскәр башлыгы Әбу-Дәҗанәгә бүләк иткән кылычта: «Курку намуссызлыкка алып бара, ә дан һәрвакыт алга илтә. Куркаклык кешене үзенең язмышыннан беркайчан да коткармаячак», — дип язылган була.

Безнең авылдан фронтка китүчеләрнең 70 процентка якыны сугыштан әйләнеп кайтмады. Гадәтем буенча, авылга кайткач, иң элек мәдәният сарае алдына куелган мәрмәр һәйкәлне карарга барам. Күпләре турында истәлекләр, очерклар язганым бар. Шул авылдашларымның берничәсен генә искә төшерәсем килә: Мәгъҗан Гайнанов 1942 елда үзе теләп сугышка китә. 1945 елның 5 мартында Вроцлав шәһәре янындагы Братш поселогы тирәсендә барган каты сугышларда һәлак була. Мина илленче еллар башында Мәгъҗан абыйның командирлары белән Харьковта очрашырга туры килде. «Бер көнне бик каты сугыш булды,—

диде алар.— Немецлар бөтен көчләрен туплап, һөҗүмгә күчте. Безнекеләр, көчле басымга чыдый алмыйча, чигенә башладылар. Тик өлкән лейтенант Мәгъҗан Гайнанов ротасы гына урыныннан кузгалмады. Югыйсә минометчылар позицияләрен җәяүлеләрдән алда алмаштырырга тиешләр иде. Ләкин рота командиры мәсьәләне үзенчә хәл итте һәм чолганышта калды. Бу безне бик борчыды, һәм, ротаны коткару өчен, полк көчле атакага күтәрелде, дошманны изеп ташлады. Мәгъҗан аңын югалткан иде, кулыбызда җан бирде. Үлем күрмәгән кешемени без, әмма күңел бу югалту белән һич тә килешә алмады, бик күпләребез елады. Дивизия командиры өлкән лейтенант Гайнановны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итте. Ләкин җиденче гвардия механикалаштырылган корпус командиры генерал-лейтенант И. Корчагин кул куймады. «Татарлардан геройлар болай да күп»,— диде.

Шундый ук язмыш һәм мөнәсәбәт әткәй ягыннан туган Мөнир абый (өлкән лейтенант Мөнир Мөхәмәтдинов Калинин шәһәрен азат иткәндә, зур батырлыклар күрсәтеп һәлак булган, фронт штабына киткән документта Советлар Союзы Герое исеменә лаек диелгән. Һәм Әхмәтнур абыйга да (майор Ә. Мөхәмәтдинов Керчьне азат итү сугышлары өчен шулай ук Геройга тәкъдим ителгән) эләккән. Менделеевск шәһәрендәге 1 нче урта мәктәпне тәмамлаган биш урыс егетенә Советлар Союзы Герое исеме биргәннәр — беркем дә, бер мәктәптән бишәү ярамый, дип әйтмәгән!..

Бервакыт миңа Якуб Чанышев абыйның бер төркем кешеләр белән сөйләшкәнен тыңларга туры килде. Берәү аңардан: «Ни өчен сез генерал-лейтенант кына?» — дип сорады. Ул хәрбиләрчә кыска һәм кырыс итеп: «Татар булганга күрә»,— диде. Менә шундый хәлләр...

Мин бер генә кешегә дә, шул җөмләдән, урысларга, урыс халкына да каршы булганым юк. Хәтта аларны гомер буена мактап йөрдем. Хәзер болай уйлыйм: әгәр татарлар Көнчыгышта монголлар, Европада — урыслар белән көрәшедә яшәмәсә, бәлки язмышлары бөтенләй башкача булыр иде. Аларның иле нәкъ бүгенге Голландия, Бельгия, Люксембург, Швеция, Норвегия, Финляндия һ. б. дәүләтләргә охшар иде, бәлки. Ләкин тарихны үзгәртеп булмый. Революциягә кадәрге әдәбият, документлар белән танышканда, бер нәрсә күзгә чалына: Русиядә, нигездә, ике халык булган икән — урыслар һәм татарлар. Аңлашыла ки, «татар явызлар урыс җирләрен басып алып, аларны 300 ел буе изгәннәр, үсешләрен тоткарлап торганнар». Беркем дә ул заманны мактарга җыенмый. Ләкин үзеннән-үзе сорау туа: элекке колонияләр Индонезия, Малайзия, Пакистан, Африкадагы Алжир, Тунис, Марокко һ. б. күз алдына, 20—30 ел эчендә, бик нык алга киттеләр. Ә урысларның «татар-монголлар»ны җиңүенә дә 500 елдан артык вакыт үткән, ә Русия һаман койрыкта сөйрәлә, моңа әле һаман XIII—XV гасырларны сылтау итәләр. Русиядә табигый байлыкның иге-чиге юк, һәм хәерчелек тә иксез-чиксез. Чын сәбәп нәрсәдә соң?

Русиянең бервакытта да диярлек (бер-ике патшадан тыш) рәтле җитәкчеләре булмаган. Ил бик киң җәелгәч, аның белән җитәкчелек итү дә кыен булган, дип уйларга кала. Тагын: Русиядә нинди генә казаклар юк: Дон, Кубань, Терек, Урал казаклары һ. б. Ә бит казан татар-төрек сүзе «качак»тан алынган. Алар — үзәк властька буйсынмый качып киткән кара халык. Мисалга Киров өлкәсе кешеләрен алсак — Псков, Новгородтан качканнар. Кыскасы, илдә тәртип булмаган, шул нәрсә бүгенгә кадәр дәвам итә. Әле дә бары бернәрсә җитми: тырышып эшләү, тәртип.

Урыс эшләми, диләр. Европа аны ялкау ди (мин үзем, мәсәлән, күп санлы бер халыкка мондый исем тагарга ашыкмас идем). Ә бит ныклап уйлап карасаң, урыска эш белән ихластан шөгыльләнергә вакыт та тимәгән: сугыш та басып алу, талау да көчләү. Урысның бүген дә бик яхшы уңдырышлы җирләре киң җәелеп ята. Кара туфраклы түгел дигәне дә, эшкәртсәң, бер дигән уңыш бирәчәк. Немец, французлар андый җирнең һәр гектарында 80—90 центнер бодай үстерер, Канададагы кебек, һәр сыердан 10000 литр сөт саварлар иде. Русиядәге кебек урмансулар, андагыдай бихисап казылма байлык тагын кайда бар икән? Монда японнар яшәсә бөтен җир шарын туендырыр иде. Ә без — ач-ялангач... Минемчә, Русиянең бүгенге хәле «татар-монголга»да, полякка, немецка, шведка да бәйләнмәгән. Бәхетсезлек шунда ки, революциядән соң властька икейөзле, булдыксыз төрле җитәкчеләр килде. Совет системасы кешене эшләмәскә өйрәтте. Чөнки ул милектән читләштерелде, авыл хуҗалыгында крепостное правоның иң кешелексез формасы яшәде. Тырыш крестьяннарны, кулак дип, Себергә кудылар, аттылар. Күпләр эшләп тә ач яшәгәч, эшкә күңел бирми башлады, эчүгә сабышты, урлашу юлына басты.

Мине аеруча борчый торган нәрсә — эчкечелек. Бу эш аерым шәхесне генә түгел, бөтен бер халыкларны аяктан ега. Гомерендә авызына хәмер капмаган мөселман-татар (гарәп бүген дә, әчми генә түгел, спиртта ясалган одеколон, хушбуйларны да сөртми), башкаларга ияреп, эчүчелеккә бирелде. Сугышка кадәр татар авылында акылга җиңел балалар бөтенләй юк иде. Ә хәзер авыл саен ангыралар мәктәбе ачарга буладыр.

Моннан ярты гасыр элек 500 йортлы авылымда күп булса ике яки өч исерек очрый иде. Аларны, «тәмуг кисәве» дип каргыйлар иде.

Революциягә кадәр авылга исә, гомумән, аракы кермәгән, кайбер халыклардагы кебек, сыра яисә ачы бал кайнату да булмаган. Бу уңайдан әткәй миңа нәрсә сөйләгән иде: «Герман сугышы алдыннан заводта эшләп йөрүче Миңнебай абзый авыл сәүдәгәрен үтергән өчен каторгага озатылды. Революциядән соң, күкрәк киереп кайтып та төште. Эчәргә, тартырга өйрәнгән. Шул яман гадәтләрен бүтәннәргә дә йоктырырга тырышты».

Милли гореф-гадәтләргә нигезләнгән тәрбия системасын булдыруны күп кенә галимнәр әйтеп калдырган. Мәсәлән, бөек педагоглар — Я. Коменский (1592—1670), И. Песталоцци (1746—1827), К. Ушинский (1824—1870), һәр халыкның үзенә генә хас традицияләре бар һәм яшь буынны шул традицияләрдә тәрбияләгәндә генә, уңышларга ирешергә мөмкин, дип өйрәтәләр. Безнең олы галимнәребез һәм язучыларыбыз Шиһап Мәрҗани, Каюм Насыйри, Риза Фәхретдинев, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов иҗатларында да шундый ук идеяләр алга сөрелә. Аңлашыла ки, балага дөрес тәрбия бирү өчен, кимендә ике шартның үтәлүе мәҗбүри: беренчесе — бала өйдә, ана кулында, икенчесе — халык традицияләрендә тәрбияләнергә тиеш. Башкача ярамый. Кызганыч ки, совет педагогикасы бу «вак-төяк»кә әһәмият бирмәде, чөнки аның тоткан юлы бөтенләй башка — «милләтсез, сыйнфый тәрбия» иде...

Я. Коменский, кеше үз гомерендә бер-бер артлы 4 мәктәп тәмамларга мөмкин, диде: аналар мәктәбе, башлангыч, урта һәм югары мәктәпләр. Бөек галим «Аналар мәктәбенә» аеруча зур әһәмият бирә һәм шул исемдә бик яхшы дәреслек тә язып бастыра. Хәлемнән килсә, мин бүген дә шул дәреслекне һәр яшь анага бүләк итәр идем. «Аналар мәктәбе» дип, педагогика остасы баланың ана кулында, өйдә тәрбия алу чорын атый. Болай уйлау, чыннан да, үзен һәрьяклап аклый. Чөнки ана — гаилә — бала өчен иң бай хисләр һәм дөньяны танып белү мәктәбе. Алты-җиде яшькә кадәр бала нинди тәрбия алса, ул соңрак та шул нигездә үсә. Лев Толстой бер дә юкка, мин өч яшькә кадәр белгәннәремне соңыннан тулыландырдым гына, дип әйтмәгән.

Тормышта бик коры, хискә ярлы кешеләрне очратырга туры килә, алар йомык, аз сүзле, артык басынкы була. Аларның күпчелеге — балалар йортында яки үги ана кулында үскән җаннар. Шушы уңайдан: әти-әниләр, балаларыгызны ятим итмәгез! диясе килә. Бүгенге сабыйларның күпчелеге балалар бакчаларында тәрбияләнә. Бер тәрбиячегә 40 бала туры килә. Монда хисләр үстерү турында сөйләү кыенрак, әлбәттә. Хисләр, нигездә, бала чакта формалашканлыктан, җәмгыять аналарга баласы җиде яшькә җиткәнче өйдә утырырга мөмкинлек тудырырга тиеш. Гарәпләрдә, мәсәлән, ул болай эшләнә: бала үстерүче хатын ире хезмәт хакының 70 процентын ала. Бу хакта сүз чыкса, бездә авызны тиз каплыйлар: акча юк! Ә дөрес тәрбия алмау аркасында җинаятьчегә, әхлаксыз бәндәгә әверелгән җаннарны асрауга акча аз китәмени?

Кайберәүләр шундый дәлил китерергә ярата: имеш, укытучыларның 80 процентка якыны — хатын-кыз. Медицина өлкәсендә бу сан тагын да югарырак. Инженерларның да 52 проценты — хатын-кыз. Аларны эштән бушатсак, нишләрбез, янәсе. Ә минемчә, хатын-кызга югары белем бирәм дип, дәүләт зур чыгымнар тота, тик алар акланмый, хатын-кыз һәм аның балалары еш авырый. Моңардан иҗтимагый эшханәләр дә, гаилә дә интегә. Бәлки хатын-кызга урта белем бирергә, аның төп вазифасына — бала табуга һәм аны яхшылап тәрбияләүгә кайтарыргадыр? Бу минем генә фикер түгел... Дөрес, моны тиз генә эшкә ашырып булмас, әмма шундый максат куйсак, җәмгыять отар, хатын-кыз үзен чын кеше итеп тоя башлар иде. Ә хәзергә ул ике камыт кигән эш аты: тегесенә дә, бусына да җигелергә мәҗбүр.

Мондый хәл халкыбызның үрчүенә дә гаять кире йогынты ясады. Халыкның бүгенге санын саклау өчен генә дә, һәр ике гаиләдә 5 бала булырга тиеш: дүртесе — ата-аналар урынына, бишенчесе — нинди дә булса сәбәп аркасында бөтенләй баласыз калган гаиләләр өчен. Ә чынбарлыкта ничек соң? Ике гаиләгә ике яки өч бала. Укучыдан гафу үтенеп, тагын балачагыма кайтам. Сугыш башлангач, июнь-июль айларында, хатыннары кулына 5—6 баларын калдырып, авылы-

быздан 35—40 яшьлек ирләр фронтка китте һәм бик азлары гына әйләнеп кайта алды. Бүген мин үскән Олы Ярминкә урамында бер-ике бала йөри, уйнарга иптәш таба алмый интегәләр. Яшьләр дә бар югыйсә, ә балалар юк. Болай булса, тиздән татар дигән затлы, олы тарихлы милләт кызыл кенәгәгә теркәләчәк. Бу — сүз уйнату түгел, чынбарлык! Яшьләргә мөрәҗәгать итәм: татар халкы бала үстерүне үзенең иң төп вазифасы итеп күргән. Коръән дә шуны куша. Үстерегез балалар, бергә шатланып яшәгез!

Бала үстерү өчен шартлар юк, тормыш авыр, ди кайберәүләр. Җәмәгать, бездә берәр җиңел вакыт булды микән? Патша изүе, колхозга куып кертү, тау кадәр салымнар, натуралата түләүләр, аннан соң — сугыш, Сталин вакытында авылның искиткеч ачлык кичерүе, Хрущев заманында бакчаларны кисү, мал тотуны чикләү, кәҗә атып йөрү кебек кәмитләр булмадымыни? Әмма хатыннар барыбер бала тапты һәм үстерде. Ә менә америкаң, англиз хатыннары, «томана» булгач, 4—5 бала үстерә булып чыга. Моңа кем ышансын соң? Шул гына: мең елларга сузылган бала үстерү гадәтләрен аякка бастырырга кирәк; кызганыч, дин белән бергә, болар да аяк астына салып тапталынды...

Гаилә, бала табу турында сүз чыккач, тагын бер мәсьәләгә тукталмый үтеп булмый. Бу — яшьләрне гаилә төзүгә әзерләү. Бүгенге яңа оешкан гаиләләрнең кимендә өчтән бере таркалып бара икән, димәк, яшьләрне өйләнешүгә әзерләү начар куелган. Бик фаҗигале хәл: миллионнарча балалар күз яше түгә, миллионнарча язмышлар челпәрәмә килә. Медикларның раславына караганда, аерылышу үзе генә дә организмны шулкадәр какшата, моны чагыштырыр бернәрсә дә юк икән. Шуңа күрә, җырдагыча әйтсәк, «Аерылмагыз, аерылмагыз, булса да сәбәпләре»!

Беркем дә ханҗалыкка чакырмый, торып булмый икән, нишлисең... Ләкин андый хәлләр җәмгыятьне какшатырга тиеш түгел.

Вильям Шекспир, дөнья ул — театр, кешеләр шуның актерлары, дигән. Бик дөрес сүзләр. Яшьләр өйләнгәч, аларга нинди рольләр уйнарга кирәк булачак соң? Ир белән хатын, әни белән әти, кияү белән килен, кайнага, кайнигәч, баҗа, каенсеңел; тора-бара әби белән бабай... Менә шул рольләргә баланы иң беренче чиратта ата-ана әзерләргә тиеш.

Безнең заманда гаилә нинди принципларда төзелә һәм төзелә ала соң? Язучы һәм галим Ю. Рюриков гаиләнең өч вариантын барлыгын әйтә. Беренчесе — «саф мәхәббәткә» нигезләнгәне. Моңа аңлатма биреп торасы юк. Ләкин нәкъ шундый гаиләләрнең таркалуга иң күп дучар булуын аңлату зыян итмәс. Сәбәп түбәндәгечә: мәхәббәт чыннан да бөек, илаһи, һәркемгә көч-куәт бирә, дәрт өсти торган хисләр дөньясы ул. Ләкин аның бер кире «гадәте» бар: «сүнә, салкыная». Гадәттә, яраткан кешең иң яхшы сыйфатларга ия (акыл, төс, гадәт һ. б.) булган кебек тоела һәм шулай күренә дә, шул сине тарта да. Инде бергә тора башлагач, бар нәрсә дә гадәтигә әйләнә, «серле тойгылар» югала башлый. Ир заты да хатынына матур сүзләр әйтүне кимегә бара. Ә хатын-кыз табигате мондый «хыянәтне» күтәрә алмый. «Син башканы тапкансың, теге вакытта болай дигән идең, тегеләй дигән идең», — дигән сүзләр белән тавыш чыгарырга тотына. Ни өчен? Ир белән хатын бер-берсенең табигатен белмәгән өчен. Менә шулай акрынлап гаилә таркала.

Икенче вариант — ир белән хатын, көчле мәхәббәт утында янмасалар да, уртак тел табалар, зур вәгъдәләрсез генә кушылалар һәм «сүз куешулар» булмагач, тыныч кына көн итәләр. Бер-берсен канәгатьләндерәләр, аңлыйлар.

Өченче вариантны идеал дип атарга була, бу — алдагы ике вариантның кушылмасы. Шулай да икенче вариант таләпләре күбрәк өстенлек итә бирәдә. Бу уңайдан зур акыл иясе, хисләр дөньясын яхшы белүче В. Белинский сүзләрен истә тотасы иде. Ул, мәхәббәткә генә исәпләп яшәү һәлакәткә китерә, упкынга илтә дигән. Шунлыктан яшь кызларга бер киңәшем бар: «Олы мәхәббәт килмәде, дип борын төшереп йөрмәгез, ошаган егетегез булса, тәвәккәлләп, гаилә корыгыз, бу бәлки олы мәхәббәткә юл салу да булыр».

Үзем үскән авылны, аның кешеләрен күз алдына китерәм дә, элегрәк аерылышуның бөтенләй булмавын, әле хәзер дә бу адымга бик сирәк кенә баруларын уйлыйм. Бу — татар гореф-гадәтләренең гаилә саклау үрнәге. Һәм шул традицияләрнең берсе — кияүгә бирү, килен алу. Бу мәсьәләдә өлкәннәр бик таләпчән булганнар: кем кызы, матурмы, сәламәтме, эш беләме, чистамы — шуларны тикшергәннәр. Ир затына — кияүгә таләпләр тагын да зуррак булган, чөнки аңа «Алла бүләк итеп хатын һәм балаларны бирә һәм ул алар өчен Ходай тәгалә алдында җаваплы». Әнә шуңа күрә, хатыны, балалары тыныч кына йоклап ятканда, ир-әти кеше салкын тиргә батып уянган, аны гаиләсе турындагы уйлар борчыган.

Фәндә психологик халәт дигән нәрсә бар. Ул — кешенең инануы, эчке дөньясы торышын аңлата. Ике якта — ирдә дә, хатында да «Бу минем язмышым, бөтен көчне тату яшәүгә бирергә кирәк»,— дигән рухи халәт өстенлек итсә, аерылышулар күпкә ким булыр иде. Мин хатын-кыз авызыннан «чират уздыру», дигәнне ишеткәнем бар. Бу инде исем өчен генә иргә барып кайту була. Шундый психик халәт, уй, инану да яшь адәм баласында. Мона без — ата-аналар да гаепле. Өйләнү — кияүгә чыгу көнбагыш чәйнәп төкерү түгел. Язмыш ул. Балалар ул. Гомер ул.

Сүз унаенда катнаш гаиләләр мәсьәләсе. Алар еш кына мәхәббәткә нигезләнеп туа. Әмма күбесе озак гомерле булмый. Урта Азиядә, Казагыстанда шундый гаиләләр, бер милләт кешеләреннән оешканнарга караганда, өч мәртәбә күбрәк таркала. Моның бер гаҗәбе дә юк: ике мохиттә, ике гореф-гадәттә, ике төрле фикерләүдә үскән кешеләргә уртак тел табу җиңелдән түгел. Беренче карашка, гади генә булып тоелган сәясәт, «интернациональ тәрбия» нәтиҗәсе булды бу. Ни өчен? Вак милләтләрне йоту өчен: катнаш гаиләләрдә үскән балаларның барысы да гадәттә, урыска әйләнәләр, чөнки «шулай гадәткә кергән, шулай дәрәҗәлерәк». Халкыбызның 43 проценты бүген шул «җаваплы бурычны үтәү» белән мәшгуль. Ә урыс бер милләткә дә бала үстерми. Безнең кызлар урыс, башкорт, үзбәк, казакъ, кыргыз, төрекмәнгә һәм тагын әллә кемнәргә уллар, кызлар үстерә. Тик татарны гына тәрбияләмиләр. Мондый гамәл азчылык милләтләрнең тамырын корыта: 1920 елда СССРда 194 милләт кешеләре яшәсә, 1979 елда 101 гә калган. 1932 елда укыту 102 телдә алып барылса, 1988 елда 39 телгә төшкән. Алары да күбрәк башлангыч мәктәпләрдә. Әйтик, күршеләребез мари, мордва, удмурт, коми, чувашларда шул хәл.

Бу хакта СССР педагогия фәннәре академиясендә сүз кузгаткач, миңа: «Кайсы телдә укысаң да, барыбер түгелмени?» — диделәр. Аларга Я. А. Коменский, К. Д. Ушинскийның ана телендә укыту турындагы фикерләрен искә төшергәч, «социализм чорында яшәмәгән галимнәрнең тәкъдимнәренә тәнкыйть күзе белән карарга кирәк»,— дип җавап бирделәр. Без нәкъ әнә шундый галимнәр тырышлыгы белән бүгенге авыр хәлгә калдык та инде. Казаныбызда да шулай уйлаучы «сыйнфый тәрбия» тарафдарлары бар. Аларга интернациональ «тәрбия», ягъни илдә бер милләтне генә калдыру рухында тәрбия бирү кыйммәт. Кәнәфиләрендә тыныч кына утырып торсалар, бик ярар иде дә, алар «төпкә җигелеп тартып барырга» комарлар. Алардан күпме тизрәк котылсак һәм милли тәрбия чараларын эшләп, тормышка ашыра башласак, яшьләрне шулкадәр тизрәк дөрес юлдан җибәрербез. Тегe «ленинчы профессорлар, доцентларның» искегә ябышып ятулары бик ихтимал: чөнки алар башкача уйларга өйрәнмәгән. Әмма аларга карап, безнең тәрбия корабы юнәлешен үзгәртмәскә тиеш.

Мәсьәлә телдә, гореф-гадәтләрдә генә түгел, аларның үзенчәлегендә, көчкодрәтендә. Мәсәлән, тәрбиядә бик уңышлы хәзинәне халык авыз иҗаты җәүһәрләрен алсак, аларны, бөтен тәэсир тылсымын саклап, тәрҗемә итеп булмавын күрербез. Туган әдәбиятыбыз әсәрләре дә шундый.

*Әллә күпкә, әллә бик озакка,*
*Ахры, мәңге оныта алмамын,*
*Тамбов урманнары уртасында*
*Усак яфраклары шаулавын.*

Такташның шушы юлларын укыгач, туган җирем, аның бик бай табигате күз алдыма килә. Усакның көмештәй яфракларын искә төшерәм. Ә инде шул юлларны тәрҗемә итеп карыйк. Бөтен хозурлык, табигатьнең бөеклеген тою хисләре югалып калырга мөмкин.

Менә «Сак-Сок» бәетен алыйк. Эчтәлеге гади, башка телдә яңгырарлык түгел. Хәтта Семен Липкин кебек оста тәрҗемә итсә дә. Ә күпме татар баласы шуны тыңлап, балавыз сыгып, иманлы, миһербанлы булып үсте.

Бервакыт әнкәй, нинди уңайдандыр, мондый бер кыйсса сөйләгән иде: «Сөләйман пәйгамбәр чит илдә патшалык итеп нык баеган һәм атасын күрергә кайткан. Онытыпмы, язмышы шулай булганмы, атасын ат өстендә килеш сәламләгән. Ә бу шулкадәр зур гөнаһ булган ки, алла Сөләйман пәйгамбәрне гафу итмәгән: пәйгамбәрләр арасыннан бары тик аның гәүдәсен генә черүгә дучар иткән». Бала — хис иясе, һәм менә шундый сүзләр аның йөрәгенә мәңгегә сеңеп кала: «Ата — бөек! Аны хөрмәт ит!» Бу инде сиңа «Укучылар өчен кагыйдәләр» парчасы гына түгел. Бер ишеттеңме, хәтереңдә сакла!

Хикәятләр чынбарлык белән расланса, әти кеше, чыннан да, үзен гали итеп тотса, аңа хөрмәт янә дә артачак. Безнең әти, җитди кеше булса да (колхоз

рәисе), ачык күңелле һәм игътибарлы иде. Эштән күпме генә соң кайтмасын, балаларын карап чыга, безгә ниндидер җылы сүз әйтә. Иртәрәк кайта икән, без тоткан балыкларны тазартырга булыша. Кул күтәрү түгел, бер генә мәртәбә дә авыр сүз әйтмәде ул безгә. Ә бит болар — татар традициясеннән...

Бүгенгедәй колак төбемдә яңгырап тора: бервакыт университет бакчасында язгы имтиханга әзерләнә идек. Бер малай: «Папочка, бүтән алай итмәм»,— дип шулкадәр кызгандырып елый, ә атасы каезлый гына моны. Хәзер инде мин моңа гаҗәпләнмим дә, чөнки Библиядә әйтелгән: «Адәм белән Һава нәселе кешеләре гөнаһлылар, ә җәзага тарту гөнаһны киметә». Бездә берәр кеше баласына кул күтәрсә, «әллә кяфер булдыңмы?» — диләр иде. Ислам диненең өйрәтүе капма-каршы: «Алла атага баланы үстерергә, сөяргә, Алла бәндәсе итеп тәрбияләргә бүләк итеп бирә» ич! Буыннан буынга килә инде бу хәл: әткәй үз атасын бик сагынып, хәтта елап искә ала торган иде. Әхмәтҗан карт балаларны бик яраткан шул: үзенең унберен үстереп бетергәч, олы улының баласын тәрбиягә алырга дип сорап йөргән. Кемдер аның бу үтенечен ностальгия, үткәннәрне сагыну галәмәте, дип уйлар. Сагыну да бардыр, ә иң кыйммәте: әнә шул картлар традициясен безгә дә дәвам иттерәсе иде!

Мин белгәндә, Фатиха картнәй шактый олы яшьләрдә иде. Ләкин һаман да төскә-башка күркәм иде әле: туры борынлы, кечкенә авызлы, чокыр битле. Билгеле инде, старшина улына чибәрне алганнар! Картнәйнең безгә — балаларга уңай йогынтысы, һичшиксез, булгандыр димен. Ике улының ике оясы — унике бала, зурлар эшкә киткәч, көн буена шул кечкенә карчык янында җыйналып кала идек. Горур, гадел, үз сүзендә нык торучы, кеше гайбәтен сату белән шөгыльләнмәүче бер зат иде ул. Аллага ышангандыр, ләкин дингә мөкиббән китмәде. Урыс белешләрен җылы искә ала иде. Карттай, халыктан недоимка җыймаган өчен, староста башы белән, урыс төрмәсеннән чыкмаган. «Атналар буе белешләрдә торырга, картка ашамлык илтергә туры килә иде»,— дип сөйләве хәтердә картнәйнең. Ул урысча шактый сукалый иде, шунда өйрәнгән, ахрысы. Гарәпчә укый, әмма язмый иде, «егетләргә хат язарсыз» дип, өйрәтмәделәр дия иде. Аның сабаклары көн саен, сәгать саен, минут саен, әкренләп канга сеңә барды. Картнәй безгә: «Курыкмагыз беркемнән, җирдә нык басып торыгыз, юк-бар белән чуалмагыз, кешедән көлмәгез»,— дип өйрәтә иде. Сүз әле бер эш. Гамәлендә дә шуңа бәрабәр иде ул. Аш-суга бик оста иде — ул оеткан каймактай катыкларның, бавырсак, печеньеләрнең тәмен әле дә телемдә тоям. Бервакыт күрше Миңлевафа әби: «Кунак килсә, үз ипиебез булса да, Фатиха җиңгидән алып тора идек»,— дигән иде. Мин моның серен сорагач, картнәй, бер ни булмагандай: «Хәтерләмим, ләкин ипи камырына күп итеп май сала торган идем»,— диде.

Бервакыт әнкәй: «Без ачлык елны Фәүзия белән бер-бер артлы бу йортка килен булып төштек. Сыерлары, сарык-кәҗәләре, кош-кортлары бар иде. Ач булмадык (әткәй белән аның энесе Гафур абый Златоустта такта ярып, онын, шикәрен, чәен, ярмасын алып кайта торган булганнар). Ирләр өйдә юк вакытта инәй (пенза мишәрләре сүзе, әни дигәнне аңлата) безне үз каршына утыртты да болай диде: «Мин үзем дә калын йортка, старшина Әсәдулла карт йортына килен булып төштем. Курыктым бик. Эш күп булды. Ләкин какмадылар. Картларның урыны оҗмахта булсын. Бераздан йорт салып башка чыгардылар. Менә хәзер сез миңа киленнәр. Балаларым булырсыз. Какмам. Тамагыгыз тук, өстегез бөтен булыр. Ләкин шартым бар: сүземне тыңларсыз, булмастайны кушмам. Урамга сүз ташымагыз. Кеше генә көләр». Картнәй сүзендә нык торган. Әнкәй дә киленнәренә бик ягымлы булды (бик йомшак, авыл советы депутатын да алла урынына күргән бер татар хатыны иде). Менә алар халык традицияләре!

Җәй көне картнәй йоклый торган түр якның тәрәзәләре ачык тора иде. Көтү кугач, уллары тәрәзәгә киләләр дә: «Инәй, киленең чәй куеп калды, әйдә безгә»,— дип чакыралар иде. Гадәттә, ул бармый, берсенә барсам, икенчесе үпкәләр, дип уйлый иде бугай. Бервакыт картнәй бик каты авырып китте һәм озак ятты. Инфаркт булды, ахрысы. Балалары, оныклары яныннан китмәде, читтән дә кайттылар. Картнәй терелде. Аннан соң да чирек гасыр чамасы яшәде. Минемчә, аны балаларының игътибарлы булуы аякка бастырды. Их, шул күркәм гадәтләрне бүген дә кочәйтәсе иде...

Татар халкының бик затлы гореф-гадәтләренең тагын берсе — гыйлем эстәү, укуга омтылыш. Бик күп диннәрдән аермалы буларак (бездә бервакытта да инквизиция булмаган), иң зур галимнәрне утта яндырмаганнар, алты миллион кешенең башына җитмәгәннәр, исламның һәр аяте диярлек белемне, гыйлемне мактый. Фән мине рисвай итәр, дип курыкмый. Шул нәрсә татарның канында булган. Авылымда ишеткәнем бар: «Бөтен кешене укырга-язарга Гайнелхәят

мөгаллимә (әнкәйнең әнисе) өйрәтте». Безнең авылда Земская школа да булган (әткәй шуны тәмамлаган), анда булачак күренекле шагыйрь Михаил Львовның әтисе Дәүләтша абый, әнисе Гөлҗиһан апа (аның кабере безнең авыл зыяратында) Габитовлар укытканнар. Хәллерәк кешеләрнең балалары шул мәктәптән соң Златоустта гимназия тәмамлаганнар. Алар арасында әткәйнең Шакир, Галим, Сабир абыйлары, Газиз дигән энесе дә гыйлем эстәгән (өчесе дә гражданнар сугышында юк булган). Шуна күрә районда беренче урта мәктәпнең безнең авылда ачылуы табигый саналган. Чөнки укытуның традицияләре яшәгән. Шул авыл мәктәбе утыздан артык фәнни хезмәткәр, дистәләрчә дәүләт эшлеклесе, хәрби белгеч үстерде. Алар арасында күренекле тюрколог, профессор, филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр Академиясе әгъза-корреспонденты Фуат Ганиев тә бар. Татарстанның халык артисткасы Зилә Сөнгатуллина да бездән. Болар — куанычлы мисаллар. Ләкин соңгы елларда зур үсешләр күренеп тормый. Шуның бер сәбәбе — туган телне санга сукмау. Мәктәпне башкорт мәктәбе дип (ә Башкортстанда бу чир бик көчле иде) игълан итмәсеннәр өчен, урысча укытуга күчкәннәр. Ә кадрлар, мохит — шул ук... Бу бәла безнең мәктәпкә генә төшмәгән. Телне бетерүнең күп ысуллары арасында иң сыналганнарының берсе — югары белемне башка милләт телендә укыту. Керү имтиханнарын урыс телендә үткәрү, вузларда укытуны да шул ук телдә генә алып бару. Моның нәтиҗәсе күз алдында. Урысларда мең кешегә 47 югары белемле; үз телләрендә укытучы Грузия, Әрмәнстанда бу сан тагын да зуррак, яһүдләрдә 300 дән артык, татарда — 22, аларның да күбесе — татар телен белмәүчеләр. Билгеле, өстән дә шуны тукып торгач, татар ата-ана мондый нәтиҗә ясый: «Татар теле кухня өчен генә ярый икән, балаларны урыс мәктәбендә укытырга кирәк». Шуның аркасында Казанда татар мәктәпләре, балалар бакчалары бетте. Хәзер хәлне бераз юлга салу өчен кайбер чаралар күрелә. Ләкин бетергәнне тергезү кыен нәрсә. Тырышырга, әле мең кат тырышырга кирәк!

Форсаттан файдаланып, мин хезмәт тәрбиясенә киңрәк тукталмакчы булам. Хәтта хезмәтне тәрбиянең аерым бер чарасы дип карыйм. Ул — аерым шәхес тормышында да, җәмгыять өчен дә хәлиткеч фактор. Шулай булган һәм булачак. Беренче кешеләр, хайваннар дөньясыннан аерылып чыккач та, хезмәткә тотынганнар: җиләк-җимеш, орлыклар, тамыразык җыйганнар, балык тотканнар, ауга йөргәннәр. Гади генә кием аларны салкыннан саклаган. Торак хәстәрләгәннәр. Тормыш бары тик хезмәт аркасында гына бара ала. Татар, тырышлыгы аркасында, бөек дәүләтләр, гүзәл шәһәрләр, корылмалар төзегән. Аларда бөтен инфраструктуралар булган. Чәчәк аткан мәдәният, сәнгать, нәхтә-затлы киемнәр, алга киткән игенчелек, һөнәрчелек күпләрне таң калдырган. Иле колониягә әверелеп, татар җирләренең иң яхшылары урыс алпавытларына бирелгәч тә, күп балалы татар гаиләләре югалып калмаган. Көлгәннәр татардан, әллә нинди кушаматлар такканнар аңа. Әмма татар яшәгән, аны гореф-гадәтләре, йолалары, теле, дине яшәткән. Петр патша яңа башкала салырга карар кылгач, меңнәрчә татарны фин сазлыкларына китереп тутырган. Чөнки, урыслардан аермалы буларак, алар оста ташчы булганнар. Үзләре һәлак булсалар, юкка чыксалар да, бер дигән яңа шәһәр торгызганнар. Петербургның XVIII гасырда төзелгән өлеше — татар сөякләре өстендә тора. Бу хакта үз вакытында, бик зур батырлык күрсәтеп, СССР халык артисты, каләм иясе Габдулла Шамуков язып чыкты. Аны төрмәдән, үлемнән дәлилләренең урыс архивларыннан алынган булуы гына коткарды.

Халык язучысы Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» исемле повестен да мин татар тормышын яктырткан, аның традицияләрен калку итеп күрсәткән энциклопедия, хезмәт кешесенә дан җырлау дип кабул итәм. Фатих Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романы да татарның никадәр тырыш, гадел икәнен тасвирлый. Бик кечкенәдән үк мин Шәйхи Маннурның «Гайҗан бабаена» гашыйк булдым. Г. Ибраһимов, М. Гафури, И. Газый, М. Әмир, урта буын язучыларыннан М. Мәһдиев, Н. Фәттах, Ә. Баян, Х. Сәрьян әсәрләрен укыган һәркем (аларның күбесе башка телләргә дә тәрҗемә ителгән) татарның арулыгын белмәүче халык икәнен күрер. Киләчәктә шул традицияләребезне һәрьяклап саклыйсы һәм үстерәсе генә иде.

Сталин, кулак дип, авылның урта хәлле иң тырыш крестьяннарын атты, Гулагта черетте. Безнең авылның Фәтхулласы, Әбхәкиме, Зәйнулласы, Шәйхетдине, Хәкимҗаны һ. б. шул тегермәндә тарттырылды. Гаепләре: аз йоклап, күп эшләгәннәр. Матур йортлар, каралтылар салганнар. Кайберләре ашлык сугу, җилгәрү машиналары алган. Әлбәттә, күрше батрак, җилкуарга бу тынычлык бирмәгән һәм Сталин «разнарядкасын» тутыру өчен алар авылдашларын Колымага озаттырганнар, аттырганнар. Ә бит беркемгә дә хәлле тормыш үзеннән-

үзе килмәгән. Әткәй Елдырхан бай хакында (Бөгелмә ягы татары) болай дип сөйләде: «Кунакчыл иде бик. Гадәте шундый булган: кунаклар уянганчы, тозакларын карап, төлке, куян алып кайта торган булган. Өлкән яшьтә булуына карамастан, чаңгыда йөргән». Ә теге әләкчеләр дөнья сәхра, җир күп булган урында мал тотарга иренгәннәр. Көздән үк үзләрен «урыска сатып», он, бәрәңге алганнар. Иртәгесе турында: «Ат уйласын, аның башы зур»,— дип кенә караганнар. Миңа шундый бер кешенең өендә булырга туры килде. Койма, капка, амбар, бәдрәф, болдыр дигәннең эзе дә юк. Йөгереп чыгалар да, әйдә кар өстенә... Өй бүрәнәләренең башларын йомычкага дип, чутлап бетергәннәр. Өйнең түбәсе тузган. Ә тирә-юньдә юкса тайга урманы, иксез-чиксез кырлар... Сугыш вакытында шундый ике кеше хәер сорап йөреп башкорт мунчасында үлделәр. Ә бит җәен гөмбә, җиләк, кымызлык җыйсаң да үлми калырга була иде. Халык шулай эшләде дә. Шул батраклар кавеменнән безнең күршедә бер апа бар иде. Кеше бәрәңге утырта, ә ул — юк, кешегә эшләп йөри. Ачуланалар: «Дүрт балаң бар, ни уйлыйсың?» — диләр. Орлык биреп, көчләп диярлек бәрәңге утырттыралар. Аннан соң ул бәрәңгенең төбен өйми теңкәнә тия. Мин ул апаны ялкау дип тә әйтмәс идем, ләкин аның дөнья күтәргә күңеле ятмый иде...

Игенче бик кызык кеше бит ул: эшкә өйрәнсен дип, үзенә мәшәкать булса да, баласын бергә йөртә. Хәтерлим: станциягә ашлык ташучы абыйлар, егылып төшмәсен дип, улларын ашлык өстенә бәйләп куялар иде. Болар атка утырып мәгънәсез йөрү түгел, бала күңелендә хезмәткә мәхәббәт орлыклары чәчү. Телевидение тапшыруларын караганда, мин аларның шундый берсенә әһәмият бирдем: инглиз карты остаханәсендә өй кирәк-яраклары — урындык, гөл савыты, ипи кунасы ясый.

Аның янында кечкенә бала — оныгы яки оныгының улы. Ул да кечкенә пычкысы белән такта телә. Чүкече белән кадаклар кага. Карт: «Икәү булгач эшләр ничек яхшы бара»,— ди. Малай шатлана. Бу — бик әһәмиятле. Малай да бабасының хәрәкәтләрен кабатлый. Шулай, бүреләр, төлкеләр дә балаларын ауга өйрәтә. Ә без нишлибез? Кешесенә карап. Авылдан бер ана хат яза: «Улым сигезенчене бетерде. Арыгандыр инде. Бригадир тынычлык бирми, кеше җитми, дип эшкә чакырып, теңкәгә тия. Кеше булмаганга без гаеплемени, шәһәрдән чакырсыннар». Бу ана киләчәгенә чокыр казый дияргә була...

Кайбер аналар кызларын «шәһәр тормышына» гына әзерлиләр. Янәсе, авылда үзебез интеккән дә җиткән. Шул кызлар Казанда трамвай йөртә, телләрен яшереп, кибетләрдә сату итә. Торырга урыннары юк, кайда эләксә, шунда яшиләр, начар юлга кереп китүчеләре дә җитәрлек. Авыл тормышы җинел түгел анысы, ләкин анда әле берәүнең дә эштән үлгәне юк. Бөтен нәрсә үзеңнеке, таза-пакь, мең кеше кулы аркылы үтми. Эш майлы ботка түгел, дип борынгылар дөрес әйткән. Үзбәк тә хезмәтне «михнәт» дип атый. Ләкин нормаль кешегә эш — ихтыяҗ ул.

Совет педагогикасы, «акча баланы боза» дигән хакыйкатьтән чыгып, яшүсмерләрне эшкә тартмау теорияләрен уйлап чыгарды. Баланың эт үтереп, кош ояларын туздырып, агач сындырып йөрүләре аны бозмый икән дә, акчалы эш боза икән. Менә сиңа мантыйк! Иранда кечкенә балаларның палас өчен жеп эрләүләрен күрсәттеләр. Ә Англия, Алмания кебек бай илләрдә балаларның җәй көне акча эшләп, үзләренә кирәк әйберләрне алуларын яшерделәр. Мин сугыш вакытында балаларның бик авыр эшләр эшләвен үз күзем белән күреп, үзем татып үстем. Алар белән хәзер дә күрешәм. Барысы да исән-саулар. Шулай булмый, эштән кем үлә, ди. Аракыдан, тәмәкедән үләләр — анысы бар.

Татарга хас тагын бер сыйфат — дуслык, үзара аңлашып яшәү. Бу хакта әллә никадәр җырлар, мәкальләр, такмаклар, әкиятләр бар. Яшь буынны дуслык рухында тәрбияләүдә аларның әһәмияте зур. Ислам, һәммә кеше Алланыкы, шуңа күрә үзара дус булыгыз, дип өйрәтә. Нигездә безнең халык ачык йөзле, кунакчыл, башка халыклар белән дә тату яши. К. Насыйри, Г. Тукайның урыслар белән дуслык хакында әйткәннәре дә һәркемгә билгеле булса кирәк. Үзбәк халкына бөек Галишир Наваи иҗатын якташыбыз профессор Габдрахман Сәгъди табып бирде. Төрекмәнстандагы беренче республика газетасына нигезне шулай ук татар кешесе — Гафуров салган. Казагыстанның һәм Урта Азия республикаларының урта һәм югары уку йортларында эшләүче татарларның саны аеруча зур. Шулар арасында күренекле тюрколог, «Идегәй» дастанының иң тулы вариантын язып алган Нигъмәт Хәким дә була. Ул Ташкентта берьюлы ике вузда — аз санлы төрки халыкларын агарту һәм үзбәк хатын-кызлары институтларында берничә фәннән сабак бирә. Гомумән, Казагыстан, Урта Азия илләрендә милли кадрлар әзерләү өлкәсендә татарлар керткән өлешнең зур икәнен

М. Әүәзов, С. Муканов, Б. Кирбабаев кебек күренекле язучылар да әйттеләр. Башкорт халкына беренче «Әлифба» китабын татар зыялысы Аюханов төзеп бирә. Башкорт мәдәниятен, әдәбиятын, жыр сәнгатен үстерүгә М. Гафури, Ш. Бабич, С. Кудаш, А. Таһиров, Ә. Вәли, Д. Исламов, С. Габәши, Н. Сабитов, Б. Гайсин, Ф. Кудашева кебек күренекле татар зыялылары искиткеч зур өлеш керттеләр. Кайбер башкорт туганнар моны «оныту» сәясәтен алып барсалар да, дөреслекне яшереп булмый.

Татарлар элекке СССРның барлык төбәкләрендә яши. Аеруча күп тупланган урыннары — Казагыстан, Урта Азия, Башкортстан, Чиләбе, Свердловск, Төмән, Кемерово, Пермь, Омск, Томск, Иркутск өлкәләре. Күрше республикаларда да милләттәшләребез яши. Егермедән артык чит илдә туганнарыбыз тормыш көтә. Кайда гына яшәмәсеннәр, башка халыклар белән дустанә көн итәләр. Кызганыч ки, телләре, тарихлары, диннәре, гадәтләре белән үзара якын татарлар белән башкортлар арасында кайбер аңлашылмаучылыклар очрый. Чынлыкта исә моңа төпле сәбәп юк. Урыс сәясәтчеләренең «суны болгатуы» гына сизелә. Хәзер бу ике республика арасында дуслык, үзара ярдәмләшү турында килешү төзелгәч, хәл уңай якка үзгәрер дигән өмет туды. Ике республика да бик зур табигый байлыкларга ия, халыклары тырыш, жирләре уңдырышлы. Бу ике халык кулга тотынышып, алга атласа, искиткеч зур уңышларга ирешәчәк. Кайберәүләр, бигрәк тә империячел даирәләр, моннардан бик курка. Аларга шатланырга мөмкинлек бирмәсәк иде.

Татар авылына барып төшүең була, сине шундук чәй эчәргә чакыралар. Ай-баена карамыйлар, алып китәләр. Мин үзем хәмер эчмим, тәмәке тартмыйм. Тәкъдим итсәләр дә, якага коймыйлар «шайтан суын». Ә күңелле гәпләшү дәвам итә. Әткәйнең сөйләгәнен әле дә хәтерлим: «Колхоз чыкканчы, кунаклашу бик таралган иде. Бу бигрәк тә кыш көннәрендә күбәя иде. Авылның бер очыннан икенче очына кошовкага атыңны жигеп, хатының белән кунакка барасың. Үзең дә, атың да бер атна кунак буласың. Шунда бик күп тормыш мәсьәләләре уртага салып тикшерелә, күпләре хәл ителә иде». Әле мин дә хәтерлим, авылга кайтуың була, сине чакырырга дип, чиратка салалар. Әнкәй үпкәләп тә ала: «Сине өйдә күреп калып та булмый»,— ди.

Татарларның кунакчыллыгы хакында Казан университеты профессоры Карл Фуксның язганнары да уйландырырлык. Ләкин нигәдер, соңгы вакытларда бу күркәм гореф-гадәт онытыла бара. Хәтта туган туган белән йөрешми. Бөтен хасиятләре — байлык туплау да, шәһәрдә яшәүче балаларына ашамлык төяп озату, оныкларына бүләк алу. Сәбәп шунда кебек: бөтен нәрсәне «файдалы-файдасыз» бизмәне белән үлчиләр.

Тәрбиягә бәйләнешле мәсьәләләр, әлбәттә, югарыда әйтелгәннәр белән генә чикләнми. Алар да, тормышның үзе кебек, иксез-чиксезләр.

Без барыбыз да — «коммунистик тәрбия» дигән илсез-жирсез, ата-анасыз тәрбия концепциясенең корбаннары. Бу өлкәдәге мәсьәләләрне өр-яңадан карап чыгасы, ул тәрбия «калыпларыннан» каттый баш тартасы, котыласы бар. Методикага тукталуымның бер сәбәбе әнә шунда.

Тәрбия турында сөйләгәндә, һәр баланың, кешенең кабатланмас шәхес, үзенә генә хас үзенчәлекле жан иясе икәнен онытмаска кирәк. Берәүгә яраган икенчегә бөтенләй бармаска мөмкин. Бу — принципиаль мөһим нәрсә. Фән, һәркемдә миллион кешенең каны бар, ди. Менә ул кайда геннар механизмының сере... Тормышта шактый еш күзәтелә торган «феномен»: бер ата-анадан туган, бер гаиләдә — микро мохиттә тәрбияләнгән балалар да төрле була. Бу нормаль күренеш һәм моның өчен куршегә шикләнеп карыйсы юк... Тик шуны онытмаска кирәк: тәрбия эшен бала тугач та башларга кирәк. Сугыш вакытында Ленинград галимнәре ата-анасыз калган ике атналык балаларны бер төркемгә жыеп, фәнчә, бөтен шартларын туры китереп тәрбия кыла башлыйлар. Бу эш сугыштан соң да дәвам итә. Нәтижә ярыйсы була. Ләкин галимнәрнең эчен бер нәрсә пошыра: арадан берсе башкалардан шактый нык аерылып тора. Сәбәпләрен эзлиләр һәм табалар да: әлеге бала төркемгә дүрт атналык булып эләккән икән, ягъни аның «тормыш тәжрибәсе» ике атнага артыграк булган!

Икенче бер мөһим як — геннар, нәселдәнлек алшартлары, сәләт, талантлар мәсьәләсе. Коммунистик тәгълимат ничек кенә боларны танымаска тырышса да, аллә нинди чаралар күрсә дә, нәсел сыйфатларын, геннарны юкка чыгарып булмый. ВКП(б) Үзәк Комитеты 1936 елның 4 июлендә «Халык мәгарифе комиссариаты системасында педалогик бозыклыклар турында» дигән карарын чыгарды һәм сәләтле балалар белән конкрет шөгыльләнүче кафедраларны юк итте. Янәсе, барлык балалар да бертөрле, нәселдәнлек, биологик башлангыч төшен-

чәсе бары юк сүз генә. Ләкин шунысы хак: балалар сәләтләре, дөресрәге, сәләт алшартлары буенча төрлеләр. Һәрбер сәламәт бала нәрсәгәдер сәләтлерәк була: оештыру эшенә, иҗат итүгә, берәр һөнәргә һ. б. Аңарда шуларның алшартлары була. Шул сәләтне үстерергә, баланың нәрсәгә омтылышы бар икәнен иртәрәк белеп, шул юнәлештә тәрбияләргә кирәк. Бу шулай ук бик мөһим. Эш шунда ки, мәсәлән, музыкага, әдәби иҗатка сәләт алшарты булмаса, күпме тырышсаң да уңышка ирешмәячәксең. Әмма шунысы үкенечле: еш кына күзәнәгенә сәләт яралгысы салынса да, уңай шартлар тудырылмау аркасында, бала тиешенчә үсми кала.

Сәләт, аның алшартлары гына түгел, темпераментны гына алсак та, балаларның ни өчен төрле булуын күзалларбыз. Вузларның «Психология» дәреслегендә мондый мисал китерелгән: холерик, сангвинник, меланхолик, флегматик дүртәүләп бер театрга барганнар, әмма спектакльгә соңга калганнар. Үзләрен ничек тотканнар соң алар? Холерик дөнья кубарып ызгыша башлаган, «Сәгатегез дөрес йөрми, мин соңга калмадым»,— дип кычкырган. Сангвинник, соңга калуын белгәч, тиз генә галеркага узган, тәнәфестән соң үз урыныма төшеп утырырмын, дигән. Флегматик тыныч кына буфетка кереп киткән, тамак туйдырып алыйм әле, ашарга өлгермәгән идем, беренче пәрдәдә барыбер әллә нәрсә булмый», дип уйлаган. Меланхолик: «Гомеремдә бер мәртәбә театрга дип чыккан идем, анда да бәхетем булмады»,— дип кәефсез генә өенә кайтып киткән.

Балаларның яшь үзенчәлеген истә тоту да мөһим. Әмма бу — аерым тукталуны таләп итә торган бик җитди мәсьәлә һәм ул — киләчәк эше. Тик шуны гына басым ясап белдерәсем килә: иң авыр, катлаулы, каршылыклы чор — яшүсмер чак (11—15 яшьләр). Бу вакытта кешене «шайтан алмаштырып куя». Әмма бу дәверне сикереп үтеп булмый. Өлкәннәргә түзәргә, үзеңнең дә шул чорны үткәрүеңне искә төшерергә кирәк.

Һәм соңгы сүз. Әгәр без, чыннан да, балаларыбызны инсафлы, кешелекле, эш сөючә шәхес итеп тәрбияләргә, үз асылыбызга кайтырга телибез икән, ислам кануннарын аякка бастырырга туры киләчәк. Чөнки татарның иң әһәмиятле, тормышчан традицияләре ислам нуры белән өретелгән.

**Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ,**
педагогия фәннәре кандидаты.

# ҮЛЕП ТЕРЕЛГӘН «ҖӘМГЫЯТЕ ХӘЙРИЯ»

Мең яшә — мең өйрән, дигәннәр. Элегрәк миңа һәрнәрсә бик аңлаешлы, яшәеш, тормыш кануннары бик ачык кебек тоела иде. Хәзер менә күп нәрсәне аңламаганмын, иң аянычы, күренеш-вакыйгаларның асыл нигезе хакында уйлап житкермәгәнмен, күп очракларда сукыр һәм чукрак булып калганмын кебек.

Әйтик, бер газетада менә мондый фикер укыдым: безнең илнең медицинасы социаль бердәмлеккә нигезләнгән: байлар фәкыйрьләр өчен, сәламәт кешеләр хасталар өчен түли.

Ә без моңа кадәр, хасталарны дәвалауны тулысынча хөкүмәт үз җилкәсенә алган, дип исәпли идек. Ә хөкүмәт соң акчаны каян ала?

Бусы хакында күбебез уйламый идек. Уйларга өйрәтелмәгән идек. Баксаң, бу бит һәрвакыт шулай булган: байлар ярлылар өчен, сәламәтләр хасталар өчен түләгән, чөнки хөкүмәткә байлыкны сәламәт кешеләр эшләп бирә, байлардан налог күбрәк алына.

Әлбәттә, бу канун бер совет хөкүмәтенә генә түгел, барлык дәүләтләргә дә хас. Хөкүмәтләр акчаны хәлле, сәламәт кешеләрдән җыялар һәм һәммә гражданнарны кайгырталар, табигый, хәлсезләр, хасталар турында күбрәк кайгыртырга туры килә.

Аерма шунда: совет хөкүмәте үзенең гражданнарына бу хакта уйланырга да, бу эшкә катнашырга да урын калдырмый иде: кешеләрдән мөмкин булганны, ә кайчакта мөмкин һәм тиеш булмаганны да каерып, кайбер чорларда хәтта талап ала һәм үзе ничек кирәк дип саный, шулай бүлә. Кешеләр үзләреннән алынган акчаның кая киткәнен белмиләр.

Әлбәттә инде, адәм баласының башы эшли, уйлары йөгерек, тир түгеп эшләп алган акчасын санаганда зиһене яхшы эшли. Гражданнарның хөкүмәттән: «Акчаларны кая куясыз?» — дип соравы бик мөмкин иде. Мондый хәл булмасын өчен, совет халкын дистә еллар буе коммунистлар партиясенә, совет хөкүмәтенә чын күңелдән бирелгәнлек рухында тәрбияләделәр, аңа һичшиксез ышанычны сеңдерделәр. Хөкүмәт һәммә кешене ашата, киендерә, торак бирә, кирәк чакта дәвалый, картайгач пенсиясен түли, дигән фикер үткәрелде, аерым кешеләр тарафыннан мескеннәргә, фәкыйрьләргә ярдәм күрсәтү, миһербанлы булу гаеп саналды.

Мондый идеология хөкүмәткә буйсынмаган, фәкать гражданнарның үзләре тарафыннан оештырылган һәртөрле игелек оешмаларына, фондларына урын калдырмый иде. 1921 елгы ачлык чорында барлыкка килгән «Помгол»ны — ягъни ачларга ярдәм итү җәмгыятен генә искә төшерик. Халыкның иң күп кырылган чорында бу җәмгыять «буржуаз, контрреволюцион» оешма буларак ябыла, житәкчеләре кулга алына. Ачларга ярдәмне хөкүмәт үзе оештыра, янәсе. Аның ничек оештырганын бик яхшы беләбез.

Хөкүмәттән бәйсез булган башка игелек оешмалары белән беррәттән татарның «Җәмгыяте хәйрия»се дә юкка чыгарылган.

Бу оешма узган гасырда ук булган. Ә бәлки ул бер генә дә булмагандыр, чөнки татарлар яшәгән күп кенә шәһәрләрдә аның изге эшләр башкаруы хакында мәгълүматлар сакланган. «Җәмгыяте хәйрия» — хәер җәмгыяте — исеменең мәгънәсенә караганда, күптөрле эшчәнлекне үз эченә ала, мохтаҗ булган картына-яшенә, хастасына, хәтта вакытлыча матди кыенлыкка дучар булган шагыйрьләргә янсә башка мәдәният әһелләренә ярдәм итә ала. «Җәмгыяте хәйрия»нең Истанбул уку йортларына татар балаларын җибәрүе хакында да мәгълүматлар бар. Һәрхәлдә, тарихчылар аның эшчәнлеген җентекләп өйрәнерләр һәм киң җәмәгатьчелекне таныштырырлар, дип өметләнәбез.

Әйе, элек оештырылган игелек җәмгыятьләре турында тулы мәгълүматлар юк, шунлыктан безгә өлкәннәр тәҗрибәсенә турыдан-туры иярү мөмкинлеге калмаган, нәкъ менә бу эштә иҗтимагый колач белән хәрәкәт итү юллары өзелгән булып чыкты. Шуны искә алып, без күңелебез кушканча, кулыбыздан килгәнчә, эшне үзебезчә башлап җибәрергә булдык.

Әйтергә кирәк, өстән кушканны гына башкарырга күнеккәнгәме, мөстәкыйль рәвештә зур эшкә алынырга өйрәнмәгәнгәме, бу җәмгыятьне торгызуга без соңарыбрак та керештек шикелле.

Моннан ике-өч ел элек, Татар иҗтимагый үзәгенең бер җыелышында бу хакта сүз кузгалган иде һәм һәммәбез дә җәмгыяте хәйрияне торгызуны хуплаган идек. Әмма бу — сүздә генә калды. Инде менә 91 нче елның ахырында Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең Президенты Марат Мөлеков мине ТИҮнең идарә утырышына чакырды. Идарә бертавыштан «Җәмгыяте хәйрия»не оештыру турында карар кабул итте.

Барыбызга да мәгълүм: яңа оешманы барлыкка китерү, аны рәсми рәвештә теркәү, аның эшен җайга салу җиңел түгел. Игелек фондларын элек тә, хәзер дә акчалы кешеләр оештыра, безнең исә кулда байлык юк иде, шулай да бу изге юлда теләктәшләр табылырына ышандык. Рәхмәт ТИҮнең актив әгъзаларына: Марат Мөлеков, Дамир Исхаков, Марс Шәмсетдинов, Рәшат Сафин «Җәмгыяте хәйрия» игелек фондының уставын төзүгә, кирәкле документларны әзерләүгә, фондны рәсмиләштерүгә күп көч куйдылар. Танылган политолог Рафаэль Хәкимов безгә киңәшләре белән зур ярдәм күрсәтте.

Мин бу оешманың беренче адымнары хакында җентекләбрәк сөйләргә телим. Хәзерге вакытта кимчелекләр турында күп сүз алып барыла, гаеп-кыекны тәнкыйтьләп йөрәк хисләребезне шактый түгәбез. Күңел каядыр омтыла, йөрәк җилкенә, көч-гайрәт күп, әмма нишләргә икәнен белмибез.

Игелек кылырга теләүчеләр дә бик күп, әмма күбесе моны ничек мәгънәле, эзлекле, колачлы итеп башкарырга икәнен белмиләр. Без «Җәмгыяте хәйрия»нең эшчәнлегенә күпләр тартылыр, район үзәкләрендә, шәһәрләрдә, авылларда аның бүлекләре ачылыр, республикадан читтә яшәүче татарлар да бүлекләр ачарлар, дип өметләнәбез. Алар өчен безнең тәҗрибәнең кирәкле булуы ихтимал.

«Җәмгыяте хәйрия» игелек фонды Татарстан юстиция министрлыгы тарафыннан 1992 елның 1 нче апреленә теркәлде. Бу — сәяси булмаган, гуманитар иҗтимагый оешма. Аның төп максаты — мохтаҗларга, фәкыйрьләргә, ялгыз картларга, ятимнәргә, күп балалы гаиләләргә ярдәм итү, яшь буынның таза-сәламәт үсүен кайгырту. Кешеләрне физик җәзалауга һәм рухи җәберләүгә каршы тору. Кыскасы: кемнең газапланганын, сызланганын, кимсетелгәнен күрсәк, без кулдан килгәнчә, мөмкин булганча, аңа ярдәм итәргә тырышабыз.

Без хөкүмәттән акча да, бина, башка берәр нәрсә дә сорамадык, бәйсез оешма буларак, һәммәсен үз кулыбыз белән башкарып, үз көчебез белән булдырырга тиеш дип саныйбыз.

Мин гомерем буе редакцияләрдә эшләдем, китаплар яздым, оештыру эшләрендә тәҗрибәм юк иде. Шуңа күрә беренче адымнарны ясау миннән шактый зур көч таләп итте һәм гомерлек истәлекләр калдырды.

Инвалидларны Корбан бәйрәме кичәсенә алып бару минем өчен аеруча тетрәндергеч бер вакыйга булды. Тәҗрибәсезлектән, белмәгәнлектән, мин моны әйләнеч юллар белән, читен итеп башкардым. Автобусны бушка бирерләрме? Инвалидларның өйләрен, билгеләнгән вакытта табарбызмы, чыгарып автобуска утырта алырбызмы? Залда аларга билгеләнгән урыннар уңайлы булырмы? Иң йөрәк түрендәгесе: аларны күргәч, кәеф кырылмасмы, күңел төшмәсме? Без бит гариплəрне күрмәскә тырышып яшибез, күз карашыбызны сәламәт, чибәрләргә юнәлтергә күнеккәнбез.

Күп йөгерергә туры килде. Инде моның очына чыксам, бүтәненә тотынмам, дигән чакларым да булды. Ләкин концерттан кайтканнан соң, горурлык һәм шатлык белән: «Мин «Җәмгыяте хәйрия» эше белән шөгыльләнәчәкмен!» — дип, үз-үземә сүз бирдем.

Бу кичтә мин үзем өчен күп ачышлар ясадым. Беренчедән, яхшы кешеләр бик күп икән. Без бит, дөньяны юньсез бәндәләр баскан, дигәнне күп ишетәбез. Баксаң, күпләр, мөмкин булганда, яхшылык кылырга омтыла икән. Начальникларның кабинет ишек төпләрендә утырган секретарьлар, гадәттә, бик төксе кыланалар, әмма минем нинди эш белән йөргәнне белгәч, йөзләре ачыла, карашлары җылына, нинди ярдәм кирәк, дип кенә торалар. «Татавтотранс» берләшмәсе, берсүзсез, менә дигән автобусны түләүсез бирде, генераль директорның урынбасары Ринат Риязович Гыйләҗев: «Мондый эшләрдә без сезгә кулдан килгән ярдәмне һәрвакыт күрсәтәчәкбез», — диде.

Автобусның шоферы да инвалидларга җайлырак булсын өчен тырышты. Мәдәният министрлыгы, залдагы беренче рәт алдына махсус урындыклар тезеп, безнең кунакларны шунда утыртты. Министр урынбасары Лилия Нарбекова үзе бу эшне оештырып йөрде: «Сезгә җайлымы, уңайлымы?» — дип, кырык эшен калдырып торып, безне үзе урнаштырып йөрде. Татарстан халык депутаты Фәндәс Сафиуллин хәлебезне белеште. Концертның режиссеры Лима Кустабаева алдан ук Корбан бәйрәменә багышланган бу кичәдә аерым игътибарга мохтаҗ кешеләрнең

булуын теләгән иде. Корбан бәйрәме — хәер бирү, корбан чалып башкаларны сыйлый торган көн бит. Артистлар, сәхнәдән төшеп, алдагы рәтләрдә утырганнарны чәкчәкләр белән сыйлап йөрделәр.

Тәнәфес вакытында берничә ир кеше янына килеп: «Мәдинә ханым, без Сезгә ярдәм итәрбез, күтәрешеп тә чагарырбыз, әйтегез генә»,— диделәр.

Әйе, күнелләрдә яхшылык кылуга омтылыш сакланган, тик безнең гадәти яшәешебездә аларга урын гына аз калган икән.

Икенче нәтиҗә шул булды: инвалидларга кызганып түгел, үз тиңең итеп карарга кирәк! Автобус иркен булып, күп кешене сыйдыра алса да, инвалидларны өйләреннән чыгарып утырту озакка сузыла, шуңа күрә без алдан ук күп кеше чакырырга уйламадык: әгәр алай итсәк, алдан чыгып утырганнары ялыгып бетәчәк иде. Ленин районыннан үзара таныш кешеләр җыелды. Сез күрсәгез иде аларның бер-берсе белән ничек сөенешеп күрешкәннәрен?! Алар елмаялар, куаналар һәм... үзләрен кызгануга бернинди урын да калдырмыйлар. Бик кыенлык белән генә йөри алганнары да йөгереп килеп култык асларыннан тотканны яратмый: «Үзем, үзем!» — генә дип торалар. Коляскада калтырап утырган үсмерләрне, аягын көчкә-көчкә шудырган кызны, ике култык таяклы чибәр йөзле хатынны беренче күрүгә җанны моң баса, әмма бу хис тиз үтә, алар белән ачылып сөйләшә торгач, күңел күтәрелә бара, үзең дә яшәүнең кадерен ныграк белә башлыйсың.

Өченче нәтиҗә — безнең көнкүреш шартлары гарип-гораба, хасталар өчен бөтенләй көйләнмәгән. Элек уйламый идем, хәзер еш искә төшә: менә бит, дим, урамнарда коляска белән йөрүчеләргә ничек җайсыздыр: юлны аркылы чыгар өчен генә дә ничә киртәне үтәргә кирәк; тротуар кырыйлары шундый биек итеп ясалган! Менә-төшә торган урыннарда — баскыч та баскыч, сөзәк кенә юлы һичкайда юк! Йортларның ишекләреннән коляска белән кереп-чыгып карагыз! Хәтта лифт ишекләренә дә коляска үтәрлек түгел! Ә инде театр залларының керү-чыгу урыннары алар өчен нинди җайсыз!

«Коляска» дигәннән. Аларның да рәтләләрен безнең илдә ясаучы юк икән. Әледән-әле газеталарда, фәлән инвалидка чит илдән коляска җибәргәннәр, рәхмәт төшсен, дигән сүзләрне укып торабыз. Әгәр дә бөтен илебез белән шулай бәрәнсәрәнләп бирелгән хәергә карап торсак, безнең аксак-чатаннарыбыз урамнарга ничек чыга алыр икән? Аннары, уңайлы коляска өйдә дә бик кирәк бит әле ул.

Әйе, без тумыштанмы, тормыштамы аяксыз-кулсыз калган, кеше ярдәменә даими мохтаҗ булган ватандашларыбызны өйдә бикләнеп яшәргә дучар иттек, аларны күрмәскә күнектек. Бездә гарип-гораба бөтенләй юк та кебек иде. Чит илләргә барсаң, инвалидларны еш очратасың. Урамнарда, музейларда, театрларда үз җайларына йөри бирәләр. Коляскалары җиңел-җайлы, баскычлардан менеп-төшәрлек, юллар салганда да, йортлар төзегәндә дә, аларны онытмаганнар: һәркайда сөзәк юллар, иркен ишекле лифтлар, хәтта алар өчен аерым бәдрәфләр көйләнгән...

Шуны уйладым: әгәр игелек кылу эшенә күбрәк халык җәлеп ителсә, әйтик, шул ук архитекторлар, шәһәрләрне планлаштыручылар, төзүчеләр, театр, цирк, филармония артистлары еш рак катнашса, алар, төп эшләрен башкарганда, инвалидларны онытмаслар иде, мөгаен.

Әлбәттә, мохтаҗларны кайгырту, концертка алып бару — мин башлаган эш түгел. Инвалидлар җәмгыяте, социаль яклау органнары, профсоюз оешмалары, төрле зур заводларның җитәкчеләре аларны даими кайгырталар, концертларга да алып баралар, елларын да оештыралар. Хикмәт шунда: без — монарчы бу эшкә бөтенләй катнашмаганнарны тартырга, ярдәмгә мохтаҗларның хәленә күбрәк халыкның күзен ачарга тырышабыз. Бу — мохтаҗлар өчен генә түгел, ярдәм итүчеләрнең үзләре өчен дә бик кирәк, чөнки яхшылык кылу күңелләрне сафландыра, тормышка якты мөнәсәбәт тудыра.

Безгә беренче адымнарыбыздан ук ярдәм итүчеләр күп булды. Мин инде, яхшылык җирдә ятмасын өчен, аларның исемнәрен халыкка җиткереп бару тиеш, дип уйлаган идем. Әмма моның өчен озын-озын исемлекләр төзергә кирәк булачак икән. Алар, билгеле, безнең фондта теркәлеп бара, бер исем дә онытылмаячак, әмма бер мәкаләдә һәммәсен санап китү мөмкин түгел. Шулай да иң беренче игелек кылучыларны атап китим әле.

«Җәмгыяте хәйрия»нең исемлегендә беренче игелек кылучы — рәссам Зифа Мөхәммәтҗанова. Ул фондның эмблемасын ясап бирде — беренче взносны хезмәте белән кертте. Эмблемада — яшел җирлектә кызыл ярымай һәм ак лалә чәчәге тасвирлана. Яшел төс — мәңгелек яшәешне, кызыл ай — сүнмәс өметне, ак лалә — тормышның яңарып торуын аңлата. Болар — Татарстаныбызның дәүләт флагы төсләре. Талантлы, тәҗрибәле рәссам җәмгыятебезнең тамгасын бик матур итеп ясады, аны иң алдынгы илләрнең вәкилләренә дә горурланып күрсәтергә була.

Фондка иң беренче булып акча керткән кешеләргә дә рәхмәтләр әйтик: болар — Казанның йон эшкәртү фабрикасы директоры Әгъмәлетдин Шәйхетдинович Шәрәфетдинов һәм Чаллы бизнесменнары, бертуган Рәфис һәм Нәфис Кашаповлар булды. Шулар биргән акчага без оешмабызны аякка бастырдык һәм Төркиядән Уфага килгән гуманитар ярдәмне, Казанга кайтарып, мохтажларга өләштек.

Бу эш мөфти Тәлгать Таҗетдин аша эшләнде.

Чит илләрдән китерелгән ярдәмне алу һәм өләшүнең үз хикмәтләре бар — анысын да әйтеп китик. Совет илендә намуссызлык, ялган, урлашу тамыр җәйгән, чит илләрдән җибәрелгән ярдәм мохтаҗларга бирелми, байларның кесәсен калынайтуга китә, дигән хәбәр бөтен дөньяга таралган инде. Шуңа күрә чит ил оешмалары ярдәмне бик ышанычлы кулларга гына бирергә телиләр. Алар алдан ук бездән исемлек сорап алдылар. Исемлеккә татарлар кертелсен, дигән шарт та куелган иде, чөнки бу ярдәм — мөселманнарның сәдакасы, диделәр.

Әлбәттә, дәүләт оешмалары мохтаҗларны диненә, милләтенә карап бүлеп эш йөртә алмыйлар. Дәүләт каршында һәммә гражданнар тигез хокуклы һәм аларның барысы да тигез кайгыртуга лаек. Без исә, бәйсез җәмәгать оешмасы буларак, игелек кылучыларның теләген искә алабыз һәм бөтен шартларын үтибез. Без меңнән артык татарның исемлеген төзеп җибәрдек, аларның һәркайсына анкеталар тутырдык. Уфадан Казанга йөк кайтарту бик кыйбатка төшәчәк иде. Рәхмәт яусын «Татавтотранс»ка, алар безгә машина бирделәр. Һәм без биш тоннадан артык он, ике тоннага якын дөге һәм бер тоннадан артык үсемлек мае кайтарып, аны Казанда мең ярымлап кешегә өләшә алдык. Үзебез генә булдыра алмас идек. Безгә социальтәэминат бүлекләре ярдәм итте, Киров районында бу эшне — Рамазан мәчете, Ленин районында инвалидлар җәмгыяте башкарды.

Юл уңаенда «Татхлебопродукты» берләшмәсенә рәхмәтләр әйтеп үтәргә кирәк: он зур капчыклар белән кайткан иде, шушы берләшмә аны икешәр кило итеп кәгазь капчыкларга тутырып бирде, бездән, фәкыйрьләр өлешеннән, бер тиен дә сорамады.

Меңәрләгән кешегә ярдәм өләшү җиңел түгел икән. Бигрәк тә ул алтышар, җидешәр кило булса. Сумка күтәреп, биек баскычларда шактый йөрелде. Әмма, бер рәхмәт мең бәладән коткара, дигәннәр бит. Күңелнең хушлануы барысын да оныттыра. Күз яшьләре белән укылган догаларны, килгән хатларны искә төшерсәң, әле дә җан жылына.

Дөрес, кырын карашлар сизәргә дә, яман сүзләр ишетергә дә туры килде. «Сез нигә бу ярдәмне татарларга гына өләшәсез, милли ызгыш-сугыш чыгарасыгыз киләме әллә?» — диючеләр дә булды. Мәсьәләне бик катгый рәвештә: «Яки һәммә кешегә бирегез, яки бу эш бөтенләй тыелсын!» — дип куярга маташучылар да булмады түгел.

Бусы инде — безнең совет тәрбиясеннән килгән караш. Бөтенесен тигезләргә маташу. Җитмеш ел тигезләргә тырыштык, күпме башлар кырылды, әмма тигезләп бетереп булмады бит! Безнең — хәер җәмгыятенең максаты — һич тә тигезләү түгел. Безнең максат — кулдан килгәнчә, мөмкин булганча, мохтаҗларга ярдәм күрсәтү. Кемгә кулыбыз җитсә шуңа. Мәчет капкасы төбендә хәер эстәүчеләр тезелешеп утыра, әмма аларның бөтенесенә тигезләп кем генә акча өләшә ала соң? Узгынчы кемгәдер бирә, калганнары икенче узгынчы килгәнне көтеп кала. Безнең эш тә шуңа охшашрак.

Безгә асылда хәер бирергә теләүчеләр үзләре тиеш дип санаганны китерәләр һәм еш кына, шушындыйрак адәмгә бирегез, дип, теләк белдерәләр. Без алар китергәнне рәхмәт укып алабыз һәм бу хәерне нәкъ алар теләгән кешегә тапшырырга тырышабыз.

Әйтик, быел безнең якта алма бик уңды. Бер ханым җир тутырып коелган алмаларга карап күрсенә: «Их, шуны ятим балаларга илтеп бирүче булсын иде!» — ди. «Безнең андый оешмабыз бар! — дим мин. — Бирсәгез, алып китәм, ятимнәргә өләшәм...»

Шулай эшлибез дә. Ятим, ярым-ятим һәм зәгыйфь балалар укый торган мәктәптә бу күчтәнәчне искиткеч куанып кабул иттеләр. Мин директорга алма иясенең адресын, телефонын да бирдем. Балалар ул апага рәхмәтләрен белдереп, рәсемнәр ясап, хат язып җибәрәләр, концертка чакыралар. Шул рәвешле ике якның да рухына күпме яхшылык иңә!

Менә киемнәр китерәләр: «Әчкечегә бирә күрмәгез, чиста күңелле, дога укый торган кешегә эләксен иде!» — диләр. Без бу шартны да үтибез. Нәрсәнең кемнән алынып, кемгә бирелгәне бәйнә-бәйнә теркәлеп бара.

Быел беренче октябрьдә халыкара өлкәннәр көне үткәрелде. Безнең бакчабыздан бу көнгә ярты центнер алма җыеп бирделәр. Күп түгел, әмма ул ике дистәдән

артык кешене сөендерергә житте. Алма иярләре: «Русны, татарны аермагыз, сөенеп кабул итәрдәй кешеләргә бирегез!» — дигәннәр иде. Мохтаж өлкәннәрнең исемлеген собестан алдык, булдыра алганча, рәттән өләштек. Әлбәттә, бер алма гына күтәреп бармадык, кибеттән сөт, кефир, булкалар алып кердек. Зөләйха Газизова, мәсәлән, үзе дә пенсионер, алмадан ике бәлеш пешереп бирде: «Миннән дә бер өлеш керсен!» — диде. Кием китерүчеләр дә булды. Шулай итеп, үзебез бара алган кешеләрнең мең рәхмәтләрен ишеттек.

Хәзергә әле без менә шулай кечкенә генә эшләр башкарып куанабыз. Бер мәктәптә укучы өч дистәгә якын мохтаж балага кышкы аяк киеме алып бирүгә ирештек. Бер инвалидның караваты юк икән, идәндә ята иде, аңа урын алып бирдек. Бер инвалид больницада ятканда, ут чыгып, киемнәре янып беткән. Аны бер кат киендердек, хәтта яхшы гына тышлы тун да бирдек.

Без инде тотылган кием-салымнар да кабул итәбез, өйләрдән дә барып алабыз, юабыз, ямыйбыз, химик чистартабыз. Аннары мохтаҗларга түләүсез бирәбез. Кайберәүләр, балама фәлән үлчәмдәге кием кирәк иде, инвалид күршебезгә чалбар кирәк иде, дип мөрәҗәгать итәләр. Аларга кирәкне эзлибез.

Әлбәттә, моның ише вак-төяк белән генә халыкның хәлен яхшыртып булмый, диючеләр булыр. Һәм, минемчә, алар хаклы түгел. Беренчедән, без әле эшне башлап кына җибәрәбез. Шушы шөгыльне яраткан, күңел белән башкарган, шуннан тәм тапкан кешеләрне эзлибез һәм табабыз. Уйлап карасаң, андыйлар бездә сирәк калды бит инде. Бер тапкыр изгелек кылучылар күп, ә менә даими аның белән шөгыльләнүчеләрне, шуны үзенең һөнәре итеп сайлаучыларны табып карагыз. Без моңарчы моңа өйрәтелмәгәнбез, яшь буынны да шәфкать кылырга күнектермибез. «Кешене кызганырга ярамый, кызгану кимсетә!» — дигән принцип канга нык сеңдерелгән. Әле дә ярый, күңелләрдә табигый изгелек бетмәгән, бетәчәк тә түгел икән!

Безнең төп максат — күңелләрне сафландыру, изгелек кылырга омтылышны күбрәк кешеләрнең, бигрәк тә яшьләрнең күңелендә куzгату.

Иманым камил, без андыйларны табарбыз. «Җәмгыяте хәйрия»нең бүлекләре һәркайда ачылыр, даими эшләп торыр. Мондый оешмалар хәзер дә бер без генә түгел, киләчәктә алар тагын да күбәер. Без — җөмләдән берсе һәм, ышанам ки, арада көчлесе, абруйлысы булырбыз. Татарның да, Кызыл Ай, Кызыл Хач оешмалары кебек, бөтен дөньяга танылган игелек оешмасы булырга тиештер бит! Һәм ул булыр. Ул безнең җөмһүриятебездә генә түгел, фаҗигаларга дучар булган башка — бүтән мәмләкәт кешеләренә дә ашыгыч ярдәм күрсәтә алыр.

Безнең киләчәккә планнарыбыз зур. Кичекмәстән үз ашханәбез, кибетебез булырга тиеш дип саныйбыз. Колхоз-совхозлар, аерым хуҗалыклар үзләре үстергән уңыштан фәкыйрьләргә өлеш чыгара алырлар, мөгаен. Борын-борыннан халыкта шундый тәртип булган бит. Без игелек иярләре биргән он, ярма, яшелчә, итмайны алып, кадерләп саклап, аннан фәкыйрьләр өчен арзанлы яисә түләүсез ризыклар пешерә алыр идек. Америка кебек бай илләрдә дә ач-мохтаҗларга урамда ризык өләшү гадәткә кергән. Бездә дә ул булырга тиеш.

Киләчәктә безнең үз шифаханәбез ачылыр, дип саныйбыз. Медицина ярдәме түләүлегә әйләнә бара һәм ул бик кыйммәт булачак. Фәкыйрьләрне, хәлсезләрне ярдәмсез калдырмау — шулай ук безнең җәмгыятьнең бурычы. Без үзебезчәң ятимнәр йортын булдыру хакында да хыялланабыз. Ул — ятимнәр өчен туган йорт кебек булсын иде, анда кеше туганнан алып, бәлигъ булганчы яшәсен, үз теләге белән, мөмкинлек булгач кына, чыгып китсен иде! Югыйсә бит дәүләтнең балалар йортларында аларны күчереп йөртәләр: өч яшькәчә сабыйлар йортында, аннары интернатка, балалар йортына, урта мәктәпне бетерүгә... урамга! Дүрт ягың кыйбла, янәсе, өлгергәнлек аттестаты алдың! Ул яшьтә кем үз баласын өеннән куып чыгара?! Шуның аркасында күпме ятимнәр кыек юлга кереп китә, харап була!

Без аларны бу бәхетсезлектән мөмкин кадәр сакларга тырышыр идек.

«Җәмгыяте хәйрия»нең картлар йорты да булырга тиеш. Франциягә баргач, безгә бер йорт күрсәткәннәр иде. Картлар йорты. Шәһәрнең матур урамына урнашкан олы йорт. Анда һәр кешегә аерым җыйнак квартир: бүлмәсе, кечкенә аш бүлмәсе, юыну урыны бар. Аскы катта ашханә, зал, медпункт, кер юу урыны. Үзен карый алмаганнарның махсус тәрбиячесе бар.

Татар халкы үзенең өлкәннәрен французлардан ким карарга тиешме әллә? Без дә ата-аналарыбызны, абый-апаларыбызны ихтирам итә беләбез. Борын-борыннан татар өендә өлкәннәрнең урыны түрдә булган. Хәзер генә ул анасына кул күтәрүчеләр, ата-анасын куып чыгаручылар күренә башлады. Мондый хәлгә чик куелырга, ата-ананы хөрмәтләмәү хурлык саналырга тиеш. Шулай да бездә ятим карткарчыклар бар, балалары инвалид булганнар бар. Менә шундыйлар өчен бездә Франциядәгедән дә шәбрәк йортлар кирәк.

Тагын бер үзәк өзгеч мәсьәлә: терелмәс хасталар, үлем көтеп ятучылар бар бит әле. Алар янында даими кеше булу кирәк, дәвалау өчен генә түгел, җан газапларын җиңеләйтү өчен дә. Алдынгы илләрдә андыйлар өчен махсус пансионатлар — хоспислар төзелә. Бездә дә ул булыр, без моның өчен дә тырышачакбыз.

Кайберәүләр, боларны укыгач, бу кеше булмас нәрсәләр хакында хыялланып йөри икән, дип уйлар, бәлки. Әмма мин язганнар — дөньяда бар нәрсә. Дөрес, алар — алга киткән, бай илләрдә. Әмма безнең Татарстаныбыз да алга китәчәк бит, безнең моңа иманыбыз камил! Үз байлыгыбызга хуҗа гына булыйк, җөмһүриятебездә тынычлыкны, иминлекне, татулыкны гына саклыйк. Иншалла баербыз!

Дәүләтнең байлыгы аерым кешеләрнең байлыгына нигезләнә, хәзер инде без гражданнары хәерче булган дәүләтнең бай булмаганына ышандык. Бездә әлегә кешеләргә баерга ирек бирмиләр, Россия законнары нигезендә җыела торган хисапсыз-сансыз салымнар баш калкыткан һәр кешене бөлдерә тора. Ләкин һәрвакыт алай булмас, салым-налоглар чама белән җыела башлар. Унган, зирәк, эшлекле кешеләргә баерга мөмкинлек туар. Алар игелекне дәүләт казнасы аша гына түгел, үз куллары белән, конкрет эшләр белән башкарырга теләрләр. Элек шулай булган бит ул. Байлар шифаханәләр төзегән — Казандагы Шамский больницасы инде ничә буынга хезмәт итә! Хәзерге заманда үсеп килгән татар эшлеклеләре дә Шамовлардан, Акчуриннардан ким булмас, алар киләчәккә калырдай изгелекләр башкарырлар, дип ышанабыз. Һәм безнең «Җәмгыяте хәйрия» аларга ярдәмче булыр. Моның өчен безгә үзебезнең ышанычлы, намуслы, эшлекле оешма икәнлегебезне исбат итәргә кирәк.

Мин бу мәкаләне 1992 елның октябрь ае ахырында язам. Ул журналда басылып чыкканчы берничә ай узар, без дә шактый яңа эшләр башкарган булырбыз, активистларыбыз артыр, төрле урыннарда яңа бүлекләребез ачылыр.

Без татарның көчле җәмәгать оешмасына әверелү юлында күпмедер алга киткән булырбыз. Уйлап карасаң, гаҗәп бит: безнең җөмһүриятебездә моңа кадәр иң көчле игелек оешмасы булып Кызыл Хач җәмгыяте саналды. Мәктәптә укыган чакта ук әниләр биргән акчадан күпмедер тиеннәрне шушы оешмага взнос итеп түләгәнебезне әле дә хәтерлибез. Яхшы оешма, бик күп игелекләр кылды. Аның тамгасы — Кызыл Хач, ягъни кызыл тәре, җитәкчеләре Мәскәүдә булды. Уйлап карыйк әле: ни өчен Татарстанда төп игелек җәмгыяте — Кызыл Хач — кызыл тәре оешмасы булырга тиеш? Гарәп илләрендә, Төркиядә, ягъни мөселманнарда, мондый оешма — Кызыл Ай җәмгыяте бит! Әгәр без үзебезне алга киткән миллә дип саныйбыз икән, әгәр Җөмһүриятебезнең мөстәкыйль дәүләтләр рәтендә булуын телибез икән — безнең үзебезнең көчле, хәлле, абруйлы Кызыл Ай оешмабыз булырга тиеш. Ул оешма без булачакбыз, безнең тамгабыз — Кызыл Ай.

Бу һич тә, безнең җәмгыять — мөселманнар өчен генә, дигән сүз түгел. Мохтаҗ булган һәркемгә ярдәм кулы сузачакбыз, тик Байрагыбызда, киемнәребездә, медицина коралларында Кызыл тәре түгел, Кызыл Ай сурәте булыр.

Дөрес, игелек оешмалары — дини оешмалар түгел. Әмма Кызыл Хач белән Кызыл Ай җәмгыятьләренең тамырлары дини оешмаларга барып тоташа. Безнең Татарстанда ашыгыч ярдәм күрсәтү машиналары Кызыл тәре тамгасы белән йөри, медицина пунктларына, җиһазларына да шул ук тамга сугылган. Без моңа шулкадәр күнеккәнбез, күрмибез дә кебек. Ә бит уйлап карасаң, тетрәнеп китәрлек: ни өчен әле Газраил белән тартышып яткан мөселман янына ашыккан табиплар Кызыл тәре балкытып килергә тиеш?! Бу — татарны ихтирам итмәүнең, аны рәнҗетүнең мисалы түгелме?!

Безнең җәмгыять — кешенең рухын кимсетүгә каршы чыгуны үзенең бурычы итеп куя. Без Татарстан сәламәтлек саклау министрлыгына, Кызыл Хач тамгасы янына Кызыл Ай сурәте куюны таләп итеп мөрәҗәгать җибәргән идек. Ике ай үтте, әле җавап килгәне юк, ә машиналардагы тамгалар — һаман шул ук.

Без — сәяси оешма түгел, дип әйткән идем инде. Әмма кешеләрне җәберләүдән, имгәнүдән, һәлакәттән саклау өчен кирәк булганда, без хокук органнарына, төрле җитәкчеләргә мөрәҗәгать белән чыгарга хокуклы. Әйтик, безнең Татарстан судлары тарафыннан иреганнән мәхрүм ителгән гражданнарыбызның күпчелеге Татарстаннан читкә, Россия колонияләренә озатыла. Әйтегез әле, кайсы мөстәкыйль дәүләт үзенең җинаятьчеләрен башка ил төрмәләренә җибәрә?! Дәүләт өчен моннан да хурлыклы тагын ни бар? Төрмәләре нинди диген әле — Россия колонияләрендә ябылуда булганнар җинаятьнең яңадан-яңа төрләренә өйрәнеп, сәламәтлекләрен бетереп, кешелек сыйфатларын тәмам югалтып чыгалар. Һәм, кире Татарстанга кайткач, яңа көч, яңа осталык белән җинаять кылырга керешәләр.

Без Татарстан Югары Советына үзебездә хөкем ителгән гражданнарны Татарстанда ябып асрау кирәклеге турында мөрәҗәгать иттек.

Әйтергә кирәк, безнең бу эшебез кайберәүләрнең күнеленә хуш килмәде. Беренче чиратта, ябылу урыннарының житәкчеләре моны хупламады. Аларның бәгъзеләре безгә ристаннарның хәлен яхшыртудан бигрәк урамда хәер торучыларның хәлен яхшырту турында кайгыртырга киңәш иттеләр. Ә ристаннарны ерак-карак озату хәерле, имеш... Аларны бөтенләй кырып барсаң да зыян булмас иде, янәсе... Суд каршына баскан һәркемне чыгарып атасың да, вәссәләм, имеш! Асулар да, кисүләр дә чутсыз-чамасыз булды бит инде совет илендә, әмма жинаятьчелек буенча дөнья рекордларын куябыз! Димәк, һәр жинаятьчене үтереп яисә төрмә-колонияләрдә төрлечә мыскыллап кына мәсьәлә хәл ителми! Тәрбияләргә туры килә! Россиянең үз кайгы-мәшәкатьләре баштан ашкан, без юлдан язган ул-кызларыбызны үзебез тәрбияләргә мәҗбүрбез. Шунсыз без жинаятьчелекне киметә алмабыздыр.

Әйе, игелек кылам дигәннәрне дә гел мактап, хуплап кына тормыйлар. Кайбер очракларда ишек төбенә дә якын китермиләр. «Хәерчедән күп нәрсә юк, акча сораучылар хисапсыз!» — дип өзеп куйган очраклар да була. Безнең бу шөгылебез кайберәүләрнең чын йөзен ачарга да бик яхшы мөмкинлек бирә икән. Безнең соңгы елларда бик күтәрелгән, властька омтылган, мактанган һәм макталган «лидер»ларыбыз бар. Мин инде, эшне башлап җибәрүгә, алар ярдәм кулы сузар, бәлки, дип өметләнгән идем. Шундый өмет белән Казан тәмәке фабрикасы директоры Бариевка телефоннан шалтыраттым. Язучы һәм «Җәмгыяте хәйрия»нең рәисе икәнлегемне әйттем, мин сезне трибуналарда күрәм, бик актив житәкче икәнсез, милли хәрәкәткә ярдәм итәсез, дидем. Аны Татарстан премьер-министры булырга теләге бар, дигәнне дә ишеткән идем.

Очрашу вакытын билгеләдек, киттем мин тәмәке фабрикасына. Үзем белән «Җәмгыяте хәйрия»нең документларын, ярдәмгә мохтаж мең кешенең исемлеген, зарланып язган хатларны алдым. Капка төбеннән үк рөхсәт белән керергә кирәк икән. Аннан шалтыраттым, килдем, дидем. Ярый, сезне кертерләр, диде бу. Ишек алды аша узып, кабинет ишеге төбенә барып җиттем. «Директор әле генә ашарга кереп китте, көтеп утырыгыз», — диде миңа секретарь. Димәк, булачак премьер-министр Бариев ашаганчы, язучы Маликова аның ишек төбен саклап утырырга тиеш!

Мин утыз ел журналист булып эшләдем. Беркайчан да, бернинди министрның да, премьер-министрның да мине болай кимсеткәне юк иде. Әгәр Җөмһүриятнең башына менеп утырса, бу адәм бөтен халыкны шулай ук ишек төбен сакларга мәҗбүр итмәсме? Номенклатурный житәкчеләрне хурлыйбыз, әмма алар арасында минем гомердә мондый тәрбиясез бәндәне күргәнем булмады.

Беренче президентыбызны сайлаганда Камил Шәйдәров исеме бик танылган иде. Ул үзенең кандидатурасын Минтимер Шәймиевка көндәш итеп куярга тырышкан иде. Әле хәзер дә матбугатта шаулый, мин Татарстанның Президенты булачакмын, дип яза. Алла сакласын! Һәр гаепләне нык җәзаларга, хәтта юк итәргә кирәк, дигән фикерне ул бик алга сөрә. Андый юлга бассак, Президентыбызның карашы шундый булса, без канлы, шәфкатьсез дәүләткә әвереләчәкбез икән. Өстәвенә бу адәмдә тупаслык, кешенең сүзен тыңлый белмәү, татарның нәрсә икәнен аңламау — баштан ашкан.

Әйе, яхшылык күп, әмма каршы чыгучылар да очрый. Һәрхәлдә, безнең эшебезгә кушылырга теләүчеләр, гел макталып, рәхмәтләр ишетеп кенә яшәрбез, дип өметләнмәсеннәр. Шулай да бу хәл шәфкать иялярен куркытмас, дип уйлыйм.

Авылларда, шәһәрләрдә, заводларда, предприятиеләрдә безгә теләктәш кешеләр табылыр. Без киләчәктә имезлек сораган сабый кебек авыз ачып, хөкүмәт күзенә мөлдерәп карап кына яши алмаячакбыз. Һәр егылганны хөкүмәт күтәреп ала алмый, һәр сабыйның башыннан хөкүмәт сыйпый алмый, җан биргән һәркемнең күзен дә ул йомдырып йөри алмый. Мин бер китапта, мохтажга, гарипкә ярдәм итә башлагач кына, көчсезләрне көчлеләр ашата башлагач кына, маймыл кешегә әйләнгән, дигән фикер укыдым. Бу чыннан да дөрес бит: кешелеклелек — ярдәмчеллек, миһырбанлы, шәфкатьле булу дигәнне аңлата. Җәмгыять шунсыз алга китә алмый.

Игелек кылуны исә, башка яхшы эшләрне башкаргандагыча бергәләп, оешып, киңәшеп үтәү улай. Безнең хәрәкәткә кушылырга теләүчеләргә, кирәкле ярдәмне күрсәтергә, уставның нөсхәсен җибәрергә, тиешле документлар белән тәэмин итәргә, даими элемтәдә торырга, тәҗрибә уртаклашырга һәрвакыт әзербез. Изге күңелле кешеләрдән хатлар көтәбез. Адресыбыз: **Казан шәһәре, Лобачевский урамындагы 6/27 нче йорт, Татар иҗтимагый үзәге.**

Дискуссия дәвам итә:

*БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ. БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ.*

**Фәрит Хатипов**

# МӨЛКӘТЕБЕЗНЕ БАРЛАГАНДА...

Соңгы елларда безнең караш бераз киңәеп, тирәнәеп киткәндәй булды. Әйтерсең лә озак вакытлар буена каплап, томалап торган элпә, яры ниндидер могҗиза тәэсире белән кубып төште дә, без күзебезне киң итеп ачып җибәрдек һәм дөньяны үз төсе, чын кыяфәте белән күрә башладык. Тормыш дигән хикмәтнең серләренә тирәнрәк, колачлырак төшенү мөмкинлеге пәйда булды.

Бу хәл, табигый ки, бүгенгене, үткәнебезне, шул җөмләдән әдәби мирасны яңача бәяләү, аңлату ихтыяҗын тудырды. Матбугатта инде бу хакта кыю гына фикерләр дә күзгә чалына башлады. Боларда бәя, мөнәсәбәтләрдәге элеккеге берьяклы үлчәмнәрнең яраксызлыгы бик дөрес күрсәтелә. Ә шуларның кайсысы яраклы һәм кулай соң? Без әле моңа җавап табу юнәлешендәге эзләнүләрнең башланып китү ноктасында гына торабыздыр. Шуңа күрә берьюлы иң тулы, төгәл хакыйкатьне төбенә кадәр ачып салырга тырышу бик үк урынлы да булып бетмәс кебек. Ул җентекләп өйрәнүне, гадел нәтиҗәләр ясауны сорый, фикерләр чарпылышын кирәк саный.

Кайбер мөхтәрәм авторлар исә мәсьәләне ничектер гади, ансат юл белән генә хәл итмәкче булалар. Ягъни совет чоры тарихының аеруча каршылыклы, чәбәләнгән этапларын чагылдыручы әсәрләрне, кара мөһер сугып, бүгенге яшәешебездән төшереп калдырырга, сызып ташларга киңәш итәләр. Тагын шунысы да бар: түбән сыйфатлы, йомшак әсәрләр һаман да җил-яңгыр күрми тыныч кына ята бирәләр, кырыс караш гүзәл әсәрләргә төбәлә. Гаделме мондый мөнәсәбәт?

Иң элек мондый тәкъдимнәрнең бик үк яңа булмаганлыгын искә төшереп үтәсе килә. Хәтерлик: егерменче еллар башында футуристлар, пролеткультчылар да, тар сыйнфый каланчадан гына карап, бик җитди, сәнгатьчә камил мирастан баш тартырга өндәгәннәр иде! Әгәр дә шулчакта җәмгыять, аек акылга колак салмыйча, мәдәни мөлкәтне тузгыту, һәм эстетик репрессия коткысына бирелгән булса, без, гүзәл сәнгать үрнәкләреннән мәхрүм ителгән хәлдә, дөнья халыклары арасында рухи җәһәттән иң фәкыйрьләре булып калыр идек, әдәби үсешебез тагын да ныграк тоткарланган булыр иде. Совет чорында милли мәдәниятебез башыннан афәтләр болай да аз кичмәде. Алфавитыбыздан аерылып, тоташ надан халыкка әйләндек, мең еллык язма, басма мирасыбызны укый алмаслык хәлгә килдек. Күпме әдипләребезнең иҗаты дисталәгән еллар буена ябылу астында ятты. Тыелу сәбәпле хәятебезнең, тарихыбызның бик мөһим яклары яктыртылмый торды.

Җәмгыять белән бергә, совет эстетикасы да үз юлында байтак хаталар, ялгышлар ясады. Ләкин, шулай булган хәлдә дә, бу урында аның бик җитди бер саваплы гамәлен әйтми үтү мөмкин түгел — ул кадерле мәдәни мирасны нигездә саклап калды, милләтләрне рухи бөлгенлеккә төшүдән коткарды. Бүген без тарихның бу сабагыннан гыйбрәт алырга бурычлы.

Соң шулай да совет чорындагы үтә каршылыклы, чуалчык хәлләрне тасвирлаган әсәрләр хәзер төсләрен җуймадылармы, уңып, тоныкланып калмадылармы? Монда шунысын әйтергә кирәк: иң әүвәл берьюлы бөтен әдәбият турында хөкем йөртү мөмкин түгел. Икенчедән, төгәл караш булсын өчен, һәр әсәрне

бүгенге аң яктылыгына тотып кабат укып чыгу сорала. Әлегә мин аеруча күп бәхәсләр куптарган әсәрләргә — күмәкләштерү хакындагы роман, повестьларга тукталырга булдым. Нәтиҗәдә, менә нәрсәләр ачыкланды. Аларның һәммәсе дә, нигездә, чорның хакимлек иткән карашын гәүдәләндерәләр, иҗтимагый күренешләрне, уй-фикерләрне коммунистик идеологиягә туры китереп чагылдыралар, милекнең, хуҗалык итүнең башка юллары, ысуллары турында уйлану тыелганлыгын әдипләр яхшы тоеп эш итәләр. Шуна күрә әсәрләрнең идея-эстетик юнәлешен идеологик диктатурадан аерып бәяләү гадел булмаячак, дип уйлыйм. Бу мәсьәләдә барыннан да бигрәк беренчел чыганакны күздә тотарга кирәк. Әмма, шуның белән бергә, әлеге әсәрләрдә объектив рәвештә чорның, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең драматизмын чагылдырган күренешләр, гыйбрәтле, сабак булырдай фикерләр дә күренеп кала. Кайберләренең хәтта бүгенге көндә актуальлекләре тагын да арта төшә. Аларга карап, чорның, җәмгыятьнең әхлак дәрәҗәсе хакында фикер йөртергә була.

Күмәкләштерүнең иң тәүге, башлангыч дәверен, егерменче еллар башындагы коммуна тормышын «Матур туганда» романында Ш. Камал сурәтләп бирде. Әмма әдип бу материалны көнелендә унбиш ел чамасы саклап йөртте, сәнгатьчә өлгергәнен, пешеп җиткәнен көтте. Ул аны 1936 елда, иң бай иҗат тәҗрибәсе туплаган чорда иҗат итте.

Коммуналар ил күләмендә киң таралмаганлыктан һәм дә озын гомерле булмаганлыктан, бездә бу теманың типиклыгына шикләнеп караучылар да булды. Ләкин мәсьәлә тегеяки бу күренешнең киң яки сирәк таралуында гына түгел. Жорж Санд «Графиня Рудольштадт» романында тагын да сирәгрәк очракны — геройның үлеп терелүен, дөресрәге, мәрткә киткәннән соң уянып яши башлавын тасвир итә. «Алтын ишәк» романында Апулей кешенең ишәккә әверелүен, ләкин кешечә аңлау сәләтен югалтмавын, «Мастер һәм Маргарита» әсәрендә М. Булгаков иблиснең безнең көннәрдә Мәскәүдә гаҗәеп могҗизалар тудыруын сурәтли. Шулай булуга карамастан, алар дөнья классикасында күренекле әсәрләрдән санала. Коммунага килгәндә исә, ул илебез тормышында реаль яшәп алган, һәм автор үзе дә аның эшчәнлегендә турыдан-туры катнашкан. Бу хәл әсәрнең тормышчан җирлеге турында сөйли.

Әсәрнең исеме матурлык турында сүз барачагын вәгъдә итә. Романнан күренгәнчә, уртак максат белән берләшкән коммунарлар арасында үтә самими, үзара хәстәрле, кайгыртучан, шул ук вакытта бер-берсенә карата таләпчән, эшлекле җылы мөнәсәбәтләр урнаша. Алар коммуна тормышы, эшчәнлеге белән үзләре мөстәкыйль идарә итәләр, барлык мөһим мәсьәләләр хакында уртага салып киңәшәләр, башлык сүзен җөпләп кенә утырмыйлар, үз фикерләрен, тәкъдимнәрен әйтәләр. Мәсәлән, печән өстенә, уракка дип ничә баш малны симертүгә куярга икәнлеген үзләре хәл итәләр.

Геройларның күркәм сыйфатлары аеруча эшне дәртләнеп, күңел биреп башкаруларында, башкаларга салынып тормауларында күренә. Алар коллективның һәм, димәк, һәр кешенең мул, житешле яшәве тик үз хезмәтләренә генә бәйләнгән икәнен яхшы төшенәләр.

Алар Әмирҗан, Григорий Чуркин отрядларына каршы көрәштә дә чын оешканлык, зирәклек күрсәтәләр. Мәдинә моннан тыш әле тагын шәхси батырлыгы, чыдамлыгы, кансыз бандит һөҗүменә бирешмәве белән дә иптәшләрен таң калдыра.

Әдип коммунарларны — физик хезмәт кешеләрен — уй-фикерле итеп, күренешләрне анализларга, бәйләнешләрен күрергә һәм нәтиҗә ясарга сәләтле, кыскасы, интеллектуаль бай итеп сурәтли.

Коллектив җанлы булу, кешелекле мөнәсәбәтләр, хезмәткә сәләтлелек халык аңында һәрчак мактауга, олылауга лаеклы сыйфат саналган. Әгәр дә, романны бүген укыган чагында, күз алдына әйбәт оешкан аренда бригадалары, аларның яшәешкә актив, иҗади мөнәсәбәте килеп китсә, бер дә гаҗәп булмаячак.

Күмәкләп эшләү авыл өчен принципта бөтенләй үк ят гадәт түгел. Күпләрнең куәтен берләштерүне сорый торган киеренке эшләрне ул элек-электән өмә белән башкара торган булган, һәм анда өмәчеләр бик теләп катнашканнар, ни нәрсәгә сәләтле, булдыклы, җегәрле булуларын күрсәткәннәр. Күмәк хезмәт уен-җыр, шаян сүз белән аралашып барган. Ул яшь җилкенчәкләрнең очрашу, күз сирпеп алу, танышу урыны да булган, кешеләр күңелендә ничектер бер нурлы, якты хәтирә булып сакланган. Шуңа күрә булса кирәк, аның хакында хәтсез матур әсәрләр язылган.

Әгәр дә дәүләт крестьянга сату өчен эреле-ваклы техника чыгарса, зирәк, иҗади хезмәткә мөмкинлекләр тудырса, бу гадәт җегәрне тагын да киңрәк

күләмдә берләштерү өчен дә бәрәкәтле җирлек була алыр иде, хуҗалыкны, машиналарны нинди масштабта, кайсы формада күмәкләштерүне җир кешесе үзе, баш белән уйлап, бик зирәк хәл иткән булыр иде. Аеруча мөһиме — болай итү конфликтка нигезләнми, буйсындыру, җимерү, таркатуны күздә тотмый.

М. Әмирнең «Агыйдел» повесте «Матур туганда» белән бер үк чорда — 1935 елда языла. Ул монда 1927 еллардагы авыл тормышын, ягъни тоташ күмәкләштерү башланганчы булган хәлләрне бәян итә. Әдәбият, сәнгатькә, бөтен җәмгыятькә көчләп тагылган чор карашы монда да чагылмый калмаган, әлбәттә. Әйтик, житешле, таза тормышлы кешеләргә, сәүдә итүчеләргә, дин әһелләренә берьяклы тискәре мөнәсәбәт әнә шуннан килә. Уңай герой Гаязга да көрәшчә тәҗрибәсе житеп бетми, анда тәвәккәллек белән башсызлык аралашып куйгалый, акыл белән уйлап, исәпләп җиткермәү аны фаҗигагә китерә.

Әмма әдип монда авыл хуҗалыгын мәҗбүри, тоташ күмәкләштерү турында сүз алып бармый, бәлки теләк белдергән егерме дүрт гаилә хуҗалыгын берләштерү, артель оештыру турында сүз бара. Әсәрдән аңлашылганча, бераздан моңа тагын үз ихтыяры белән берничә гаилә кушыла. Кулак дигәннәре дә сыйныф буларак куылмыйлар, бәлки конкрет җинаять өчен кулга алыналар. Әсәрдә, гомумән, чыннан да бай дип әйтерлек зур мөлкәт ияләре күренми.

Тулаем исә повесть яшьлеккә хас хыял-омтылышларны, хис-кичерешләрне, укымышлы яшьләрнең иҗтимагый активлыгын, авыл халкына ярдәм итәргә тырышып йөрүләрен — җәмгыять өчен бик кирәкле, беркайчан да әһәмиятен югалтмый торган сыйфатларны тасвир итә. Әсәр ягымлы, җылы лиризмга төреп язылган.

Ләкин, шулай да, чынбарлыкта күмәкләштерү үтә кырыс шартларда барды һәм бу кырыслык әсәрләрнең аһәненә дә йогынты ясамый калмады.

Авылдагы бәрелешләр турында бездә тәүге сүз әйтүче Г. Ибраһимов булды. Аның «Тирән тамырлар»ы 1928 елның августында язылып бетә һәм шул ук елның ахырында нәшриятта басылып та чыга. Ул чакта китаплар нишләптер бик тиз басыла торган булган. Әдәбият белемендә бу роман күмәкләштерү турындагы әсәрләр рәтендә карап йөртелә. Ләкин Фәхринең «артель, коммун, колхоз» дигән сүзләре монда әле асылда теоретик планда гына әйтелә, шуларның берәрсен төзү процессы үзе сурәтләнми. Ә менә совхозларның инде реаль яшәгәнлекләре күрсәтелә. Шуларның берсенә башлык итеп, белгеч буларак, Вәли Хәсәновны билгелиләр. Ул килгәндә, совхоз милкендә эшкә яраксыз дүрт чирле ат, дүрт кысыр сарык, чүп басып бетергән сигез дисәтинә арыш, бодай, тары, солы кишәрлекләре була. Шушы хуҗалыкны рәткә кертер өчен Хәсәнов, әсәрдән аңлашылуынча, тәүлегенә унсигезәр сәгать эшли. Дүрт ел эчендә аяклы мал йөз башка житә. Шул җөмләдән совхоз тирә-яктагы терлекләр токымын яхшыртырдай нәсел айгырлары, үгезләр, тәкәләр булдыра, күрше игенчеләргә арзан хак белән югары сортлы орлыклар өләшеп тора, күрше авылларга тракторлар белән ярдәм итә, өч басудан күп басулы чәчү әйләнешенә күчә, бөтен Идел буенда беренче үрнәк совхозга әйләнә.

Романда Вәли Хәсәнов, мәгълүм булганча, Фәхрине үтертүдә, дөресрәге, шуңа ишарә итәрдәй гамәлдә — акча бирүдә гаепләнә. Совхоз мәсьәләсе дә шушы җинаятькә бәйләп кузгатыла. Тикшерү вакытында да, хөкем барышында да хуҗалыкның бу күрсәткечләре кире кагылмый, тик уңышка килү юллары гына гаепләнә, эшчеләрне тәүлегенә ундүрт-унбишәр сәгать эшләтү, бүтән совхозларга тиешле дотацияне йоту, бәлән совхозларның милкен, килгән тракторларны үзенә үзләштерү хисабына ирешелгән, дип бәяләнә, совет кануннары, тәртипләре моңа юл куйган булып чыга.

Фәхри дә, нигездә, шушы хуҗалыкка мөнәсәбәт яктылыгындарак тасвирлана. Аның үзенең йортында хуҗалык иткәнлеге күренми. Өйләнешкәч «байтак еллар кемдә туры килсә, шунда өйдәш торып гомер иттеләр». (Г. Ибраһимов. Әсәрләр. Сигез томда. 3т.-К., 1975, 156 б.). «Үзенә аерым бер өй салып керү ничектер аның башыннан ук чыгып киткән иде» (159 б.). «Өйне, Фәхри читтә чакта, хатыны Гайшә салып керә. Аның каравы Фәхри «Уртак» исемле коммуна төзи. Әмма житәкчеләрнең тәҗрибәсезлеге, фронтка китеп барулары, хатын-кызларның талашып, ызгышып бетүләре аркасында коммуна таркала, йортлар, амбарлар яшен сугудан янып бетәләр. Авыл кешеләре бу хакта: «Алар, коммун ясыйбыз дип, фон Киллернең менә дигән хуҗалыгын ничә айда ашап бетерделәр»,— дип сөйлиләр. (265—266 б.) Ләкин, шулай да, әсәрдә коммунаның таркалуы түгел, үрнәк совхозның эшчәнлеге тәнкыйтьләнә. Ул чорда, күрәсең, хуҗалыкның, нинди хәлдә булуыннан да бигрәк, кем житәкчелегендә эшләве мөһимрәк саналган булса кирәк. Романда әле, гомумән, крестьян шөгыленең,

коммунистлар кул астында хуҗалык итүнең унай үрнәге тасвир объекты итеп алынмый. Әмма үрнәк хуҗалыктан кер эзләү, артель, коммунага димләү вазифасы романда нәкъ менә Фәхригә тапшырыла. Әмма, объектив рәвештә, укучыга бу өндәүләр түгел, бәлки эш рәте белүнең, күнел биреп, тырышып эшләүнең, җир серләренә төшенүнең әһәмияте ныграк ышандыра.

Инде Фәхрине үтертү мәсьәләсенә килик. Моңа ни дәрәҗәдә катнашы барлыгы турында Вәли Хәсәнов судта болай сөйли:

«— Гыйммади карт миңа әйтте: бу эт Фәхриләрнең авызларын капламый булмас, диде. Акчасыз эш чыкмый, майламый таба купмый, диде. Мин ваклап тикшермәдем. Берәрсен сыйларга уйлыйлардыр, берәрсенә бүләк бирәләрдер, дип исәпләдем. Менә үзен карарсың шунда, дидем дә утыз сумны бирдем». (375 б.) Ягъни, әйтүенә караганда, Вәли Хәсәнов Фәхрине үтерергә кушмаган. Хөкем барышында да моны раслардай бер дәлил дә китерелми. Сорап килгән кешегә аның акча биреп җибәрүе хакында гына әйтелә. Шулай да Вәли Хәсәнов үлем җәзасына хөкем ителә. Инде Иванов, Сәләхиевларга килгәндә исә, әсәрдә аларның Фәхрине үтерүгә гомумән бертөрле дә катнашы күренми. Романда аларның Вәли Хәсәнов белән экономик, хуҗалык бәйләнешләре, бүләк бирешүләре, ярдәмләшүләре хакында гына сүз бара. Рәсми яклаучылар да бу тарафтан гәп кузгатмыйлар. Иванов, Сәләхиевлар бишәр ел төрмәгә хөкем ителәләр.

Элегрәк без Зирекле ишаны Габдулла хәзрәт язмышына аерым илтифат юнәлдермичәрәк үтеп китүне кулай күрә идек. Хәлбуки, әсәрдә ул шактый күренекле зат итеп бирелә. Волбашкарма, авыл советы кешеләре аның хакында:

«— Ишанның даны бик зур. Бөтен тирә-якның мөселман крәстиәне ана әүлия дип карый»,— диләр. Әмма Садыйк Минлебаев башкача уйлый, ул Шәмсигә Зирекле авылына кораллы армеецлар ияртеп барырга куша, «кирәген күрерсең. Атарлык булса, безгә хәбәр итәрсең»,— ди. (354 б.)

Шәмсиләр, волбашкармага да, авыл советына да хәбәр итмичә, түшәктә яткан авыру ишан өенә басып керәләр, мөлкәтен фәкыйрьләргә тараталар. Әмма төнен алар барча әйберләрне дә кире ишан йортына китереп бирәләр. Өстәвенә, ишан ябылган өйнең ишек төбендә дога-фатиха алып калырга дип килүчеләрдән су буе чират тезелә.

Ишан иманына тугры кала, «без фәкать аллаһы тәгаләнең әмерләренә генә буйсынабыз»,— дип белдерә. Гайнетдинов Шәмси аны стенага терәп атып үтерә. Автор аңлатмасында «кануннан матдәләр тикшерергә вакыты булмады»,— диелә. (359 б.)

Шулай итеп, бәндә гомерен кыю бер очракта җинаять санала, бөтен роман шуның тамырларын юллауга багышлана, икенче мәлдә үзенә күрә бер егетлек кебегрәк итеп бирелә, аның өчен берәүне дә хөкем каршына китереп бастырмыйлар. Бу җәмгыятьтә, әсәрдән аңлашылганча, төрле кешенең кадере төрлечә булып чыга.

Халык күңелендә исә руханилар башкачарак урын били. И. Гази «Канатланып чак» әсәрендә мәчетне, мулла йортын тузгыткан өчен авыл кешеләренең ярсуын, нәфрәтләнүен сурәтли, өлкә комитеты вәкилләрен алагаем кыйнап ташлауларын, ат урынына чанага җигеп, хәзрәт җиһазларын үз өенә илтеп куйдыртуларын бәян итә.

«Тирән тамырлар»да ишанны атып үтерү күренешен укыганнан соң, күңелгә байтак сораулар килә. Судсыз-нисез җан кыюларның алга таба логика буенча тагын да киңрәк күләмдәге репрессияләргә юл әрчүен автор ул вакытта әле күз алдына китереп житкерә алмаган булуы ихтимал. Ләкин, художник-психолог, фикер иясе буларак, мондый законсызлыкларның инсан җанын имгәтүен, кансызлык, миһербансызлык психологиясен, ерткычлык инстинкты тудыруын ничек күрә алмады икән? Автор биредә детектив материал белән эш итә. Димәк, монда әдәби мотивлаштыру юридик нигезләүгә таянырга тиеш була. Моның искә алынып житмәвен ашыгыбрак иҗат итү белән генә аңлатып буламы? Мәгълүм таркаулыкны, кабатлану очракларын, персонажлар сөйләменә сәерлек элементларын кертеп җибәрүне күздә тотканда, болай уйларга да урын бар кебек. Ләкин шулай да төп сәбәп тирәндәрәк ятмый микән?

Унҗиленче ел борылышына кадәр безнең әдәбият гуманистик, югары әхлаклы әдәбият иде. Ул табигый гамәл, омтылышларны, сәламәт тойгы-кичерешләрне чагылдырды, халыкның бәхетле яшәешенә, үсешенә комачаулык итүче күренешләрне тәнкыйтьли килде. Г. Ибраһимовның үзенең ул чактагы әсәрләрендә дә без законсызлыкны хуплау яки миһербансызлыкны гадәти хәл дип бәяләү очракларын күрмибез. Әгәр шулай да әсәргә җинаять, үтерү вакыйгалары кертелә икән, алар персонажның холкы-табигате, тормыш ситуациясе белән, психологик яктан нигезләнә, авторның гаепләве, тискәре мөнәсәбәте ачык сизелә.

Октябрь көннәреннән соң әхлак принциплары кискен үзгәрде. Хакимиятнең дин әһелләренә, руханиларга карата үтә кырыс, каты сәясәте матур әдәбиятка да килеп керде. Партия хакимияте әдәбиятның гуманистик кыйблысын үзгәртте, бүтән якка борып җибәрде. Язучылар яңа җәмгыятьнең барлык күренешләрен ул чакта сүзсез кабул итәргә һәм мактап сөйләргә бурычлылар иде.

Бу хәл герой образын гәүдәләндерү, характерны яктырту стилендә дә күренде. «Тирән тамырлар»да персонажның ниндилеге бер үлчәм белән — революциягә, гражданнар сугышына мөнәсәбәте, катнашы белән билгеләнә. Әдип инсанны күп төрле сыйфатлар җыелмасы итеп караудан баш тарта кебек. Ул аеруча каһарманның партиялелегенә басым ясый, сәяси оешмага мөнәсәбәт кешенең иң төп, мөһим сыйфатларын гәүдәләндерә дип саный, моңа бик саллы эстетик вазифа йөкли:

«... комсомол егетне ияртеп, совет йортына китте. (137 б.)

«... чуваш коммунисты Паларусов иптәш җибәрелгән иде». (145 б.)

«Муенына кызыл галстук бәйләгән яланаяклы кечкенә кара малай басу капкасын ачып кертте». (150 б.)

Геройның төп сыйфатын шушы рәвешле сәяси оешма әгъзасы булу ягыннан гына характерлау совет чорында гына күренә башлый.

Чор каршылыклары әсәрнең сәнгатьчә фикерләү системасында да урын алган. Хуплау юнәлешендә бәян ителгән кайбер хәл-әхвалләр асылда тәнкыйть кебегрәк яңгырыйлар.

Гәрчә хуҗалыкларны үз җае белән, эчке ихтыяҗ дәртләндерүе җирлегендә берләштерү мөмкинлеге булса да, хакимият башта ук конфликтлы юлны сайлады, ныклы хуҗалыкларны тузгыту, яшәеш рәвешен үзгәртү, крестьянны җирдән аеру, тыңлаучан эш көченә әйләндерү, колхозларны дәүләтнең арзан савым сыерына әверелдерү мәсләген күтәреп чыкты. Аны тормышка ашыру чиксез күп михнәтләр, күз яшьләре, эчке сыкраулар аркылы барды. Повесть, романнарыбыз шул көннәрнең драматик коллизияләрен сурәтләп калдырдылар.

Вакыйгаларның кайнар эзеннән барып язылган әсәрләрнең берсе Ф. Хөснинең «Җир тыңлый» романы булды. Ул 1930—31 елларда языла һәм 1931 елда басылып чыга. Үз заманында бу әсәр байтак шау-шу кузгатты, аеруча көр тавышлы тәнкыйтьчеләр авторны — егерме өч яшьлек егетне — кулак идеологиясен үткәрүдә гаепләп чыктылар. Әмма биредә хәлле кешеләргә теләктәшлек белдерүдән дә бигрәк партократиянең һәм аның күзенә карап торган тәнкыйтьчеләрнең чынында куркаклыгы, ул-бу чыкмагае дип, үз күләгәләреннән өркеп яшәүләре хакында гына сүз йөртү дөресрәк булмас микән? Шулай бит ул: хакимият үзе крестьяннарга каршы көрәш ачып җибәрә, революция ясый, үзе юаш кына әдәби әсәр алдында да кан калтырап тора. Мин бу романны шушы арада кабат җентекләп укып чыктым һәм бертөрле дә гаеп-кыек очратмадым. Автор авылны, хакимиятнең крестьяннар язмышына йогынтысын бар барлыгы, үкенечләре, гаделсезлекләре белән күрергә һәм күрсәтергә тырыша. Әсәрдә кулаклар язмышына кагылышлы сурәтләр дә бар, әлбәттә. Менә, мәсәлән, волбашкарма комитетыннан Якты тау авылындагы барча кулакларны егерме дүрт сәгать эчендә илдән сөрергә дигән боерык килә. Ягъни иң беренче эш итеп авылны баету, мул тормышка чыгару түгел, ярлылык буенча тигезләү бурычы куела. Әмма фәкыйрьлек кимәлен ни дәрәҗәдә билгеләргә? Башта исемлеккә җиде гаилә теркәлә. Болар арасында тегерманче, мулла, «симез хатыны белән арык сыерыннан башка» мөлкәте булмаган мәзин, Шакир бай, йон тетү машинасы, сепаратор тоткан Ярхәмнекеләр, революциядән соң сәүдә итеп алган Сөнгать, урта хәлле Гыйлаҗи бар. Актив һәм ярлылар җыелышы ахырдан Гыйлаҗи гаиләсен бу кара исемлектән сызып ташларга карар кыла.

Хәтсез еллардан соң, зур тәҗрибә туплап, күренекле әдип булып җитешкәч, «Йөзек кашы», «Җәяүле кеше сукмагы»ның авторы булып танылгач, Ф. Хөсни бу романга кабат әйләнеп кайта һәм ышанычлы кул белән өр-яңадан язып чыга. Монда «Җир тыңлый» әсәрендәге кайбер сурәт-бизәкләр дә ялтырап-ялтырап кала. Ләкин, билгеле бер иҗади бәйләнеш булган хәлдә дә, «Утызынчы ел» бөтенләй башка, яңа әсәр ул. Барыннан да бигрәк сәнгатьчә эшләнеше белән ул бик югары кимәлдә тора. Әдип монда әзер организмга ит кундыру, кан йөгертү, җан өрдерү белән генә чикләнмәгән, мул хисле, мөлаем-моңсу мөстәкыйль бер әсәр иҗат иткән.

«Утызынчы ел»да житешле кешеләр арасыннан алгы планга Галләм хаҗи образы килеп чыга. Ул башлыча мөлкәткә, туган туфракка мөнәсәбәте белән күренә. Менә авылдагы хакимият вәкилләре аңа яшерелгән икмәген алырга дип киләләр.

Цивилизацияле илләрдә игенне яшерү хаҗәте дә, тартып алу ихтыяҗы да юк. Артыгын хуҗа үзе шатланып китереп сата, тиешле хакын алып китә. Монда исә бәясен түләү турында бер авыз сүз дә чыкмый. Икмәкне бушка алып китәләр. Бу хактагы уйлары хакында әсәрнең баш герое Вафин бер хатында болай яза: «Каршы килүчеләргә карата 107 статьяны кулланабыз. Бүтәнен белмәсәләр дә, монда ул статьяны белеп алган батраклар байтак, кулакның яшергән ашлыгын эзләп табарга дигәндә, җиңнәрен сызганып торалар» (Ф. Хөсни. «Утызынчы ел.» 1963, 32 б.) Шулай итеп, илнең экономикасы табигый алыш-бирешкә, сәүдәгә түгел, куркытуга, тартып алуга, талаучының да, талanучының да рухын гарипләндерүгә корылган булып чыга, ягъни крестьян белән дәүләт арасындагы мөнәсәбәт үз эчендә даими конфликт чыганагы саклап кала.

«Матур туганда» романындагы Садыйк хаҗиның алтын-көмешләрен водокачка астыннан казып алганда да нинди дә булса хөкем карары, ордер-фәлән күрсәтелми. Ә менә нәтиҗәсе ачык сизелә. Әмирҗан, Чуркин отрядлары мөлкәтне тартып алуга реакция буларак оешалар. Ахыр чиктә гражданнар сугышының да төп сәбәбе әнә шуна кайтып кала, тартып алынган байлык миллионнарның каны, гомере белән түләнде.

Инде Галләм хаҗины туган туфрактан куып җибәрү мәсьәләсенә килик. Монда безне бигрәк тә аргументлаштыру кызыксындыра. Тик торганда илдән сөрүне аклау өчен автор төп нигезне — канунны, хөкем карарын файдалана алмый — монда закон хөкеме йөрмәде. Димәк, образлы сурәткә сыенырга кала. Волком сәркатибе Батталов: «Колхоз төзү өчен безгә арабызда булган чүп үләннәрен йолкып ташларга туры киләчәк. Шушы көннәрдә без сезнең авылда да раскулачивание үткәрергә тиешбез»,— ди. (110 б.) Шулай итеп, ярлы, урта хәлләр файдалы культура, ә таза, нык тормышлылар чүп үләннәре булып чыга. Әмма, уйлабрак караганда, умырып, җилкенеп эшләүчеләр түгел, ялкаулар, хөрәсәннәр чүп үләне булмый микән? Бу очракта укытучы Сәрвәр Шамкина уйлары, авыл кешеләренең сүзләре үтемлерәк яңгырый. «Бик каты кыланмыйбызмы без кешеләр белән? Бөгеп җибәрмибезме икән? Кояш астында һәркемнең дә яшәргә хакы юкмыни?» — дип уйлый Сәрвәр. (166 б.) Шул авылның хатын-кызлары үз фикерләрен тагын да ачыграк әйтеп бирәләр: «Ат карагын да тикшермичә-нитмичә генә Себер җибәрмиләр ие элгәре» (197 б.). Бу юлларны укыгач, әсәр безгә янача күренгәндәй тоела.

Романда Нажия образы бик мөһим урын били. Аның гамәл-омтылышлары, хис-кичерешләре асылда бөтен әсәрнең аһәңен, моңын билгели. Чибәрлеге, хискә байлыгы, зирәклеге өстенә, мөстәкыйль эш итәргә, тормышчан, масштаблы фикер йөртергә дә сәләтле ул. Әсәрдә Нажия, байлар мохитен, үги әнисен үз итмичә, авыл яшьләре, комсомол тирәсенә елышучы тынгысыз зат итеп тасвирлана. Ул, тәвәккәлләп, спектакльдә уйный, ашлыкларының яшерелгән урынын күрсәтә, комсомолга алуны сорап гариза бирә, чәчен кистерә, грамоталылыкны күтәрү эшенә ихлас булышырга тели. Нажия белән Котдус Вафин бер-берсен яратышалар. Ләкин Вафинның хис, гамәлләре шактый каршылыклы. Гәрчә авыл кешеләренең тормышын, яшәү рәвешен тамырдан үзгәртергә атлыгып йөрсә дә, Нажияне — кулак кызын — үз араларына кертергә, комсомолга алырга секретарьның кыюлыгы, мөстәкыйльлеге җитми — сүз булудан шүрли. Тойгысын, мәхәббәтен тыеп, басып торуы да ахыр чиктә куркаклыгыннан килә. Заман, тәртипләр хисне авызлыклауны таләп итә. Әти-әнисе белән бергә Нажия — матур чәчәк тә — илдән сөрелә, язмышы чатнап сына. Шул мәлдәге мөлдерәмә тулы тойгы, кичерешләрен ул Вафинга бер-ике җөмлә белән язып калдыра. Ул иң әүвәл сөрдерерлек нинди гаебе бар икәнен белмәве турында әйтә. «Нишләдем икән соң мин ул хәтле кулак кызы булып?» — дигән сорау куя ул хакимият әһелләре алдына, гөнаһын берәүнең дә төшендереп, аңлатып бирә алмаганлыгын күрсәтә, шуннан соң Вафинга күңелендә нинди хисләр саклап йөрткәнлеген ачып сала: «...Ярата идем мин сине, Котдус абый, хәзер дә яратам и шулай ярата-ярата китәм дә. Син шуны сизмәдең... Әллә сизеп тә сизмәмешкә салышып йөрдең инде. Бәлкем, ялындырырга теләгәнсең, юк инде, ялына торганнардан түгел без, ялына торганнарны Янбулат базарыннан эзләп карагыз». (209—210 б.)

Бу җәһәттән И. Газиның «Канатланыр чак» әсәрендәге гади крестьян егете Гыймран тәвәккәлрәк, үткенрәк булып чыга, сөйгәнен — шулай ук кулак кызын — өлкә комитеты вәкиле Хәлим булышлыгы белән төрмәдән чыгаруга ирешә дә, шул ук төнне Уралга, заводка китеп баралар, бәхетле гаилә коралар, олы ихтирам йөзеннән улларына Хәлим исеме кушалар.

Котдус исә бик тиз үкенә үкенүен, әмма терсәкне тешләп булмый.

И. Газиның «Канатланыр чак» әсәре «Онытылмас еллар»ның өченче китабын тәшкил итә. Әдип аны 1965—69 елларда яза. Бу өлештә ул вакыйгаларны

утызынчы елга китереп җиткерә. Баштагылары кебек, тоташы белән сурәтле фикерләрдән тукылган, лирик жылы, драматик киеренке әсәр ул.

Гафият образы укучыларга баштагы ике китап буенча да яхшы таныш иде. Кендеге белән җиргә береккән, аны ихлас яратучы, серен белүче, күнел биреп, җиренә җиткереп эшкәртүдән ләззәт, тәм табучы чын игенче ул. Булдыклы, иген эшенә сәләтле, сәламәтлеге, куәте дә ташып тора. Табигый, аның хуҗалыгы да төзек, житешле. Ул, совет өндәмәләренә ышанып, сәләтенә, зирәклегенә таянып, үрнәк хуҗалык булдырырга дәртләнеп йөри. Кыскасы, бәхетне ул хәләл күкрәк көче белән табарга өметләнә. Ләкин, күмәкләштерү башлангач, баюга таба барасың дип, аны кулаклар рәтенә кертәләр һәм куплэр белән бергә волость чиркәвенә ябып куялар. Себергә озатылганчы алар шунда көтәргә тиеш булалар.

Хәлим, партия өлкә комитеты вәкиле, урта хәлле Гафиятнең ябылуына гаҗәпләнә, аны азат итә. Ләкин Гафиятне көтелмәгән шатлыктан соң ук ачы хәсрәт биләп ала.

«— Нәрсә син,— диде Хәлим,— төрмәдән чыкканга бер дә куанмыйсың, ахры?

Гафият кыймылдап, чайкалып куйды.

— Куанырга,— диде ул төссез тонык тавыш белән,— син менә мине төрмәдән коткардың, ә сине чакырып кунак итәргә минем өем юк, хатын, бала-чагам кеше мунчасында тора, терлек-туарымны бүлешеп бетерделәр. Сакал кырырга бритвам да калмады, кайсыдыр алып чыгып китте.» (И. Гази. «Канатланыр чак» — К., 1973, 237 б.)

Колхозга димләү әсәрләрдә ничек бирелгән? Авыл кешеләре моңа ничек караган? Роман, повестьлардан күренүенчә, үгетләү, кыстауларның төп ысулы өркетү булган. Өмер сәясәте бәндәләр күңеленә шом салып узган. Ф. Хөсни болай яза: «Авыл башына җиткәнче шулай үзе белән үзе сөйләнеп барды Әхмәтҗан. Авыл башына җиткәч, «жу!» итеп күңеленнән яңа бер курку узды: әйтик, көннәрдән бер көнне «кулак» дип авылдан сөрсәләр?» (230 б.)

Күмәкләштерү фронтындагы җиңү хакына түрәләр авыл хуҗалыгы нигезенең җимерелүе, булдыклы кадрларның тузгытылуы белән дә исәпләшеп тормаганнар. Аларны илнең экономикасы түгел, революция ясап алу үзе ныграк мавыктырган.

Тагын шул хәтлесе дә бар: гомумән, социалистик революция тарихындагы кебек, монда да күмәкләштерү теориясе тормыштагы тәҗрибәдән килеп чыкмады, ә бәлки әүвәл идея туды да, соңыннан шуны берни белән дә исәпләшмичә гамәлгә ашыру башланды. Шуңа күрә персонажлар да әңгәмә барышында нинди дә булса реаль уңай үрнәккә таянмыйлар, якты киләчәк, алдагы оҗмах белән кызыксындырмакчы булалар (тик хур кызларын гына искә алмыйлар). Әмма ул вәгъдәләр агай-энене бик үк ышандырып җиткерми: «Бик җәннәт итеп күрсәтәләр инде күрсәтүен дә, ул җәннәтнең соң идән-сәкесе, сәкегә җәеп ятарлык мамык түшәк-ястыгы булырмы икән? Әллә югыйсә идәнгә салам түшәк җәеп кенә яткырырлармы икән?» («Утызынчы ел», 183 б.)

Үгетләү, димләү эшендә иң йогынтылы дәлил итеп трактор кулланыла. Әмма ул да әле совхозларга гына бирелә икән, колхозларга ышанып тапшырсаң, аның күмәк кулакка әйләнүе, баеп китүе бар, ул чагында инде артель гел тилмереп дәүләт күзенә карап тормаячак, үзен бәйсез хис итәчәк. Шуңа күрә трактор, комбайннар МТС кулында тупланды. Ә инде индивидуаль хуҗалыкта файдаланырдай җыйнак техника чыгару турында җәмгыятьтә дә, әдәбиятта да бер сүз дә кузгатылмады. Шул ук вакытта хакимият крестьянны атсыз — пар канатсыз калдырды. «Утызынчы ел» да Бытбылдык Әхмәтҗан күңеленнән шундый уйлар үтә: «Менә бит, хода бәндәсе... Нинди заманага калды башларыбыз. Үз хайваныңны үзең җигәргә ярамый» (229 б.). Авыл кешесе ат урынына үзе җигелергә мәҗбүр булды.

Колхозга мөнәсәбәтне сурәтләгәндә, әдипләр крестьянның эчке омтылышларын да күздә тоталар, әлбәттә. «Утызынчы ел»дагы тол хатын Җаббар Гайниясенең имана җирен сөрергә аты юк. Ул әнә шул ваемын җилкәсеннән төшерү нияте белән артельгә кермәкче. «Агыйдел»дәге крестьяннар, көчләрне берләштереп, яткын, чирәм җирләрне күтәрергә, шунда яшелчә үстерергә телиләр.

Шуның белән бергә кайбер әсәрләрдә колхозга керү юмор аша бәян ителә, кайчак хәтта пародия төсен дә алгалый. «Утызынчы ел»дагы Әгъләм, атына ял бирү сылтавы белән, сабан күләгәсенә башын куя да каты йокыга тала. Шул арада аты артель атлары янына килеп чыга. Колхозчылар Әгъләмне көлеп, мыскыллап каршы алалар:

«— Алашаң булып алашаң колхозга керергә дип килгән, синдә шул алаша сознаниесе чаклы да сознание юкмыни, Әгъләм?» — диләр. (348 б.)

Әгъләм артельгә керергә була.

Әсәрдән колхозны вакытлы күренеш дип карау сизелә. «Утызынчы ел»да Гафи бик җитди рәвештә сорап куя:

— «Кара әле, кем, Касыйм туган, син укыган кеше инде, безнең ише катып калган сала мужигы түгел, беләсеңдер: бу колхоз дигәннәре, мәйтәм, кайчан булса да бетәр микән соң? Бер дә рәте-башы күренми хәзергә» (144 б.)

Аларны барыннан да битрәк теге җәннәт дигәненә көчләп кертү хафаландыра. Сталин хаты чыккач, алар җиңел сулап куялар. Ләкин аның каршылыклы, ике яклы булганлыгы бик тиз аңлашыла. «Утызынчы ел»дагы Гафи Җиһангиров өчен бу мәкалә, автор раславынча, «аяз көнне китереп суккан яшен булды» (238 б.) Ул хат басылган газеталарны төргәге белән җыеп ала да яшереп куя, хәтта ячейка секретаре Вафинга да күрсәтми. Ә «Канатланыр чак» тагы волком сәркатибе Ногманов болай сөйли:

«— Сталин хатын гарәп хәрефләре белән бастырып чыгарып, кантком бөтен эшне бозып ташлады. Яналиф белән бастырырга кирәк иде, берәү дә рәтләп укый алмаган булыр иде» (196 б.) Бу хат, алар фикеренчә, оешып житкән эшне кинәт сүтеп ташлый. Башта тизрәк йөз процент күмәкләштерүне таләп иттеләр. Инде хәзер шуның өчен тәнкыйть итәләр, дип саныйлар.

Крестьяннарны исә керү-кермәү ирекле, дигән фикер кызыксындыра. Алар бу документка зур өмет баглыйлар. «Канатланыр чак»тагы бер агай аны печән саткан акчаның яртысын түләп ала. Шуңа нигезләнеп, бик күп гаиләләр тизрәк колхоздан чыгу ягын карыйлар. Әмма чыгучыларга атын, орлыгын, иген коралларын кире бирмиләр. Үз җирләрен дә кайтармыйлар, авылдан еракта гы кызыл балчыклы калку, түбә җирләрне генә кисеп бирәләр, керү-чыгу ирегe әнә шул дәрәҗәдә була. Колхоз тозагына бер килеп эләккәч, барлык хокуклар югалганын игенчеләр бик тиз төшенеп алалар, алар карап торган барлы-юклы мөлкәтеннән генә түгел, мөстәкыйль уйлау, эшләү, хезмәт җимешеннән үзенчә файдалану ирегеннән дә колак кагалар. Бу чараны үткәрүдә шәхес мәнфәгате искә алынмады, тик дәүләт ихтыяҗын канәгатьләндерүгә генә өмет багланды. Фикер хәрлеге, мәсьәләнең асылына төшенергә тырышу гаеп саналды.

Бу җәһәттән Ә. Еникинең «Вөҗдан» повесте игътибарга лаеклы. Башка әсәрләрендәге кебек, монда да әдип мәсьәләнең психологик ягына игътибар итә, күмәкләштерү хәрәкәтенең аерым бер шәхес язмышына бөтенләй көтелмәгән яктан китереп сугуын, җанына, рухына төзәлмәс яра салып узуын хикәяли. Әсәрнең бөтен сюжеты психологик киеренкелеккә корылган.

Повесть 1966—68 елларда иҗат ителә. Ләкин монда сурәтләнгән хәлләрне әле ул чакта да ачык текст белән язарга ярамый иде. Шунлыктан ул, бик җитди, затлы булса да, «Казан утлары»нда басылмады да. Тик 1973 елда, «Без дә солдатлар идек» китабына ышыкланып кына, дөнья йөзен күрде.

Әсәр Хәбиб исеменнән, Бәкер дустына язган хаты рәвешендә хикәя ителә. Хәбиб монда җанын, вөҗданын борчыган бер үкенечле тарих турында сөйли.

Бер уйлаганда, Хәбиб язмышына драматик коллизия бер дә кагылырга тиеш түгел кебек иде. Ул бит — совет җәмгыятенең үз кешесе, ярлы крестьян малае. Рабфакны тәгамләгәч, мех фабрикасында эшли башлый. Эшен дә җиренә җиткереп, төгәл башкара, эшчеләр дә, түрәләр дә зарланмыйлар үзеннән. Кешеләр белән мөгамәләсе дә тигез, җылы, эчкерсез. Өстәвенә яшь кенә, чибәр генә өйрәнчек эшче кыз Хафаза белән дуслашып, яратышып китәләр. Мех осталары — мишәр агайлар инде аларны өйләндерү хакында да сүз кузгатып куялар, туй чыгымнарын да күтәрешергә әзер торалар. «Озак та үтми моның сере ачылды: алар фикеренчә, әгәр мин өйләнмәсәм, Хафаза кебек шундый әйбәт кызның әллә нинди юньсез кешегә эләгеп куюы бар — менә нәрсә аларны бик борчый икән! Кызык... Яхшы ат белән яхшы кызны яман кулга җибәрмәү — бу татарның борыннан килгән гадәте булса кирәк» — ди хикәяләүче (Ә. Еники. Әсәрләр: Өч томда. 2 т. — К., 1991, 68 б.)

Шуның белән бергә, бу чорда тирә-юньне бер-беренә ышанмау, шикләнү атмосферасы чолгап ала, һәрдаим сизгерлеккә, уяулыкка өндәп торалар. Басыйр кебекләр хәтта үтә тыйнак, гадел, үз һөнәренең чын осталары булган мишәр агайларга да бик үк ышанып бетмәскә киңәш итә. Басыйр ишеләр фикеренчә, алар иске белгечләр, капиталга хезмәт иткәннәр, хосуси милекчелек белән агуланганнар, бай ялагайнар, кыскасы, безнең заманга күпмедер дәрәҗәдә үги кешеләр.

Уяулыкны Басыйр үз хәлен төзәтү өчен дә файдаланмакчы була. Моңа кадәр ул комсомол җитәкчелегендә эшләп алган, әмма әхлакый чатаклык өчен ул урыннан куылган. Әмма инде хакимлек итүнең, күрсәтмә, әмер биреп йөрүнең тәмен татып өлгергән. Яңа эштә ул үтә тырышып сизгерлек, уяулык күрсәтү

белән кабат күтәрелергә тырыша. Иснәнеп йөргән кешегә, әлбәттә инде, җае да чыгып тора.

Авылга, авыру әнисен күрергә кайткач, Хәбиб янына туган-тумача, танышбелешләр җыела, шәһәр кешесеннән берәр җылы сүз ишетмәкчеләр. Шул ук вакытта бик тирәндә, күңел төпкелендә басылып яткан теләкләрен дә әйтеп бирәләр — колхозга көчләп кертмәсеннәр, хаксыз рәнҗетү, өркетүләр, колхоздан чыккан гади крестьянны подкулачник ясап илдән сөрүләр бетерелсен иде, диләр. Шулай фикер йөртергә аларга Сталин хаты кыюлык бирә.

Шәһәргә кайткач, Хәбиб бу хакта Хафаза белән дә эч серләрен уртаклаша, авылдашларының ни уйлаулары турында сөйли. Ни хикмәт: бу сөйләшүләрнең эчтәлеге Басыйрга да мәгълүм була. Ул тәҗрибәсез, беркатлы кыздан бөтен сүзләрне җайлап-җайлап суырып чыгара.

Нәтиҗәдә мехбазаның ачык партия җыелышы Хәбибне, колхозга каршы котыртуда, кулаклар җырын җырлауда гаепләп, эштән куарга дигән карар чыгарып куя. Ләкин Хәбибнең «кулак агенты» булуына җыелышны алып барган партком сәркатибе Перов үзе дә ышанмый икән, икенче көнне «чепуха бу!» — дип кырт кистереп әйтә. Бу җыелыш аңа киеренке шартларда уяулык күрсәтү, фаш итү сылтавы белән үзенең урынын ныгыту, дәрәҗәсен күтәрү өчен генә кирәк булган икән.

Шулай итеп, монда сафлык белән хөсетлек бәрелешә һәм мәкерлелек җиңеп чыга. Чөнки ул хакимият сәясәтенә таяна.

Бирегә хикмәт сәламәт рухлы егеткә, гамәле, сүзе, үе белән дә намусына тузан бөртеге кадәр дә кер кундырмаган кешегә нахак яла ягуда, искә-санга алмаган яктан сугыш миңгерәүләтүдә генә дә түгел. Әлбәттә, монысын да аз дип әйтеп булмый. К. Фасиев ишеләрдән андый күрәләтә нигезсез гаепләүләрне Ә. Еникинең үзенә дә аз ишетергә туры килмәде. Үз башына төшкән кеше моның нәрсә икәнен яхшы белә. Мәсьәләнең тагын да четреклерәк, аянычрак ягы бу яланың Хафаза исеме белән, Хәбибнең үзенең сөйгән кызы исеме белән бәйләнгән булуында. Әгәр дә Хәбиб үзен аклау нияте белән чаралар күрә башласа, телиме, теләмиме, Хафаза исеме телгә алыначак. Хәбиб бит авылдан алып кайткан тәэсирләрен бары тик аңа гына сөйләде. Ләкин егетнең Хафаза өстенә күләгә төшерәсе килми. Хис, кичерешләр киеренкелегенең чыганагы да — әнә шунда.

Бу әсәр иҗтимагый хәлләрнең, илдәге гомум атмосфераның шәхес язмышына йогынтысы, социаль киеренкелек шартларында кешегә сак мөнәсәбәт җитмәве, аның законда таяныч таба алмавы хакында сөйли.

Моңарчы без, әсәрләрне анализлаганда, күбесенчә уңай геройларның фикер сөрешенә генә игътибар итә килдек, тискәре яки каршылыклы персонажларның карашы ул кадәр әһәмиятле түгел, аларның сөйләменә нинди дә булса житди мәгънә салынмый, аны тик кире кагу, бәхәсләшү өчен генә файдаланырга мөмкин, дип саный идек. Ләкин бүген, әлеге әсәрләрне күзне ачыбрак укыгач, фикер беркадәр үзгәрә төште: чынында исә аларның сүзләрендә хәят дөреслеге кайчак тирәнрәк, төгәлрәк тә чагыла икән. Бу җәһәттән «Җир тыңлый» романындагы Фәйзи фикерләре гыйбрәтле. Элекке курсташы Сәрвәр Шамкинага язган хатында ул «революциягә чаклы урыс табаны астында изелеп килгән татар авыллары»ның язмышы турында уйлана, совет чорындагы сыйнфый бәрелешләрнең зарурлыгына, мәҗбүрилегенә шикләнеп карый. Чөнки, әле генә әсәрләрдән күреп киткәнчә, көрәш бит асылда ярлы һәм житешле кешеләр арасында түгел, ә бәлки хөкүмәт белән крестьяннар арасында барды, һөҗүм-тузгытуны да игенчеләр түгел, хакимият башлап җибәрде. Әсәрдә Фәйзинең бу ясалма революцияне хупламавы сизелә: «Тукта, мин әйтәм, социализм дигән әкиятне тудыручылар нәрсә эшләп яталар икән? Ипи чиратында торып сугышмыйлармы икән, дим. (Катылыгым өчен ачулана күрмәгез тагын. Йомшак булырлык сәбәпләр булмаганга шулай катымын. Хәер, большевиклар каты булуны яраталар бит). Шулай дип тоттым да Сезгә хат яздым» (Фатих Хөсни. «Җир тыңлый.» — К., Татиздат, 1931, 53 б.) Ул кызыллануны балалык авыруы дип саный.

Хаттан күренгәнчә, аны, Көнчыгыш педагогия институтының татар әдәбияты бүлегендә укып чыккан белгечне, гомумән Татарстанның мөстәкыйльлеге, мәдәниятенең барыр юлы да дулкынландыра. Ул «ертылган шәһрәт тотып калган» төрки халыкларны, Кавказ, Кырым мөселманнарын берләштерү идеясен күтәреп чыга, «барысы да берләшкән вакытта, безнең әүвәлге шәһрәтебезне табуыбыз үтә табигый бер нәрсә», дип раслый, кыйбла итеп бөек шарыкъ мәмләкәтен, үзенә хас бөек мәдәниятен сайларга, шул юл белән барырга кирәк иде, ди һәм ахырдан «без, урыслар артыннан ияреп, аларның гасырлар буенча өстенлек кылып килгән хаким мәдәниятләре тарафыннан йотылабыз», дигән нәтиҗә ясый.

«Канатланыр чак»тагы Дәүләтъяров та укучыларга «Онытылмас еллар»ның алдагы китаплары буенча таныш. Аларда ул милләтче рәвешендәрәк тасвирлана. Биредә исә аның Татарстан республикасы төзелгән көннәрдәге һәм аннан соңгы уй-фикерләре бәян ителә. Ул җөмһүриятнең мөстәкыйль яшь башлавына ихлас куана: «Тик кайбер чыдамсызраклар үзләренең карталарын бик иртә ачтылар: янәсе, Мәскәү югарыдан команда биреп тормасын, ходайның ярдәме белән без үзебез генә дә юл яра белербез, дип кычкырдылар. Кызыл Армияне оккупацион армия дип атап, республика туфрагыннан чыгарырга йөрделәр». (66 б.) Кызыл Армияне сыйфатлаган «оккупацион» эпитетын без соңгы елларда күбесенчә Балтика буе илләреннән ишетә идек. Андый бәяләр үзебезнең әдәбиятта иртәрәк тә чагылган икән ләбаса. Ләкин, әсәрне моңарчы ничә кат укып чыгуга да карамастан, аерым дикъкать юнәлтергә ярамагач, аларны күрми үткәнбез.

Дәүләтъяров карашынча, бераздан властька суллар килә. Аларның мәсләге белән Дәүләтъяров бөтенләй килешә алмый. «Аларга синең татар милләтең өч тиен бер акча. Алар сыйныфка табына, анда да эшче сыйныфка гына, крестьяннар алар өчен ниндидер абстракт категория... Телдә партиянең милли программасын корьән урынына тотып ант итсәләр дә, гамәлдә милли сәясәтне тормышка ашыру өчен кыл да кыймылдатмыйлар» (67 б.) Бу юллар бүген хәзерге администрация-әмер системасы хакында әйтелгән кебек укылалар. Әсәрдән күренүенчә, Дәүләтъяров Идел буена татарларны күчерү эшен оештыра. Әмма аны бай татарларны күчерүдә гаеплиләр. Хәлбуки, моның да сәбәбе бик өстә ята: ярлыларның, яңа җиргә күчеп, яңа йортлар салырга акчалары булмый. Дәүләтъяров татар крестьяннарын Себергә күпләп күчерү, җөмһүриятебездә калган татар халкын сыегайту белән дә килешми. Дәүләтъяров Татарстанның чын мөстәкыйльлек алуына өмет итә, «кайчан да булса бер көнне татар үз республикасына үзе, бары тик үзе генә хуҗа булыр дип, руслар командасыннан котылыр дип хыяллана һәм татарларның үз арасыннан чыккан яшь белгечләр булдыру артыннан бик тырышып чаба иде» (68 б.)

Шовинистик хакимияткә нәкъ менә шул эшчәнлек, татар халкы турында кайгырту ошамый. Рәсми пропаганда Дәүләтъяровка бөтенләй тискәре бәя бирә: «Ә сез беләсезме Дәүләтъяровның кем икәнен? Белмәсәгез, белегез! Ул Татарстан — татарлар өчен генә дип, руслар РСФСРга күчсеннәр, ә Татарстан җөмһүрияте Федерациядән чыксын, үзенә бер дәүләт булып яшәсен дип дәгъвалаучы ата милләтче, булачак татар дәүләте өчен кадрлар хәзерләп йөрүче, татар студентларына махсус стипендия түләү өчен Казан нэпманнарыннан акча җыючы бер контр!» Дәүләтъяровка әнә шундый тамга сугыла. Бу мисаллар суверенитетка, мөстәкыйльлеккә бару юлында җөмһүриятебез үткән фикер көрәше тарихын да күз алдына китереп бастыралар.

* * *

Мин монда күмәкләштерүнең күбрәк кеше җанын әрнеткән якларына, шуларның әдәби әсәрләрдә чагылышына тукталдым. Ләкин, моңа карап, повесть, романнарда колхозлаштыру тоташ тәнкыйть рухында гына тасвирланган икән, дигән нәтиҗә калмасын. Ул, хакимият идеологиясенә яраклы рәвештә, кирәкле, зарури бер үзгәреш итеп сурәтләнде. Әмма, шуның белән бергә, безнең әсәрләрдән колхозлар гел балкып торган йөзләре белән генә дә күренмиләр. Бу хәрәкәтнең бик җитди драматик төеннәре дә яктыртыла әсәрләрдә, колхозларның мәҗбүри хәрәкәт буларак оешуы, законсызлыкның көчәюе, әхлак дәрәҗәсенең түбәнәюе, кешенең кадере кимүе, хакимият тарафыннан яклау таба алмавы хикәя ителде. «Утызынчы ел», «Вөҗдан» кебек әсәрләрдә әдипләрнең эчтән көюләре, әрнү-сызланулары нык сизелә. Бүгенге көндә әлеге роман, повестьлар чорның поэтик документы булып хезмәт итәләр, дәвернең сулышын тоярга булышалар, бик мөһим эстетик вазифа башкаралар. Бөтен хикмәт — аларда бәян ителгән хәятны объектив дөрес аңлата белүдә. Тискәре күренешләр күпчелек әсәрләрдә урын ала бит. Аңа карап без ул әсәрләрдән баш тартмыйбыз. Күмәкләштерү турындагы роман, повестьларда да нәрсә уңай, нәрсә тискәре икәнен бүгенге аң яктылыгында бәяли белергә, тискәренең чыганагын анык төшендерергә бурычлыбыз. Сәяси репрессияне гаепләп тә, мәдәни репрессиягә өндәү үзен акламас дип уйлыйм.

## Фәнис Яруллин

# АЧЫ ЯЗМЫШ СӘХИФӘЛӘРЕ

Узган ел «Казан утлары»ның 6—7 нче саннарында Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» дигән күләмле генә повесте басылып чыккан иде. Нишләптер бу әсәр игътибардан читтә калды. Хәер, бездә күрмәмешкә салыну чире бар инде. Кайбер сәбәпләр аркасында минем үземә дә бу әсәрне соңарып укырга туры килде. Вакыйгалар божралы сюжет аша эзлекле ачыла. Әсәрнең мускулы тыгыз, теле әйбәт. Артык җөмләләр юк дәрәҗәдә.

Бу повесть нәрсә турында соң? Әлеге сорауга кыска гына җавап бирергә уйласак: әсәр унике яшьлек Кәбир исемле малайның язмышы турында диярга мөмкин. Ләкин бу информация гына укучыга берни аңлатмас.

Әсәр Кәбирнең юлга җыенуыннан башлана. Менә ул Зөлхиҗә әбиләрендә. Малай Зөлхиҗә әбиләренең бәрәңге-ипиләрен эзләп-эзләп үзенең утлыкка яшерелгән юл капчыгына җыя. Дүрт көнлек юлга әзерләнә ул. Әмма Зөлхиҗә әбиләренең ризыкларына кул сузу малайга гаять авыр. Автор монда урлашырга тормыш мәҗбүр иткән малайның халәтен аңлату өчен бер кызыклы деталь тапкан: ул юлда ашарга дип әбиләренннән чәлгән ипине уң кулы белән түгел, сул кулы белән ала. Сул кул, әйтерсең аныкы түгел. Һәм бу деталь уникe яшьлек малайның холкына бик ябышып тора. Укучыда кечкенә геройны кызгану һәм аны кичерү хисе кузгала.

Уникe яшьлек Кәбир нишләп әбиләренә килеп чыккан соң әле? Нигә ул алардан качарга йөри? Әсәрне укый башлау белән күңелдә шушы сорау туа. Баксаң-күрсәң, моннан берничә көннәр элек Кәбир үзенең әнисе белән колхозның Бамбук исемле атын җигеп, Оренбург читендәге совхозда яшәп ятучы әнисенең апасы Зөлхиҗә әбиләренә барган булган икән. Дөресрәге, Зөлхиҗә әбиләренең өметләндергеч хаты аларны монда тартып китергән. «Безнең, ходайга шөкер, кара булса да, ашар икмәгемез, саварга сыерымыз бар, бәрәңге, кишер-чөгендерне әйткән дә юк. Килгән хәлдә бер-ике капчык бәрәңге, берәр пот он, бераз атланмый алып китәр идеңез...»

Мондый хат, әлбәттә инде, тормышның очын очка ялгап яшәүче Кәбир белән аның әнисенең күңеленә сары май булып ята. Әйе, Зөлхиҗә әбиләре чагыштырмача әйбәт яшиләр. Аның ире Муса совхозда тракторчы. Кайчандыр кулак дип туган якларыннан сөрелеп, биредә икмәкле, ягъни «һавасыннан да җитлеккән арыш исе килгән» якларда төпләнеп калган алар. Кулларыннан килгән кадәр, әнә, Кәбирләргә дә ярдәм итмәкчеләр. Ләкин, хәерчегә җил каршы дигәндәй, монда килгән төндә үк боларның атларын бүре яралый. Куркып, атлары аягын да сындыра. Ә сугыштан соңгы чорларда колхозның ат тикле атына зыян китерсәң, түрәләрдән рәхим-шәфкать көтмә инде!

Кәбирләрнең атын яралаган Соры бүре дә монда ниндидер эчке мәгънәгә ия. Ул гади бүре генә түгел, каһәрле язмыш символы да. Авторның «Соры бүре үзенең корбанын болай гына калдырмаячак, янадан да эзәрлекләячәк» диюе алдагы бәлаләргә ишарә булып яңгырый. Чыннан да, Кәбирләрнең язмышы җиңелдән түгел. Атасы сугышта һәлак булган. Бабаларын һәм аның туганнарын кулак дип авылдан сөргәннәр. Бабасы акылдан язып кайта.

Инде менә колхозның бүре яралаган атын илле чакрымдагы совхозда калдырып, Кәбир белән әнисе Сания авылга кайтып төшә. Шушы көннән Кәбирләргә якты тормыш бетә. Кайчандыр үзенең артыннан йөргән Галләм, элеккe үчләрен алырга да җай чыгуга сөенеп, Санияне эзәрлекли башлый. Бөкебаш Галләм — колхозда бригадир, ул участковый Сәйфуллин белән дус. Колхоз рәисе Зәйнетдин дә Галләмнең сүзеннән чыга алмый. Аның әләкләреннән куркып яши. Мондый Галләмнәр сугыш һәм аннан соңгы чорны чагылдырган әсәрләрдә шактый күп тасвирланган иде инде. Автор монда Галләм характерын ачуда кызыклы гына штрихлар тапкан. Мәсәлән ул, кайбер кире персонажлардан үзенчәлекле буларак, ачуыннан катып кына йөрми, ныграк эчеп алса, үзе эзәрлекләгән кешеләрне җәлләп, чын-чынлап елый. Әлеге елавы белән үзенә карата кызгану хисләре тудыра. Шуның белән яшәүчән һәм куркыныч та Галләм ишеләр.

Әнә Санияләргә дә ул участковый Сәйфуллин һәм депутат Сажидә белән килеп керә. Әйберләрне язу башлана. Түрәләргә сөяркә булып йөрүче кәнтәй депутат Сажидә Саниянең сандык төбендәге беләзек, йөзек-алкаларын тартып чыгара. «Теге вакыт фронт өчен әйберләр җыйганда бирмәгән иденмени, калдырып әйбәт иткәнсең»,— дигән булып, Санияне чеметкәләп ала.

Тиздән Санияне төрмәгә алып китәләр. Менә шунда инде әнисен коткарыр өчен унике яшьлек Кәбир тәвәккәл адым ясый: беркемгә әйтми-нитми генә авылдан чыгып китә дә, Зөлхиҗә әбиләрендәге яралы атны авылга алып кайтмакчы була. Ә ара илле чакрым!

Үзенең аты белән нәни герой бер тән, бер җан булып бара. Ул аты белән сөйләшә. Ат та аңа җавап кайтара. Һәм бу, ничектер, бик табигый килеп чыга. Аты киреләнсә малай бер атына, бер үзенә суга. «Менә күр, сине генә түгел үземне дә чыбыркылыйм»,— ди. Минемчә, әсәрнең ин уңышлы урыннары нәкъ менә шунда — ир белән атның кушылуында. Мондый урыннарда әсәргә тирән фәлсәфә, шигърият килеп керә. Авторның фәлсәфәсе белән геройның уйлары бергә кушылып тормышның, яшәешнең беркемгә дә җинел түгеллеген искәртә. Әгәр әсәрдә нәни геройның эчке монологлары автор фикерләре белән үрелеп бармаса, повесть сугыштан соңгы авыл тормышын чагылдырган татар әдәбиятындагы йөз дә беренче һәм гадәти бер әсәр булыр иде.

Малай дүрт көнлек юлны үткәнче укучы аның бөтен тормышы белән танышырга өлгерә. Кәбирнең үткәне катлаулы һәм гыйбрәтле булган кебек, әлеге дүрт көнлек юлда да аңа шактый мажараларга очрарга туры килә. Уйламый да барганда чегәннәр килеп чыгып, аның атын алып китәләр. Кәбирнең, әйтерсең, атын түгел, бөтен өметләре, ышанычлары, хыяллары белән бергә йөрәген умырып алалар. Ул өзгәләнеп елый. Әгәр атыннан коры калса, аның өчен бөтенесе бетте дигән сүз бит. Әнисенең дә башы төрмәдә чериячәк! Кәбир өйдән өйгә йөреп, хәер эстәргә тиеш булачак. Әйе, малайның өмете, тормыш тоткасы — шушы аксак ат. Шуңа күрә ул, куркуын җиңеп, чегәннәр артыннан китә. Чегәннәр атны үзләренең таборларына алып кайталар. Алар арасында да кешелекле бәндәләр бар икән бит: әнә табор башлыгы Кәбирнең тишек чабаталарын, капчыгындагы юлга дигән бәрәңгеләрен күреп, малайны кызгана. Атны биреп җибәрергә куша. Дөрес, Кәбир атны кулдан ычкындырмас өчен үзе дә нык тырыша: ялына-ялвара, биеп тә күрсәтә. Чегәннәр хәтта моның иске чабатасы урынына чүәкләр дә биреп җибәрәләр.

Юлда рәхимле кешеләр шактый очрый Кәбиргә. Чуваш Чтапан дәдәй, аның кызы Настя. Настяның мәхәббәте. Бу мәхәббәт күздән яшь китерерлек. Күңелендә әле хис уянмаган малайга үзенең яратуын аңлата алмыйча гаҗиз булган үсмер кыз фаҗигасе. Башка бер автор булса, укучының нервыларын бераз кытыклап алыр өчен Настяны чишендереп ташлар иде. Чөнки сюжет тукымасында моңа урын бар. Җитмәсә Нәстүк малайга: «Өйдә, су кереп чыгабыз»,— дип тәкъдим ясап тора. Бер-берләренә кысылышып ятып төн кунганда да әллә нинди «мәхәббәт мажаралары» белән укучыны шаккатырып булыр иде. Ләкин автор мондый арзанлы «шаккатыризмнар» юлыннан китмәгән. Аның нияте кырыс хакыйкатьне тормыштагыча күрсәтү. Һәм, чынлап та, әсәргә заман сулышы өрәм дип, Кәбирне мондый мавыгулар сукмагына тартып кертсә, автор үзенең максатына ирешә алмаган булыр иде. Минем аңлавымча, автор шушы нәни героеның һәм атның катлаулы язмышы аша авыл кешесен җирдән биздерүнең нинди юллар белән эшләнүен күрсәтә. Ат монда гади бер колхоз аты гына түгел, ул кайчандыр Кәбирнең «кулак» бабаларыннан алынган, затлы нәселдән, аннары фронтка озатылып, сугыш афәтләре кичергән, мина ярчыгы эләгеп яраланган, үзенең фронтташ дусты Нәбине үлемнән саклап калган, госпитальләрдә дәваланган. Кыскасы, ир-ат кичергән, ил кичергән барлык авырлыкларны үз иңендә татыган, күтәрешкән. Шуңа күрә автор аны бөтен күңел җылылыгын салып тасвирлый. Бу ат җир кешесенең җаны икәнлеген укучыга һәрдаим сиздереп килә.

Кайчандыр Воронеж якларында бергә яуга кергән Бамбук белән очрашкан, карт солдат Нәбинең күңелендә сугыш хатирәләре кузгала. Алар Бамбук белән чын солдатларча сөйләшеп алалар. Соңыннан, ат саклаучы малайлар йоклагач, Нәби намаз укый һәм намазы ахырында мондый теләкләр тели: «Хәтәр сугышларда башлары югалган ватандашларым, барлык тере һәм тере булмаган рухлар ихтыярына кабул ит, илаһым. Үз табигатең һәм чит табигатьләр иминлеге хакына! Балаларым, балаларымның балалары хакына ошбу Кәбир атлы ятим сабый, рыясыз ат җаны — Бамбук кардәшемне сугышларда исән-аман саклап калдырган канатым итеп, барлык сырхаулардан азат ит, күктән очырт, җирдән йөгерт, илаһым».

Әсәрнең иң тетрәндергеч җире — атны сую вакыйгасы. Кәбир Бамбукны көчкә-көчкә авылга алып кайтып җиткерә. Кайда юмалап, кайда чыбыркылап, кайда артыннан этешеп. Ат, бичара, әҗәле якынайганны сизенгәндәй, авылга якынайган саен адымнарын акрынайта. «Алып кайтма мине колхозга»,— дип Кәбиргә ялварып та карый. Ләкин Кәбиргә атны алып кайтмый ярамый: аның әнисенең язмышы шушы аксак атка бәйләнгән.

Кәбир, өстеннән зур бурыч төшергәндәй, атны алып кайтып тапшыра. Ә иртән торса, дусты Харис аңа коточкыч хәбәр әйтә: «Бамбукны суялар!» Бу хәбәр Кәбиргә маңгаена кусәк белән тондыргандай тәэсир итә. Алар атны суя торган җиргә чыгып чабалар. Бамбукны коткармакчы булалар. Ләкин кая ул, кан исен сизгән бүреләрдәй Аккүз Сафалар, Ярар Ярыяхмәтләр малайларның үзләрен бәйләп ыргыталар. Ат суела. Эченнән дүрт айлык колыны чыга. Аны кычыткан арасына ыргыталар. Автор бу детальгә тирән мәгънә салган. Колынның тумаган килеш анасы карынынннан тартып алынуы, ул матурлыкны, киләчәкне карында ук үтерү белән бер. «Сугымчылар атны арканнардан арындырган арада ул (Кәбир) тагын бер мәртәбә Бамбукҗанның күзенә карады. Бу күзне, бу карашны Кәбир беркайчан да онытмас: нәрсәдер мәңгелеккә өзелде, ир белән ат арасындагы нисбәт җимерелде. Тормыш озак, бик озак мантымас. Җыр тынар, әкият яңгырамас. Табигатьтән мул бирелгән һәм иртә өлгергән зирәк ир акылы белән Кәбир шуны аңлады: ир белән ат арасындагы бүгеннән башланган өзеклек тиз генә ялганмас, һәрхәлдә, егерменче гасырда ялгана алмас. Бу өзеклек кешеләрне бик күп бәлаләргә китерер».

Әйе, җир кешесен аттан аеру аны өметеннән, ышанычыннан аеру иде. Җир кешесе атсыз гына түгел, җансыз калды. Ә җансыз яратып та, нәфрәтләнеп тә, илһамланып та булмый. Шуңадыр, җиргә битараф буыннар килде. Алар инде җир хуҗалары түгел, нинди дер көнлекчеләр генә.

Әсәр Кәбир белән Харисның ат йөрәген имән төбенә илтеп күмүләре белән тәмамлана. Бу малайлар өчен инде җирдә бар да бетте. Алар, бәлки, начар юлга да басмаслар, әмма һавадагы арыш исеннән тәм табып, ат йөздерүләрдән ләззәт алып, яңа туган колыннарга сокланып, сабантуйларда атлар чабышыннан әсәрләнеп яшәүче җир кешесе булмаячаклар.

Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат»ын укыгач колак төбендә озак кына нәни геройның: «Мбамбо-бимбо. Сама-рана-сама»,— дигән сәер сүзләре яңгырап тора. Болар ниндидер шигъри лейтмотив булып, Кәбирнең әле малайлыктан чыгып җитмәвен, шул ук вакытта кырыс чынбарлыкка каршылыгын күрсәтәләр.

Әсәр бетте. Атны, дөресрәге, җирнең җанын тотып суючыларга күңелдә нәфрәт кузгалды. Автор үз теләгенә иреште. Авыл белән, атлар белән бергә җаныбызның да бер өлешен югалтуыбызны без бүген генә аңлый башладык шул әле...

**Хөрмәтле укучылар!**

Журналыбыз битләрендә сөйләшү дәвам итә. Сездән хатлар, фикерләр, мәкаләләр көтәбез.

# КӨНБАТЫШ БАШКОРТСТАННЫҢ БОРЫНГЫ ТЕЛЕ

Урындагы фәнни, публицистик әдәбиятта төньяк-көнбатыш Башкортстан кайчандыр тоташы белән башкортча сөйләшкән дигән фикер яши. Бу төбәкнең хәзерге теле (көнбатыш диалект дигәннәре) башкорт теленең татар теле йогынтысына бирелүе нәтиҗәсендә акрынлап урнашкан, дип исәпләнә. С. Миржанованың язуына карагаида, монда өлкән буын кешеләре, имештер, һаман да әле үз телләрен өзеп кенә «татар теле» дип атамый. Алар, әлбәттә, хәзер аны «башкорт теле» дип тә әйтә алмый. «Үзебезчә тел инде»,— диләр.

Күп кенә авторлар телнең мондый хәлен җирле халыкның тарихы белән бәйләп аңлатырга тырышалар. Төньяк-көнбатыш Башкортстанда, куәтле демографик процесслар аркасында, халык саны нисбәтенең үзгәрүенә ишарә ясала. Бу җәһәттән XVIII гасырның азагы — XIX гасырның башы үзенчә бер чик итеп алына. Шушы чиккә җиткәнче монда, татарлар арта барган хәлдә, башкортлар күпчелек саклап килгән. Шуннан соң, чикне үткәч, башкортлар акрынлап азчылык хәленә төшкән, ә татарлар өстенлек алып киткән, диләр. Беренче чорда татар теле өчен башкортлашу, ә икенче чорда башкорт теле өчен татарлашу хас булган, дип исәпләнә. Ахыр чиктә, төньяк-көнбатыш Башкортстанда татар теленең кулланылыш тарихы бик кыска, статусы ничектер тотрыксыз булып чыга. Башкорт теле борынгы, төп тел хәлендә торып кала.

Хәзерге Татарстанның читендә, Агыйдел, Ык, Кама, Танып буйларында, башкорт теле XIX гасырда һәм хәтта XX гасыр башларында да әле көчендә булган, дип раслаучылар бар. Ә дәлилләр? Алар, әлбәттә, җитәрлек түгел. Төрле басмаларда, мәсәлән, үткән гасыр шагыйре Гали Чокрый белән бәйле мисал китерелә. Ул Тәтешле районының Иске Чокыр авылында туган. Һәм, язуларында, үзен «ирәкте башкорты» дип атаган. Аның улы Гарифулла Киеков (шулай ук шигъри, тарихи-этнографик әсәрләр калдырган шәхес) үзенең бер кульязмасын «Шура» журналы идарәсеннән, «телең тач башкортча икән» дип, кире кайтарулары турында язган. Аның тагын шундый шигырь юллары бар:

*Бераз әбйәт (бәет) укыр булсам,*
*Теле башкорт, нәдар (ярлы), диләр.*

Менә шуларны тарихчы М. Колшәрипов кына түгел, М. Нәдерголов белән С. Миржанова кебек филологлар да «чокрыйлар башкортча сөйләшкән» дигән нәтиҗә өчен файдалана.

Моның ише фактлар ниндидер сәяси максаты булган публицистик әдәбият өчен, бәлки, ярап та куядыр. Әмма алар гыйльми нәтиҗә өчен ышанычлы таяныч була алмый. Гали Чокрыйның да, аның улы Гарифулла Киековның да язмалары «кырык пичәт» астында түгел. Аларны алып укырга һәм үз фикереңне булдырырга мөмкин. Икесе дә иске татар әдәби теле традицияләрен дәвам итә. Гарифулла Киеков юкка гына: «Төрки белгәннең күрке бардыр»,— димәгән. Атасының да, улының да иҗатында китапча чуар тел артында татарчалык ярылып ята.

Төньяк-көнбатыш Башкортстанның кайчандыр башкортча сөйләшүе турындагы төшенчә фәнгә исбатлау юлы белән түгел, аксиома рәвешендә кертелә. Моның өчен бердәнбер нигез — җирле халыкның тарихи язмаларда (һәм өлешчә хәзер дә) башкорт дип аталуы. Ә борынгы тел (җирле сөйләш) үзе нинди булган? Аның фонетикасы, грамматикасы нинди? Моны әле беркемнең дә тасвирлап биргәне юк. Шуңлыктан аның хәзерге фәндә урнашкан «башкорт теле» төшенчәсенә мөнәсәбәте турында сүз алып бару да читен. Ныклап таяныр нәрсә юк.

Безгә башта шушы борынгы сөйләшне ачыкларга тырышырга кирәк. (Шуннан аның кайсы телгә караганлыгын әйтү кыен булмас.) Ләкин моны ничек эшләргә? Ул сөйләшнең эзләрен каян, ничек табарга? Монда менә шулай «тикшеренү материалы һәм методикасы» дигән шактый четерекле мәсьәлә калкып чыга.

Эшне, күрәсең, борынгы язмалардан башларга кирәктер. Фәндә аларны тел тарихын өйрәнү өчен иң уңай һәм ышанычлы чыганак итеп карыйлар. Төньяк-көнбатыш Башкортстан территориясендә үткән гасырлардан калган тарихи истәлекләр күп. Бу исәпкә, аерым алганда, Пугачев хәрәкәте белән бәйләнешле документларны кертергә була. Табылган язмалар инде шактый өйрәнелгән дә. Казанда Ф. Фасеев, Ф. Хисамова, Уфада Р. Халикова кебек галимнәрнең хезмәтләре чыкты. Нәтиҗә нинди? Иске язмалар көнбатыш башкортларының сөйләмә телен күз алдына китерәме? Моны раслау кыен. Өч төрле нәтиҗә билгеле: 1) Тарихи истәлекләр татар әдәби телендә (икенче караш буенча, иске төрки тел белән) язылган. Бу тел үзенең асылы белән ясалма күренеш: төрле кардәш (һәм кардәш түгел) телләрдән, диалектлардан, төрле тарихи катламнардан булган лексик, фонетик, грамматик үзенчәлекләрне берләштерә; 2) Иске язмаларда, шуның белән бергә, татарча сөйләм теле үзенчәлекләре чагыла; 3) Язмаларның башкорт теле белән туры бәйләнештә булуы ачык билгеләнми. Р. Халикова, мәсәлән, гарәп әлифбасында **з, с, һ** авазларын билгели торган хәрефләр булса да, иске язмаларда башкорт теленең бу авазлары чагылыш тапмаган, ди. Аларда башкорт теленең үзенә генә хас грамматик формалары да аерылып тормый.

Күренүенчә, әлеге язмаларны безнең максатта файдалану уңайсыз: аларның җирле сөйләш белән бәйләнеше хәзергә катлаулы мәсьәлә булып кала. Аларда табылган сөйләм теле күренешләре (татарчалык) шушы төбәккә хас булганмы, әллә әдәби тел белән бергә читтән (Казан ягыннан) килгәнме — моны ачык әйтеп булмый.

Максатка туры килгән язмаларның булмавы төньяк-көнбатыш Башкортстанның борынгы сөйләшен табигый бөтенлегендә (җөмләләр, тоташ сөйләм рәвешендә) күз алдына китерергә мөмкинлек бирми. Ләкин сөйләшнең аерым билгеләрен эзләргә барыбер урын кала. Без монда, беренче тапкыр буларак, бөтенләй башка төр материалга таянып эш итмәкчебез. Патша администрациясенең Башкортстан тарихына караган бай архивы сакланган. Менә шунда көнбатыш башкортларының меңнәрчә исемнәре теркәлгән. Ыру-кабилә, җир-су, авыл-шәһәр, гореф-гадәт, һөнәр-дәрәҗә атамалары күп. Болар, билгеле, урысча транскрипциядә бирелгән, җирле сөйләш үзенчәлекләрен тулы көенчә сакламаган. Әмма мөһим фонетик (урыны белән — грамматик) закончалыклар урысча текстка системалы рәвештә күчә барган.

Шулай итеп, без урысча эш кәгазьләрендә чагылыш тапкан җирле сөйләш үзенчәлекләрен барларга кирәк дип исәплибез. Тикшеренү материалы итеп XVII гасырның икенче яртысыннан XVIII гасырның соңгы чирегенә кадәр язылган рәсми документлар («Материалы по истории Башкирской АССР. Москва. 1936, 1949, 1956) алына (ары таба кыскартып: МИБ).

Бу төр язмаларның борынгы сөйләш үзенчәлекләрен билгеләү өчен ярарлык һәм өметле чыганак булуы беренче карашка ук күренеп тора. Әйтик, башкортлар арасындагы чуалышлар турында хөкүмәткә җибәрелгән рәсми кәгазьләрнең берсендә (1709 ел) бер үк төрки исемнең ике төрле язылышы игътибарны тарта: бер биттә — Кучюм, ә икенче биттә — Кусюм. Хикмәт нәрсәдә? Сүз беренче очракта Себер татарлары ханы, ә икенче очракта Казан юлы башкорты турында бара. Документны төзүче урыс кәнсәчесе (Иван Топильский), аңлы рәвештәме-түгелме, барыбер, татар исемен ч белән, ә башкорт исемен с белән теркәп куйган. Документта, шулай итеп, шәхеснең кайсы халык вәкиле булуы, кайда яшәве белән бергә, тел үзенчәлеге чагылыш тапкан. (МИБ, 1936, 258—259 битләр). Мондый фактларны күпләп җыеп, системалы анализ ясасаң, аерым төбәкләрнең телен ярыйсы ук чамаларга була.

Без караган чорда (100 елдан артык вакыт эчендә) якынча исәп белән 10 500 шәхеснең исеме теркәлгән. Шуларның 30—40 проценты — урыс, угыр-фин исемнәре, 60—70 проценты — төрки исемнәр. Бу соңгы төркемдә җирле халык (башкорт) исемнәре 90 процент чамасы. Калган өлешне күчеп килүчеләр (Казан татарлары, мишәрләр һәм башка төркиләр) алып тора. Тикшеренүче өчен менә никадәр материал!

Билгеле, бу материал тулы күләмендә безнең максатка хезмәт итә алмый. Аны, беренчедән, территориаль яктан чикләргә кирәк була. Без монда тик төньяк-көнбатыш Башкортстанда яшәгән (башкорт булып теркәлгән) кешеләр-

нен исемнәрен алабыз. Икенче мөһим принцип: безгә, югарыда күргәнебезчә, башкорт телендә бер төрле, татар телендә икенче төрле әйтелә (телләрне аера) торган исемнәр кирәк. Аларны дүрт төрле фонетик тәңгәллек буенча сайлыйбыз:

1. **Татарча ч, башкортча с.** Мәсәлән: Чурагол — Сурагол, Илчебай — Илсебай, Балтач — Балтас.

2. **Татарча с, башкортча һ.** Мәсәлән; Сабанчы — һабансы, Сәргол — Һәйәргол, Сарыбай — Һарыбай.

3. **Татарча ж, башкортча й.** Мәсәлән: Җәлил — Йәлил, Атҗитәр — Атйитәр, Җантимер — Йәнтимер.

4. **Татарча ж, башкортча ж.** Мәсәлән: Хужа — Хужа, Хажгали — Хажгали, Нәжибә — Нәжибә.

Төрки исемнәрне урысча транскрипциядә ничек бирү мәсьәләсе теоретик планда махсус эшкәртелмәгән. Шулай да гамәли урнашкан принциплар инде бар. Алар төп (чыганак) тел үзенчәлеген мөмкин булган дәрәҗәдә саклауны күздә тота.

XVII—XVIII гасырларда патша администрациясе документларында теркәлгән исемнәрне шул җәһәттән күзәтик. Система өчен аларны югарыдагыча дүрт төркемгә бүлеп алабыз.

Татарча **ч**, башкортча **с** белән йөри торган исемнәр. Урысча текстта (транскрипциядә) һәр ике вариант очрый. Мәсәлән: **ч** белән (жәя эчендә кабилә күрсәтелә): Акчуваш Юкачев (елдәк), Аккыш Тленчеев (шәмшәде), Казакай Чурашев (каңлы), Коштан Чулаков (дуван), Чураш Аювчин (танып), Колый Балтачев (су-таныи), Чаптар Сартыков (бүләр), Чермыш Юсупов (гәрә), Тойчибай Сабанаев (гайнә), Чурагул Дускеев (ирәкте), Лачин Ибаков (каршен), Илчибай Буляков (балыкчы).

**с белән:** Кусюм Якупов, Балтас Агышев (янәй), Каскын Татлыев (шәмшәде), Биксентей Тиктимекеев, Акман Аксурин (гәрә), Бабис Казакаев (дуван). Кайбер очракта **с** авазы **з** белән бирелә, мәсәлән: Балтач Кузюмов, Козюм Беккенин (гәрә).

Татарча **с**, башкортча **һ** белән йөри торган исемнәр. Болар транскрипциядә тик **с** белән бирелгән. Мәсәлән: Сатлык Кучуков, Сарбай Илкеев (таныи), Сарыбай Игиликов, Сарыбаш Аимбетов (ирәкте), Сатый Биккулов, Сармаш Ураев, Сююндук Уразаев, Сююш Беккенин, Сыртлан Аитов (гәрә), Сатылган Бердыков (шәмшәде), Сагандык Мусин (янәй) Суяргул Агабеков (бүләр), Арыкбай Сатлыгаков (эчке елан).

Исемнәрнең х, г белән бирелеше (башкортча һ урынына) бөтенләй очрамый.

Татарча **ж**, башкортча **й** белән йөри торган исемнәр. Транскрипциядә **ж** авазының **з** яки **дж** белән бирелүен, ә **й** авазының үзгәрешсез калуын күтәргә була. Чынында тарихи документларда **з** варианты өстенлек ала. Мәсәлән: Кинзя Ишимбетов (эчке елан), Кинзибай Акчувашев (елдәк), Акзигит Карамшаков (дуван), Касым Зюванов (гәрә). **З** урынына **д** куллану бар, мәсәлән: Тимяш Киндикеев (таныи), **ж** кайвакыт **ч** белән бирелә, мәсәлән: Коштан Чумаков (каңлы), Мусала Чапаров (ирәкте).

Башкорт телендә ишарәле **й** варианты сирәк. Мәсәлән: Янсура Ногаев (елан), Ямил Илчигулов (дуван), Янаберя Мустаев (шәмшәде).

**Ж — ж** тәңгәллеге транскрипциядә ачык аерылмый. Татарча **ж** варианты, югарыда күргәнебезчә, **з** белән бирелгән. Башкортча **ж** варианты транскрипциядә сакланмаган, **з**, **й** белән алмашынган. Нәтиҗәдә исемнәрнең татарча һәм башкортча фонетик вариантлары бер-берсенә каршы куелмый башлаган.

Теркәлгән исемнәрнең җирле сөйләштәге яңгырашын транскрипция нигезендә реконструкцияләп, түбәндәге исемлекне төзергә мөмкин.

1. Транскрипциядә татар теле үзенчәлеген саклаган (башкортча варианты очрамаган) исемнәр:

**ч белән:** Илче, Илчегол, Илчебай, Илчембәт, Көчкилде, Теләнче, Чирмеш, Акчирмеш, Чувашай, Акчуваш, Урманчы, Ыкчыбай, Туйчы, Туйчыбай, Лачын, Ялчы, Борчак, Тыныч, Кичмәк, Күчембай, Карчыга, Яңгырчы, Казанчы,Чучка, Чулак, Алчокыр, Чура, Чуракай, Чүрәкәй, Чураш, Чурагол, Байчура, Бичура, Бикчура, Колчура, Төмәнчура;

**с белән:** Сабанчы, Сабанай, Сыртлан, Сакбай, Сатлык, Сатылган, Сатлыгак, Сатыш, Сандык, Сагындык, Сарбай, Сарыбай, Сарбаш, Сармаш, Сәзми, Сөендек, Сәргол, Сөеш, Сәрмәт, Сәлек, Сырым, Кансуяр;

**ж белән:** Кинҗә, Кинҗәбай, Җомак, Җобан, Атҗитәр, Акҗегет, Байҗегет, Җома.

2. Татарча да, башкортча да теркәлгән исемнәр: Көчек-Көсәк, Балтач-Балтас, Күчем-Күсем, Акчура-Аксура, Янчура-Йәнсура.

3. Тик башкортча вариантта очраган исемнәр: Каскын, Корос, Бәбес, Биксәнтәй.

Анализны дәвам итеп, татарча һәм башкортча яңгырашлы исемнәрнең кулланылыш ешлыгы турында фикер йөртергә мөмкин. Чура нигезле исемнәр 52, Сура нигезлеләре 2 тапкыр очрый. Көчек — 18, Көсөк — 3, Балтач — 4, Балтас — 7; Күчем — 1, Күсем 4 тапкыр теркәлгән.

Бездә кабиләләр буенча да мәгълүматлар бар. Мәсәлән, янәй кабиләсенә караган исемнәр бөтенесе 89, шуларның 78 е — татарча, 11е — башкортча. Бу саннар гәрә кабиләсендә — 50 (40—10); елан кабиләсендә — 32 (30—2); танып кабиләсендә — 22 (18—4); каңлы кабиләсендә — 15 (14—1); шәмшәде кабиләсендә 14 (12—2); гайнә кабиләсендә — 6 (5—1). Моннан тыш елдәк кабиләсеннән 13, бүләр кабиләсеннән — 10, уран кабиләсеннән — 6, кыргыз кабиләсеннән 5 исем теркәлгән, шуларның бары да татарча.

Шулай итеп, статистик анализ фонетик анализ материалларын тагын да көчәйтә. Күпчелек исемнәр транскрипциядә татар теле үзенчәлеген саклаган. Башкорт теле үзенчәлеген чагылдырган исемнәр бик аз (уннан бер өлеш).

Күзәтүләрдән беренче нәтиҗә шундый: Төньяк-көнбатыш Башкортстан халкының сөйләм теле үзенең мөһим фонетик үзенчәлекләре (төп яңгырашы) белән XVII—XVIII гасырларда ук хәзерге хәленә (татар теленә) якын булган яки бөтенләй туры килгән. Бу сөйләштә чатнап торган татарча (яки гомумтөрки) **ч** авазы өстенлек иткән. **С** урынына **һ** куллануның эзе дә юк. **Җ** авазы үзен сиздереп тора.

Тагын шуны әйтергә була: бу төр үзенчәлекләр, төньяк-көнбатыш белән чикләнмичә, көньяк-көнбатышка да җәелгән дигән тәэсир туа. Мең ыруларыннан алынган 82 исемнең 75е, юрматы ыруларыннан алынган 28 исемнең 24е, табын ыруларыннан алынган 30 исемнең 28е татар теленә хас. Көньяк кыпчак ырулары тоташы белән гомумтөрки яңгырашлы исемнәр (36 берәмлек) калдырган.

Шулай итеп, көнбатыш Башкортстанның моннан берничә гасыр элек үк, нигездә, татарча сөйләшүе турындагы нәтиҗә өчен житди дәлилләр бар. Ләкин сүзне шуның белән чикләргә ашыкмыйк. Монда хәзергә ачыкланмаган сораулар торып кала. Без китергән ономастик материал, чыннан да, жирле сөйләш фонетикасын чагылдырамы? Аңа ышанырга мөмкинме? Монда татар әдәби теленең һәм, гомумән, Казан ягы укымышлыларының йогынтысы юкмы?

Бу сорауларга җавап бирү өчен XVII—XVIII гасырлардан калган документларның нинди шартларда язылуын күз алдына китерергә кирәк.

Без караган материаллар 1714 елга кадәр Рәсәй патшалыгының Уфадагы приказ йортында, шуннан соң Уфа провинция кәнсәсендә, аның Бөре, Каракүл, Минзәлә крепость (воевода) идарәләрендә, Оренбург губерна кәнсәсендә язылган. Арада үзәк хөкүмәт департаментларының рәсми кәгазьләре дә бар. Документларның төренә карап, аларны язу тәртибе дә беркадәр аерыла. Аннары, документларның төзелеше вакыт үтү белән үзгәреп торган, камилләшкән. Шулай да бер мөһим үзенчәлек сакланган. Күпчелек очракта документны язган, юридик актта катнашкан һәм аңа шаһит булган кешеләр, тәрҗемәчеләр күрсәтелә. Эш кәгазе гадәттә шундыйрак сүзләр белән тәмамлана: **«Писал подьячий (...) Башкирец (...) тамгу свою приложил (...) У сей записи свидетели (...) Толмачил (...)»** Безне монда документларны үз кулы белән язган һәм юридик акт вакытында тәрҗемәче булып катнашкан шәхесләр кызыксындыра. Төрле чорда төрлечә подьячий, писец, пищей дип йөртелгән кешеләр кемнәр? Тылмач яки тәрҗемәче функцияләрен кемнәр үтәгән? Тарихи язмаларның тел үзенчәлеге (бигрәк тә төрки исемнәрнең транскрипциясе) шулар белән нык бәйләнгән.

Документларны язу-теркәү белән шөгыльләнүчеләр (подьячий, писец, пищик) турында шуны әйтергә була. Алар — барысы да урыслар. Татар теленә дә, башкорт теленә дә мөнәсәбәте булмаган кешеләр дип уйларга кирәк. Алар янында һәрвакыт тәрҗемәче басып тору үзе үк шул турыда сөйли.

Рус администрациясе рәсми язышу, кәнсә эшләрен чит халык вәкилләренә (төркиләргә) ышанып тапшыра да алмаган, әлбәттә.

Тылмач һәм тәрҗемәчеләр мәсьәләсе беркадәр катлаулырак. Иң элек, шунысы игътибарны тарта: бу ике вазифа атамасы эчтәлекләре белән бер-берсенә бөтенләй үк туры килеп бетми. Аларның үзләренә генә хас үзенчәлекләре бар. Тылмач — телдән тәрҗемә итүче. Даль сүзлегендә ул шулай аңлатыла да: «Толмач — переводчик с языка на язык: в большинстве случаев устный, словесный переводчик». Тәрҗемәче (переводчик) язма текст белән эш итә. Гомумән, шул эшкә сәләтле кеше. Аерма эшнең ысулына гына да кайтып калмый. Тылмач эчтәлекне үз сүзләре белән якынча аңлата, ә тәрҗемәче төгәл итеп күчереп бирә.

Шунысы кызык, тарихи документларда тылмач булып күбесенчә урыслар, ә тәрҗемәче (переводчик) булып төркиләр теркәлгән. Бу ике вазифа атамасы шәхеснең титулы рәвешендә бирелмәгән очракта да, урысларга карата «толмачил», төркиләргә карата «переводил» сүзләре кулланылган.

XVII—XVIII гасырларда язылган эш кәгазьләре буенча билгеле тылмачлар һәм тәрҗемәчеләр 120 дән артып китә. Алар арасында төркиләр — 10—15 кеше, калганнары — урыслар. Төрки исем-фамилияле тәрҗемәчеләрне монда тулысынча китерергә була. Чит ил эшләре коллегиясендә Мөхәммәт Тәвкилев, Уфа провинция канцеляриясендә Килмөхәммәт Ураков, Абдулла Кирәев, Уфа воевода идарәсендә Ишмөхәммәт Рәхимголов, Карый абыз Рәхимголов, Уфа приказ йортында Сүнчәләй Кирәев, Оренбург губерна кәнсәсендә Роман Уразлин, Арслан Бикмәтов, Усман Арсланов кебек тәрҗемәчеләр эшләгән.

Эш урынын (җирле администрация идарәсен) билгеләү кыен булган очраклар бар. Күрәсең, кайберәүләр тәрҗемәче вазифасын очраклы рәвештә генә башкарган. Көнгер бистәсеннән Абдулла абыз Йосыпов, Казаннан — Дүсәй абыз Ишкәев, Йосып абыз Ишбулатов, Оренбургтан Мәхмүт абыз Мәмәтбилов шундыйлар исәбеннән булырга охшый (боларны кайбер кәгазьләрдә мулла дип тә күрсәтәләр).

Телгә алынган (төрки исем-фамилияле) берничә тәрҗемәченең татар булуы документаль рәвештә раслана. Мәсәлән, Килмөхәммәт Ураков турында «ясак түләүче татар» («ясащный татарин»), Ишмөхәммәт Рәхимголов турында «йомышлы татар» («служалый татарин») дигән мәгълүмат китерелә. Роман Уразлинның чыгышы белән Свияжск өязеннән булуы күрсәтелә. Бу заманда абыз, мулла дәрәҗәсенә күтәрелгән Карый Рәхимголов, Абдулла Йосыпов, Арслан Бикмәтов, Дүсәй Ишкәев, Йосып Ишбулатов кебек шәхесләрне дә татар дип әйтергә урын бар.

Исем-фамилиясе урысча булган тылмачлар арасында керәшен татарлары эзләргә була. Мәсәлән, Уфа приказ йорты тәрҗемәчеләре Дмитрий Сюзмин һәм Дмитрий Вершинин «яңа чукынганнар исемлегеннән» («новокрещенного списку») дип күрсәтелә. Тәрҗемәче Мишка Сокуровның урыс булмавы төсмерләнә. Ул имза куйганда, өстәп, үзенең икенче (төрки) фамилиясен яза («Ширяев он же», «Ширяев тож»). Урысча исеменең дә Мишка рәвешендә йөрүе үзенчә мәгънәле. Кәгазьләрнең берсендә, текст эчендә, тагын бер керәшен тылмач («Микишка — новокрещенный») телгә алына.

Шулай итеп, чыгышы белән татар булуы исбатланган тәрҗемәчеләр очрый. Ләкин алар — диңгездә бер утрау. Тәрҗемә белән шөгыльләнүчеләрнең күпчелеге (90 проценттан артыграгы) — урыслар. Бу факт үзе үк безнең тикшеренүдә файдаланылган ономастик материалның транскрипциясенә татар йогынтысының ни дәрәҗәдә булуы турында сөйләп тора.

Хәлне тагын да ачыклый төшәргә мөмкин. Безнең материалда төрки исем-фамилияле тәрҗемәчеләр өлеше берничә проценттан артмый. Ул да эзлекле рәвештә татарчалаштырылган берәмлекләрдән тормый. «Ясак түләүче татар» Килмөхәммәт Ураков кулыннан үткән тәрҗемәдә дә, мәсәлән, Нугай юлы башкорты Каскынов фамилиясе үзенең башкортча яңгырашын саклаган.

Димәк, материалның ышанычлылыгы (транскрипциянең сыйфаты) күбесенчә урыслар арасыннан булган тылмачлардан тора. Алар турында нәрсә билгеле? Кайберләренең, мәсәлән, кайсы сословиедән булуы күрсәтелгән. Иван Вяткин, Федор Валов, Филипп Гоголев, Иван Бикетов, Петр Золотухин, Матвей Брякотин — сарай крестьяннары, Иван Никитин, Александр Гордеев, Иван Сундыренин, Федор Найденов — драгун полкы хезмәткәрләре, Алексей Каменев — Оренбург казагы. Боларның тәрҗемәче һөнәрен ничек үзләштерүенә килгәндә, моның урында өйрәнчеклек юлы белән барганлыгы билгеле.

Шундый бер документ игътибарга лаек. Безгә таныш тәрҗемәче Килмөхәммәт Уракованың әби патша Елизавета Петровна исеменә җибәргән мөрәҗәгате (1746 ел). Менә шунда, башка кайбер мәсьәләләр белән бергә, тәрҗемәчеләр мәсьәләсе куела. Уракованы башка өязләрдән килгән тәрҗемәчеләр (урыслар) борчый. Ул аларның урындагы телләрне яхшы үзләштергән кешеләр булмавы турында яза. («Тамошних башкирских и татарских языков много не разумеют»). Аларны җирле халык вәкилләре («ис тамошних иноверцев») белән алмаштырырга кирәклеген әйтә. Бу тагын шуның белән нигезләнә: урысларга төрки телләрдән тәрҗемә итү, гомумән, авыр. Бу телләрдә һәрвакыт күпме булса да гарәп, фарсы сүзләре очрый. Мондый сүзләрне алар аңлый да алмыйлар. Ары таба җирле идарә кәнсәләрендә урыслар арасыннан өйрәнчекләр тоту үзен акламый дигән фикер белдерелә. (МИБ, III том, 562—563 битләр).

Бу чорда урысларга көнчыгыш телләрен укытуны күздә тоткан беренче проектлар гына төзелә. 1733 елда Георгий-Якоб Кер «Көнчыгыш телләре академиясе» проектын тәкъдим итә. Бу, академик А. Кононов сүзләренә караганда, кеше ышанмаслык (фантастик) проект була. Анда, гарәп, фарсы телләре белән бергә, татар теле белгечләре әзерләү максаты куела. Моның зарурлыгы шуның белән аңлатыла: Русия империясе Төркия солтаны, Кырым ханы, кыргыз, үзбәк, башкорт яклары белән татар телендә язышa. Азия дәүләтләреннән укымышлы, итагатьле илчеләр килеп йөри, алар белән әңгәмә кору ихтыяжы бар. Көнчыгыш телләрендәге тарихи язмалар белән эш итәргә туры килә. Ниһаять, көнчыгышта империянең яшерен эшләрен алып бару өчен анда үтеп кērерлек ышанычлы кешеләр кирәк. Боларны урысларның үз араларыннан әзерләү максаты куела.

Ләкин Кер проекты һәртөрле сәбәпләр белән тормышка ашырылмыйча кала. Урысларга татар теле укыту XVIII гасырның икенче яртысында гына башлана. Ул гимназия, университет дәрәҗәсендәге уку йортларына кертелә. Аның белән дини уку йортлары, хәрби училищелар шөгыльләнә. (Бу турыда А. Кононовның «Россиядә төрки телләрне өйрәнү тарихы» дигән китабында җентекле мәгълүмат бирелгән.)

Безнең якта, Уфада, Оренбурда, Минзәләдә, Чиләбедә урыс мәктәпләре 1720 елдан эшли башлый. 1770 елдан аларда татар теле кертелә. Монда күбесенчә дворян, купец, казак һәм солдат балалары алына. Шушы чорда Оренбургта губерна учреждениеләре өчен (беренче тапкыр!) тәржемәчеләр әзерләү эше оештырып җибәрелә. 1763 елда анда 10 кеше укый.

Димәк, безнең игътибарда булган документларда «татар йогынтысы» исбатланмый. Алар урысларга татар теле укытыла, тәржемәчеләр махсус әзерләнә башлаганчы язылган.

Тикшеренүгә икенче бер юнәлеш бирергә дә мөмкин. Җирле администрация хезмәткәрләре арасында моңа кадәр әле телгә алынмаган зур бер төркем бар. Аларны ыру (волость) старшиналары янындагы писарьлар дип йөртәләр. Болар үзләренең чыгышлары ягыннан кемнәр? Һәм җирле администрация документларын язуда ни дәрәҗәдә катнашканнар?

Шунысы билгеле, писарьларны XVIII гасыр урталарыннан урыс администрациясе билгеләгән. Бу эш өчен, барыннан да бигрәк, дәүләт хезмәтендә булган, укый-яза белгән мишәрләр яраклы дип табылган. Мишәр писарьларны башкорт старшиналары янында укымышлы булышчылар гына түгел, урыс администрациясенең «күз-колагы» (яшерен агентлары да) итәргә тырышканнар. Уфа өязе писарьларының ант тексты сакланган. Анда мондый сүзләр бар: җирле идарә мәсьәләләренә кагылышлы указны (1763 елның 11 февралендә чыккан), һәр атна саен укып, старшиналарның исенә төшереп торырга. Әгәр берәрсе (старшинамы-түгелме, барыбер) «император галиҗәнапларының ихтыярына каршы эш кылса», шунда ук язма рапорт бирергә. Рапорт өстенә «яшерен» дип язылган булырга, һәм ул колониаль хакимият ышана торган кеше аркылы гына җибәрелергә тиеш. Писарьлар шундый шартларны үтәргә ант итеп, кул куйган. Аларның урыс администрациясе белән мондый мөнәсәбәттә булуы катгый сер итеп сакланган, серне ачкан кешегә үлем җәзасы яки бөлгенлек янаган. (МИБ, III том, 542—543 битләр).

Мондый миссия белән җибәрелгән кешеләрне урыннарда берсүзсез кабул иткәннәр дип булмый. Еш кына аларны кире какканнар, үз кешеләре белән алмаштырганнар. Әй волосте писаре йомышлы татар Абдулхәсән Йосыповның провинция кәнсәсенә язган хатында, мәсәлән, шундый бер вакыйга хәбәр ителә. 1772 елда провинция кәнсәсе аны волость писаре итеп билгеләгән була. 1776 елга кадәр тиешле икмәген һәм акчасын алып эшли. Ләкин шуннан соң аңа түләүне туктаталар. Писарьлыкка үз араларыннан булган кешене сайлап куялар. (МИБ, V том, 545 бит). Тагын бер факт. Гайнә волосте старшинасы Туктамыш Ишбулатов Екатеринбургка яңа законнар әзерләү комиссиясенә язган рәсми хатында писарьларны читтән китерүне туктатырга тәкъдим итә. Урында да укымышлы кешеләр җитәрлек, дип яза ул (Үзәк тарихи архив материалларыннан, 109 нчы эш).

Шундый каршылыклы көрәш баруына карамастан, бу чорда, XVIII гасырның урталарыннан, писарьларның күбесенчә йомышлы татарлар арасыннан булуын танырга мөмкин. Аңа кадәр (безнең игътибарда булган документларның төп өлеше язылган чорда) патша администрациясе җирле үзидарә эшләренә артык тыгылмаган. Ыру (волость) башлыкларын һәм аның хезмәткәрләрен урында сайлап куйганнар.

Инде волость писарьларының өяз, губерна кәнсәләреннән чыккан документларны язуда катнашуына килгәндә, шуны әйтергә була: алар, әлбәттә, күп

юридик актлар (мәсәлән, жир сату, общинага кабул итү) вакытында арадашлык иткән. Ләкин урысча документларны язу, юридик акт вакытында тәржемәчелек итү аларның вазифасына керми. Безнең тикшеренү объекты булган ономастик материал писарьлар катнашлыгында татарчалашкан дип әйтү дөрес булмас иде.

Тарихи документларны язу шартлары белән танышканнан соң шундый фикер ныгый: транскрипциядә бирелгән ономастик материалның татарчалыгын «чит йогынты» дип раслау өчен нигез юк. Документлар күбесенчә урыслар кулыннан үткән. Татарлар катнашлыгы өлешчә генә. Жирле халык исемнәренең «татарчалаштырылуы» исбатланмый. Алар, күрәсең, ишетү (яңгыраш) буенча теркәлгән. Безнең карашка, транскрипциядә жирле сөйләш фонетикасы чагыла.

Тупланган ономастик материалда жирле сөйләш чагылуын башка (лингвистик характердагы) дәлилләр белән дә расларга мөмкин.

Барыннан да элек, күп кенә исемнәрнең язылышы төрле икәнен әйтергә кирәк. Нинди дә булса традиция (кагыйдә) урнашып житмәгәнлеге күренеп тора. Мәсәлән: **Исламгол** (Изламгул, Ислангул, Истамгул, Сламгул); **Чурагол** (Чурагул, Чюрагул, Черагул, Черегул); **Вәлит** (Валит, Увалит, Уалит); **Кыдрас** (Кадряс, Кодряс, Кудряс, Катрас, Кодряш); **Өмет** (Умет, Умит, Умют, Умят); **Түлкечура** (Тюлкучура, Тюлкучюра, Тулкучера, Толкучюра); **Мәсәгут** (Мясогут, Месогут, Мясегут, Масегут, Мосегут, Мюсогут); **Ибраһим** (Ибрагим, Ибраим); **Мирас** (Миряс, Мряс). Толмач белән писец исемнәрнең яңгырашын үзләре «тота» алган дәрәҗәдә теркәп куйганнар.

Бер үк кешенең исем-фамилиясе күп кабатланган очраклар игътибарга лаек. Әйтик, Таньш волостеның Кыйгазы авылы башкорты Чурагол Туйгилдин 6 документта 52 тапкыр теркәлгән. Документлар төрле вакытта (1709 елдан алып 1717 елга кадәр) төрле кешеләр тарафыннан язылган. (Тәржемәчеләре Уфа приказ йортыннан Андрей Норкин, Любим Кондаков, Георгий Сокуров, Семен Кириллов, Уфа провинция канцеляриясеннән Андрей Вязмитинов.) Мондый шартларда, билгеле, транскрипция бөтенләй бертөрле булып чыкмаган. Исемне Чурагул, Черагул, ә фамилияне Тойгильдин, Тогильдин рәвешендә очратабыз. Ләкин колакка ачык ишетелешле **ч** авазы (татар теле үзенчәлеге) тоташ саклангап. Башкортча **с** варианты бөтенләй кулланылмый. Шәмшәде волостеның Шады авылы башкорты Ибраһим Көчеков 1706 ел белән 1719 ел арасында 5 документта телгә алына. (Тәржемәчеләре Уфа приказ йортыннан Василий Кондаков, Яков Кормщиков, Уфа провинция кәнсәсеннән Дмитрий Новокрещенов, Дмитрий Косаткин). Һәм монда да шул ук хәл: татарча ч эзлекле бирелә. Гәрә волостеның Нугай авылы башкорты Күзекәй Чәрләков 4 документка шулай (**ч** белән) кергән. Документлар Каракүл бистәсендә 1738—1747 елларда теркәлгән; тәржемәчеләре Федор Валов, Семен Ведерников, Матвей Брякотин, Иван Бикетов,— безнең мәгълүматлар буенча, сарай крестьяннары.

Татарча (яки гомумтөрки) яңгырашлы исемнәр янында урыны белән аларның башкортчалары очрау шулай ук үзенчә мәгънәле. Менә берничә документ. 1)Шәмшәде волосте башкортлары жир сата (1709 ел). Арада Чычкан һәм Каскын исемле кешеләр бар. 2) Янәй волосте башкортлары жир өлешенә кертә (1736 ел). Башкортларның берсе Акчура, икенчесе Күсем. 3) Гәрә волосте башкортлары оброк договоры төзи. Аңа Туйчы белән Көсек кул куйган. Татарчалаштыру үзенә күрә бер принцип булса, барлык исемнәр дә татарчалаштырылмас идемени? Бу соңгылары нишләп башкортча калыр иде икән?

Тарих материаллары белән танышып утырганда, жирле сөйләшне билгеләүгә (идентификацияләүгә) турыдан-туры кагылышлы документлар килеп чыга. Сүз ахырында укучылар игътибарына шуларны тәкъдим итмичә булмый.

Барыннан да элек, шул чор тәржемәчеләренең күнбатыш башкортлары сөйләшен ничек бәяләвен белү әһәмиятле. Алар аны татар теленнән аермаганнар. Үзләре тәржемә иткән сөйләшне «татар теле» дип исәпләгәннәр. Үзләрен «татар теле тылмачы» («татарского языку толмач») дип атаганнар. Тәржемәчеләр юридик акт субъекты булып катнашкан очракта, аларның вазифа исеме шулай тулы итеп теркәлгән. Мәсәлән, жир сату турындагы документта: «...запись Бирского городка татарского языку толмачу Любиму Гаврилову сыну Кондакову» (МИБ, III том, 51 бит); жирне уртагыннан эшкәртү турындагы документта: «...запись татарского языку толмачу Дмитрию Игнатьеву сыну Косаткину» (шунда ук, 89 бит); бурычка акча биреп тору турындагы документта: «А порукою в той кабале писаны: татарского языку толмачи Дмитрий Сюзмин, Андрей Вязмитинов, Иван Гавренов» (Шунда ук, 26 бит). Бу биш исем-фамилия 50 ләп документта очрый. Алар шәмшәде, таньш, каршен, елан, дуван, уран, гайнә, бүләр, елдәк кабиләләре сөйләшләреннән тәржемә иткәннәр.

Башкорт булып теркәлгән кешеләрнең үзләренең дә жирле сөйләшкә мөнәсәбәте чагылган документлар бар. Әйтик, жир саткан вакытта «координатларны» аеруча ачык билгеләргә кирәк. Әгәр топонимик объект жирле сөйләштә бер төрле, русча икенче төрле аталса, ул атамаларның икесе дә күрсәтелгән. Шул ук вакытта жирле атама алдыннан «татарча» («по-татарски») дип куелган. Беркадәр сәер бу, ләкин факт. Менә шундый бер документтан өзек: «Лета 1754-го года мая 21-го дня... Байлярской волости башкирцы... дали сию на себя запись в том, что отдали мы... старинные вотчинные свои рыбные ловли, озеро, по-татарски Юлберды, а по-русски Лодеешное...» (МИБ, IV том, 80 бит). Янәй кабиләсе документларыннан (1753—1762 еллар): «Отдали мы вотчинные свои рыбные ловли, озеро, по-татарски Быргыдин, а по-русски Найдан» (шунда ук, 68 бит); «озеро: по-татарски Улу куль, а по-русски Дербешинское» (92 бит); «озеро, по-татарски Кишкинды, а по-русски Осакаревое» (143 бит); «озеро, по-татарски Кииды, а по-русски Малой Сагадак» (204 бит); «озеро, по-татарски Кургу, а по-русски Сомово» (237 бит). Гәрә кабиләсе документларыннан (1762 ел): «...отдали мы... старинные вотчинные рыбные ловли, озеро, по-татарски Ялан, а по-русски Кабан» (238 бит); яки менә үзенчәлеклерәк очрак: «озерки, называемые как по-русски, так и по-татарски Бакаринские» (64 бит).

Безнең карашка, монда «татарча» сүзе очраклы кулланылмаган. Аны жирле сөйләш атамасы итеп кабул итәргә туры килә. Югыйсә жир хужалары исеменнән (беренче затта) язылган документта болай дип әйтү нигә кирәк? Бу урында «татарча» сүзен бары тик «безнеңчә», «безнең телдә» дип кенә аңларга була.

Бер яктан, бу — бик табигый нәтиҗә. Көнбатыш Башкортстан халкы, Казан татарлары шикелле үк, болгар, кыпчак кабиләләренең берләшүе нигезендә оешкан. Телләрнең туры килүе мөмкин. Шартлар бар. Ләкин безнең мондый нәтиҗә, икенче яктан караганда, кабул итү өчен уңайсыз. Ул стандарт түгел. Монда, һичсүзсез, житди каршылык бар: халык үзе — бер төрле, ә теле — икенче... Гадәти «симметрия» өчен йә этноним, йә тел атамасы башка булырга тиеш.

Монда, шулай итеп, фәндә күптән тикшерелә торган мәсьәлә кузгала: «башкорт» сүзе бу урында этнониммы соң? Аны этноним итеп файдаланучылар патша администрациясенең рәсми документларына таяналар. Анда көнбатыш Башкортстан кабиләләре, чыннан да, «башкортлар» дип теркәлгән. Ләкин шунысы билгеле, урыс администрациясе жирле халыкны этник, этнографик (һәм, әлбәттә, лингвистик) төркемнәргә бүлү белән шөгыльләнмәгән. Аны, барыннан да элек, социаль төркемнәр кызыксындырган. Ул эш кәгазьләрендә сословие атамалары кулланган. Әлеге кабиләләр Рәсәйдә бердәнбер, үзенчәлекле башкорт сословиесенә кертелгән, жир мәйданы, ясак шарты буенча төп (этник) башкортлар белән бер исәптә йөртелгән.

Мондый караш белән килешү-килешмәү укучының үз ихтыярында калсын. Аны киләчәктә, һичшиксез, тагын да ачыклыйсы, өстәмә дәлилләр белән ныгытасы бар. Моның ише катлаулы мәсьәләдә, һәрхәлдә, катгыйлык була алмый.

Безнең материал фонетика өлкәсе белән чикләнгән. Без хәзергә үзебезне кызыксындырган борынгы сөйләшнең яңгырашы белән татар теленнән аерылмавын (гомумтөрки характерда булуын) ачык күрәбез. Бу нәтиҗә фәнни әйләнешкә кергән башка кайбер чыганаклар белән дә раслана. Россия Фәннәр академиясенең Санкт-Петербург бүлекчәсе архивында сакланып калган, XVIII гасырга караган кульязма сүзлекләр шуңа бер мисал. Башкорт телчеләре аларны көнбатыш башкортлары арасында язып алынган дип исәпли. Ләкин сүзлекләрдә башкорт теленә хас авазлар теркәлмәве, гомумтөрки фонетика чагылуы танылa. Шуны исәпкә алып, Э. Ишбердин төньяк-көнбатыш Башкортстан сөйләшләрендә гомумтөрки ч һәм с авазлары борын заманнардан бирле үзгәрешсез (**с** һәм **h** белән алмашынмыйча) кулланылган, дигән фикер белдерде. Г. Йосыпов, бу якта табылган борынгы кабер ташларындагы язмаларны өйрәнеп, тагын да кыркурак нәтиҗә ясады. Аның фикеренчә, көнбатыш башкортлары телендәге гомумтөрки фонетик күренеш (әлеге **ч**, **с** авазлары), Казан татарлары йогынтысы гына булып калмыйча, болгар чорыннан ук килә булырга тиеш. 1342—1343 елларда Дуван ыруы зиратына куелган ташта (хәзерге Кушнаренко районы) ч хәрефе бар («тарих ете йүз кырык өчдә»). Икенче ташта (1706—1707 еллар) «сикез», «тамгасы» сүзләре **с** белән язылган).

Без монда үзебезнең нәтиҗәләрне көнбатыш Башкортстан сөйләшләре турындагы беренче гыйльми язмалар белән дә чагыштыра алабыз. Алар XIX гасырның азакларында, моннан 100 ел элек, рус төркологлары А. Бессонов һәм Н. Катанов тарафыннан басып чыгарылган. Боларның беренчесе Минзәлә, Бөре өязләре, Пермь губернасы, ә икенчесе Бәләбәй, Минзәлә өязләре башкортлары

арасында булган. Аларның сөйләшләре, бер яклап, Казан татарлары, ә икенче яклап, көнчыгыш башкортлары теле белән мөнәсәбәттә карала. Көнбатыш башкортлары Казан татарларына иң якын телдә сөйләшә, дигән нәтиҗә ясала. Шул ук вакытта көнчыгыш Башкортстанда бөтенләй башка (үзенчәлекле) тел урнашкан булуы әйтелә. Казан татарлары теле белән Көнбатыш Башкорстан сөйләшләре арасындагы аерма **идән — изән, жакшы — яхшы, ким — кәм, төче — чөче, өйрә — үрә, оят — ыят** кебек мисаллар аркылы күрсәтелә. Һәркемгә аңлашылып торуынча, мондый фонетик үзенчәлекләр көнбатыш Башкортстан сөйләшләрен Казан татарлары теленә кискен каршы куймый һәм башкорт теле белән нык бәйләнешкә кертә алмый. А. Бессонов белән Н. Катанов моны яхшы аңлаганнар. Алар көнбатыш башкортларын урыны белән «татарлашкан башкортлар» дип атарга мәҗбүр булганнар.

А. Бессонов белән Н. Катановның замандашы — этнограф Д. Соколов (башкорт тамгалары турындагы хезмәт авторы) көнбатыш Башкортстан сөйләшләрен башкорт теле системасында карау белән, гомумән, килешеп бетмәгән. Ул башкортларны, һич югы, ике зур төркемгә аера белергә кирәклеге турында яза. Аның раславынча, беренче төркем этнографик нигездә, ә икенче төркем Русия законнары, «Башкортлар турындагы положение» буенча билгеләнә. Бу соңгы төркем (социаль хәле буенча башкорт сословиесендә булган кешеләр) өчтән бер өлешне алып тора.

Ахыр чиктә, шуны әйтәсе кала. Төньяк-көнбатыш Башкортстан сөйләшләре йөз ел элек тә, ике йөз ел элек тә, өч йөз ел элек тә татарча (яки гомумтөрки) яңгырашлы булган. Бу хәлне Казан татарлары йогынтысы дип кенә карарга ярамый. Монда, күрәсең, борынгы бабаларның уртаклыгы үзен нык сиздерә.

Көнчыгыш башкортларына хас сөйләш үзенчәлекләре көнбатыш Башкортстанда җәелеп китә алмаган. Безнең материалда алар нибары уннан бер өлеш тәшкил итә. Шулай булуы гаҗәп тә түгел. Төп башкорт кабиләләре (тәңгәвер, үсәргән, бөрҗән һ. б.) XVII—ЖVIII гасырларга үзләренең хәзерге территориясендә төпләнгән була. Көнбатышта аларның аерым өлешләре генә калган.

Көнбатыш Башкортстанда сөйләм теле, үзенең табигый үсеш юлыннан тайпылып, кискен үзгәрешләргә дучар булган, икенче тел (татар теле) белән алмашынуга барып җиткән дип раслау кыен. Безнең көннәрдә кайбер даирәләрнең, монда халыкны башкортча укытып, аны, имештер, «элекке теленә кире кайтару» идеясе тарихи-лингвистик планда нигезләнә алмый.

**Радик СИБӘГАТ,**
Башкорт дәүләт университетының
татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире,
филология фәннәре докторы, профессор.

# ОНЫТЫЛГАН ШӘХЕС

Татар драматургиясендә беренче булып күп серияле сәхнә әсәрләре язуны башлап җибәргән һәм киноэкранга юл ачкан олы драматург Әхмәт Таҗетдиновның исеме һәм әсәрләре татар театрына, драматургиясенә бәйле мәкаләләрдә еш кына телгә алынса да, аның иҗаты, әсәрләренең социаль яңгырашы турында бүгенге көнгәчә сүз әйтелгәне юк.

Дөрес, бу драматург турында тулы сүз әйтүе кыен. Ул кыенлыкның сере — драматургның бер генә әсәренең дә диярлек сакланмавында (алар шәхес культы чорында юкка чыкканнар) яки табылган кадәресенең дә тулы булмавында: берничә сериядән торган әсәрләрнең йә баштагы, йә уртадагы, яисә соңгы сериясе генә сакланган. Билгеле, күп серияле әсәрләрнең бер сериясенә генә таянып, драматург иҗатына тулы анализ ясау мөмкин түгел.

Драматургның иҗатын өйрәнү хәзер инде авырлаша бара. Аны белгән, иҗатын хөрмәт иткән каләмдәшләре, әсәрләрен сәхнәгә куйган режиссерлар һәм ул әсәрләрдәге образларны иҗат иткән артистларның хәзер инде берсе дә юк. Шулай ук театр сәхнәләрендә һәм киноэкраннарда Әхмәт Таҗетдинның әсәрләре буенча куелган спектакльләрне һәм экранга төшерелгән фильмнарны караган тамашачылар саны да сирәгәеп бара.

Мин драматург Әхмәт Таҗетдин турында байтактан бирле эзләнү белән шөгыльләндем. Шактый гына мәгълүматлар тупланды. Олы буын артистларның драматург хакындагы җылы хатирәләрен тыңладым, язып алдым, аның әсәрләре буенча куелган спектакльләргә язылган рецензияләр белән таныштым, туганнары белән бәйләнешкә кердем, хатлар алыштым һәм алар яшәгән шәһәрләргә дә барып килергә туры килде...

Төп фамилиясе Рахманкулов булган бу драматургның нәсел башы бик ерактан килә. Татарстан территориясенең борынгы бүленеше буенча әйткәндә, Көнбатыш Кама алды, ягъни Казан арты авылларының берсендә туган, шунда алпавытка сатылган һәм таза гәүдәле, юан беләкле булганы өчен «дөньяга алла тарафыннан иңдерелгән эш көче» мәгънәсенә туры китереп Рахманкол дип аталган колдан башлана ул. Һәм шушы атама алдагы җиде буынның фамилиясенә әйләнеп китә.

Рахманкуловларның барысы да менә шушы колның берданбер улы Габде-Кәрим һәм аның баласы (Рахманколның оныгы), лашманлыкта йөргән, казна крестьяны саналган Заһир каныннан таралганнар, дип уйланыла.

Заһирның дүрт ир баласы (Хөсәен, Мөхәммәтҗан, Хаҗиәхмәт) һәм ике кызы (Гарифә, Сәхипҗамал) булган.

Драматург Әхмәт Таҗетдинов — менә шушы Заһирның икенче баласы Мөхәммәтҗан абзыйның кече, төпчек улы.

Мөхәммәтҗан абзый улларын мулла итәсе килә, чөнки заманы өчен бердәнбер абруйлы һәм «саваплы, изге» хезмәт. Ата боерыгына буйсынып, ике улы: Габдрахман белән Зыятдин мулла булып китәләр, ә Әхмәт журналистика юлына баса һәм абыйларының ярдәме белән Истанбулга укырга китә.

Атадан ярдәм булмагач, Әхмәткә эшләп укырга туры килә. «Тәгарифел Мөслимин» (Мөселман дөньясы хәбәрләре белән таныштыру мәгънәсендә) редакциясенә әдәби хезмәткәр булып урнаша.

1915 елда Россиягә кайта һәм Оренбур шәһәрендә чыга торган «Шура» журналында эшли. Революция алдыннан һәм революциядән соң Троицк шәһәрендә яши һәм шагыйрь Шәехзадә Бабич белән «Хөр милләт» исемле газета чыгара, аның баш редакторы була. Ш. Бабичның «Яшәсен эшчеләр», «Хөррият бүләге», «Тәмсия кисәге» кебек революцион рухлы шигырьләре беренче тапкыр менә шушы газетада басылалар.

Әхмәт Тажетдин житмешенче яшенә чыкканда, 1954—55 елларда Горький шәһәрендә вафат була.

Ленинград шәһәрендә яшәүче туганы Мөхәммәт Рахманкулов (Мөхәммәт Рахманкулов — Ә. Тажетдиновның атасы — Мөхәммәтҗан абзыйның энесе Хаҗиәхмәт улы, хәрби диңгез флоты вице-адмиралы) миңа язган хатында: «1958 яисә 1959 ел иде микән, мин Мәскәү астында «Архангельское» санаториясендә ял иттем,— ди дә,— һәм шунда, кырыгынчы елларга хәтле Казанда яшәгән, хәзерге вакытта Мәскәүдә «Внешторг» системасында эшләүче бер татар кешесен очраттым...» — дип яза. Сүз Казанда чакны, башта ВКП(б) өлкә комитеты аппаратында, ә соңыннан ТАССР Халык комиссарлары Советы председателе булган Әмин Хәлилович Тынчеров турында бара. Менә шушы Тынчеров Мөхәммәт аганың Әхмәт Тажетдинов туганы икәнлеген белгәннән соң, аңа драматургның ничек һәм кайда үлгәнлеген сөйләп бирә. Мөхәммәт ага хатында әйтелгәнчә, Әхмәт Тажетдинов, реабилитацияләнү турындагы шатлыклы хәбәрне күтәрә алмыйча, йөрәге ярылып үлә.

Бу хәбәр Татар дәүләт академия театрының элеккеге режиссеры Гомәр Девишев тарафыннан да раслана. Ул танылган музыкант Исмәгыйль ага Һилаловка Әхмәт Тажетдиннең Горький шәһәрендә үлеп калуын һәм аны җирләүдә үзенең катнашуын бәйнә-бәйнә сөйләп бирә.

Инде олы драматургның биографиясендәге моңа кадәр билгеле булмаган якларына тукталыйк.

Беренчедән, шушы көнгәчә драматургның ике (Тажетдинов, Рахманкулов) фамилиядә йөрүенең сәбәпләрен белми идек. Хәзер ул ачыкланды.

Баласын мулла итү теләге белән яшәгән Мөхәммәтҗан абзыйга кече улының юлдан язуы, ягъни журналистикага бирелеп китүе бер дә ошамый. Үгет-нәсихәтләрнең тәэсире булмагач, ата баласын орышып та, куркытып та карый, ләкин Әхмәт баскан юлыннан чигенми. Эш чыкмаслыгын сизеп, ата кеше алла каршында гөнаһлы булып калудан курка һәм Әхмәттән баш тарта — аны Тажетдинов фамилиясендәге, балалары булмаган ирле-хатынлы гаиләгә, рәсми төстә яздырып, балалыкка бирә.

Мөхәммәтҗан карт икенче якны да истә тоткан булса кирәк. Әхмәтнең бертуган агасының улы Габделхәй Рахманкулов сүзләренә караганда, ата баласының киләчәген күздә тотып баласыз гаилә сайлаган, гаиләдәге бердәнбер бала ул заман законы буенча солдатка алынмаган.

Бер атуда ике куян: алласы каршында үзен дә аклый, авыр солдат хезмәтеннән баласын да коткара.

Драматургка Тажетдинов фамилиясе менә шулай тагыла. Әмма ул үзен төрлечә йөртә: Әхмәт Рахманкулов та, Әхмәт Тажетдинов та була, күп очракта исә Әхмәт Тажетдин Рахманкулов булып йөри.

Биографиясендәге ачыкланмаган икенче нәрсә — аның исеме. Исеме бар иде. Шаһиәхмәт. Тик менә...

1978 ел башында Казанда яшәүче олы яшьтәге Шакир абзый Хәкимҗанов Татарстан дәүләт музеена Г. Тукайның бер фотосын китерә. Бу, бөек шагыйрьнең Троицк шәһәреннән киткәндә агалы-энеле Рахманкуловларга рәхмәт йөзеннән ядкарь төсендә, 1912 ел, 5 август датасы белән бирелгән фото. Менә шушы фотоның артындагы Тукай автографында Шаһиәхмәт Әхмәттәрәй дип язылган. Бу нәрсә мине бер тиклем шиккә төшерде. Шуннан соң туганнарына мөрәҗәгать иттелде. Әмма алар: «Әби аны гел Шаһи яисә Шаһиәхмәт дип дәшә иде»,— дән артык нәрсә әйтә алмадылар.

Гарәп сүзлеге: «шаһи» сүзен борынгы Иран илендә, хәерчеләргә өләшенә торган вак, бер тиенлек акча, дип аңлата, ә Әхмәт — ул данлы, шөһрәтле дигән мәгънәне бирә. Нинди капма-каршылык. Шундый исем була аламы? Юк! Димәк, ана тарафыннан тагылган бу шаһи сүзендә ниндидер усал максат ята.

Драматургның анасы Фәрзәнә абыстайның Кабаниха характерындагы карчык икәнлеген ишетеп белсәм дә, оныкларыннан тулырак мәгълүмат алу өчен Ташкентка барып чыгарга туры килде.

Шушы очрашуда Габделхәй абый: әтисенең Г. Тукайны үзләренә чакыруына әбиләренең бик тә каршы булуларын, шуның аркасында еш кына җанҗаллар чыгуын. Тукай килгәч тә ачуыннан зәһәренә баткан әбисенең зәнкилек белән оныкларын (Габделхәй дә шунда керә) шагыйрь янына якын барудан катгый төстә тыюын, бабкаларен тилгәннән саклаган ана каздай ыслап йөрүләрен, «Ул кешедә үләт зәхмәте, йокмасын»,— дип кисәтүләрен сөйләгәч, Фәрзәнә абыстайның бик тә кырыс, бик тә фанатик карчык булганлыгына тәмам ышандым.

Әңгәмә вакытында тагы да улының «сафсата китаплары» язуына әбинең риза булмавы, фатиха бирмәве һәм ана белән бала арасында җитди гаугалар булганлыгы беленде.

Шушыларны тыңлаганнан соң, ана баласының «начар юлда йөрүенә» гарьләнеп, аны вак һөнәр кешесе дип кимсетергә, түбәнсетергә теләп, исеменә үз белдеклеге белән шаһи сүзен өстәмәде микән, дигән фикер туа.

Дөрес, бу исбат ителмәгән нәрсә, фәкать безнең фараз гына. Шулай да, бу фаразда беркадәр дөреслек тә бар кебек. Ата-ананың каләм көче белән көн күрүне түбәнчелек, хурлык дип санаулары һәм андагы тупас сыйфатлар белән «шаһи» сүзендә уртаклык сизелә. Алар мәгънәви бәйләнәләр дә шикелле.

Минемчә, Рахманкулов гаиләсендә өч ай яшәгән Тукай боларның барысын да белгән һәм фото артына Әхмәт аганың тулы чын исеме язылган булырга тиеш. Бу да хәзергә фараз гына. Хакыйкать туу таныклыгында. Троицк шәһәр ЗАГСыннан: «Штатыбызда мәчет кенәгәләрендә язуларны укый алырлык кешеләребез юк»,— дигән җавап алынгач, якын елда үзем барып актарырга булдым.

Ә хәзергә ябыштырылган «Шаһи»ын да, Гәрәй исемен дә калдырып, гәрчә Әхмәт компоненты ялгызлык исем була алмаса да, сыйфатына карап кеше исеме функциясе итеп куллануны драматург үзе дөрес тапкан икән, без дә аны Әхмәт дип кенә атыйк.

Егерменче еллардан алып Әхмәт Таҗетдин Рахманкулов драматург буларак таныла һәм комедия, драма, трагедия жанрларында икешәр, өчәр, дүртәр серияле утызга якын әсәр яза.

Аның әсәрләре кайда гына уйналмасын — Казан, Мәскәү сәхнәләрендәме, Оренбур, Уфа, Әстерхан шәһәрләрендәме, Урал-Себер һәм Урта Азия театрларындамы — зур уңыш казана һәм матбугат та үз вакытында авторның иҗатын күренекле драматурглар рәтенә куеп бәяли.

«Дин юлында» белән «Банат» — Әхмәт Таҗетдин Рахманкуловның беренче сәхнә әсәрләре. Беренчесендә мәчеткә хатын-кыз җенесен кертү-кертмәү тирәсендә барган гауга фонында хатын-кыз хокукы мәсьәләсе яктыртылса, икенчесендә Троицк шәһәрендәге бер бай кызының фаҗигале язмышы күрсәтелә.

Аеруча «Упкын», «Боз астында дулкын», «Үлмәс ханым», «Җиһан тетрәгәндә», «Килмешәк», «Сафура», «Аферист», «Тигәнәк», «Ах-ух һәм компания», «Кара күләгәләр» кебек күп серияле әсәрләре драматургка шөһрәт китергән әсәрләр булып санала.

Гадел Кутуй үзенең бер мәкаләсендә: «Рахманкулов күп эшли, күп яза торган драматург» икәнлегенә басым ясый да «аның әсәрләренең мәүзугълары (эчтәлекләре) асылда буржуа-мещан тормышының череклегән күрсәтүгә, җинаятьләрен ачып салуга» багышланганлыкларын әйтә. («Татар дәүләт академия театры». 1928 ел, 4 нче сан.)

Чыннан да, драматургның әсәрләре хыянәт белән җинаятьчелекне фаш итүгә багышланганнар. Ә кайберләре революциягә хәтле хөкем сөргән сыйныфлар даирәсендә булгалап торган коточкыч сенсацион вакыйгаларга корылган. Андыйларының нигезенә, башлыча, Троицк һәм Уралның башка шәһәрләрендә булган вакыйгалар салынган.

Мондый шәхси фаҗигаләргә корылган тематика белән кызыксынуны башка драматурглар иҗатында да очратабыз. Мәсәлән, К. Тинчуринның «Соңгы сәлам»е сюжетына татар фабриканты Галим Мишкинның кече баласы Гали белән булган фаҗига алынган. Г. Камалның «Бәхетсез егет»ендә дә Уфа бае Сәгыйть Сабитовлар гаиләсе трагедиясе, ә Ярулла Вәлинең «Оят яки күз яше»ндә Сембердәге татар баеның бозык тормышы күрсәтелә.

Югарыда әйтелгәнчә, Әхмәт Таҗетдин Рахманкуловның кульязмалары да, әсәрләре дә сакланмаган. Театрлар архивларында булганнары да, режиссерлар һәм аерым артистлар кулларындагылары да эзсез югалганнар. Ул елларда язу машинасы булмаган, сораган бер театрга автор үз кульязмасын җибәргән, театрлар күчереп алганнан соң, кире кайтарганнар. Кире җибәрелмәсә дә, бу хәл артык борчу тудырмаган, чөнки ул заманда бер уйналган әсәрне кабатлап кую сирәк булган һәм китап итеп бастыру белән дә артык кызыксынылмаган...

Татарстан дәүләт музее подвалларыннан Исмәгыйль ага Һилалов драматургның дүрт әсәрен табып, Г. Ибраһимов исемендәге институтка тапшырды. Алар дүрт серияле әсәрнең икенче һәм дүртенче серияләре булган «Боз астында дулкын» белән «Җиһан тетрәгәндә», тагы да «Килмешәк» һәм «Сафура». Драматургның Оренбургтагы туганы тарафыннан җибәрелгән «Документ» драмасы исә театр белгече Хәсән Гобәйдуллинда саклана. Ул Казан сәхнәсендә уйналмады,

1934 елда Байсеитов тәржемәсендә һәм аның постановкасында Казакъ дәүләт академия театрында куелды һәм драматургның бу әсәренә яшь композитор Латыйф Хәмиди тарафыннан махсус музыкаль бизәлеш язылды. «Музыка» нәшриятында 1964 елда басылган А. Юсфин китабында композиторның бу хезмәте сәхнә әсәрләренә язылган беренче иҗат җимеше итеп күрсәтелә.

Егерме бишенче ел урталарындагы афишаларга күз салсак, Әхмәт Тажетдин Рахманкулов әсәрләренең Татар дәүләт академия театры репертуарында ныклы һәм төп урын биләве ачык чагыла. Кайбер сезоннарда аның хәтта, дүртәр, алтышар әсәре уйналган. Бу Фатыйма ханым Ильская истәлеге белән дә раслана. «Әхмәт Тажетдин асылда серияле әсәрләр язды. Бу үзе тамашачыларны гына түгел, артистларны да түземсезлек белән ул әсәрләрнең дәвамын көтәргә мәҗбүр итә иде. Ә инде теге яки бу әсәренең дәвамы куелу турында анонс афишасы чыкса, тамашачылар шашалар иде... Гомумән, аның әсәрләре еш һәм күп куела иде. Башка драматургларның бер яки ике әсәре уйналса, Әхмәт Тажетдинның кайбер сезоннарда бишәр, алтышар әсәре куела иде. Аның әсәрләрендәге геройлар бик белеп, иләк аша үткәрелеп язылган образлар,— ди Фатыйма ханым сүзен дәвам итеп.— Аның әсәрләрен без артистлар көтеп ала һәм берәр әсәреннән роль ала алсак, шатлана идек. Чөнки аның әсәрләрендә артист иҗаты өчен азык мул була торган иде, җәелеп уйнарлык, тулы канлы образларга бай иде аның әсәрләре. Бари Тарханов, Мохтар Мутин, Зәйни Солтанов, Мифтах Әпсәләмов, Шакир Шамильский кебек татар сәхнәсенең филләре Әхмәт Тажетдин әсәрләрендә иҗат дингезендәге балыклардай хис итәләр иде үзләрен. Минем үземә дә бу драматургның барлык әсәрләрендә дә диярлек уйнау насыйп булды һәм ул образлар иҗади үсешемә, осталыгымны чарларга ярдәм иттеләр».

Әйе, Әхмәт Тажетдин Рахманкулов әсәрләрендәге образлар артистлар үсеш алымнарын баетуда, осталыкларын камилләштерүдә, актерлык диапазоннарын киңәйтүдә, ниһаять, профессиональ яктан үстерүдә зур роль уйнаганнар.

Шушы спектакльләрдә уйнап, Хөсәен Уразиков та талантлы артист буларак танылa. Рецензияләрдә Гыйсмәт хәлфәсе «Упкын» (турында «тирән акыл белән уйлап, аңлап уйнады» диелсә, Гыйрфан солдаты турында «Җиһан тетрәгәндә») «Уйнаучыларга килгәндә, иң беренче урында Гыйрфан солдат ролендәге Уразиков һәм итче Гыйнетдин ролендәге Тархановлар торалар. Әсәрдәге шушы ике типны Уразиков белән Тархановлар иҗат итмәгән булсалар, спектакльнең барышында бик зур китеклек булыр иде»,— диелә.

«Үлмәс ханым» спектаклендә Фатыйма Ильская белән Нәфыйга Араповалар аеруча уңышка ирешәләр. Үлмәс ханым роле турында автор: «Бу рольне уйнар өчен сәхнәгә чын мещанканың үзен чыгарганнар мени»,— дип, образның Ильская тарафыннан тормышчагыча реаль планда иҗат ителүенә басым ясый. Арапова уенына карата матбугатта: «Бер генә күренештә күренгән кечкенә генә роль белән дә осталыгын ике йөз процентка җиткереп уйнады»,— дигән сүзләрне укыйбыз.

Шулай ук «Сафура» спектаклендә Н. Таждарова иҗат иткән Сафура белән Ф. Камалова тудырган Тамара образлары да югары бәяләнәләр. Аеруча Тамараны (Ф. Камалова) «Ирләр башын әйләндерүче, таш астыннан чыккан интригантка, аферистка, авантюристкага хас булган барлык нечкәлекләрен табып уйнады»,— диелә. «Җиһан тетрәгәндә» спектаклендәге Бикбов (З. Солтанов), генерал (Н. Сакаев), офицер (Х. Сәлимҗанов) тагы да аның «Тигәнәк»тәге җилкуар Мифтахны зур осталык белән иҗат ителгән образлар буларак макталалар һәм югары бәя алалар.

Гомумән, Казан сәхнәсендә уйналган Әхмәт Тажетдин Рахманкулов әсәрләренең барысына да диярлек рецензия язылган. Бу, әлбәттә, уңай һәм күңелле факт. Ул рецензияләрдә, уңай фикерләр белән бергә, кайбер артистлар уенындагы йомшаклыклар да, драматург белән режиссер-постановщикларга кагылган кимчелекләр дә әйтелә.

Ләкин бер рецензиядә дә драматургның әсәре тулы анализланмый. Ихтимал, бу берничә сериядән торган әсәрнең беренче сериясенә бер автор, икенчесенә — икенче, өченчесенә — өченче рецензент тарафыннан язылудандыр. Беренчесеннән алып соңгы сериясенә хәтле бер генә автор карап язган рецензия юк. Билгеле, китапның башын яисә урта бер өлешен, яки соңгы битләрен укып кына тулы бер фикергә килеп булмаган кебек, күп серияле сәхнә әсәрләренең дә барысын да карамыйча, бер сериясен карап кына, тулы бәя биреп булмый.

Беркадәр тулырак бәя бирүгә булган омтылышны, Фәтхи Бурнаш мәкаләләреннән сиземләп була. 1927 елда басылган зур күләмле мәкаләсендә («Безнең юл»

журналы. 1927 ел, 4—5 саннар.) Фәтхи Бурнаш 1926—27 елгы сезон репертуарына тулы анализ ясый. Мәкаләдә шушы сезона Әхмәт Тажетдин Рахманкуловның алты әсәре куелуы турында әйтә дә, әсәрләрне дүрт группага бүлә. Алты әсәрнең икесен («Җиһан тетрәгәндә» белән «Аферист») идеология ягыннан тотнаклы, ә калган дүртесен («Упкын», «Боз астында дулкын», «Үлмәс ханым» һәм «Килмешәк») сәхнәгә куярга яраклы һәм кирәкле әсәрләр булуын күрсәтә. Һәм соңгы дүрт әсәр хакында фикер каршылыклары булуы ихтималына ишарә дә ясап куя.

Шул ук елның «Сезон уңае белән» язылган икенче бер мәкаләсендә («Татар дәүләт академия театры», 1927 ел, 1 нче сан.) Ф. Бурнаш Әхмәт Тажетдинның «Тигәнәк» исемле әсәрен һәрьяклап мөкәммәл эшләнгән әсәр итеп саный.

Ә инде «Ун ел эчендә татар театры» исемле мәкаләсендә («Безнең юл» журналы, 1927 ел, 10 нчы сан.) Ф. Бурнаш Әхмәт Тажетдинны Әмири, Исәнбәт, Такташ, Тинчурин кебек драматурглар рәтенә куеп «Сәнгать ягыннан да, идеология ягыннан да хәзерге массаны канәгатьләндерә алырлык әсәрләр биргән» драматурглар янына бастырып бәяли.

Драматургның урынын билгеләүдә шушы мисаллар белән чикләнеп, аның әсәрләренең кино өчен сценарий итеп алынуларына күчик. Драматургның Ленинградтагы туганы Мөхәммәт Рахманкулов үзенең бер хатында кайчандыр Казанга килүе, абзасы Әхмәт Тажетдиннарда торуы һәм шунда бик тә әһәмиятле бер очрашуга шаһит булуын яза. «Беркөнне,— ди ул — Әхмәт абыйларга Такташ, Бурнаш, Ильская һәм тагы да мин танымаган берничә кеше килеп керәләр. Алар «Койрыклы йолдыз» картинасының титрында Әхмәт абыйның исеме күрсәтелмәвенә ризасызлык белдереп, «Востоккино» адресына протест язарга кирәклеге һәм шул хакта кинәшләшергә килгәнлекләрен әйтәләр».

Шушындый ризасызлыкларны Б. Тарханов, М. Мутин, Ф. Бурнашлардан үземнең дә ишеткәнем бар иде.

Әйе, «Востоккино» тарафыннан «Комета» исеме белән нәфис фильм эшләнгән һәм ул Казанда төшерелгән. Бу турыда утызынчы елларда радиостудиядә эшләгән чакны Габдрахман абыйның (Камал Икенче) сөйләгәнен әле дә хәтерлим. Шул уңай белән Казанга Мәскәү театрлары артистлары килә, алар арасында Казан кызы Галина Семеновна Кравченко да була. Ул берничә ел элек төшерелгән «Булат батыр» картинасында Казан губернаторының бертуган кардәшенең кызы образын иҗат иткән, ә «Комета» да аңа татар кызы Хәят ролен бирәләр һәм ул татар көнкүреше белән тирәнрәк танышу, гореф-гадәтләрен өйрәнү максаты белән башка артистларга караганда Казанга атна-ун көн алдан килә. Артистка әзерләп куелган кунакханәгә төшми, аны артист Камал Икенче квартирага Яңа бистәдәге бер татар гаиләсенә урнаштыра.

Бик озак еллардан соң, шушы истәлекне хәтердә яңартып, Казан кызы Галина Семеновнаны эзләргә тотындык һәм аның белән очрашырга теләп бер баруымда Мәскәүдәге фатирына шалтыраттым. Ләкин ул бераз сырхап торганлыктан, мине кабул итә алмады. Телефон аша сөйләшү белән генә канәгатьләнергә туры килде. Әмма шунысы мөһим — фамилиямне әйтүгә, ул мине бүлдереп:

— Сез әллә драматург Рахманкуловның улымы? — дигән сорау бирде. Түгеллегемне әйттем дә, үгезне мөгезеннән тотып алу нияте белән, үзем дә тиз генә:

— Сез аны ничек беләсез? — дип сорау бирдем.

— Белмәскә. Яшь чагымда аның «Пучина» әсәре буенча төшерелгән «Комета» да мин Хәят образын иҗат иттем...

Башка берни белә алмадым. Сорауларымның беренче сүзләрен генә әйтергә өлгерәм, ә ул бүлдерә дә, бер-бер артлы Казан турында сораша башлый. Бик сагынган, күрәсең. Хәтта Казанның урамнарына хәтле кызыксына. Олы яшьтә бит, җитмәсә сырхау, шуңа күрә тиз арыды һәм безнең сөйләшү өзелде.

Ә менә «Вечерняя Казань» газетасының 1982 ел, 28 октябрь санында И. Сибгатуллин имзасы белән «Родом из Казани» исемле мәкалә басылган. Ул архив документларына таяныпмы, яисә шул Г. С. Кравченко белән очрашып язылганмы — анысын әйтә алмыйм. Тик бу язма Габдрахман абый Камал сөйләгәннәрне дә һәм әлеге артистканың сүзләрен дә тулысы белән раслый. «Картину «Комета» по пьесе татарского драматурга А. Рахманкулова «Пучина» снимал режиссер студии «Востоккино» Валерий Инкижинов, прославившийся исполнением главной роли в фильме В. Пудовкина «Потомок Чингизхана».

Димәк, «Комета» исемле нәфис фильм Әхмәт Тажетдин Рахманкуловның «Упкын» әсәре буенча төшерелгән булып чыга.

1935—36 елларда драматург атаклы кинорежиссер В. Пудовкин белән Урта Азия большевикларының революцион эшчәнлекләре турында зур күләмле сцена-

рия өстендә эшли. Шул уңай белән драматург, материал туплау өчен, Сәмарканд шәһәренә күчә. Кызганыч ки, бу хезмәт шәхес культы орында өзелеп кала.

1928 елда Ленфильм тарафыннан төшерелгән «Мулланың өченче хатыны» исемле картинаның да сюжетына Әхмәт Таҗетдин Рахманкулов әсәре алынган, дигән сүзләр йөри. Ләкин әле ул бүгенге көнгәчә ачыкланмаган. Бу картинаның сценариясен Американың Голливуд сценаристкасы Люсиль Сквайр (ире буенча Вильямс) яза.

Люсиль Вильямс 1970 елда тагын Мәскәүгә килә. Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына, ди. Ул килгәндә мин Мәскәүдә командировкада идем. Көч-хәл белән генә бу сценаристканың кинодраматурглар һәм журналистлар белән оештырылган очрашуына эләктем. Һәм, форсаттан файдаланып, бу фильм турында сүз чыккач: «Мулланың өченче хатыны» картинасының сценариясенә нигез итеп кайсы язучы әсәре алынды?» — дип язу җибәрдем. «Ниндидер нацмен әсәре бугай, хәтерләмим»нән башка сүз әйтә алмады Л. Вильямс.

Әмма шушы кичәдә мин бу нәфис фильмның «Совет нәфис фильмнарының белешмә-каталогында» 677 нче номер белән теркәлүен белдем. Соңгы ышаныч Мәскәү кинопрокат базасында иде. Сакланган булса, бәлки фильм титрлары нәрсә дә булса әйтер? Гомумән, бу — рәсми рөхсәтләр алуга бәйләнгән мәшәкатьле эш булды.

...Шулай итеп, Әхмәт Таҗетдин Рахманкуловның әсәрләре — заманы өчен актуаль саналган, җәмгыять өчен куркыныч каршылыклар белән йөзгә-йөз бәрелешүдән гыйбарәт конфликтларга корылган әсәрләр. Драматург үз иҗатында искелек белән көрәште, күп типларның битлекләрен ачты, хыянәт һәм җинаятьне фаш итте. Дәүләт кесәсенә кул сузган пычрак җаннарга, ришвәтчеләргә, алдашу юллары белән эш башына менеп корткычлык итүче чит элементларга, мал-байлык өчен кеше үтерүдән дә чиркانмаучыларга каршы тамашачыларда көчле нәфрәт уятты.

**Шәриф РАХМАНКОЛОВ.**

*Безнең календарь*

## Гариф Галиевнең тууына 90 ел

Гариф Закир улы Галиев 1903 елның 10 маенда Азнакай районының Урманай авылында сәүдәгәр гаиләсендә туган. Җиде яшендә әтисез калган Гарифны күрше Бәйрәкә авылы мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Ул мәдрәсәдә дөньяви фәннәрдән дә азмы-күпме белем ала. Бигрәк тә матур әдәбиятны яратып укый, күзенә күренгән һәр китап белән танышып бара.

1918 елның көзендә Бөгелмә шәһәрендә ачылган өч еллык укытучылар семинариясенә укырга керә. Әмма 21 нче елгы ачлык укуын тәмамларга ирек бирми. Туган авылына әйләнеп кайткан Гариф авыл Советы сәркатибе булып эшли, Казанда чыгучы «Крестьян газетасы»ндә үзенең беренче язмалары белән катнаша. Шул көннәрдән алып, тормыш дулкыннары аны кая гына ташламасын, яшь әдип беренче планга әдәби хезмәтне куя, күп укый, күп яза. 1927 елда аның Мәскәүдә «Кызыл Армия хикәяләре» дигән беренче китабы басылып чыга.

Утызынчы елларда ул әдәби эшчәнлеген бик активлаштыра. 1931—1941 елларда дистәгә якын китабы дөнья күрә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Г. Галиев сугышның башыннан алып 1946 елга хәтле армия хезмәтендә була. Фронт газеталарында эшли, яңа әсәрләрен иҗат итә. Сугыштан соң газета-журналларда эшләп, үзенең күпсанлы әсәрләрен яза. Әдәбияттагы төп темасы — авыл, андагы тарихи вакыйгалар, үзгәрешләр, хезмәт кешесенең рухи дөньясы. Повестьлары, йөзләгән хикәяләре, балалар өчен язган әсәрләре, пьесалары, очерклары белән язучы әдәбиятыбыз тарихында тирән эз калдырды. Аның әсәрләре бүген дә укыла, бүген дә кешеләрдә яңа әхлак сыйфатлары тәрбияли.

Гариф Галиев 1985 елның 22 мартында Казанда вафат булды.



*«Бәхет турында җыр»лар язган, «Сайра, сандугач» дип эндәшеп, аның моңында «безнең илдән матур ил юк» дип тәкърарлау ишеткән шагыйребез, хезмәт һәм сугыш ветераны Мөхәммәт ага Садрига май аенда 80 яшь тулды.*

*Бәхет төшенчәсеннән башка, чыннан да, шагыйрь гомерен күзаллап булмыйдыр. Әйе, бала чагыннан ук ятим калып, авырлыкта үскән, әмма «бөек бишьеллыклар» чорында «ударник эшче»дән «ударник шагыйрь»гә әверелгән — Такташ чыгышларын тыңлаган, турыдан-туры Х. Туфан һәм М. Җәлилләр ярдәмендә әдәбиятка килгән егет бәхетле булмыймы?*

*Каһәрле Сталин диктатурасы елларыннан да, сугышлардан да исән-сау калып, «Мин Берлинны алдым!» дип горурлык кичергән — орден-медальләр тагып илгә кайткан кеше бәхетсез була аламы?*

*Сугыштан соңгы авыр елларны, авыл тормышын матур дип ышанып, ихлас-садә әсәрләр язу, катлаулы, болгавыр чорларда илһам таба алу да бәхеттер, бәлки? Хәер, бу чор әсәрләренә карата галиҗәнаб вакыт үзенең сүзен катгый итеп әйтсә дә, чараң юк...*

*РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Почет билгесе» ордены кавалеры М. Садри бүгенге үзгәрешләр яктылыгында да үткән яшьлеге, «яшәсен дә яшәсен, дип, бөкресе чыккан», алданган, бүген инде үз урынын яшьрәкләргә эстафета иткән үз буыны турында да сыкранып язмый. Ул — һаман да үзен солдат, сабыр ир һәм шагыйрь итеп тоя. Мондый егетлек үзе үк бәхет түгелме? Укучыларыбызга бу санда тәкъдим ителә торган юбилей шигырьләре дә шул хакта сөйли, безнеңчә.*

**Рәдиф ГАТАШ.**

# Мөхәммәт Садри

## Син сугышны оныт, диләр

/ПОЭМАДАН/

*«Безгә каршы монда бик күп татарлар сугыша. Алар акылларыннан язган кешеләр һәм мин татарны төшемдә күрергә дә куркам...»*
*(Немец гаскәрие Рудольф Вольфганның Сталинградтан Германиягә язган хатыннан.)*

Син сугышны оныт, диләр,
Ул күптән үткән, диләр,
Ул җирләрдә иген үскән,
Булган да беткән, диләр...

Юк, онытмыйк кан-яшь койган
Ул елларның һичберсен;
Тик үлгәннәр сөйли алмый
Күргәннең бөтенесен.

Дон янды, Днепр, Висла,
Янды Мәскәү елгасы...
Ут диңгезе итте фашист
Басып алган дөньясын.

* * *

Җирнең асты өскә килде —
Җәһәннәм итте фашист,
Мин сезне җиңел җиңәм дип,
Иделгә җитте фашист.

Үз телен шәп белгән татар
Урысча да өйрәнде
(Ә фашистлар лыгырдавын
Тыңларга да җирәнде):

— Ни шагу назад! — дип, татар
Әйтте урыс дустына;
— Вместе насмерть стоим! — дип,
Басты хәтәр постына.

Шундый боерыклар ишетте
Фронтта, ут эчендә;
Утлы яшен егәрлеге
Булды татар көчендә.

Бу батырлыкны тарихчы
Чын исеме белән атар.
Янса — янды, үлсә — үлде,
Чигенү белмәде татар.

Ут капкан кайнар Иделнең
Ярында пеште фашист;
Иделле татар үченнән,
Миллионлы дуслык көченнән
Кәкрәеп төште фашист.

Әйе, атакада татар
Йә яшен, йә ут булды.
Ул фашистның котын алып,
Канын коеп юк булды.

Ә ярасын бәйләп алгач,
Ул тагын басты сафка:
Канга — кан! Без яшь гомерне
Бирмәбез арзан хакка.

* * *

Син сугышны оныт, диләр,
Булган да беткән, диләр,

Мондый сүзне яман атлы
Надан йә дошман сөйләр.
*1993.*

## Күңел уйлый, хәтерли...

Күңел уйлый, күңел йөри,
Оча әллә кайларга...
Аякларым гына менә
Теләмиләр атларга,—
Җитәр инде, диләр алар,
Күп чаптың чит-ятларга.
Иделдән үттең Днепр,
Одерга, Дунайларга...
Чибәр кызлар сине үпте,
Булмадың син кайларда?!

Җиңү яулап Ватаныңа,
Үткәч ут өермәсен,
Нечкә билләрне кочаклап,
Синме ул биемәдең?!

Яшь чакта көчле идем шул,
Кайда да сынатмадым,
Иделдәге татар данын
Дунайда да акладым.

Өйгә кайтыр алларыннан
Сугышчылар ялында
Штрауска биедек без,
Түшәбезгә дә кермәгән
Император[1] залында.

Өйгә кайткач, Идел-йортта
Ачтан егылып үлмәскә,
«Биетте» безне Сталин
Ачлы-туклы хезмәттә.

«Яшәсен!» дип эшләгәнбез,
«Яшәсен!» дип янган без,
«Яшәсен!» дип бөкре чыккан,
Хәлдән тайган, арган без.

Ә кемнәр яшәгән икән
Безнең «яшәсен»нәргә?
И раббем! Мәскәү яшәгән
Безне санап юләргә...

И әрәмгә үткән яшьлек,
Мин сине күзалладым,
Мәгънәсез бу «карт-аю»дан
Яшь акты, түзәлмадым.

---

[1] Вена шәһәрендәге Австрия монархиясенең император сарае (Хофбург) 1945 елда, вакытлыча совет офицерлары йорты иде.

Ә шулаен мин шулай да
Әйтим шушы уңайда:
Баттал абзыйча «кабергә
Чират» тормыйм хәзергә:

Тая-тая карт аягым,
Тотып таем-таягым,
Тышта саф — җинел һава дип,
Йөрәккә дә зур дәва дип,
Хатын-кызлар артына,
Басам сөт чиратына...

*1992.*

## Пегасым, ак канатым

И Пегасым, Пегасым син
Илаһи акбүз атым!
Алмагач чәчәк атканда,
Кошлар дәртле сайрашканда,
Бер серләшик, канатым.

Син ачтың тоягың белән
Изге илһам чишмәсен,
Ул мәңгегә дәвам итсен,
Буыннан-буынга китсен,
Рух чишмәсе кипмәсен.

Минем дә илһам канатым
Син бит, кадерле Пегас;
Әллә ач, ятим үскәнгә,
Яшьлек солдатта үткәнгә,
Җырлаттың бугай бик аз.

Хисләрем кәгазь битенә
Төште күз яшем тулып,
Күп җыр-моңым ил сагында
Канлы сугыш учагында
Яндылар солдат булып.

Сихри чишмәдән дәрт алып,
Илһамым, акбүз атым,
Илем өчен янып-көеп,
Казан һәм Иделне сөеп
Җырладым, ак канатым.

Зур теләгем шул, канатым:
Тәнем көл булсын җирдә,
Җаным синнән һич калмасын,
Ул былбыл булып сайрасын,
Яз саен туган илдә!

Мәңгелек син, и Пегасым,
Илһамым, акбүз атым,
Алмагач чәчәк атканда,
Кошлар дәртле сайрашканда
Кочам сине, канатым!

*1993.*

## Бу әсәрләрне дә Думави язган

*Октябрьдән соңгы заманнарыбызда әдәби мирастан, бигрәк тә XX гасыр башы татар поэзиясе һәм прозасыннан, башлыча дөньяви эчтәлекле әсәрләр эзләп, шуларны фәнни өйрәнү һәм халкыбызга җиткерү белән шөгыльләндек. Инде дөньялар үзгәреп китте, һәм менә күрәбез: безнең бу рәвешле эш итүебез бик үк дөрес булмаган икән. Чөнки революциягә кадәрге әдәбиятыбыз күгендә якты йолдызлар булып кабынган күренекле әдипләребез иҗатында шундый әсәрләр бар ки, аларда фани дөнья борчулары, адәм баласының уй-кичерешләре ислам диненә бәйле мотивлар, дини образ-сурәтләр ярдәмендә, аларның мәгънәви эчтәлекләренә нигезләнеп биреләләр. Кайбер әсәрләрдә исә (мәсәлән, «Дин вә мәгыйшәт» журналында) шагыйрьләрнең лирик герое тулысы белән дини кичерешләр эчендә яши. Әдәбият белемендә әле аз өйрәнелгән мондый күренешләрнең асыл сәбәпләре аңлашыладыр да: гасырлар дәвамында татар халкының рухи тормышы, әхлакый йөзе ислам өйрәтмәләре, фәлсәфи нигезләре белән тыгыз, аерылгысыз бәйләнешкә кергән. Ислам дине татар милләтен авыр, фаҗигале заманнарда таркалып, эреп юкка чыгудан, инкыйразга тарудан саклап калган. Халык сулышына, аһ-зарына сизгер күңелле каләм ияләре моңардан читтә торып кала алмаганнар, әлбәттә.*

*Әнә шундый иҗатчыларның берсе — Нәҗип Думави (1883—1933). Моңа кадәр без аны 1905 ел революциясе тәэсирендә кулына каләм алган, иҗтимагый гаделсезлекләрне, сугышлар фаҗигасен куе, эмоциональ буяулар ярдәмендә оста сурәтләп биргән шагыйрь һәм прозаик сыйфатында күзаллап килдек. Әмма аның иҗат мирасында «Коръән», «Коръәннең зары», «Сәҗдә» кебек әсәрләр дә бар. Боларында ислам фәлсәфәсенә, дин тәгълиматына, өйрәтмә һәм йолаларына бәйле яклар ачык чагылыш табалар.*

*Тууына 110 ел тулган көннәрендә без күренекле татар әдибе Нәҗип Думавиның шундый әсәрләреннән берничәсен журналыбыз укучыларына тәкъдим итәргә булдык.*

**Зөфәр РӘМИЕВ.**

### Коръән

Кайвакыт мин буш булам: нишлим хәзер? Мин буш, димен;
Әй күңел, син нишләдең? Мин бит әзер! Эш куш, димен.

Шул вакыт күңлем куша Коръән тилавәт итмәгә[1],
Шундый зур, шундый мөкатдәс эшкә кыям итмәгә[2].

Инде мин хәйран булам ошбу вакыт үз-үземә,
Җөмлә гыйсъяннар[3], җинаятьләр төшәләр исемә.

Мин ничек Коръән кодесне[4] тотыйм бу кул илә,
Хәлбуки, мин күпме гыйсъяннар кыйлам шул кул илә.

---

[1] Тилавәт итмәгә — укырга.
[2] Кыям итмәгә — керешергә.
[3] Гыйсъяннар — каршылык күрсәтүләр, бозыклыклар.
[4] Кодес — изге.

Күпме ялганнар, лэгуләр[1] булмагандыр телдә, дим,
Булмый, мин җөрьәт итә алмыйм, оятлы бәндә, дим.

Кыскасы, Коръән укылмый, мин шулай мәхрүм калам,
Монда да бер зур гөнаһ булмасмы дип тагын янам.

*«Нәҗип Думави шигырьләре» китабыннан. 1912.*

## Җир кортлары

Дөньяның һәр бәндәсе бер туктамый гыйсъян итә —
Аннары ислах өчен хак әнбия ирсал итә[2].

Бер-бер артлы күпме нәби[3], күпме рәсүл[4] килмәгән!
Әмма һичберсе: менә яхшырдылар бит, димәгән.

Һәммәсе, зарый кыйлап: Раббем, гаҗизмен, булмый, ди,
Шулкадәр азган адәм: тыңламыйдыр, ди, күрми, ди.

Бәндәнең шунча явызлыктан һаман исрарене[5]
Күрдекеннән катыгъ иткәндер[6] нәби ирсалене[7].

Мин шулай уйлап торып бик шикләнәмен, куркамын,
Әллә нишләр төсле каһәр безне — без җир кортларын.

Бер газап берлә килер дә җир шарын тотар кебек,
Әллә кайда ыргытып бәрер, аны ватар кебек.

*«Нәҗип Думави шигырьләре» китабыннан. 1912.*

## Мәэюскә[8]

Мокътаза хикмәтенчә ошбу дөнья ин дамәт,
Мотлакан, бер әсбәбә мине ирер һәрбер халәт[9].

Бәс, туганкай, әйт ачык: нәрсә сәбәп бу яэсеңә[10],
Син әманмы[11] бервакыт икъбаль[12], бәхет килмәсенә.

---

[1] Лэгуләр — буш сүзләр.
[2] Ислах өчен хак әнбия ирсал итә — төзәтер өчен алла пәйгамбәрләр җибәрә.
[3] Нәби — пәйгамбәр.
[4] Рәсүл — алла илчесе (пәйгамбәр).
[5] Исрарене — кирелеген, үзсүзлеген.
[6] Катыгъ иткән — тыйган.
[7] Нәби ирсалене — пәйгамбәр җибәрүне.
[8] Мәэюскә — өметсезләнүче кешегә.
[9] Бу дөнья яшәгәндә шушындый хикмәт булыр: һичшиксез, һәрбер халәткә бер сәбәп китерер мине.
[10] Яэсеңә — өметсезлегеңә.
[11] Әманме — ышанасыңмы.
[12] Икъбаль — уңыш.

Юк, әфәндем, бик хатадыр, итмәгел алдан хөкем —
Бундый хөкем дөньяда тик яңгылыш алган хөкем.

Һәр заманның үз башына аеры-аеры хөкме бар,
Кыйл тәвәккел[1] раббеңа, ул нишләсә дә ирке бар.

Яшь, матур, пакь чәһрәңез ник соң чытык көнен-кичен —
Нәрсәгә ул? Кем елый соң, кем яна синең өчен?

Юк, туган, бер кем дә янмас, бәндәнең һәркайсысы
Мөбталә[2] бер кайгыга — һәр бәндәнең үз кайгысы.

Бәс, таләп итмә мәдәд[3] һич бәндәдән хәсрәтеңә,
Тик сабыр ит тә тәвәккел кыйл хода хәзрәтенә.

*«Нәҗип Думави шигырьләре» китабыннан. 1912.*

## Сәҗдә

Әй золым астында тапталган, изелгән пакь күңел!
Дөньядан бизгән вә дөньяга бөтенләй ят күңел!

Син чара тапмыйм дисең бу кайгыңа, бу дәрдеңә —
Бар чара: син тик тәвәҗҗеһ ит[4] тә каин кыйл[5] раббеңа.

Әй бөтен гомере усаллык берлән үткән карт җани[6]!
Вөҗданың изсә изәр, курыкма, аның да бар җайый.

Син бары бөк тә башыңны ит тәвәҗҗеһ раббеңа,
Рәхмәте киңдер аның һәм шул лаек бит шаныңа[7].

Ул гали бит, ул газыйм[8] һәм ул рәхим бит, ул барый[9] —
Чүп кадәр тормый аңарга нисбәтән дөнья шары.

Кайвакыт мин шундый уйларга батам да аптырыйм;
Аңламыйм, никтер күңел курка, вә дер-дер калтырыйм.

Ихтыярсыз мин төшәм сыгылып, ятамын сәҗдәгә —
Бер гараиб[10], бер гаҗаиб хәл хис итәм шул сәҗдәдә.

Кайда ул тормыш кыенлыктан ходайга зарлану,
Кайда ул кайгы, гөнаһ, хәсрәтне монда уйга алу!

Тик үтеп киткән күңел бердән, димагъ[11], баш эшләми,
Дөньясы тулган, күңел ялвармый, һич шәй[12] эстәми.

---

[1] Кыйл тәвәккел — тапшырыл.
[2] Мөбталә — дучар ителгән.
[3] Мәдәд — булышлык, ярдәм.
[4] Тәвәҗҗеһ ит — йөзеңне юнәлт, борыл.
[5] Каин кыйл — тапшырыл (?).
[6] Җани — җинаятьче.
[7] Шаныңа — дәрәҗәңә.
[8] Газыйм — бөек.
[9] Барый — яратучы, алла.
[10] Гараиб — күрелмәгән, ишетелмәгән.
[11] Димагъ — ми.
[12] Шәй — нәрсә.

Тик күңелдә бер рәхәт бар: ул халикъ[1], мин мәхлукый,
Ул бар иткәндер мине, мин мәхлукый һәм мәхрукый[2].

Тапшырылганмыз аңарга, эстәмим бернәрсә дә,
Ихтыяр анда, разый мин, ихтыяр, нишләсә дә.

*«Хәсрәт чаткылары» китабыннан. 1914.*

## Бер генә секунд хатирәсе

Һич ышаныч юк руза, намаз, зәкятләргә безем:
Таки анлар җитмиләр рух-җанны пакьләргә безем.

Бездә бар фисыкъ-фөҗүр[3] шул рузачы, намазчыда;
Бездә бар ялганчы, гайбәтче нәзер-ниязчы да.

Син теләрсең гәр явыз күңлең ходаңны аңласын,
Бәс, оныт бу дөньяның бар мәгънәсе, бар гаугасын.

Тик ходай алдына тезләнде дә укы син тәсбихың,
Тәсбихы пакь әйләсен кальбең[4] вә күңлең тәшвишен.

Шул халәттә бер тәвәҗҗеһ ит[5] тә күңлең сыкрасын,
Үксеп-үксеп, тәмле-тәмле күз вә кальбең егъласын.

Аһ, әгәр мин шул халәттә гомремә тик бер генә,
Тәсбихын әйтеп, тәвәҗҗәһ әйләсәмче тәңремә.

Һич тә сыенмас идем рузам, намаз, зәкятемә,
Шул җитәр иде кыямәттә минем нәҗатемә[6].

Басмаңыз пичәт «кяфер» дип, әй ашыкчан мөслимун[7]:
Яуме мәхшәрдә[8] булырмыз кем вә кемнәр йаслимун[9].

*«Хәсрәт чаткылары» китабыннан. 1914.*

## Гаед көне

Булса да миндә җыен кайгы вә хәсрәт упкыны,
Изһар итмәм[10], асла белгертмәм аны мин гаед көне.

Гаед көнендә көчләнеп булса да мин шат, мин рәхәт,
Яшь вакыттан бирле үзләшкән миңа ул шом гадәт,

---

[1] Халикъ — яратучы, алла.
[2] Мәхрукый — җәзаланган.
[3] Фисыкъ-фөҗүр — начар эш, бозыклык.
[4] Кальбең — йөрәк, җан.
[5] Тәвәҗҗеһ ит — бер якка карап йөзене юнәлт.
[6] Нәҗатемә — котылуыма.
[7] Мөслимун — мөселман.
[8] Яуме мәхшәрдә — мәхшәр көнендә.
[9] Йаслимун — аллага буйсынган.
[10] Изһар итмәм — күрсәтмәм, ачып салмам.

Бар адәм көлсен, шаярсын, уйнасын — син ян, имеш,
Шат, көләч чәһрәңне гаедтән син генә кызган, имеш.

Юк, күтәрми вөжданым, бу эш гөнаһтыр дим дә мин —
Нәкъ котырган төсле шатланам, көләм, уйныйм да мин.

Ник бөтен дөньяга ут капмый, нигә янмый бары,
Ник югалмый, тапталып бетми икән дөньяң малы?

Истә дә юк, мин һаман шат, мин һәнүз уйныйм, көләм;
Башкаларда шундый ук һәм шат вә рәхәтлек күрәм.

Бәс, ходаем (нә зарар!), һәр көнне гаед кыйлса идең,
Мин көлеп, уйнап кына һәр гаедне уздырса идем.

*«Хәсрәт чаткылары» китабыннан. 1914.*

## Коръәннең зары

Инде имкян[1] юк, тәкатьсезмен, ышанмыйм сабрыма,
Төрле яктан аттылар уклар — кадалды бәгъремә.

Кайда ул зур шанлы пәйгамбәр Мөхәммәд — кайда ул?
Тиз китер, алсын мине тиз, таптыйлар бит садрыма[2].

Күпме истинҗасы юк[3] җаһил[4] итә миңа һөҗүм,
Күпме ялганчы тота, тарта мине үз кәйфенә!

Аңлаган юк миндәге әсрар[5] вә сөннәт алланы[6],
Йөртәләр мөэминнәрең дә тик догалык урнына.

Чын Камиллек бит минем тоткан юлым — ник белмиләр?
Мөштәрәк[7] сүз бит бу фәнчә: гаммәгә, яшь-картына.

Исләре киткән «любовь» дип әһле әфкяр[8] барчасы,
Ул «любовь»лар бит Камиллектән фәкать бер баб[9] кына.

Әй тәгалү[10] чын Камиллеккә — сәваэн бәйнәкүм[11]
дип торам — һич аңлаган юк, игътибар юк хөкмемә.

Мин беләм, син аңлыйсың, мәкъбүл булыр ошбу догам,
Бәс, кубәйт Муса нәбиләрне лаекча шаныма[12].

*«Хәсрәт чаткылары» китабыннан. 1914.*

---

[1] Имкян — мөмкинлек.
[2] Садрыма — күкрәгемә.
[3] Истинҗасы юк — пакьләнүсез.
[4] Җаһил — надан.
[5] Әсрар — серләр.
[6] Сөннәт алланы — алла кушканны.
[7] Мөштәрәк — уртак.
[8] Әһле әфкяр — фикер иясе.
[9] Баб — өлеш, кисәк.
[10] Тәгалү — әйдәгез, күтәрелегез.
[11] Сәваэн бәйнәкүм — үзара тигезлеккә.
[12] «Минем дәрәҗәмә лаеклы Муса пәйгамбәр кебекләрне күбәйт» мәгънәсендә.

# РИЗАЭТДИН БИН ФӘХРЕТДИН ГАИЛӘСЕ



Укучым!

Менә синең өчен тагын бер тарихи сирәк очрый торган фоторәсем. Ул 1927 елның җәендә, гаилә әгъзалары беренче мәртәбә тулысынча бергә җыелгач, Уфада алдырылган. Ни аяныч: беренче һәм соңгы тапкыр бергә җыелулары була аларның.

Гаилә башлыгы — ата кеше, гадәтенчә, рәсемнен иң уртасында утыра. Ул күптән түгел генә Мәккәдә булып үткән Бөтендөнья мөселманнары конгрессыннан (корылтаеннан) кайткан. Корылтайның исә рәисе урынбасары булган. Кем соң бу асыл зат? Ул — Ризаэтдин бин Фәхретдин — мөфти, дөньяга данлыклы галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе, атаклы язучы һәм журналист, үзенчәлекле талантлы мөгаллим-педагог. Әйтелгәннәрнең бер микъдары гына да тарихи шәхес өчен җитәрлек булыр иде.

Р. Фәхретдин озак еллар атаклы «Шура» журналының башында тора (журнал большевиклар тарафыннан 1918 елда ябыла). «Шура» татар әдәбиятының һәм иҗтимагый фикеренең һәрвакыт үзәгендә тора, ул үзенә күрә зыялылар өчен «өй университеты» хезмәтен үти. Бу журналны укып, тулы бер буынның эстетик һәм иҗтимагый карашлары тәрбияләнә. Аны, татарлардан тыш, башкорт, казах, кыргыз, үзбәк һәм башка төрки мөселманнар алдыра. «Шура»ны чит илләрдә укучылар да аз булмый. Алдыралар, тәрҗемәсез-нисез укыйлар...

Татарларның рухи дөньясында Ризаэтдин бин Фәхретдин Шиһап Мәрҗани, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай исемнәре белән янәшә тора; таланты белән дә, шәхес буларак та алардан һич тә калышмый, дисәк — ялгышмабыздыр. Шуңа күрә дә аның дуслары арасында Йосыф Акчура, Садрый Максуди, Җ. Әфгани кебек асыл затлар һәм шул чорның татар әдипләренең бик күпләре булган...

Гаилә башлыгы — ата кеше янәшәсендә, билгеле инде, аның тугрылыклы һәм сөекле хәләл җефете Нурҗамал абыстай утыра. Ул да гаҗәеп сәләтле һәм белемле-мәгълүматле шәхес. Әтисенә икенче яктан килеп сыенганы — кызы Әсма ханым Шәрәф (бу фоторәсем өчен без аңа бурычлы). Ә утырып һәм басып төшкән шәхесләр — Р. Фәхретдиннең иң якыннары — алар арасында шулай ук күренекле затлар күп. Улларыннан Габдрахман — танылган тарихчы, күп китаплар авторы; Габделәхәт — мәгълүм экономист (икътисадчы). Сәгыйть белән Рәшит, кызлары Зәйнәп тә һәркайсы үз өлкәсендә танылган белгечләр булалар. Шунда ук Әсманың ире Галимҗан Шәрәф — әүвәл Татар-Башкорт җөмһүриятенең, аннары Татарстан җөмһүриятенең җирле икътисадына нигез салган шәхес. Ул шулай ук Татарстан җөмһүриятенең беренче елларында татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрүдә зур өлеш керткән кеше. Әнә бер читтәрәк — киленнәре Фирдәвес. Ул Шакир Рәмиевнең кызы, Закир Рәмиевнең (Дәрдмәнд) туганнан туган сеңелесе. Ә инде Рәмиевләр нәселенең татар рухи дөньясына булган йогынтысы турында сөйләп тору да кирәкмидер. Фирдәвеснең сеңелесе Камилә әүвәле Рәсәйдә, аннары Төркия парламентында депутат буларак танылган Садрый Максудиның хәләл җефете була һәм ире белән бергә аның фаҗигале язмышын кичерә...

Вакыт, вакыттан да бигрәк, большевистик тоталитар режим, башка миллионнарча гомерләрне аямаган кебек, бу күренекле гаилә кешеләрен дә аямый. Ризаэтдин бин Фәхретдин 1936 елда вафат була. Сталинның үлем тегермәненнән аны өлкән яшьтә булуы гына коткарып калды, дип сөйлиләр вафатыннан соң. Ай-һай, тагын берәр ел яшәсә, мөфтине кем дә булса ул афәттән коткарып кала алыр идеме икән? Чөнки 1937 елда, хәзрәтнең үлеменнән соң озак та үтми, аның сердәшләреннән һәм көрәштәшләреннән кырыктан артык кеше кулга алына. Алар арасында Кашшаф Тәрҗеманов белән Мөхлис Буби кебек күренекле шәхесләр дә була. Мөфти хәзрәтнең ике улы 1937 елда — берсе Уфада, берсе Мәскәүдә атып үтереләләр. Кияве Галимҗан Шәрәф, Гулаг лагерьларында ун елдан артык гомерен калдырып, авыру һәм рухы сынган хәлдә кайта. Кайтса... аңа гаиләсе белән Казанда яшәргә рөхсәт юк икән! Ә менә мөфти хәзрәтнең ике оныгы Ил-ватанны яклап сугыш кырларында ятып калалар. Гаиләнең исән калган затлары исә озак еллар буена халык дошманнарының туганнары дигән каһәрле мөһер белән яшәргә мәҗбүр булалар.

Күрдек ки, Ризаэтдин бин Фәхретдин гаиләсе тарихы да бик тә гыйбрәтле. Ул да безнең тарихыбыз һәм без аны онытмаска тиешбез. Төп сабак шулдыр! Халыкны кол итү шәхесне кол итүдән башлана. Шуңа күрә бүгенге көннәргә дә игътибарлы һәм сизгер булыйк. Ә Заман, кызганычка каршы, бик болгавыр заман...

**Булат СОЛТАНБӘК,**
Татарстан мәгариф хезмәткәрләре белемен күтәрү институтының мәдәният тарихы һәм теориясе кафедрасы мөдире.

# ОРЕНБУРДАГЫ СӘГЫЙТЬ БИСТӘСЕ

Балтыйк диңгезеннән Европага «тәрәзә» ачкач та, Петр I патша игътибарын Уралның көньягында яткан далаларга юнәлдерә — шуннан Азия илләренә чыгу юлын булдырырга ниятли. Әнә шул далаларны үзләштерү нәтиҗәсендә ул, бердән, Шәрекъкә сәүдә вә сәясәт юлын салуны, икенчедән, арзанлы чимал, беренче чиратта алтын-көмеш табуны күздә тота.

Барыннан да бигрәк Урта Азия ханлыклары белән әйбәт мөнәсәбәт булдырып, ике арадагы сәүдәдән күп кенә табыш алырга хыяллана. Бу өлкәдә әле аңа көндәшләр булмый.

Рәсәй хөкүмәте икътисади бәйләнешләрне Һиндстанга чаклы житкерергә өметләнә. Тик боларны гамәлгә ашыру өчен Рәсәйнең Европа белән Азия арасында терәге булырдай ныгытылган кала корып җибәрү зарур була.

Шәрекънең иксез-чиксез байлыгына юлны өйрәнү максаты белән Петр I патша 1714—1715 елларда бер-бер артлы ике экспедиция җибәрә. И. Д. Бухгольц җитәкләгән беренче экспедиция Хива һәм Бохара турында аз-маз мәгълүмат туплау, Каспий диңгезенең көнчыгыш яр буен өйрәнү һәм Әмударьяның иске юлын эзләү белән чикләнә.

Ә инде 700 кешелек отряд Ямыш күле буенда ныгытма корырга тотынгач, калмыклар 100 меңле отряд белән һөҗүм итәләр. Өч ай буена каршы торып та, беркемнән ярдәм-фәлән килмәгәч, И. Д. Бухгольц, үзенекеләрне алып, кайтып китәргә мәҗбүр була.

Икенче экспедициянең җитәкчесе итеп А. Б. Черкасский билгеләнә. Әмма Урта Азиядәге биләмәләргә Каспий диңгезе ягыннан үтеп керергә тиешле экспедиция һәлакәткә дучар ителә. Төрле җирдә булсагыз, ризык белән тәэмин итү җиңелрәк булыр иде, дигән сылтау белән Хива ханы аларны бишкә бүлеп, төрле җиргә урнаштыра. Хива халкы шуннан файдаланып кала: биш отрядның бишесенә дә һөҗүм итә, солдатларын кырып сала; Черкасскийның үзен үтереп, баш тиресенә печән тутырып, сөенче рәвешендә Бохара әмиренә җибәрәләр...

Рәсәй белән Хива арасындагы мөнәсәбәтләр яман төс ала. Хиваның Рәсәйдәге илчелеге кулга алына, фәкать берсенең кулына хат тоттырып, иленә кайтарып җибәрәләр. Ике арада сәүдә эшләре туктатыла. Бекович-Черкасский корып куйган кальгаларны урыслар ташлап киткәч, төрекмәннәр җимереп аталар.

Урта Азия ханлыклары белән сәүдә эшләрен куертып җибәрүдән Рәсәй күп табыш алыр, дип өметләнгән Петр I, бу хәлләргә бик нык кайгырса да, ниятеннән һич тә баш тартмый. Бохара әмиренең А. Б. Черкасский экспедициясен һәлак итүчеләрне хупламавыннан файдаланып, Флорио Беневени дигән кешене илче итеп җибәрә.

Сәүдә юлы казакъ далалары буйлап сузылган була. Шунда кәрваннарны талау, урыс сәүдәгәрләрен әсир итү гадәткә кергән бер хәл булып, зур каза китерә. Сәүдә кәрваннары имин генә йөрсен өчен, иң әүвәл Кама арьягында яшәүче башкорт-татарларны буйсындырып, чик буен ныгыту зарур була. Әнә шул максатны күздә тотып, Петр I заманында 900 чакрымга сузылган һәм 5 кальганы, 15 редутны, 8 форпостны эченә алган Иртеш ныгытмалары корыла.

Моның белән генә чикләнмичә, сәүдә кәрваннары килеп-китеп йөри алырлык бер үзәк булдыруны күздә тотып, 1718 елда Петр I Җаек буенда кальга салу идеясен күтәреп чыга. Әмма үзе моны гамәлгә ашыра алмыйча, дөнья куя. Варисларына Урта Азиягә үтеп керү юлларын өйрәтеп калдыра.

Көньяк Урал далаларын, Оренбург каласы калкып чыгачак җирләрне үзләштерүдә Петр I идеяләрен яклаучы И. К. Кириллов, В. Н. Татищев, И. Н. Неплюевларның роле зур. Әнә шул рәвешле Оренбур каласы Урта Азия белән сәүдә

---

[1] Урысчадан, бераз кыскартып, Кыям Миңлебаев тәрҗемә итте.

итүдә урысларның форпосты булып китә һәм ике арадагы багланышларны ныгытуда төп урынны алып тора. 1742 елда губернатор булып алгач та, И. И. Неплюев иң әүвәл (1743 ел) каланы яңа урынга, хәзерге урынына күчерттерә, сәүдә эшләрен, һөнәрчелекне шәһәрдә җәелдерү белән генә чикләнеп калмыйча, Урта Азия ханлыкларына кәрван-кәрван товар җибәрә.

Сәүдә эшен белүчеләрне үзендә туплау максатын күздә тотып, Уфа, Самар, Казан һәм бүтән шәһәрләргә чакыру кәгазьләре таратып, Оренбур каласына килеп төпләнергә өнди, йорт һәм каралты-кура торгызу өчен бушлай җир бирергә, бүрәнәсен-кирпечен табыштырырга вәгъдә итә, ун елга ссуда биреп торырга була. Сәүдәгәрләрдән алына торган салым-налогны да киметә.

Аның өндәмәсенә элек-электән казакъ халкы белән аралашучы, сәүдә итүче, Оренбурда сәүдә эшләрен беренчеләрдән булып башлап җибәрүче Казан татарлары ризалык белдерә. Тик менә егетләрен солдатка алмауларын, мәчет салып, ислам динен тотарга, шәригать кушканча яшәргә рөхсәт бирүләрен таләп итәләр.

Оренбурда бай сәүдәгәрләрнең бергә тупланууын хуплап, Рәсәй сенаты 1744 елның 8 март указы белән Казан татарларыннан хәллерәк 200 гаиләгә яңа урынга күченергә һәм «коммерция эшләрен җәелдереп җибәрергә» рөхсәт итә.

Татар сәүдәгәрләренә төпләнү өчен Оренбурдан 20 чакрымда, Сакмар суының уң ярында урын бирәләр. Әнә шул рәвешле Сәгыйть бистәсе барлыкка килә. (Аны тагын Каргалы бистәсе дип тә йөртәләр.) Бистә бу эшне башлап йөрүче Сәгыйть Аитовның исеме белән атала: Казаннан ул 200 гаиләне Оренбурга алып килә дә Берда бистәсе белән Югары Каргалы инеше арасында, Сакмар суы буеннан үзләренә урын сорап ала. Оренбурның губерна канцеляриясе 1744 елның 19 сентябрендә аның таләбен уңай хәл итә.

1745 елның 8 август карары белән Сәгыйть Аитовка таныклык кәгазе бирелә. Ул таныклык шартларында төпләнеп утыру өчен уңайлыклар тудыру күздә тотыла. Карарда тагын Хива, Бохара, Ташкент һ. б. Азия илләреннән төрле һөнәр ияләренең бистәдә төпләнеп яшәве хуплана, андый телеге булган кешеләргә һичбер тоткарлык кылмыйча, ярдәм күрсәтү таләп ителә.

Урта Азия белән генә түгел, Һиндстан белән дә сәүдә эшләрен җәелдереп җибәрүне күздә тотып, И. И. Неплюев янә дә Рәсәйнең унар-егермешәр мең белән эш итүче сәүдәгәрләреннән сәүдә компаниясе оештырып җибәрергә, аның директоры итеп Оренбур татарын билгеләргә кирәклеген әйтеп хөкүмәткә мөрәҗәгать итә. Һәр кәрванда компания әгъзасы яки аның татар приказчигы йөрергә тиеш, дигән фикер әйтә. Әмма аның бу проектын хуплаучы табылмый. Шулай да губернатор сәүдә эшләрен еракларга җәелдереп җибәрү ниятеннән кайтмый һәм әлеге эшендә иң әүвәл сәүдә хикмәтләрен белүче татарларга таяна.

Уңай шартлар тудыргач, Сәгыйть бистәсе тиз арада үсеп китә: 1760 елда 300 йорт булып, 1158 ир-ат саналса, 1767 елда ир-ат саны 2174 кә җитә, ә инде 1769 елда бистәдә 1000 йорт санала, ире-хатыны — барлыгы 9468 кеше була.

Казан татарлары Оренбурда гына сәүдә итү белән канәгатьләнмиләр, бәлки әле Урта Азия якларына да чыккалыйлар. Шул рәвешле Сәгыйть бистәсе тиз арада ошбу төбәкнең сәүдә үзәгенә әверелә, сәүдәгәрлектән зур табыш алып, бик нык баеп китүчеләр дә була. Андый байлар малны эшкә җигү ягын карыйлар — кечерәк кенә поташ заводлары салып җибәрәләр; хәер, ул заводлар бик тә примитив була.

Сәүдәгәрләрдән бигрәк губернаторга файда: алардан алган табыш елына 50—60 мең сумга җитә һәм И. И. Неплюевның өлкә белән идарә итү өчен тоткан бөтен чыгымнарын каплый. Ә бит хөкүмәт сату-алудагы малның нибарысы 2% тан 5% ка чаклысын гына тотып кала. Анда да әле чит мәмләкәтләрдән кергән алтын-көмештән бер тиен дә тотылмый. 1748—1755 еллар эчендә генә дә алтын (коелма һәм фарсы, һинд, бохар акчалары хәлендә) — 50 пот, көмеш исә (коелма, зиннәтле әйбер яки акча хәлендә) — 460 пот килеп керә.

Ә менә ефәк, мамык, ефәк катнашкан тукымалардан, парча-мазар, пәрдәчаршау, каракүл, кәшимир яки иран паласлары, һинд кисеясе ише нәрсәләрдән, өрек, пестә, киш-миш кебек җимешләрдән салым тотыла.

Сәгыйть бистәсе бик нык үсеп киткәч, 1784 елда ратуша булдырыла, шәһәр белән шул идарә итә башлый. 1787 елда бистәне Оренбур казаклары гаскәренә кертәләр һәм Каргалы станцасы дип йөртә башлыйлар. Әмма андагы татар егетләренә казаклар гаскәрендә хезмәт итү читенгә килә, шуңа тиздән бистәне башкорт гаскәренә кушалар. Анысы бетерелгәннән соң исә, гәрчә бистәнең үзендә башкортлар бармак белән генә санарлык булса да, Сәгыйть волосте башкорт авылы дигән исем тагыла.

Оренбурның үзендә генә түгел, Урта Азия мәмләкәтләрендә дә татар сәүдәгәрләренең дәрәҗәсе зур була. Бөтен мөэмин-мөселман халкы арасында алар үз кешеләр булып санала, хөрмәт вә ышаныч казана. Әйтик, Бохара ханлыгында аларга карата хөкүмәт үзе дә, барча халык та дустанә мөнәсәбәттә була; урыс купецларына салына торган салымның яртысы гына салына (тегеләр 5% түләгәндә, мөселман сәүдәгәрләр 2,5% кына түли).

Бохараның үз сәүдәгәрләре товарны әҗәткә алып, аны сатып кайткач, табышны бүлешергә мәҗбүр булалар. Ә менә татар сәүдәгәрләре товарны Бохарада шул ук бәягә акча түләп алгач, Оренбурда аны бохар сәүдәгәрләре саткан бәягә сатып та, барлык табышны үз кесәләренә салалар, беркем белән дә бүлешмиләр. Рәсәй товарларын Бохарага алып барып сатудан — янә табыш.

1785 елда Оренбурдан татар сәүдәгәрләре фәкать Бохараның үзенә генә дә 168,3 мең сумлык товар алып китәләр. Малның төрлесен: хәтфә-парча, ситсы-киндер, ефәк яулык, алтын-көмеш әйберләре, корыч-чуен, бакыр, кәгазьләр, энәләрише нәрсәләрне алалар. Гомумән, Урта Азия мәмләкәтләренә: тире-яры, постау, атлас-фәлән, көзге-мазар, беләзек-йөзек, шикәр, балавыз, бакыр, кадак һ. б. — хәтсез күп әйбер илтеп саталар. Сәүдә эшенең зур маһирлары да мәгълүм: Муса Макъсудов, әйтик, 110,6 мең сум белән, Гобәй Мусин 15,5 мең белән, Сөләйман Нәзеров 13,4 мең белән, Мөхәммәт Йосыпов 10,9 мең сум белән эш йөртә.

Наполеон белән сугыш дәверендә әлеге сәүдәнең әһәмияте дә, килере-төшеме дә бермә-бер арта. Өстәвенә әле, кием-фәлән белән, акча-мазар белән тәэмин итеп, Уфага рекрутларын җибәрәләр. Ул чагында инде Сәгыйть бистәсенә Бохарадан, Урта Азиянең бүтән шәһәрләреннән 75 сәүдәгәр килеп тупланган була. Урыс армиясен кием-салым, азык-төлек һәм акча белән тәэмин итеп торуда алар да катнаша.

Урта Азия сәүдәгәрләренә 1755 елның 1 декабрендә чыккан карар нигезендә Рәсәй шәһәрләрендә сату-алу эшләре тыелу сәбәпле, бистәгә килеп тупланучы мөселман сәүдәгәрләре арадашчылар сыйфатында татарларны яларга мәҗбүр булалар. Ә инде татар сәүдәгәрләре Мәкәрҗә ярминкәсенә дә, бүтән җирләргә дә иркенләп йөриләр, салымны да башкалардан азрак түлиләр.

Сәгыйть бистәсенә әле тагын Урта Азиядә сату-алу эшендә йөреп бөлгенлеккә төшкән яисә таланган-ниткән кешеләр дә киләләр. Аларның кайберләре генә приказчик-мазар булып урнашу бәхетенә ирешә. Калганнары исә хәллерәк кешеләргә бүтән төрле эшкә ялланырга мәҗбүр була. Шулардан тора-бара әйбәт кенә итекчеләр, пешекчеләр, көмешчеләр һ. б. һөнәр ияләре чыга.

Екатерина ИИ (әби патша) Рәсәй белән идарә итү эшендә муллаларга да таянырга, мөселман халкына шулар аркылы йогынты ясарга ниятли. Сәгыйть бистәсенә дә беркадәр җиңеллек килә. Мөселман диненә ирек бирелгәч, Сәмәрканд белән Бохарадан муллалар агыла башлый. Мәхәллә мулласы булудан тыш, алар әле төрле мәдрәсәләрдә, башка уку йортларында да белем бирәләр. Чөнки әби патша указы белән, «татар, фарсы, бохар якларында яткан» көньяк губерналардан уку йортларында урысларга да гарәп телен өйрәтү максаты куела. Ишаннар һәм муллалар шул рәвешле мөселман динен-мәдәниятен үзләштерүгә төп сәбәпчеләр булып китәләр. Инде тора-бара монда белем алган шәкертләр «моңарчы исемнәре генә мөселман булган күчмә халык» — казакъ халкына дин гыйлемен өйрәтергә җибәрелә башлый. Әнә шул рәвешле, үзе зур, үзе күркәм яңа мәчете булган Сәгыйть бистәсе бөтен Оренбур губернасының дини мәркәзенә әверелә.

**Гөлсем МИХАЛЕВА,**
тарих фәннәре кандидаты.

**Әхәт Сафиуллин**

# Йөрәккә — ачкыч

ШАЯН ХИКӘЯ

Халык бик начарланды бит әле, җәмәгать: тел кашырга ярата. Берәр нәрсә теленә кердеме, өзелгәнче шуны чәйни. Мәнә минем дә «Хатын аеручы Гафиятулла» дигән данымны тараттылар.

Соң, ул хатын аеруларның сәбәпләре бар бит югыйсә. Лыгырдап йөрүен йөриләр, ә менә аңларга теләмиләр...

Беренче хатыннан башлыйк. Өйләнешеп, пар сандугачлардай гына яшәп ятканда, миңа җир участогы биреп куйдылар. Менә шунда өй әмәлләргә кирәк иде. Моның бик тә зур эш икәнен башына төшкәннәр генә белә торгандыр. Менә кайда икән ул мәшәкать дигәннәре! Алай да, анда чаба, монда йөгерә торгач, бүрәнәләр юнәттем. Өйне әнә шул бүрәнәләрдән бастырып куярга иде исәп.

Берсе — үземә, икенчесе — хатынга булыр, дип ике балта сатып алдым. Мондый авыр заманда бу эшкә кеше яллап булмас, мин әйтәм, ыштансыз калырбыз...

Килдек бакчага. Менә шулай, шулай, җанкисәгем, дим хатынга, менә сиңа балта, уч төпләренә төкерешеп, шушы йортны салып куйыйк әле. Авырлыгы да, рәхәте дә үзебезгә булыр.

Менә шулай тәмле тел белән, йомшак кына итеп әйттем. Чөнки хатын-кыз белән ничек сөйләшергә кирәк икәнен беләм мин! Хатын-кыз йөрәгенә ачкыч таба белергә генә кирәк!

Суздым мин карлыгачыма балтаны. Күрсәгез иде, нинди балта бит әле! Күршем чәч алырдай итеп кайрап бирде!

Хатын балтаны кулына алды да әйләндерә-әйләндерә карарга кереште. Әйтерсең, гомерендә күрмәгән нәрсәсе! Шулай гаҗәпләнеп карап-карап торды да атып ук бәрде балтаны.

— Мин кулыма балта тотып, бура бурар өчен чыктыммыни кияүгә?! Ирләр эше ич бу! — дип, елап та җибәрде җанкисәгем.

И-и, болай эш бүлә башлагач, булмады инде бу, дим эчтән генә. Булырга охшамаган. Хәзер бездә, монысы ир-ат эше, монысы хатын-кыз эше, дип аерып торасы юк. Барыбыз да тигез хокуклы ич!..

Күпме генә аңлатып карасам да, карлыгачымны кулына балта алырга күндерә алмадым. Йә, әйтегез, мондый хатын белән ничек тормыш итмәк кирәк?! Менә шуннан соң, үлеп яратсам да, аерылышырга туры килде.

Хатынның икенчесеннән дә уңып булмады. Шулай беркөнне ванна бүлмәсеннән атылып килеп чыкты бу.

— Ни булды, — мин әйтәм, — нигә шулай очынасың?

— Безнең ванна торбасы ага икән ич, Гафиятулла! Тизрәк берәр чарасын күрергә кирәк, астагы фатирны су басуы мөмкин, — ди бу миңа.

Монысын аңлыйм, дөрес борчыла, кәнишне. Тик хәзер кимчелекне күрсәтүчеләр, житешсезлекләргә бармак белән төртүчеләр бик күбәеп китте бит әле, җиң сызганып, эшләргә атлыгып торучы гына юк. Безгә менә шунысы кирәк аның хәзерге заманда! Андый-мондый нәрсә күрдеңме, тот та эшләп куй син аны, алай бик акыллы икәнсең. Менә булырсың кеше! Карлыгачыма әнә шундыйрак фикер әйттем.

— Юкка чәчрәп йөргәнче, ал да эшләп-ясап куй әле шуны, жанкисәгем,— дип тә өстәдем.

Җайлап, йомшак кына итеп әйттем. Чөнки хатын-кыз белән ничек сөйләшергә кирәклеген яхшы беләм. Алар, күгәрчен гөрләгәндәй, йомшак тавыш белән әйткәнне яраталар.

— Балконда сумалалы бау булырга тиеш. Тыгызлагыч тимере дә, чүкеч тә шунда,— дип күрсәтмә дә бирдем хатынга. Эзләп, вакыт уздырмасын, мин әйтәм.

Шулай дип әйтүем булды, нишләптер тораташтай катты да калды минем карлыгачым. Керфекләрен челт-челт иттереп, тик миңа карап тора.

— Бу синең эш, ал да тыгызла! Минем эш — юу, җыю, пешерү,— диде ул аннары.

Монысы белән дә аерылырга туры киләчәген менә шул минутта аңладым. И-и, дим эчтән генә, болай үзара эш бүләргә калгач, булмый инде! Икең дә бер уй белән яшәмәгәч, тормышмыни ул?! Өзелеп яратсам да, нишләмәк кирәк... Хак тәгалә бергә-бергә яшәргә язмаган, күрәсең...

Өченче хатынны... Тукта, анысы белән араны ни өчен өздем соң әле?.. Ә-ә, хәтерләдем! Эш болай булды.

Беркөнне шулай безнең авыл шоферы килеп керде. Әни аның артыннан ике капчык бәрәңге биреп җибәргән икән, рәхмәт төшкере! Хәзерге көндә моның нинди байлык икәнен әйтеп торасы да юктыр.

Телевизордан «Ну, погоди!» дигән мультфильм карап утырган чагым иде. Күргәнегез бардыр, би-ик кызык нәрсә бит! Шуңа күрә ахырына тикле карап бетерәсе килде. Ике генә капчыкны хатын үзе дә алып менәр әле, дим эчтән генә.

— Алып мен инде шуларны, бәгырем! — дидем мин карлыгачыма.

Кычкырмадым, матур гына, йомшак кына итеп әйттем. Чөнки хатыннар белән сөйләшә беләм мин...

Йөз чакрымнан артык җир үтеп ишегалдыбызга килеп җиткән шул «кыр тәкәләрен» шатланып кына алып менәсе инде югыйсә! Берәр юньле хатын булса, кушмыйча да чыгып чабар иде. Ә минеке — юк! Идән юып яткан җиреннән чүпрәген тотып бәрде дә, ике кулын биленә куеп, миңа текәлде. Күзләре ялт-йолт килә, минсиңайтим. Шулай афишага баккан кәҗәдәй карап-карап торды да:

— Уйлап кара әле, ахмак, бу синең эш түгел микән? Бишенче катка капчык ташырга, әллә мине үгез дип беләсеңме?! — диде.

Менә бит нинди хатыннар да очрый дөньяда! Кеше алдында сиңа шулай дип торсыннар әле! Җир ярылса, җир тишегенә кереп китәрсең. Якташым шуны авылга кайтып сөйләсә?! Адәм ыстырамы бит.

И-и, дип уйладым эчтән генә, монысыннан да уңмадым. Аерылышам! Дөньяда җүнле хатын-кыз беткәнме әллә?! Үз тиңемне тапмый калмам әле!

Озак эзләргә туры килмәде, таптым бит, әй! Дөрес, монысы үземнән бераз олырак яшьтә. Аның каравы, ярата да, сөя дә белә, йомшак телен дә җәлләми. Яратуы көчледер, күрәсең. Гел үз янында гына тотар иде инде мине. Хәтта кичләрен эштән каршы алырга килә, бәгырькәем. Уңга да, сулга да кагылмыйча туп-туры өйгә кайтабыз. «Сагындым»,— ди. Дөрес, тайпыласы килгән чаклар бар, әлбәттә. Кайчак сыра эчәргә дә кагыласы килә. Ләкин — юк! «Сыра бавырны черетә» — ди хатыным. Анысы дөрестер дә. Әллә ниткән цирроз дигән авыру турында үземнең дә ишеткәнем бар.

Аннары хатынымның монысы чисталыкны бик ярата, кәнишне. Шуңа күрә арыдым, дип тормыйм, соң дип тормыйм, эштән кайтып керүгә, һәр кич саен идәнебезне юарга туры килә. «Йокларга үзебезгә рәхәт булыр»,— ди сандугачым. Дөрес әйтә, рәхәтләнеп шундук сизәм: кайбер көннәрдә идәнне юып бетерүгә, сабый бала шикелле йоклап китәм. Тор, арысланым, ашарга берәр нәрсә әмәллә инде, дип үбеп тә ала әле шунда. Торам, янында шулай диеп хәләл җефетең биеп торганда, ничек йоклап ятасың ди?

Әй, үлә инде мин пешергәнне яратып. Дөрес, әле аның белән кавышканчы үзем дә берни пешерә белми идем. Рәхмәт төшкен, иренмәде, өйрәтте.

Шуның аркасында хәзер бик күп нәрсә эшли беләм. Керен дә юам, үтүклим дә. Хәтта кайчакта вак-төякне ямаштыргаларга да туры килә. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дигәннәр бит.

Кыскасы, пар күгәрченнәрдәй чөкердәшеп торабыз шушы хатыным белән. Кешеләр көнләшерлек, минсиңайтим. Әйтәм бит, хатын-кыз йөрәгенә ачкыч таба беләм, дип...

**Анжей Козиол**

# КОМПЬЮТЕР

Безнең оешмага компьютер алдылар. Зур гына сандыкка охшаган нәрсәкәй икән ул. Үзе, фокусчы сыман, авызыннан тишкәләнгән кәгазь тасмалар чыгара. Үзе, күрдегезме, абзагыз ничек житез эшли, дигәндәй, яшькелт лампочка күзен кыскалап куя. Чыннан да, өлгер икән шул. Үзенең шундый «уңган» ярдәмчесе табылганга баш бухгалтерның сөенече йөзенә бәреп чыккан. Күзләре компьютер лампочкасыннан да болайрак елтырый.

— Иллә дә яхшы иттек әле моны алып,— диде ул гомер буе чут төймәләрен тарта-тарта сөялләнгән бармакларын уыштырып.— Белмәгәне юк, жаныемның! Теләсә нинди мәсьәләне чишә. Аласыны да, бирәсене дә секунд эчендә санап ташлый. Хәтта ки, алимент-мазарны да тотып калырга онытмый, хи-хи!

Бу хикмәтле машинаны көйләүче инженер да, кулларын чүпрәк кисәгенә сөрткәләп, сүзгә кушылды:

— Мәсьәлә чишү генәме соң?

— Теләсә нинди сорауга җавап бирә ала бу могҗиза...

— Кит әле, булмас ла!—диде бүлек башлыгы Жабиц, ышанмаган булып.

— Соң, ышанмасагыз, сораулар биреп карагыз,— диде инженер бер дә исе китмәгән кыяфәт белән.

Шунда безнең хезмәткәрләрдән иң тыйнак-тартынучан дип саналган Бабская барыбызны да уздырып:

— Биш бишең ничә була?—дип сорады.

Ә компьютер уйлап та тормастан: «Егерме биш» дигән җавапны төкереп кенә чыгарды.

— Туктале, минем сорауга җавап биреп карасын,—диде бүлек башлыгы Жабиц.—Йәле, 456 ны 381 гә тапкырлагач, нинди сан килеп чыга, ә?

Инженер компьютер түбәсендәге ярыкка сораулы тасманы төшереп жибәрде. Җавап янә доп-дөрес булып чыкты: 173736.

Жабицның да бирешәсе килмәде. Кулындагы шпаргалкасына карап алганнан соң, мәсьәләнең тагын да катлаулырагын бирде:

— Әгәренки 1247 не 6532 гә тапкырласаң?

Компьютер бу мәсьәләне дә, тиен чикләвек ваткан кебек, бик ансат чиште.

Бүлеккә алынган яңа урындыкларның бәһасе күпме, жыештыручы апаның хезмәт хакы ничә таңкә, узган айда пар казаны астына күпме күмер ягылган—барысын да бәйнә-бәйнә төпчендек. Ул исә һич тәртелми-нитми төгәл җаваплар бирә барды. Бу тимер шайтан командировка чыгымнарының тиешеннән артып киткәнлеген дә, бүлектәге хезмәткәрләрнең кирәгеннән күбрәк икәнен дә белә булып чыкты. Җитмәсә, бөтен кимчелегебезне күзгә бәреп әйтә. Безгә шактый ук «эссе» булып та китте.

— Гуманлы түгел бу, безне эшсез калдырмакчы!—диде арадан берәү.

— Тагын бер сорау бирергә мөмкинме?—Бу янә теге Бабская тавышы иде.—Мондый тырышлыгың өчен нәрсә бирәләр соң сиңа?—дип, ул компьютерның күзенә чекерәеп карады.

— Мондый сораулар бирергә ярамый,—дип каршы төште инженер.—Конкрит түгел бу. План үтәлеше белән кызыксынсагыз, тагын бер хәл иде...

Пан Жабиц бу юлы Бабскаяны яклауны кирәк тапты:

— План үтәлешен Мәнди анасы да әйтә ала. Сораганга җавап бирсен!

Компьютер дәшмәде. Бу хәл безне кыюландырып жибәрде.

— Ә нинди яңалыклар ишеттең?—дип сорады кемдер.

Акыллы машинабыз авызына су капты. Шуннан файдаланып, аны яңадан-яңа сораулар белән күмдек:

— Белмәсәң, белмим, диярга кирәк! Нәрсә чыгымчылаган буласың?

— Бәлки, син без ишетмәгән мәзәкләрне беләсеңдер, ә? Сөйләп жибәр!

— Ә сәркатип кызыбызны кичә өенә кем озатып куйды? Ә-ә, белмисеңме! Шул-шул менә...

Компьютер чыгымчылавын дәвам итте. Ул безнең бүлектәге хәл-әхвәлләр белән таныш түгел шул әле. Белмәссең, киләчәктә, бәлки, бу сорауларыбызга да чатнатып җавап бирер бу тимер шайтан. Әмма ләкин бу юлы теше үтмәде.

Без: «Кеше акылын алыштыра алырдай машина буламыни ул!»—диешеп, жиңүчеләр буларак, зур канәгатьләнү тойгысы белән таралыштык.

Полякчадан **Шамил МАННАПОВ** тәрҗемәсе.

Бу шигырь үрнәге «Совет әдәбияты» журналының 1939 елгы 3—4 саннарыннан алынды.

**Редакция.**

## Ƣ. TUQAJ

# KITMIBEZ!*

Qara jəzlər bezne bulmas eşkə təklif[1] ittelər,
Sezgə monda juq irek, soltan çirenə kit! dilər.
Kitmibez bez, bezgə anda mondaƣьdan eş qibn,
Mondaƣь un urnьna, ul çirdə 15 şpion.
Mondaƣь təslykder anda həm qazaqlar ƣəskəre,
Qamcьlar şul iske qamcь, başqalьq tik fəslәre!
Anda bit bardьr xəzinəne talavcьlar, şəker
Ac muziktan soꞑ kisəkne tartqalavcь, ber şəker!
Bez çylərme yzebezne utqa iltep nik terik?
Bu qьzu çirdən cьƣьp taƣьn səqərgə[2] nik kerik?
Bez kycərbez, in elek kycsen bezem amsarьmьz,[3]
Həm də qajtsьn monda ytkərgən bezem aqsarьmьz[4]
Monda tudьq, monda ystek, mondadьr bezneꞑ əçəl[5]
Bəjləmeş bu çirgə bezne təꞑremez (ƣizze və çəl[6])
Iꞑ bəjek maqsat bezem xər məmləkət — xər Rusiə!
Tiz genə quzƣalmьjbьz bez, əj geruhe rusiə[7]
Ap-acьq bu ber çəvaptьr, syzdə tygel basmada
Если лучше вам, туда сами пожалуйте, господа!

1907.

* SSSR Fənnər Akademiəse ƣilmi sotrudnigь iptəş Rəjemef (Məskəvdən) çibərgən bu şiƣer derestən də 1907 nce jьlda basьlƣan „Ƣabdulla Tuqaj şiƣerləre" (4 nce divan jaki dəftər) kitabьnnan başqa hicber məçbyƣəgə kerməgən.

1905 nce jьlƣь revolytsiədən qurqьp qalƣan qajber reaksion uꞑ tatar burƶua matbuƣatь feodallьq corьnda jəşəvce soltan Ƣəptelxəmit Terkiəsenə kycyne jaꞑadan ideallaştьra başlьj. Tuqajnьꞑ bu acь satirasь şuşь kycygə qarşь jynəltelgən.

---

1 Ɵndədelər-kocladelər.
2 Tamuƣ.
3 Şəhərlərebez.
4 Ytkərgən tarix.
5 Ylem.
6 Ƣizzətle həm bəjek.
7 Qara jəzlər, qara geruhlar.

## ИҖАТ ВӘКИЛЛӘРЕ — ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында республиканың иҗат берлекләре җитәкчеләре белән киңәшмә уздырылды. Анда Татарстан Республикасы Президентының «Мәдәният һәм сәнгать работникларын социаль-экономик яклау өлкәсендә кичектергесез чаралар турында»гы Указын үтәүнең барышы каралды. Сөйләшүләр вакытында иҗат кешеләренә салым ташламалары ясауга, аларны адресль яклауга, иҗат берлекләре эшчәнлегенә булышуга кагылышлы мәсьәләләр игътибар үзәгендә булды.

Киңәшмәне Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин алып барды.

## ПРЕЗИДЕНТЛАР ХӘБӘРЛӘШӘ

АКШның Нью-Йорк шәһәрендәге Төрки-татар ассоциациясеннән хәбәр итүләренә караганда, ошбу елның февраль ахырында Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев АКШ Президенты Билл Клинтонга хат белән мөрәҗәгать иткән.

Җөмһүриятебез Илбашы Б. Клинтонны югары дәүләт постына сайлануы белән котлап, аңа һәм Америка халкына иң якты теләкләрен юллаган. М. Шәймиев шулай ук АКШ Конгрессында «Азатлык» радиостанциясенең татар-башкорт редакциясе эшен туктату мәсьәләсе каралачагы турында хәбәр алынуын һәм бу уңайдан тирән борчылуын белдергән.

«...Татар-башкорт редакциясе демократия идеяләрен үткәрә, аның мөхәррирләрен Татарстанда яхшы беләләр. «Азатлык» безнең халык арасында популяр, Россия һәм Үзәк Азиядәге тотрыксызлык шартларында татарлар үзләренең мөстәкыйль тавышларына ия булган һәм сәяси хәлгә йогынты ясый алган «Азатлык» радиостанциясенең татар-башкорт редакциясен саклап калу һәм, хәтта, нығыту бик урынлы булыр иде»,— дип хәбәр итә М. Шәймиев әлеге мөрәҗәгатендә.

АКШтагы татар общинасы вәкилләреннән билгеле булганча, Президент Б. Клинтон космик элемтә буенча, җавап йөзеннән, Казан Кремленә шалтыраткан һәм Президент М. Шәймиевкә үзенә карата әйтелгән җылы сүзләр өчен рәхмәт белдергән. Татар-башкорт редакциясе мәсьәләсе белән кызыксыначагына ышандырган.

## ОЛУГ ӘДИП ХӨРМӘТЕНӘ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында күренекле татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның туууына 115 ел тулуга багышланган тантана булды. Аны Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары И. Хәйруллин алып барды. Әдипнең иҗаты һәм тормыш юлы турында Татарстан Фәннәр академиясе президенты М. Хәсәнов доклад белән чыкты. Аннары Татарстан Язучылар берлеге һәм «Туган тел» җәмгыятенең Г. Исхакый исемендәге премияләре бирелгән әдипләр Г. Бәширов, Ә. Еники, Р. Даутов, Ә. Рәшиткә олы бүләкнең таныкнамәләре һәм акчалата әҗерләре тапшырылды.

Тантаналы җыелышта Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, Премьер-министры М. Сабиров, Татарстан Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары З. Вәлиева катнашты.

Соңыннан Татар дәүләт академия театры Г. Исхакыйның «Зөләйха» драмасы нигезендә куелган спектаклен күрсәтте.

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНДА

Күптән түгел Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты бюросының киңәйтелгән утырышы булды. Анда чит илләрдә һәм башка төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез өчен кыска дулкыннарда татарча радиотапшырулар булдыруга әзерлек эшләре каралды.

Бу мәсьәләне тикшерүдә «Татарстан» телерадиокомпаниясе җитәкчеләре, галимнәр һәм элемтә хезмәткәрләре катнашты.

## «ТАТАР-ИНФОРМ» АГЕНТЛЫГЫ ОЕШТЫ

Татарстан җөмһүриятенең, Россия Федерациясенең, БДБ илләренең һәм чит ил дәүләтләренең массакүләм информация чараларында Татарстанның сәяси, икътисади, иҗтимагый, мәдәни тормышын чынбарлыктагыча яктырту максатыннан чыгып, Татарстан Президенты М. Шәймиевнең 1993 ел, 27 март Указы нигезендә, «Татар-Информ» агентлыгы төзелде.

Агентлыкның генераль директоры итеп Гомәр Хәмзә улы Богдалов билгеләнде.

## «ВАТАН»НЫҢ ЯҢА ПРЕЗИДЕНТЫ

3 мартта «Ватан» җәмгыятенең нәүбәттәге конференциясе уздырылды. Анда чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән бәйләнешләрне ныгыту буенча башкарылган эшләр хакында идарә хисабы тыңланды. Аннары яңа җитәкчелек сайланды.

«Ватан» җәмгыятенең яңа президенты итеп элек шуның вице-президенты булып

эшләгән журналист, каләмдәшебез Дамир Гыйсметдин тәгаенләнде.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» КӨННӘРЕ

15-20 апрельдә мәркәзебезнең Г. Тукай музеенда «Казан утлары» журналы көннәре үткәрелде.

Ул халкыбызның бөек улы Габдулла Тукайның вафат булуына 80 ел тулган көндә «Хәтер сәгатьләре» белән башланып китте. Иртәнге якта Татарстан Язучылар берлеге, «Казан утлары» журналы, Мәдәният министрлыгы, Тукай музее вәкилләре, шагыйрьләр, әдипләр, төрле һөнәр ияләре Тукайның изге каберенә чәчәк салдылар. Аннары зиратта һәм шулай ук Тукай музеенда ерак Ливиядән килгән мөселман Әхмәт Хөсәен Батыр, Татарстан җөмһүриятенең баш мөхтәсибе Габделхак хәзрәт Саматов, Ш. Мәрҗани мәчетенең өлкән имам-хатыйбы Габделхәбир хәзрәт Яруллин мәшһүр шагыйребез рухына Коръән багышладылар.

Музейда «Казан утлары» журналы көннәрен рәсми төстә ачу булды. Бирегә җыелган тамашачылар Татарстан Мәдәният министры урынбасары Мөҗип Низамиев һәм журналның баш мөхәррире Равил Фәйзуллинның чыгышларын зур кызыксыну белән тыңладылар.

«Казан утлары» — безнең тормышыбызда», «Ислам сәнгате. Каллиграфия. Шамаилләр. Татар мәчетләре» дигән күргәзмәләр (соңгысына галим вә рәссамнардан Нәҗип Исмәгыйль, Рөстәм Мөхәммәтҗан, Сергей Карпенконың хезмәтләре куелган иде), Михаил Козловскийның фоторәсемнәр галереясе белән танышканнан соң, Тукайга багышланган шигъри митинг башланып китте. Аны журналның бүлек мөхәррире шагыйрь Рәдиф Гаташ алып барды.

Тыңлаучылар алдында Тукай бүләге лауреатларыннан нәфис сүз остасы Айрат Арсланов белән шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов, шагыйрә Лена Шагыйрьҗан, «Ялкын» журналының баш мөхәррире Җәүдәт Дәрзаман, «Казан утлары» журналы хезмәткәрләреннән Рашат Низамиев, Шамил Маннапов, Тәүфикъ Әйди һ. б. чыгыш ясады. Әлеге очрашуда халкыбызның яраткан җырчысы Зөһрә Сәхәбиева һәм танылган музыкант, гармуннар ясау остасы Хәйдәр Искәндәревның катнашуы нур өстенә нур булды. Казанның Г. Ибраһимов исемендәге гимназиясе һәм 30 нчы мәктәбе укучылары концерт-күчтәнәч белән килгәннәр иде.

Очрашу залдагыларның кумәкләшеп Г. Тукайның «Туган тел» җырын башкаруы белән тәгалләнде.

Музейда «Казан утлары»ның һәр көне зур җанлылык, әдәби-музыкаль очрашуларга бай булып үтте.

## «ТАТНЕФТЬ» — КОМПОЗИТОРЛАР СПОНСОРЫ

Күптән түгел генә Әлмәттә, Сарманда, Мөслимдә һәм Азнакайда Татарстанда нефть чыгара башлауга 50 ел тулу уңаеннан җыр бәйгесе булып узды. Шул истәлекле көннәрдә нефть чыга торган төбәкләрдән җыелган һәвәскәр композиторлар тамашачыларны үзләре иҗат иткән яңа әсәрләр белән таныштырдылар. Алар арасында Әлмәттән Рәис Нәгыймов, Зиннур Сафиуллин, Роберт Андреев, Булат Юнысов, Алабугадан Валерий Әхмәтшин, Владимир Мировaев, Азнакайдан Сафуан Хәбиров, Чаллыдан Ринат Гобәйдуллин, Илдус Низамов, Мөнир Шәрәфетдинов һәм Казаннан Рөстәм Сәрвәров бар иде.

Җыр бәйгесен үткәрүдә төп спонсор «Татнефть» берләшмәсе (генераль директоры — Ринат Галиев) булды.

## «ШӘҺРИ КАЗАН»НЫҢ ПАР КАНАТЫ

Сөекле Татарстаныбызның бәйсез дәүләт булуы, үз телебезне, мәдәниятебезне, борынгыдан килгән гореф-гадәтләребезне халыкка кайтару һәм җиде миллионлы татарның бердәнбер рухи мәркәзе булган Казан тормышын, башкала хәбәрләрен татар дөньясына ирештерүне үзенең төп мәсләге итеп алган «Шәһри Казан» газетасы канатларын көннән-көн киңрәк җәя.

Ошбу елның 6 февраленнән башлап «Шәһри Казан» һәр шимбә саен «Миллият» исеме астында газета эчендә газета бирә башлады. Аның сәхифәләрендә сәясәт, татар дөньясы, тарих, әдәби мирас, гореф-гадәтләр, гыйбрәтле язмышлар киң яктыртыла.

Бер үк вакытта «Шәһри Казан»ның урыс телендә «Волжский курьер» дип исемләнгән кушымтасы айга 2 тапкыр 8 битле булып чыга.

## КИНЕМАТОГРАФИСТЛАР СЪЕЗДЫ

Татарстан кинематографистлар берлегенең чираттагы съезды булып узды. Анда берлекнең идарә рәисе итеп Р. Копосов сайланды. Танылган кинематографистлар Х. Фәхретдинов, Б. Галиев, Л. Кузина, Д. Хохлов, Ю. Гвоздь, В. Беспалов идарә составына кертелделәр.

## ЮБИЛЕЙ

«Чаян» журналының 70 еллыгына багышланган тантана Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында зур күтәренкелек белән үтте.

Татарстан Республикасы вице-президенты В. Лихачев, юбилярны котларга килгән күпсанлы кунаклар чаянчылар хезмәтенә югары бәя бирделәр.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Әдәбият өлкәсендәге уңышлары өчен язучы Марсель Баян улы Галиевка, «Чаян» журналының татар әдәбияты һәм тәрҗемә бүлеге мөдире Дәлфәт Госман улы Маликовка (Зөлфәткә) «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# «КҮГӘРЧЕН ГӨРЛИДЕР...»

Санкт-Петербург рәссамы Марат Таҗибаев үзенең «Күгәрчен» исемле әсәрен татар халык чигү үрнәкләренә охшатып, ефәк тукымага төсле буяулар белән эшләгән. Шартлы рәвештә «төсле декоратив графика» дип йөртелгән бу алым кыска гына бер сүз белән батик дип тә атала.

Рәссам ефәк тукымага эшләгән әлеге әсәрендә төсләр өстенә аппликация дә кулланган. Бу исә күгәрчен образының контур сызыкларын да, силуэтын да бергә берләштереп, көчәйтеп җибәргән.

Марат Таҗибаевның «Күгәрчен»е беренче мәртәбә 1991 елда С.-Петербургта булып үткән «Татарт» күргәзмәсенә куелган иде. Бу әсәр — дүрт паннодан торган композициянең бер өлеше генә. Композиция тулысы белән махсус шул күргәзмә өчен иҗат ителгән һәм, Этнография музееның Мәрмәр залында үзәк диварга куелып, зур уңыш казанган иде. Әлеге күргәзмә шул ук елның җәендә Казанга күчеп килгәч, аны Татарстан җәмәгатьчелеге дә ихлас кызыксынып кабул итте.

Татар халык сәнгатендә кош образы элек-электән әкияти дә, тотемистик шартлы бер сурәт тә булып килә. Күгәрчен исә һәрвакыт ак бәхетләр, йортта иминлек-муллык билгесе, төрле явыз кара көчләрдән, авырулардан-сырхаулардан саклаучы изге кош. Шуңа күрә дә татар халык җырларында күгәрчен иң еш телгә алына, иң күп җырлана. Күгәрчен сынын-сурәтен без авыл өйләренең челтәрләп-челтәрләп киселгән тәрәзә яңакларында, койма-капкаларда да күрәбез. Чигелгән сөлге-тастымалларда да ул, кошның алтын каурые рәвешендә укалы бәрхет калфакларда да ул. Хәтта татар зиратларындагы күп кенә кабер ташлары да шартлы рәвештә кош сыны белән очлана.

Марат Таҗибаев исә үзенең «Күгәрчен»енә заманча төсмерләр салган, ул үзе дә: «Традицион сәнгать мотивларын хәзерге сәнгатькә якынайтырга омтылдым»,— ди. Күгәрчен төрле төстәге тасмалар өстендә бирелгән. Алар, бер караганда, төрле илләрнең ту-байраклары кебек тә, икенче карасаң, гап-гади генә чигүле сөлгетастымалларыбызны да хәтерләтә. Әмма күгәрчен үзе алар фонында чикләрне белмәүче, канатлары белән һава ярып, бар дөньяларны кочучы илаһи кош итеп сурәтләнгән.

Марат Таҗибаев 1940 елда Казагыстанның Казалинск шәһәрендә туган. Ашхабадта (Төрекмәнстан) сәнгать училищесында, аннары Ленинградның Мухина исемендәге югары сәнгать-сәнагать училищесын (1969) тәмамлаган. Хәзер дә С.-Петербургта яшәп иҗат итә. Рәссамнар берлеге әгъзасы һәм Тукучыларның Халыкара җәмгыяте әгъзасы (АКШ). Аның төп жанры — гобеленнар иҗат итү. Гобелен — кулдан тукылган сюжетлы рәсемле келәм ул. Марат Таҗибаев бу өлкәдә үзен дөнья күләмендә таныткан рәссам. Аның әсәрләре — гобелен-келәмнәре бик күп илләрнең һәм шәхси, һәм җәмәгать биналарының диварларын бизи. Хәзерге вакытта Марат Таҗибаев әсәрләре Америка Кушма Штатлары һәм Канадада халыкара күчмә күргәзмәдә күрсәтелә. Ул күргәзмәгә дөньяның төрле почмакларыннан иң оста утыз дүрт рәссамның гобеленнары җыелган. Бу, әлбәттә, Марат Таҗибаев өчен бик зур казаныш һәм аңа халыкара танылу китерәчәк.

Татар рәссамы Марат Таҗибаев иҗаты әле безнең Татарстанда да, аерым алганда, Казан, Чаллы, Әлмәт кебек калаларыбызда киң танылыр, аның гобеленкеләмнәре безне дә сөендерер дип ышанабыз.

**Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,**
сәнгать белгече.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотосурәте.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы Кави Латыйп.

**М. КОЗЛОВСКИЙ** фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Милләтебезне үстерүгә, көчәйтүгә ярдәм итәрдәй басмалар бер-бер артлы дөнья күрә тора. Үткән елны Татарстан китап нәшриятында әнә шундый изге максатлы байтак кына җыентыклар басылып чыкты. Рәүфә Уразман тарафыннан язылган «Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре» дигән китапны укучылар аеруча кызыксынып кабул итәр дип уйлыйбыз. Авторның күп еллык эзләнүләренә һәм фәнни экспедиция табышларына таянып язылган бу китапта Идел-Урал төбәгендә яшәүче татарларның XIX—XX йөзгә караган традицион йола, гореф-гадәтләре һәм бәйрәмнәре эзлекле төстә тасвир ителә. Автор бәян иткән материалларның төп өлеше әдәбиятта беренче тапкыр чагыла һәм бу ягы белән ул киң катлау укучылар өчен, шулай ук күптөрле белгечләргә дә файдалы булачак.




Халык тарихы белән дин тарихы аерылгысыз рәвештә бер-берсенә бәйләнгән. Һәм бу уртаклык, бу бәйләнеш төрле риваятьләрдә дә ачык чагылыш таба. Фәрит Яхин хикәяләвендә басылып чыккан «Пәйгамбәрләр тарихы» исемле китапта сүз пәйгамбәрләрнең тормышы һәм эшчәнлеге хакында бара. Китап заманында күп тапкырлар дөнья күргән һәм мәдрәсәләрдә, гаиләләрдә кулдан-кулга йөртеп укылган.

Бүгенге көн укучыларын дин дөньясына якынайтуда бу китап күркәм юлдаш булачак.

Бу китапларны якындагы кибетләрдән таба алмасагыз, түбәндәге адрес буенча соратып алырга була:

**420066, Казан шәһәре, Чистай урамы, 3 нче йорт, «Төрки китап» кибете, «Книга-почтой» бүлеге.**

Бәясе 20 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)